


# казан утлары

6
июнь - 1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

6

ИЮНЬ
1970

## Бу санда:

Г. УСМАНОВ. Кем идек без һәм кем булдык . . 3

МИНЕМ РЕСПУБЛИКАМ

Х. ТУФАН. Татарстан итеп күтәрдең. Шигырь . . 14
З. НУРИ. Ирек мәйданы. Шигырь . . . . . . . . 15
Н. АРСЛАНОВ. Үз илем, үз республикам. Шигырь . 15
М. ШАБАЕВ. Июнь иле. Шигырь . . . . . . . . 16
Р. ГАТАУЛЛИН. Халкым уллары. Шигырь . . . . . 17
Р. ГӘРӘЙ. Казаным. Шигырь . . . . . . . . . 17
М. ӘГЪЛӘМОВ. Минем офыгым . . . . . . . . 18

ПОЭМА, ШИГЫРЬ, ХИКӘЯ, ПОВЕСТЬЛАР

Д. ЗӨБӘЕРОВА. Дустым авазы. Повесть . . . . . 19
Ә. РӘШИТОВ. Буыннар эстафетасы. Поэма . . . 52
Г. МӨХӘММӘТШИН. Йөрәктәге эзләр. Повесть . . 61
Р. РИЯН. Еракларданd килэм. Салчы сүзе. Иртәнге музыка. Шигырьләр . . . . . . . . . . 85
С. САБИРОВ. Хәтәр сәфәр. Хикәя . . . . . . . 87
И. НИЗАМОВ. Җилкәнә икерелгән кәймә. Хикәя . 93

ДУСЛАР ҖЫРЫ

М. ЛЬВОВ. Шагыйрьләр. Апрель аенда. Сыйфатлар. Дуслар юлга дәшә. Салават былбыллары. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 105
С. МӘҮЛЕНОВ. Нурлы яңгыр, җылы җил. Агыш. Тукай кабере янында. Кабан күле буенда. Казанның нәкъ уртасында. Татар кызы Галиябану. Галиябану, аман тор. Оялаган өй алдында. Син күрмәдең әле. Шигырьләр . . . . . . . . . 108

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. ХӨСӘНОВ. Исәнме, кеше!.. Очерк . . . . . . 111

БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ

Ф. МИНУШЕВ. Игенче хезмәте . . . . . . . . 118
И. МӨХЕТДИНОВ. Иң мөһим бурычларның берсе . 121
Ф. ХӘКИМОВА. Игелекле эшебез . . . . . . . 125

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. ӘХМӘДУЛЛИН. Драматургиябезнең кайбер тенденцияләре . . . . . . . . . . . . 128

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. КАШШАФ. Аның идеяләре белән рухланып . 138

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

М. САДРИ. Ут эчендә очрашулар . . . . . . 146
Ә. УСМАНОВ. Партизан учаклары . . . . . . 159

Кечкенә рецензияләр . . . . . . . . . . . 169

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. КЛИМЕНТОВСКИЙ. А. Н. Радищев . . . . . 172

КАЛЕНДАРЬ БИТЛӘРЕННӘН

Автономиябез тарихы . . . . . . . . . . . 177
Саннар, фактлар . . . . . . . . . . . . 184

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

ГОМӘР ГАЛИ . . . . . . . . . . . . . . . 185

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

В. МОНАСЫПОВ. Ньютон биномы. Шәмси кәләше. Юморескалар . . . . . . . . . . . . 186
Г. НАСЫЙРОВ. Бик нәни дүрт хикәя . . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 1/IV-1970 ел. Басарга кул куелды 25/V-1970 ел. ПФ 09053. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87746 экз. Заказ С-222. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.

**Гомәр Усманов,**
Татарстан АССР Министрлар
Советы председателе

# КЕМ ИДЕК БЕЗ ҺӘМ КЕМ БУЛДЫК

Россия Федерациясендә автономияле иң зур республикаларның берсе — Татарстан республикасын дүрт елга иле диләр. Бәрәкәтле җирен аның бөек Идел,назлы Кама, көмеш сулы Вятка һәм гүзәл Агыйдел ярып үтә. Иксез-чиксез кырларында шаулап иген үсә, җиде кат җир астыннан бетмәс-төкәнмәс хәзинәләр чыгарыла. Намуслы, хезмәт сөючән, хәр күңелле кешеләр яши бу җирдә.

Татарстан республикасы Совет властеның формалашкан вакытында, гражданнар сугышы хәрабәләре һәм ачлык хөкем сөргәндә, михнәтле елларда туа. Советлар илендә милли республикалар, шул исәптән Татарстанны да, төзүгә бәйләнгән барлык мәсьәләләр белән Владимир Ильич Ленин үзе шөгыльләнә.

1918 елның 17 гыйнварендә үк инде Владимир Ильич милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты каршында Үзәк Мөселман комиссариаты, җирле Советларда мөселманнар эше буенча бүлекләр төзү турындагы декретка кул куя.

Үзәк Мөселман комиссариаты һәм җирле Советлардагы бүлекләр халыкны милләтче контрреволюция белән көрәшкә тартуда, татар хезмәт ияләренә ленинчыл милли политиканы аңлатуда, Советлар тирәсенә эшче-крестьяннарны туплауда зур роль уйный.


Казан большевиклары һәм Мөселман комиссариаты, хезмәт халкының автономиягә омтылуын һәм татар буржуаз милләтчеләренең Идел — Урал штаты дигән нәрсә төзү проектына каршы көрәшнең зарури икәнен дөрес аңлап, советчыл милли дәүләтчелек формаларын эзләделәр.

1918 елның 22 мартында милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты, җирле Советлар һәм Мөселман комиссариаты карарына таянып, Татар-Башкорт Автономияле Совет республикасы төзү турындагы Положение проектын раслады.

Әмма бу проектны тикшергәндә татар һәм башкорт халыкларының, шул исәптән күпчелек коммунистларның да, аерым автономияле республикалар төзү теләге исәпкә алынмаганлыгы ачыкланды.

1919 елның 21 ноябрендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Икенче Бөтенроссия съездында В. И. Ленин татар, башкорт делегатлары группасын кабул итте һәм аларга татар, башкорт автономияле республикаларының шунда яшәүче хезмәт халкының фикерен исәпкә алып төзелергә тиешлеген әйтте.

1919 елның 13 декабрендә РКП(б) ҮК Политбюросы Татар-Башкорт АССР турында махсус карар чыгара. Бу карарда съездга килгән күпчелек делегатларның, шул исәптән башкорт делегатларының барысының да, Татар-Башкорт республикасы төзүгә каршы булуын искә алып, милләтләр эше буенча Халык Комиссариатының 1918 ел



*Татарстан АССР картасы янында.*

22 март декретының юкка чыгарылуы әйтелә. Анда: «Әгәр татар коммунистлары тарафыннан гариза керсә, Татар республикасы төзү мәсьәләсен аерым тикшерергә»,— диелә. Чыннан да, 1919 елның ахырына инде татар халкының үз автономияле республикасын төзү теләге тәмам ачыкланып җитә.

1920 елның 26 январенда Владимир Ильич Ленин председательлегендә РКП(б) ҮК Политбюросы җыела һәм татар халкының автономияле дәүләтен төзү мәсьәләсе нигездә уңай хәл кылына.

1920 елның 22 мартында В. И. Ленин Кремльдә РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросы җитәкчеләре С. Сәетгалиев, Б. Мансуров һ. б. ны кабул итә һәм алар белән татар халкының автономиясен төзүдәге практик мәсьәләләр турында сөйләшә. Бюроның кайбер вәкилләре, бигрәк тә соңыннан буржуаз милләтче буларак фаш ителгән Солтангалиев, Татар-Башкорт республикасын яклап чыгалар. В. И. Ленин бу позициянең хата һәм зарарлы булуын ышандырырлык итеп дәлилли.

Партиянең IX съезды вакытында Казан губернасы җитәкчеләреннән бер группа — И. И. Ходоровский, Г. С. Гордеев һәм А. И. Догадов — В. И. Ленин белән очрашалар. Татарлар арасында республика белән җитәкчелек итәрлек хәзерлекле кадрлар юк дип, алар татар республикасы төзүнең кирәксез һәм файдасыз булуын исбатларга тырышалар. Ленин бу дәлилләрнең дөрес түгеллеген фаш итә. Бу иптәшләр, В. И. Ленин белән очрашканнан соң, карашларын тамырыннан үзгәртәләр һәм Татарстан АССР төзүгә актив катнашалар.

1920 елның 4 маенда РСФСР ХКС ның В. И. Ленин җитәкчелегендә уздырылган утырышы Татарстан Автономияле Совет Республикасы төзү мәсьәләсенә караган материалларны әзерләү өчен комиссия оештыра. ТАССР төзү турындагы декрет проекты 1920 елның 25 маенда ХКС утырышында карала һәм: «Татар Автономияле Совет Республикасы турындагы Положениене принципта кабул итәргә»,— дигән карар чыгарыла. Яңадан бер кат җентекләп эшләнгәннән соң, закон проекты яхшы дип табыла һәм РСФСР ВЦИК һәм ХКС тарафыннан кабул ителә.

Татарстан республикасы дәүләт аппараты органнары, Халык Комиссариатларының саны, аларның бурычлары билгеләнә. Советларның Учредительный съездына кадәр власть Ревкомга тапшырыла.

1920 елның 8 июнендә Татарстан республикасы төзү мәсьәләсе РКП(б) ҮК Политбюросында тикшерелә. Утырышта В. И. Ленин председательлек итә. Бу киңәшмәдә Политбюро члennарыннан тыш М. Ф. Владимирский, С. Сәетгалиев, И. И. Ходоровский һ. б. катнаша.

ҮК Политбюросы Сәетгалиев (председатель), Казаков, Ходоровский, Хәкимов, Бочков һ. б. составында төзелгән ТАССР Ревкомын раслый. Шул ук утырышта республиканың югары партия органы итеп РКП(б) ның өлкә комитетын тану турында карар чыгарыла. Өлкә комитеты партия конференцияләрендә сайланырга тиеш була.

1920 елның 25 июнендә ТАССР Ревкомы Казан Губерна Башкарма Комитетыннан властьны рәсми рәвештә кабул итеп ала һәм Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы игълан ителә.

ТАССР төзелү Коммунистлар партиясе алып барган милли политиканың — барлык халыкларның тигез хокуклы булуларын һәм дуслык политикасының тантана итүен тагын бер тапкыр раслады.

* * *

Ленинчыл милли политиканың тормышка ашуы нәтиҗәсендә, Совет власте елларында Татарстан республикасы илебезнең иң эре промышленность һәм культура үзәкләренең берсенә әйләнде.

Революциягә кадәрге Казан губернасы патша Россиясенең иң артта калган районнарыннан берсе булды. Михнәт эчендә һәм хокуксыз яшәде хезмәт халкы. Күп төрле авырулардан йөдәде. Казан губернасында 6250 кешегә бары бер врач, ә 500 кешегә больницаларда бер койка туры килә иде. Ел саен күпме халык туса, шул кадәр үк үлә барды.

Губерна халкы наданлыктан җәфа чикте. Революциягә кадәр татарлар өчен казна хисабына эшли торган 35 кенә башлангыч мәктәп бар иде. Казан губернасында яшәүче һәр кешенә укытуга хөкүмәт елына уртача 12,5 тиен акча җибәрсә, шуның бары тик 0,5 тиенә генә татарлар өчен тотыла. Мөселман руханилары һәм милли буржуазия



*Татарстан АССРның беренче гербы.*

ачкан мәктәпләр балаларның аңын гореф-гадәт, дин йолалары белән агуладылар, башка милләтләргә карата дошманлык рухында тәрбияләделәр.

**Күп яттык без мәдрәсәдә,**
**Аңламадык бер нәрсә дә...—**

дип, Габдулла Тукай нәкъ әнә шул еллардагы мәдрәсә шәкертләре турында җырлады. «Вестник воспитания» журналы 1906 елгы саннарының берсендә Россиядәге вак халыкларның наданлыгын бетерү өчен 4—5 мең ел вакыт кирәк булачак дип язды.

Казан губернасының экономикасы нинди кызганыч хәлдә булуын күз алдына китерүе кыен түгел. Ул бары тик шәм, сабын кайнату, чыпта сугу һәм кәрзин үрү белән дан тота иде.

Болар инде барысы да артта калды. Октябрь революциясе татар халкын, изелүдән, хәерчелектән һәм хокуксызлыктан коткарып, бәхетле, азат тормыш юлына алып чыкты.

Партиянең политик һәм оештыру эшчәнлеге аркасында, социаль-экономик үзгәрешләр нәтиҗәсендә, 1925 елның декабрендә булган партиянең XIV съездында ук инде илебез социалистик индустриялизациягә борылыш ясады. Алда меңнәрчә завод-фабрикаларны үзгәртеп кору, экономиканың өр-яңа тармакларын булдыру, промышленность үзәкләренең тупланган урыннарын үзгәртү бурычлары торды. Шул ук юнәлештә Татарстан хезмәт ияләренә дә гаять зур эш эшләргә туры килде. Индустриялизациянең башлангыч чорында ук инде яшәп килгән промышленность предприятиеләрен үзгәртеп кору, яңаларын булдыру буенча республикада зур эш эшләнде. Шулай итеп, 1926—1928 елларда Мәскәү — Казан тимер юлының шпал ясау һәм такта яру заводлары, Казан холодильнигы, 3 нче номерлы фанера заводы эшли башлады. Шөгердәге гудрон заводы өр-яңадан корылды. 1928 елның августында зур куәткә ия булган беренче Казан мех фабрикасы сафка басты һәм Татарстанда көчле мех промышленностеның үсүенә нигез салынды. Дербышкадан Казанга кадәр тимер юлның коньяк тармагы үткәрелде.

Ләкин болар әле беренче адымнар гына иде. Патша самодержавиесеннән мирас булып калган артталыкны алар гына әле бетерә алмадылар. Бары тик партиянең XV съездыннан соң гына Татарстанда экономика көчле темплар белән үсеп китте. Билгеле булганча, партиянең бу съездында илнең артта калган милли районнарында экономиканы югары темплар белән үстерү турында сүз барды.

Социалистик ярыш һәм ударниклык хәрәкәтенең киң җәелүе, эшче сыйныфының героик хезмәте нәтиҗәсендә республикабыз бишьеллык планны дүрт ел да 3 айда үтәп чыкты. Искедән калган утыз предприятие баштан ук үзгәртеп корылды, кустарь промышленность системасындагы 40 предприятие төзелде. Егерме яңа эре предприятие, шул исәптән язу машиналары заводы, СССРда бердәнбер булган кетгут заводы, саго заводы, атаклы Казан мехкомбинаты, беренче номерлы Казан ТЭЦы һ. б. төзелде. Татарстанның яңа төзегән шул предприятиеләрендә генә дә 12 меңнән артык кеше эшли башлады. Тулаем алганда Татарстан промышленносте бөтен илдә барган үсешкә караганда ике тапкыр кызурак темплар белән үсте.

Татарстанда беренче бишьеллыкта күбрәк җиңел промышленность тармаклары үсүгә әһәмият бирелсә, икенче бишьеллыкта инде авыр индустрия предприятиеләрен үстерүгә йөз тотылды. Бу елларда промышленностьның химия һәм металл эшкәртү тармаклары үстерелде һәм республикабыз СССРның куәтле индустрия районнарының берсенә әйләнде.

Икенче бишьеллык план да вакытыннан алда үтәлде. Шул елларда СК-4 һәм машина төзү заводлары төзелде. Кинопленка һәм фотожелатин, ясалма күн заводлары, фетр фабрикасы, битум заводы, Казан ТЭЦ-1, ТЭЦ-2 ләрнең икенче чираты салынуында дәвам итте.

Татарстан өченче бишьеллыкта да зур бурычларны хәл итте. 49 эре предприятиене яңадан салу һәм үзгәртеп кору күздә тотылды. Республика хезмәт ияләре химия, металл эшкәртү, энергетика промышленностьларын, тимер юл һәм су юлы транспортын тагы да үстерү буенча зур көч куеп эшләргә тиеш булдылар. Нефть ятмаларын тикшерү һәм бораулау өчен хөкүмәтебез зур суммада акча тотты,

Татар нефтен эзли башлауның беренче планнары В. И. Ленин исеме белән бәйле. 1919 елда ук инде, Владимир Ильичның тәкъдиме буенча, академик Губкин җитәкчелегендә Татарстанга геологик экспедиция җибәрелә. Шул ук елның 26 августында экспедиция Урал белән Идел арасында зур нефть ятмалары барлыгы турында Казаннан Ленинга телеграмма җибәрә.

Шулай итеп, социалистик стройның, партиябез үткәргән ленинчыл милли политиканың өстенлекләрен файдаланып, сугыш алды бишьеллыкларында Татарстан илнең артта калган аграр районыннан индустриаль республикаларның берсенә әйләнде.

Барлык совет халкы кебек үк, Татарстан хезмәт ияләре дә Бөек Ватан сугышы елларында немец-фашист илбасарларын һәм япон империалистларын тар-мар итүгә лаеклы өлеш керттеләр. Татарстан уллары сугыш кырларында совет патриотизмы һәм героизмның искиткеч үрнәкләрен күрсәттеләр. Эшчеләр һәм крестьяннар фронтка ярдәмнәрен көн саен арттыра бардылар.

Сугыш алды бишьеллыкларында тудырылган көчле промышленносте һәм алга киткән авыл хуҗалыгы булган Татарстан Совет Армиясенең тылдагы иң эре базаларыннан берсе булды.

Татар халкы уллары, Ватаныбызның башка милләт халыклары белән иңгә иң торып, фашистларга каршы батырларча көрәштеләр. Нигездә Татарстан хезмәт ияләреннән торган 18 нче укчы дивизиянең командирлары һәм сугышчылары Смоленскины яклап сугыштылар. Якташыбыз Советлар Союзы Герое Г. Б. Сафиуллин җитәкчелегендәге дивизия фашистларны Сталинград янында тар-мар итте. Татарстан сугышчыларыннан кырык кеше Днепрны кичкәндәге батырлыклары өчен Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемне алдылар. Шулар арасында Гали Закиров, Фәхрази Галиев, Петр Сафронов, Баян Дәүләтов, Самат Садриев, Нәкыйп Сафин, Вилей Бурмистров һ. б. лар бар.

Я. Чанышев, Ф. Булатов, Г. Сафиуллин, Ә. Рамазанов, Нагайбаков, Әпсәләмов, Конев, Кутлин, Кирсанов, Шафранов, Яковлев һ. б. якташ генералларыбыз җитәкчелегендә гаскәрләребез данлы сугышчан юл үттеләр. Дошман тылында партизан отрядларында көрәшкән Татарстан егетләре дә зур батырлыклар күрсәттеләр.

Казан дәүләт университеты аспиранты Назар Бирюков җитәкчелегендә Смоленск тирәләрендә сугышкан партизан отрядында гына да Татарстаннан 200 дән артык кеше бар иде.

Якташыбыз М. Җәлил һәм аның көрәштәшләренең батырлыгы бөтен дөньяга билгеле булды. Патриот шагыйрь палач балтасына башын куйган көе:

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигыремдәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма,—

дип җырлады.

Ватаныбыз халкыбызның фашизм белән көрәштәге батырлыгына югары бәя бирде. Татарстанның ике йөзгә якын сугышчысы Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булды, 100 меңнән артык кеше орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. Сугыш елларында Советлар Союзы Герое исемен алган сугышчылар саны буенча татарлар илебездә дүртенче урында торе.

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң, Совет дәүләте үсешендә яңа этап башланды. Илебез тыныч хезмәт һәм социалистик җәмгыятьнең алга таба үсеш юлына аяк басты.

Сугыш фаҗигаләреннән фронт үткән җирләр генә түгел, бәлки илебезнең барлык республика һәм өлкәләре, шул исәптән Татарстан да, күп җәфа чикте. Бу хәл барыннан да бигрәк авыл хуҗалыгында сизелде. Эшче көчләр җитми иде. Сугышка кадәрге чор белән чагыштырып караганда 1945 елда эшкә яраклы кешеләр саны 200 меңгә ким булды. Сугыш беткән елларда республиканың авыл хуҗалыгы техникасы тузып беткән, чәчү җирләре, терлекләр саны шактый кимегән иде. Илдә тынычлык урнашкач халыкның бөтен көче сугышның аяныч нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелде.

Республиканың барлык хезмәт ияләре тырышлыгы белән кыска вакыт эчендә промышленность һәм авыл хуҗалыгы торгызылды, алай гына да түгел, сугышка кадәрге дәрәҗәдән узып кителде. Сугыштан соңгы бишьеллыклар нәтиҗәсендә нефть һәм химия промышленносте көчле темплар белән үсә башлады.

1959—1965 елларда республика үзенең экономикасы үсешендә яңа зур адым ясады. Шул елларда халык хуҗалыгы үсешенә 3 миллиард сум акча тотылды. 400 дән артык промышленность предприятиеләре, цехлар, шул исәптән 40 зре предприятие сафка бастырылды. Промышленность продукциясенең күләме бу елларда 1,8 тапкырга үсте. Бигрәк тә энергетика, нефть, машина төзү һәм башка промышленность тармаклары кызу темплар белән үсте.

1969 елда Татарстанда промышленность продукциясе бирү дәрәҗәсе сугышка кадәрге еллар белән чагыштырганда 300 тапкырга артты. Республикадагы индустриаль үсеш темпы бөтен илнеке белән чагыштырып караганда 4 тапкырга артык.

Промышленность продукциясенең кайбер төрләре буенча Татарстан илебездә шактый күренекле урын тота. СССРда табылган нефтьнең 30 проценттан артыгы, табигый газның 6 проценты, кул сәгатьләренең 10 проценты, кинофотопленканың 45 проценты, олеин кислотасының — 70, стеарин кислотасының 45 проценты Татарстан өлешенә туры килә. Компрессор һәм турбокомпрессорларның күп төрләрен җитештерү буенча Татарстан СССРда бердәнбер республика булып санала. Татарстан кыска вакыт эчендә иң күп нефть табу районнарының берсенә әйләнде. Соңгы өч ел эчендә генә дә илгә 279 миллион тонна нефть һәм 9 миллиард кубометр газ бирелде. Республика нефтьчеләре алдында 1970 елда нефть табуны 100 миллион тоннага җиткерергә һәм соңгы бишьеллык буенча шул күләмне тотарга дигән зур һәм катлаулы бурыч тора.

Нефть промышленносteның үсеше шәһәрләр һәм эшче поселоклары үсешенә зур йогынты ясады. Республиканың көньяк-көнчыгышы танымаслык булып үзгәрде. Нефтьчеләрнең башкаласы — Әлмәт шәһәре искиткеч матур якның үзәгендә утыра. Бөгелмә, Лениногорск шәһәрләре күзгә күренеп үсә, нефтьче һәм төзүчеләр өчен хәзерге заманча эшләнгән яңа шәһәр — Җәлил шәһәре төзелә.

Республикада углеводород запасының күп булуы зур химиянең эре предприятиеләрен төзү өчен зур мөмкинлекләр бирә. Казанда органик синтез заводы төзелде, ул халык хуҗалыгы өчен бик кирәк булган фенол, ацетон, полиэтилен эшләп чыгара башлады. Түбән Кама химия комбинатының беренче продукция җитештерү цехлары 1967 елда сафка басты. Илгә югары сыйфатлы синтетик каучук һ. б. бик күп төрле продукцияләр бирә торган предприятиеләрнең иң зурысы булган бу комбинатның беренче чираты бишьеллык азагына төзелеп бетәчәк.

Химия промышленносteның кинофотопленка, фотожелатин, резина-техник әйберләр, дарулар, кер юу порошоклары производстволары шикелле башка тармаклары да үсүләрен дәвам итә.

Бөтен илдәге шикелле үк, Татарстанда да Ленинның илне электрлаштыру идеясе уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. 1940 елны республикада электр энергиясе җитештерү бер кешегә 117 киловатт-сәгать булса, 1969 елны ул кеше башына 4216 киловатт-сәгатькә җитте. Бер кешегә электроэнергия җитештерү буенча Татарстан Австрия, ФРГ, Бельгия, Франция, Италия, Испания шикелле капиталистик илләрне узып киткән дигән сүз бу.

Ә бу исә авыл хуҗалыгы производствосын һәм авыл өйләрен электрлаштырырга зур мөмкинлек бирә. Хәзерге вакытта 83 процент колхоз һәм 93 процент совхозлар илебезнең дәүләт энергия системасына тоташтырылган. Ә 1970 елда барлык авыл хуҗалыгы районнары да электроэнергияне үзәк чыганаклардан алачаклар. Хәзер Зәй ГРЭСының икенче чиратын, Түбән Кама химия комбинаты ТЭЦы һәм Түбән Кама ГЭСы төзелеп ята. Бишьеллык тәмамланганчы Казанда 2 номерлы станцияне үзгәртеп кора башлау, шулай ук 3 номерлы станцияне салып бетерү күздә тотыла. Шул чаралар гамәлгә ашырылганнан соң, Татарстанның энергетик куәте Братск ГЭСының көченнән дә артып китәчәк.

Куәтле машина төзү промышленностеннан башка хәзерге заман индустриясен күз алдына китерүе дә кыен. Көчле техника, оешканлык, тәртип һәм иң яхшы машиналар кемдә булса, шул өстенлек ала, дип өйрәтте В. И. Ленин.

Республикабызда төрле-төрле продукция бирә торган 30 дан артык машина төзү предприятиесе эшли. Алдагы бишьеллыкларда ул тагы да зуррак темплар белән үсәчәк. 1970 елда ук инде Чаллы шәһәрендә гигант автозавод салына башлады.

Республикабыз предприятиеләрендә производство культурасын һәм техник дәрәҗәне күтәрү буенча да зур эш алып барыла. Күп санлы автомат, ярымавтомат линияләр, конвейерлар, программалы идарә итү станоклары производствога кертелә.

Татарстан промышленностенда хәзер химия һәм нефть-химия производстволарында күп кенә прогрессив методлар кулланыла.

Республикабызда бик күп алга киткән җиңел һәм азык промышленносте предприятиеләре эшли. Югары механизацияле мех эшкәртү предприятиеләре, йон юу, җитен туку, трикотаж, итек басу, тегү, кун эшләү, аяк киеме фабрикалары бөтен илгә таныл. Ленин орденлы мех берләшмәсе илдә эшкәртелә торган сарык тиресенең 50 процентка якынын бирә. «Спартак» аяк киеме комбинаты 1969 елны 11 миллион пар аяк киеме җитештерде. В. И. Ленин исемендәге Казан җитен комбинаты 1940 ел белән чагыштырганда эшләп чыгаруны 2,7 тапкырга арттырды.

Татарстан промышленностеның башка тармаклары да шундый ук югары темплар белән үсүен дәвам итә.

Үткән бишьеллыкларда республикабыз авыллары зур деңгыл юл үттеләр. Аз җирле, ярлы, ялгыз крестьян хуҗалыклары югары механикалы колхоз һәм совхозларга әйләнделәр. Алар производствоны алдынгы авыл хуҗалыгы практикасына һәм фәннең иң яңа казанышларына нигезләп алып баралар. Авыл хуҗалыгындагы казанышлары һәм колхоз, совхозларны ныгытуда ирешкән уңышлары өчен 1934 елда Татарстан республикасы хөкүматебезнең югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнде.

Республикада булган 700 гә якын колхоз һәм 172 совхозның 4,4 миллион гектардан артык җире бар. Югары механизация һәм электрлаштыру хәзерге заман авыл хуҗалыгы производствосының төп сыйфатлары булып тора. Җир эшкәртү культурасы һәм терлекчелекнең үсүе авыл хуҗалыгы культураларының, терлекчелек продуктларының артуын тәэмин итте. Күп заманнардан бирле йөз пот уңыш алу телеге игенче өчен хыял гына булып калган иде. Ә хәзер 100—150 пот уңыш алу Татарстанның күп районнары өчен гадәти бер хәлгә әйләнде. Әле күптән түгел генә республикабыз хөкүматкә 40—45 миллион пот кына икмәк саткан булса, соңгы елларда ул ике тапкыр артты.

Җир эшкәртүдәге уңышлар терлекчелекнең үсүенә дә зур йогынты ясады. 1940 ел белән чагыштырганда ит җитештерү 3,5 тапкыр, сөт һәм йомырка җитештерү 3 тапкырга артты. Терлекчелек продуктының барлык төрләре буенча хөкүматнең әзерләү планы вакытыннан алда үтәлә.

Авыл хуҗалыгын күтәрү буенча Партия һәм Хөкүматебез тарафыннан соңгы елларда күрелгән җитди чаралар нәтиҗәсендә бу өлкәдә зур җиңүләргә ирешелде. Бишьеллыкның беренче дүрт елында ук инде ашлык 40 процентка якын, ит — 30, сөт — 35 һәм йомырка җитештерү 48 процентка артты. Күбрәк бодай һәм карабодай шикелле кыйммәтле культуралар исәбенә, хөкүматкә ашлык сату планы бишьеллыкның дүрт елында ук тулды. Тулаем һәм товар продукциясенең үсеше колхоз һәм совхоз производствосының керемен шактый күтәрде. 1964 ел белән чагыштырганда колхозларның акча кереме 1969 елда ике тапкырга диярлек үсте һәм 436 миллион сумга җитте. Хезмәткә түләү фонды 1,3 тапкыр күтәрелде. Бер хезмәт көненә хәзер уртача 3 сум түләнә.

Совет власте елларында Татарстанда яхшы оештыру сәләтенә ия булган, белемле җитәкче кадрлар, авыл хуҗалыгы белгечләре үсеп чыкты. 1928 елны республикада авыл хуҗалыгы белгечләреннән 160 кеше генә булса, хәзер колхоз һәм совхозларда урта һәм югары махсус белем алган 5,5 мең кеше эшли. 50 меңгә якын механизаторлар куәтле техника белән идарә итәләр. Республикада авыл хуҗалыгын тагын да күтәрү, колхоз һәм совхозларның экономикасын ныгыту буенча күп эш эшләнде. Ә бурычлар тагын да зуррак. КПСС ҮК 1968 елгы Октябрь Пленумы авыл хуҗалыгы производствосының үсеш темпларын тизләтү, авыл хуҗалыгы продуктларының барлык төрләрен арттыру бурычын куйган иде.

Татарстан хезмәт ияләре бу бурычны үтәү өчен барлык көчләрен куялар. Алдагы бишьеллыкта ашлык житештерү 4 миллион тоннага житәчәк. Бу хәзерге вакыт белән чагыштырганда 10 процентка артык булачак дигән сүз. Сөт житештерү 1314 мең тонна, ит житештерү 368 мең тонна булачак. Бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимеш житештерү дә нык үсәчәк.

Республикада терлекчелек продуктларын һәм уңышны тагын да арттыру өчен кирәк булган шартлар барсы да булдырылган һәм алда торган бурычлар барсы да тормышка ашарлык.

Материаль-техник базаның ныгый баруы, колхозлар һәм совхозлар экономикасының үсүе, кадрларыбызның квалификациясе һәм осталыгы күтәрелү авыл хуҗалыгы производствосын концентрацияләштерү һәм специальләштерү өчен зур мөмкинлекләр тудыра.

Республикадагы өч шикәр заводы каршында ит житештерү буенча специальләшкән зур хуҗалыклар төзелә башлады. Биредә елына 40 меңгә якын мөгезле эре терлек симертеләчәк. Тәтеш районының «Путь Ильича», Октябрь районының «Дружба», Әлмәт районының «Красный маяк» колхозларында шундый хуҗалыклар эшли дә башлады инде. Дуңгыз симертү буенча эре комплексны 5 хуҗалык төзелә. Аларның һәркайсында елына 50 меңгә якын дуңгыз симертеләчәк. Шәһәрләр һәм промышленность үзәкләре зоналарында сөт житештерү буенча комплексны эре фермалар салына. Кошчылыкны специальләштерү дә республикада зур уңыш белән бара. «Птицепром» тресты системасында специальләштерелгән 13 хуҗалык булып, соңгы өч елда йомырка житештерү 23 тән 74 миллион данәгә житте. Бу елның башында «Ключинский» кошчылык совхозында автомат линияләр һәм программалы җайланмаларга корылган цех эшли башлады. 19,5 мең тавык асрала торган бу цех белән бөтен дөнья стандартына туры килгән катлаулы машиналар идарә итә. Анда бары тик ике кеше эшли.

Авыл хуҗалыгы производствосын концентрацияләү һәм специальләштерү эшләре зур чыгымнар сорый. Бишьеллыкның соңгы дүрт елында авылдагы капиталь-көнкүреш биналары һәм торак йортлар төзү дә зур колач белән бара. 1966—69 елларда гына да республикабыз авылларында 76 мең урынлы клуб, 36,5 мең укучы өчен мәктәп, 9,6 мең урынлы балалар бакчалары һәм 148 мең квадрат метр торак мәйданы төзелде. Алдагы бишьеллыкта авыл хуҗалыгы өчен капитал салымнар икеләтә артачак һәм шул максат өчен ел саен 120 миллионга якын акча тотылачак. Соңгы вакытларда колхоз һәм совхозларның үзәкләрен заман таләпләренә туры китереп салу күздә тотыла. Биектау районының Шәпше авылында «Урак-чүкеч» колхозын үрнәк итеп төзү бара. Биредә 400 урынлы клуб, 192 балага мәктәп, 90 урынлы балалар бакчасы, аптека, фельдшер-акушерлык пункты, мунча, көнкүреш комбинаты, административ бина, сәүдә үзәге, телефон станциясе һәм бер, ике, дүрт, шулай ук уналты квартиралы йортлар салына. Шундый ук төзелеш тагын 8 хуҗалыкта бара.

Алдагы бишьеллыкта авыл хезмәт ияләре газ белән тәэмин ителәчәк. Колхоз һәм совхоз эшчеләреннән 31 мең йортка, 217 производство һәм 100 көнкүреш биналарына газ кертелде дә инде. 1975 елның ахырына тагын 240 мең йортка газ кертеләчәк. Бу колхоз һәм совхозларда яшәүче семьяларның нәкъ яртысы дигән сүз. Шулай ук 1472 производство һәм 745 культура-көнкүреш биналарына газ кертү күздә тотыла.

Татарстан авыл хуҗалыгы техник прогресс этабына аяк басты. Хәзер хезмәт процессларын автоматлаштыру, производствоны программалы идарә итү мәсьәләләре киң тәртибенә куела. Болар барсы да авыл хезмәт ияләренең көнкүрешен тамырдан үзгәртәчәк. Хезмәт культурасы белән бәйле рәвештә көнкүреш культурасы да үсәчәк.

Индустрияләштерү елларында республика транспортында да зур үзгәрешләр барлыкка килде. Элек кечкенә паровозлар тетәп утырган юлларда хәзер куәтле тепловозлар, дизель поездлары чаба. Октябрьгә кадәр Татарстан территориясендә тимер юлларның озынлыгы 163 километр гына булса, хәзер инде ул 740 километрга житте.

Кайвакытта кинолентадарда кызык бер күренеш чагылып үтә: яшел чирәм баскан сәзәк яр. Яр өстендә черек түбәле өйләре чәчелеп яткан фәкыйрь авыллар, ә елга өстендә көпчәкләрен суга шап-шоп бәреп, тәбәнәк морҗасыннан кара төтен чыгарып, пароход я буксир үтеп китә. Алар шул кадәр акрын кыймылдый, нича кара-

саң да бер урында тора сыман. Октябрь революциясенә кадәр Иделдә дә, Камада да, Агыйделдә дә, Вяткада да әнә шул күренеш булган. Хәзер исә бу елгаларда комфортабельле теплоходлар, җилдәй җитез «Ракета»лар, «Метеор»лар йөзә. Елга портларында көчле краннар йөк бушата. Механикалаштыру нәтиҗәсендә су транспортындагы хезмәт җитештерүчәнлек 15 тапкырдан артыкка үсте.

Республикада яңадан-яңа автомобиль юллары салына. Машиналар саны торган саен күбәя. Хәзер шәһәр һәм районнар арасында 246 маршрут булып, 12 мең километрга сузылган бу юллардан көн саен дистәләрчә автобуслар чаба.

Татарстанда һава юлы беренче тапкыр 1927 елда ачыла. 1937 елда Казан аэропортында 15 самолет була. Казан аэропорты көн саен АН — 10, ИЛ — 18, АН — 24, ТУ — 124 самолетларын кабул итә.

Совет Татарстанында мәгариф, сәламәтлек саклау һәм культураның зур темплар белән үсүе ленинчыл милли политиканың тантанасын тагын бер кат раслый.

Социаль һәм фәнни техник прогрессның кызу темплар белән үсүе, югары механизацияле производство хәзерге заман яшьләреннән югары дәрәҗәдә культуралы һәм киң белемле булуны таләп итә.

Хәзерге вакытта республикада 3383 мәктәп булып, анда 720 мең бала укый. Соңгы егерме ел эчендә республикабыз вузлары һәм техникумнары 225 меңгә якын врач, агроном, зоотехник, укытучы һ. б. белгечләр тәрбияләп чыгарды.

Татарстанда хатын-кыз белгечләрнең саны — 108,9 мең кеше. Республикада һәр дүрт инженерның берсе — хатын-кыз. Мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә 88 процент хатын-кыз эшли.

Татарстанда галимнәрнең зур бер отряды эшли. Казан галимнәре фәннең барлык тармаклары буенча эшлиләр. Химикларның, математикларның, механикларның, физик һәм филологларның хезмәтләре Советлар Союзында гына түгел, бик күп чит илләрдә киң танылды.

Халыкны сәламәтләндерү проблемасын да Совет Татарстаны уңышлы хәл итә. 1970 елда, бөтен илдәге шикелле үк, Татарстанда да холера, чума, тиф, бизгәк, полиомиэлит, трахома, чәчәк шикелле авырулар бөтенләй бетерелде. Республикада 30 меңнән артык койкалы 286 больница бар. Хәзер һәр мең кешегә 9,5 койка, 2 врач һәм урта белемле 7 медицина персоналы туры килә.

Хәзер республикабызда 6677 врач эшли. Шуларның 1747 се милли кадрлар.

Тормыш шартлары яхшыру һәм медицина хезмәте күрсәтүнең югары дәрәҗәсе нәтиҗәсендә хәзер республика хезмәт ияләренең уртача гомере 70 яшькә туры килә.

Октябрь революциясе һәм Татарстан АССР төзелү милли культураның үсүенә чикләнмәгән мөмкинлекләр тудырды. Культура өлкәсендәге ленинчыл милли политика милли культураларның бөтен дөнья күләмендәге үсешенә, аларның бер-берсе белән аралашып, бер-берсен баетып яшәвенә юл ачты.

Нәкъ менә шул принцип кыска гына вакыт эчендә республикабызга культура өлкәсендә зур биеклекләр яулап алырга мөмкинлек бирде. Әнә шул процесс барган елларда татарлардан беренче профессиональ композиторлар, беренче милли опера һәм балет, зур һәм катлаулы формаларда язылган беренче музыкаль әсәрләр һ. б. туды.

Татарстан язучылар оешмасы РСФСРда иң зур оешмаларның берсе. Ул үзенең сафларында 130 га якын каләм остасын берләштерә. Язучыларыбызның китаплары күп кенә СССР халыклары һәм чит илләр теленә тәрҗемә ителә. Татар язучыларыннан К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Г. Бәшировның «Намус» романнарына СССР Дәүләт премиясе бирелде.

Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил иҗаты бөтен дөнья поэзиясенең казанышына әверелде. Татар профессиональ музыка иҗатына нигез салучы Салих Сәйдәшев 20 нче елларда яза башлады һәм аның кабатланмас иҗаты бик тиз халыкка танылып, көннән-көн чәчәк атты. Хәзер татар композиторлары отрядында 32 композитор һәм музыка белгече бар. Алар халкыбызга 15 опера, 6 балет, 4 музыкаль комедия бирделәр, симфония, концерт, ораторияләр яздылар.

Н. Җиһановның «Алтынчәч», «Җәлил» опералары, Ф. Яруллинның «Шүрәле» балеты, М. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе совет музыкаль культурасының алтын фондына керделәр.

Безнең художниклар союзында 39 член һәм 20 кандидат бар. Алар сынлы сәнгатьнең күп төрле жанрларында — живопись, скульптура, графика, агачка кисеп эшләү, керамика, тукымалар бизәү һ. б. өлкәләрдә эшлиләр. РСФСРның халык художнигы Х. Якуповка, РСФСРның атказанган художнигы Л. Фәттахка «В. И. Ленин Татарстан АССР төзү турындагы декретка кул куя» дигән зур полотно өчен СССР Дәүләт премиясе бирелде.

Республикада театраль культура нык үсте. Казанда илнең иң өлкән театрларыннан берсе булган В. И. Качалов исемендәге Зур театр эшли. Г. Камал исемендәге Татар академия театры да инде җиденче дистәне тутырып килә. Моннан 30 ел элек опера һәм балет театры ачылу — татар милли культурасының зур казанышы булды. Республика күчмә театры, Әлмәт, Бөгелмә, Минзәлә дәүләт театрлары, Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры, курчак театры да халкыбызга зур культура хезмәте күрсәтә.

Г. Тукай исемендәге дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле, симфоник оркестр, лекторий-концерт һәм эстрада коллективлары елына 2000 нән артык чыгыш ясый. Татарстан АССРның симфоник оркестры төзелү милли музыкаль культура үсешендә күренекле этап булып тора.

Республикада 1602 авыл клубы, 212 культура йорты, 130 профсоюз клубы һәм культура сарае, 1763 халык китапханәсе, шуның өстенә аерым оешмалар каршындагы 250 китапханә, 2348 киноустановка, 10 музей халыкка күп кырлы белем бирүдә, культура зәвыгы тәрбияләүдә күп ярдәм итә. Яңа проект белән салынган 2,5 мең кешә сыешлы цирк та безнең куанычыбыз һәм мактанычыбыз булып тора.

Казан дәүләт консерваториясе, музыкаль, сынлы сәнгать һәм театр училищелары, культура-агарту училищесы сәнгать һәм культура учреждениеләре өчен кадрлар әзерлиләр.

Шулай итеп, республикабыз үткән 50 ел эчендәге экономика һәм культурабыз үсешен күз алдына китерсәк, халыкның тормышын үзгәртеп коруда Ленин идеяләренең тормышка ашуы, партиянең ленинчыл милли политикасының тантанасы ачык күренә.

* * *

Республикабыз экономикасы һәм милли культурасының үсеше тугандаш халыклар семьясында һәм аларның ярдәме белән барды. Социалистик үсешнең барлык этапларында да илебезнең эре промышленность һәм культура үзәкләрендәге хезмәт ияләре Татарстанны заман таләпләренә туры килгән техника белән, квалификацияле эшчеләр һәм инженер-техник кадрлар белән тәэмин итеп торды. Мәсәлән, нефть промышленностен үстерүдә Татарстанга Әзербайҗан, Украина, Башкортстан, Дагстан, Сахалин һәм Краснодар өлкәсе нефтьчеләре, вышка төзүче, нефть табучы осталарын җибәреп, шулай ук күп төрле машина һәм җиһазлар белән дә бәя биреп бетермәслек зур ярдәм күрсәттеләр.

Ә Татарстан үз предприятиеләрендә эшләнгән машина һәм җиһазларны, нефтьне, язу машиналарын, җылылык энергиясен үлчәү приборларын, компрессорларны, кинофотопленка, полиэтилен, фенол, кетгут, мех һәм резина-техник әйберләр, автогараж кораллары, сәгатьләр, медицина кораллары һәм башка әйберләрне илебездәге барлык тугандаш республикаларга һәм 67 чит илгә чыгара.

Татар мех берләшмәсендә эшкәртелгән мехлар дөнья базарында да күренекле урын тоталар. Тюлень, манылган тиен, махсус ысул белән эшкәртелгән сарык тиресенә сорау бик зур. Казан мехчылары эшләп чыгарган әйберләр Брюссель һәм Монреальдә булган бөтен дөнья күргәзмәләрендә «Гран-При» зур алтын медален алдылар. Җир асты магистральләре буйлап, илнең көнчыгышына да, төньягына һәм көнбатышына да нефть ага.

«Дуслык» нефтьүткәргече Татарстанда башланып, Польша, ГДР, Чехословакия һәм Венгриягә кадәр барып җитә.

1968 елны Татарстан предприятиеләре экспортка 347,2 миллион сумлык 300 исемдә әйбер чыгарсалар, 1969 елда инде ул 380 миллион сумга житте.

Бу мисаллар барсы да Татарстанның илебездәге башка республика һәм өлкәләре белән, социалистик илләр һәм башка чит илләр белән булган экономик бәйләнеше турында сөйлиләр. Татарстандагы иҗади көчләрнең профессиональ дәрәҗәсе һәм осталыгы югары күтәрелү, республика хезмәт ияләренең эстетик зәвыгы һәм культура дәрәҗәсе үсү илебездәге башка халыклар белән культура элемтәсе киңәюе нәтиҗәсендә бара.

Хәзер Татарстанга Советлар Союзының зур сәнгать осталары, атаклы иҗат коллективлары һәм шулай ук чит илдәге артистлар да зур теләк белән киләләр. Аларны бирегә зур концерт заллары, яхшы сәхнәләр генә тартмый. Югары культуралы, эстетик зәвыклы, чын сәнгатькә бәя бирә белүче тыңлаучы-тамашачылар барлыгын да яхшы беләләр алар.

Сәнгать һәм әдәбият декадалары, атналыклары культура элемтәләренең күңелле бер формасы булып тора. Соңгы елларда Татарстанда Башкортстан, Чувашстан, Мари АССРларның әдәбият һәм сәнгать атналыклары булып үтте. 1962 елда үткәрелгән рус әдәбияты һәм сәнгате бәйрәме республикабыз культура тормышында бер вакыйга булып калды. Алма-Атада татар әдәбияты һәм сәнгате, ә Казанда казакъ әдәбияты һәм сәнгате бәйрәмнәре үткәрелү шул матур традициянең дәвамы булды. Ленинград язучылары һәм сәнгать осталарының Казанга килүләре, 1967 елда Татарстан иҗат көчләренең Ульяновскида булулары, 1968 елда үткәрелгән Чехословакия культурасы көннәре хезмәт ияләрендә күңелле тәэсир калдырды. 1969 елның җәендә Әзербайҗан һәм Үзбәкстан язучыларының һәм сәнгать көчләренең Казанга килүләре дулкынландыргыч бер бәйрәмгә әйләнде. Болар барысы да социалистик милли культураларның бер-берен баетулары, үзара йогынты ясаулары — ленинчыл милли политиканың гүзәл үрнәкләре булдылар.

Казан — В. И. Ленинның туган көненә багышлап үткәрелә торган традицион музыкаль фестивальләр шәһәре булып тора. Ел саен бирегә Мәскәү, Ленинград иҗат коллективлары килә. Польша һәм Чехословакия, Венгрия һәм Румыния, Болгария, Югославия, ГДР илләреннән килгән сәнгать осталарын да республикабыз алкышлап каршылый.

Төрле иҗат оешмаларының үзара элемтәләре көннән-көн ныгый бара. Соңгы елларда гына да республикабыз язучылары Киров, Ульяновск, Горький өлкәләрендә дә әдәби очрашулар үткәрделәр. Композиторлар һәм язучылар бергәләп Төмән, Пермь, Астрахань өлкәләрендә, Башкортстан, Удмуртия, Мари автономияле республикаларында әдәби-музыкаль кичәләр оештырдылар. Мәскәү һәм Ленинградка иҗади отчетлар белән бардылар.

Безнең әдипләребез, композиторларыбыз, художникларыбыз, артистларыбыз илебезнең барлык почмакларында көтеп алынган кадерле кунак булалар. Республикабыз театрлары һәм концерт бригадалары Урал, Себер, Урта Азия, Кавказ, Идел буе өлкәләре, Балтик буе шәһәрләрендә гастрольләрдә була. Республикабызның бию сәнгатенә Кореяда, Кытайда, Монголия Халык Республикасында да югары бәя бирделәр. Татар артистлары Н. Юлтыева, Ф. Насретдинов, Ә. Нарыковлар Бирмада, Вьетнамда, Кытайда, ә Р. Садиков белән С. Хантимировалар Канада, Индия, Малайзия һәм Пакистанда уңышлы чыгышлар ясадылар.

* * *

Совет Татарстанының уңышлары һәр өлкәдә гаять зур һәм куәнычлы, ә алдагы көннәрдә тагы да зуррак куанычлар көтелә. Тулай продукция икеләтә артырга тиеш. Кама буенда республиканың өченче эре промышленность районы күтәреләчәк. Түбән Кама ГЭСы һәм Европадагы иң эре заводлардан берсе булган Чаллы автомобиль заводы эшли башлаячак. Авыл хуҗалыгы тагы да югарырак баскычка күтәреләчәк.

## Хәсән Туфан

### Татарстан итеп күтәрдең

Төмерләрнең шушы көннәргә дә
Җитүләрен күреп, күрәсең,
Еракларда калган бала чакны
Искә ала бүген йөрәгем.

Ни өчендер үзен «татар түгел,
Мөселман мин!» дигән әтине
Кайберәүләр «князь» диләр иде,
Кайберәүләр — «Казан ятиме».

Нигә шулай?
Ник тартына кеше
Чын исемен телгә алырга?
Әгәр патша үзе типсә сиңа,
Ярдәм сорап кемгә барырга?!
Кемгә?

Без шуларга җавап эзләп үстек
Россиянең туксан телендә.
Одессадан Аляскага кадәр
Сузылып яткан дөнья төбендә.

Ул чор үтте.
Бетте инде, Ильич,
Бетте инде тию, тибүләр:
Анафема булып тоела инде
Халыкларны мыскыл итүләр.

Ничә гасыр буе типкәләнгән,
Яраланып беткән исемне —
«Татар» исемен
Татарстан итеп
Күтәрдең син — кояш шикелле.

Төп нигезен үзең салган эштә,
Дуслык иле төзү эшендә
Азмы инде үстек, үзгәрдек без
Илле еллык гомер эчендә!

Торган саен арта бара, Ильич,
Сине сагыну безнең йөрәктә.
Заман үзе шундый итте безне,
Заман үзе шуңа юнәлтә.

## Зәки Нури

### Ирек мәйданы

*Өзек*

Иркен мәйдан. Исеме аның — Ирек.
Йөрәк сүзен монда күз әйтә.
Юл күрсәтеп һәм юнәлеш биреп
Ильич тора шушы үзәктә.

Июнь төне. Үтә күренә томан.
Еракларда кичке җыр тынган.
Бер минутка гүя ул да тынган
Чыккан мәлгә Обком йортыннан.

Күрә синең һәрбер борылышны ул,
Ялгыш бассаң — җавап әзерлә.
Агышында шаулы тормышның ул
Нәкъ уртада тора хәзер дә.

Иярченнәр күренә кебек күктән,
Ил аларны күпләп очырган!
Киң галәмгә гүя үрләгәннәр
Старт алып Ленин учыннан.

Монда аулак. Монда уйлар тирән.
Иртәгемә шуннан керәм мин:
Кич життеме — киңәшергә киләм
Шул мәйданда Ленин белән мин.

## Нури Арсланов

### Үз илем, үз республикам

Тусам да киң казакъ даласында,
Үссәм дә мин атта-ярдә,
Гел ашкындым Казан каласына,—
Истәлекле, изге җирләргә.
Бу туфракта минем туган илем,
Йорт корганнар монда бабамнар,
Монда минем акчарлаклы Иделем,
Үз халкым, үз республикам бар!

Күзен киткән казлар язын кайта,
Кыйгаклашып, Идел-суларга.
Киек казлар... Без дә төрле якка
Таралганбыз, охшап шуларга.
Бер кайтмаса, бер кайталар илгә,
Өмет өзми кайталмаганнар:
Идел-йортта Татарстан дигән
Үз илем, үз республикам бар!

«...Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал!»лар
Борынгыча яңгырый колакта,
Гадәт булып киткән безгә алар —
Юллар илткән безне еракка.
Гизсәләр дә башлар кайларда гына,
Күңелдә гел Идел — якты яр,
Йөрәкләрдә мәңге яшь торган
Үз илем, үз республикам бар!

## Марс Шабаев

### Июнь иле

Июнь иле безнең Татарстан,
Сабан туйлар иле, җыр иле,
Кунак җыя бүген куана-куана,
Пар атлары булыр җигүле.
Сорасагыз:
Дистә гасырларны
Үзенә сыйдыра ничек бу и л л е?
Ленин кулы раслаганга шулай
Могҗиза күк безнең юбилей.
Менә колхоз. Җиде милләт халкы
Эшли монда тотынып кулга кул.
Бәйнәлмиләл бәйрәм үткәрүдә
Гыйлем бирә ала бу авыл.
Кара алтын калалары булган
Әлмәт, Җәлил, Баулы, Бөгелмә
Нефте, газы, химияләре белән
Килеп кергән менә бүгенгә.
Халкыбызның хәләл хезмәте бу,
Могҗиза да түгел, секрет та.
Ленин кулы раслый дөреслеген
Егерменче елгы декретта.
Сала, кала саен сабан туйлар...
Олы бәйрәм бүген — юбилей!
Июнь иле — Татар йорты гөрли...
Киләчәккә дәшә бу и л л е.
Туган җирем бүген оран сала,
Таратсыннар Идел җилләре:
Бүген бәйрәм!
Бәйрәм үтәр — халкым эштә булыр,
Сызганулы булыр җиңнәре!

## Рәдиф Гатауллин

# Халкым уллары

*Монолог*

...Үз Ватанын, намусын саклап, азмы
көрәшкән ул —
минем туган халкым!
Якташларым —
ил уллары чыккан
яуга, яклап ирегең — бөек хакын.
Һәр изүгә, җәбер-золымнарга
нәфрәт, корал белән каршы барган.
Ханнарның да, ак патшаларның да
я Җик Мәргән,
я Канкаев — Пугачауның
көчле кулы булып йөзенә бәргән.
Халкым уллары!
Сез
Рәсәй өчен
Наполеонга каршы гаскәр биргән.
Хәбәрләр бар:
юлыгыз булган
декабристлар белән,
народниклар белән.
Ә соңыннан —
сез Ямашлар белән,
халкының зур хакын сораган
бөек улы — тугры Тукай белән
зур юллардан килгән...

Халкым уллары! Сөенегез —
Октябрьда туган — сез яулаган ирек иле.
Бүген инде аның 50 елы...
Гасырларда таба алмаган
бәхет
бүген һәрбер күнел тулы.
Бәхет — бөек Ленин улы.

## Рәшит Гәрәй

# Казаным

Болак буйларында йөрим
Җәйге таң атканда мин.
Җырлар багышлыйм,
                    Казаным,
Сине яратканга мин.

Ефәк офыкларын балкый
Мең төрле төсләр белән.
Акчарлаклар очып уза
Казанка өсләреннән.

Кызлар җыры ишетелә
Чия бакчаларында.
Бакчалар сулмас, таңнарың
Тыныч атсалар гына.

Гөлләр тирбәлә... Җилләрнең
Назлау-иркәләвеме?!
Яратам, Казан, мин синең
Тыныч иртәләреңне.

## Мөдәррис Әгъләмов

### Минем офыгым

> Кулләре дә бер болганып
> бер тона,
> Җилләре дә бер кузгалып
> бер тына.

Туган якның кояшлары без —
Шул офыктан без дә калыктык
Бер кояшы — илчесе булып
Хезмәт сөйгән гүзәл халыкның.

И, бу офык, изге бу офык,
Болыт булып килсә кем дә кем,
Әкияттәге толпар шикелле
Аягүрә басар милләтем.

Татарстан — безнең бу офык,
Без тәгәрәп төшсәк кызара.
Ир-егетен җуйган офыкта
Кара төннәр торып сүз ала.

Уйланасың, борчыласыңдыр,
Туган ягым — изге офыгым...
Яшәрүең — хәятың өчен
Булса иде калкып чыгуым.

Татарстан — изге офыгым!

Диләрә Зөбәерова

# ДУСТЫМ АВАЗЫ

ПОВЕСТЬ



Югалуыммы бу минем, әллә табылуыммы соң?! Мин ике ут уртасында калдым.

Чү... Нәрсә булды әле миңа? Үземне утәли курә башладым шикелле. Ничә айлар, ничә еллар буе күңелемне сызган вөжданым язгы ташудай дәррәү кузгалды да үткәнгә үкенечләремне, югалтканнарымны, оныткannарымны айкап ташлады: сикәлтәле сукмакларга әйдәгән мин-минлегем һәм шуның аркасында тормышка ашты дигәндә чәлпәрәмә килгән хыялларым, шул юлда аймыл булышкан зур бәхетем, ә соныннан... заяга үткән еллар, онытылган хис-тойгылар барысы да күңелемдә янарып, бер-бер артлы күз алдымнан үттеләр.

Карасана, бер уйласаң кеше дигәненнең язмышы, яшьлеге үз кулында бит. Яшь чагында барысы да — бәхетең дә, киләчәгең дә, картлар әйтмешли, тәүфигың да үзең белән. Менә шул кодрәтле чагыбызның кадерен беләбезме соң без?!! Ә бит яшьлекнең дәртле шаукымына сугылып кемнәр генә егылмаган да, кемнәр генә адашмаган. Әгәр дә инде син шул бәхетсезлеккә дучар икәнсең, менә моны онытма: ерып чыга алмас урманнар, төзәлмәс яралар сирәк дөньяда. Димәк, син үзеннең бәхетең, якты хыялларың өчен гомерең буена көрәшергә тиешсең. Миндә бу фикерләрне бүген генә аннан ишетелгән аваз уятты.

Дөнья бер мәлгә чайкалып куйды, башым сафланып, күз алмаларым җиңеләеп киткәндәй булды.

Мин залыбыз уртасында басып торган килеш бер мәлгә әсәрләнеп калдым.

Беразга онытылырга теләп, почмактагы телевизор капкасын күтәрдем дә Мәскәү клавишасына бастым.

Шуны гына көткәннәрмени, тамашачыларым кузгалды. Әнкәсенең ниләр уйлаганын сизенгәндәй, шыпырт кына басып, кызым чыгып утырды. Аның артыннан, газета кыштырдатып, әткәсе күренде. Гадәти гаилә тынлыгы. Күзләр — тонык экранда. Фильм башланачак. Әнә бербер артлы афиша сүзләре тибрәнә башлады. Уйларымнан оеп исемен хәтерләми калдым, таныш режиссер исеме күзгә чалынды.

Кызык соң. Кеше, дөньясын онытып, кино карый. Кемнеңдер язмышы белән мавыга. Ә бит ул язмыш әнә шул сценарист күңелендә туган, ре-

жиссерга таянып сәхнәгә баскан әзер язмыш лабаса... Тукта, нигә соң кеше тормышын да көйләп, җайлап торучы әнә шундый режиссерлар юк икән? Ашыкма, чынлап уйласаң, бар түгелме соң алар? Бар алар, очрый алар. Тик кеше дигәнең аларга буйсынамы соң? Ул яшьлегендә үзен һәртөрле акыл иясеннән өстенрәк хис итә.

Башланды... Чуен рельслар буйлап тузгак башлы бер кыз чаба. Кулында озын сабаклы кыр чәчәкләре.

Бала чак белән хушлашкан чак. Ваемсыз яшьлек иртәсе. Кинокадрлар алышына тора, ә минем алда һаман шул тузгак чәчле кыз.

Нәрсәсе белән җәлеп итте соң әле мине бу шаян чәчби, кай ягы белән таныш әле ул? Мине янадан элекке уйларым биләде. Шул арада алдымда икенче экран пәйда булды. Ә үзем кыр чәчәкләре кочаклаган әлеге кызыйга әверелдем.

Бар иде минем дә шундый чакларым.

* * *

Педучилищеда укып йөрибез. Бер елдан диплом тоттырып мәктәпләргә озатачаклар. Ә үзебез, мин сиңа әйтим, ни үсмер түгел, ни балигъ булып булмый. Дәрестән чыгабыз да чүәкләрне кулга тотып Тоймага таба йөгерәбез.

— Назира, сөенечен нәрсәдән!

Борылып карасам, үкчәмә басып Факиһә килә. Кулында яшькелт конверт.

— Ике кыяк юа!

Тау кәҗәседәй бер генә ыргылам, хат инде минем кулымда.

Кем язганын, каян килгәнен тикшерену юк, иптәшләрдән арткарак калам да конвертны ачам. Чоры шундый, шафталу җимешедәй алсуланып, тулып килгән чытлык чак, хатлар ява, уртәлә, кылана торган чак, үзем укыйм, үзем сөйләшәм:

«...Назира, исәнмесез!

— Әү,— дигән булам,— саумысыз,— дим,— кем буласыз соң сез? — дим. Аңлатмасы уртадарак икән.

...Камил атлы мин... (исеме матур икән). Казан университетында укыйм (оһо!) ...Авылдашыгыз Габдулла белән бер факультетта (тарих өйрәнәсез икән), бер курста (миннән ике-өч яшькә дәү булып чыктын)... Адресыгызны аннан алдым... (каникулга кайткач кирәген бирәм Апушның). Җавап язсагыз, үземне бик бәхетле санар идем... (Казан кызларга корыганмыни...) ...Ихтирам белән Камил...»

— Ә?! Икәүләп язганнармыни әле бу хатны? Ихтирам исемле егет безнең таракта тора. Ихтирам... Ихтирам... мәгънәсе бар ич аның... И-и, аңламый да торам, хөрмәт дигән сүз ич ул!

Хатны шатырдатып йомарладым да кесәмә салып кызлар артыннан йөгердем. Һаман бер сүз, чоры шундый иде, гел ашкына, гел талпына торган чак. Моңа тагын шул сәбәп бар: сугыштан соң сулыш алып, туйганчы ипи ашап, баллы чәй эчеп, кешеләрчә яши башлаган чак. Биография сыманыбыз ике юлдан торса да, дөньяның әчесен татыган, бала чактан лаеш шулпасын чөмергән, төрлесен кичергән иде инде безнең башлар. Бомба тавышына уяндык, бишектән биш айдан төштек, эткәй йөзен күрмәдек, наз тоймадык, прәннек тешләмәдек, елашырга, көлешергә оялдык. Базда үргән бәрәңге сабагыдай ак чырайлы, арык, тешләк балалар булып үстек. Хәзер шуларның әҗәте кайта.

Хатына каршы җавап-мазар язмасам да (бу яшьтә әдәпнең игътибар дигән пункты онытылып тора), Камилнең әллә исеме, әллә шул «ихти-

рамы» инде күнел кырыенда үзенә бер оя тапты бит. Шул кунаклаган жиреннән әледән-әле үзенең барлыгын сиздертеп торган көне.

Мина хат тапшырган Факиһә — партадашым ул минем. Шуның артыннан жан атып йөрүче Әнәс бар. Дустымның моны сизмәмешкә салышкалаганын тойсам да, бик читкә тибәрәсе килми егетне. Әледән-әле кирәге килеп чыга. Мине үз итә. Уку залына керсәм дә, лабораториягә керсәк тә, клубка барсак та ул алып куйган урында утырабыз. Рәсем дәресләрендә дә хәлебезгә керә ул, малайлар «художник» бит алар.

Ярдәмен-иен күреп торсам да, жае чыккан саен үртәп үзәгенә үтәм Факиһәнең. Әз генә аерылып торсак, сорау яудыра башлыйм:

— Кая бардың әле миннән башка?..

— Карагай төбенә.

— Ә-ә-ә, тумас борын пеләшләнгән Әнәсең басып тора диганнәр иде анда. Кара әле, әче катык белән юсын әле ул башын, әl Дустымны килеш-килбәте житеп бетмәгән егетләр янында күрәсем килми.

Факиһә мина караганда басынкы ул, аны болай гына үртәп булмый. Ә мин — «бәләчник кыз» аның каршында бөтерелергә тотынам. Итәгемне ике ягыннан чеметеп жилпи-жилпи такмаклый башлыйм.

Ялтыр-йолтыр ялтырыйдыр
Боз өстендә су өсте.
Сөясеңме Әнәсеңне, әйт әле, пожалысты.

Менә шунда инде Факиһәм бер «женләнеп» ала. Уймак авызларын бүлтәйткәләп мине мыскыллый башлый:

— Үзеңне әллә кемгә куймасана. Пеләш булса да сина «карамаган».

— Әстагы... (монысы әбиемнән отkan сүзем) яр тапмастай кыз булсам, Казаннардан торып күзләмәсләр иде әле үземне.

— Күргәннәр инде Камилеңне (алдаша), сазап беткән бер карт студент, ди.

— Белдең! Аңа унтугыз гына әле. (Мин дә шаяртам). Андый егет солтаны Алабугада юк та әле.

— Ул солтан, ә син...

Факиһәнең ачуын китердем, шуңа яманлый. Ышанып куймагыз тагын, юри генә әйтә. Алай ук күз төшмәслек кыз түгел Назира апагыз.

Мине гел анама охшагансың диләр. Әнкәем, беләсегез килсә, авылда беренче кыз булган. Мулла кызы дип тормаган, сәхнәләрне ду иткән, авыл яшьләрен шаккатырып, Галиябануны уйнаган кыз. Аның сөлектәй зифа буен, тезенә төшкән кара толымнарын, «кәүсәр чишмәседәй» саф тавышларын искә алучылар бүген дә байтак. Мин аңа охшаганмын икән, димәк, андагы буй-сын, андагы чәч, андагы тавыш миндә дә бар дигән сүз. Бу кеше сүзе генә түгел, мин үз кыяфәтемне көзгедән дә бик шәп күреп торам. Каш бар, күз бар. Әткәйнеке төсле кылыч борын бар. Аннары әле мин биим дә. Шуның өстенә, юбалгы түгелмен, модистка, диләр, Львовта апам бар. Жизнәм — офицер. Украин кызларының күзен яндырган «модный» күлмәкләр өстемдә. Аэропорттан, тимер юлдан әллә кайда, читтә утырган ярым провинциаль шәһәр өчен ярап тора ул. Кимчелекләрем дә бар барын, аларын мондый чакта күрмәмешкә салышырга була.

Мәктәптә чагында кешенең дәрәжәсе өлгерешенә, сәләтенә карап йөри бит әле. Ул яктан да бәхет бар минем. Мөхәммәтдиновлар, Фатыймалар кебек училище йолдызы саналмасам да, чиреккә өчле чыгартканым юк диярлек. Диярлеге шул, дөресен әйткәндә, геометриягә теш үтми. Нигәдер, кирәксенмим мин аны. Бригадирлыкка жыенмыйм, галим буласым да юк. Аның каравы, мин географияне су кебек эчәм. Сукыр карта янына басыйм гына, кулымдагы күрсәткеч серле таякка әйләнә дә куя. Тагын шул бар (монысын үзем дә бик сизенеп, сөенеп торам),

әйбәт укытучы булырсың, диләр. Практик дәресләрем матур гына үтә... иде, шулай да менә мондыйрак бер вакыйга...

Безнең заманда Шишкин музеена житәрәк бер татар башлангыч мәктәбе бар иде. Укытучы буласылар — беренче чирканчыкны шунда алабыз.

Миңа да чират житте. Дүртенче класска бер дәрес тапшырдылар. И сөендем, и тырышып әзерләндем, репетицияләр ясадым. Ничек итеп ме? Бүлмәдәш кызларымны каршыма тезеп утырттым да «укытучылы» уйнадык.

Ниһаять... звонок. Йөрәк дөп-дөп итә. Үткән дәрес кабатланды. Яңасын аңлаттым. «Грузиядә чәй плантацияләре». Күргәзмә материалны Әнәс ясап бирде. Шома бара. Йомгакладык. Максатка ирешелгән. Тик... Нигә шалтырамый соң әле кыңгырау? Сәгатькә күз төшерсәм, сискәнеп киттем. Тәнәфескә кадәрме... башланмаган унбиш минут вакытым бар. Меңләгән нерв күзәнәкләрем буйлап эсселе-суыклы әллә ниләр йөгерде. Күтәрелеп карарга базмыйм. Бер үземә ничәмә-ничә күз төбәлгән. Класс шыгрым тулы укучылар. Эскәмияләрдә энә төртер урын юк. Үземнең группадашларым. Артта өстәл артында методист, педагог, укытучылар утыралар. Нишләргә тиеш мин хәзер? Ничекләр кыскартыйм соң гомеремнең шушы унбиш минутын... Мондый мәктәпләрдә балалар үткер булалар. Парталар кымшана, пышылдаулар ешая... Сизенделәр. Кулга алырга кирәк үзләрен. Күңелгә бер тәкъдим килде.

— Укучылар, хәзер без сезнең белән кояшлы Грузиягә сәяхәткә барып кайтабыз. (Шомлы секундлар жанлы тынлык белән алмашынды.) Әйе, әйе, сәяхәткә, тик поездга төялеп түгел, менә шушы утырган жирдән, күңел белән генә.

Укытучым Мәймүнә апама күз сирпеп алдым. Ул матур итеп елмаеп куйды, миңа шул гына кирәк, кыюланып киттем.

— Минжамал әбигә Грузиядә яшәүче улы (телгә нинди исем килде диегез — Камил килде) Камилдән посылка килеп төшә. Сургуч баскан әржәне ачып жибәрсәләр, ни күрсеннәр — туп кадәрле әфлисуннар, яшькелт-сары мандариннар, әйтерсең, шушы әржәгә Грузиянең хуш исле, жимешле бер бакчасы сыйган.

Күчтәнәчләр арасында тышына «Чәй» дип язылган бер кәгазь пакет килеп чыга. Сүтеп баксалар — кыштырдап кипкән вак-вак яфраклар. Кичен күчтәнәч исен сизеп борыннары кытыкланган күрше-күләннәр жыелган боларга.

— Хәзер мин сезне ата-бабагыз күрмәгән фасонный чәй белән сыйлыйм,— дигән Минжамал әби, пошкырып утырган самовар башындагы чәчәкле чәйнегенә үрелгән.

Әллә татлы жимешләрдән соң авыз тәме үзгәргәнме, әллә хужа чәйне куерак агызганмы, тустаганны иренenә тидергән бер кунак чыраен сыта:

— ...Ай, вай...

Укучыларым пырхылдап куйдылар. Үземә дә бик кызык тоелып китте бу хикәям.

— Ни өчен тәмсез пешкән әбинең чәе, укучылар, кем әйтә? Берничә кул сузылды.

— Мөслимә?

— Яфрак кына бит әле, чын чәй түгел, апа, иеме?

— Дөрес. Фоат, нәрсә дисең?

— Фабрикадан чыккач кына яфрак чын чәйгә әйләнә...

— Әйе, яле, Гөлүс ни әйтер?

— Минжамал әби бүген безнең белән шушы дәрестә утырса, чәйнегенә яфрак тутырмас иде!

— Молодец.

Ул арада кыңгырау шалтырады. Класстан кая басып, ничек чыкканымны хәтерләмим, әмма педкабинетка кайткач методистыбыз Мәсгудә апамны кочаклап үксегәнем бүгенгедәй күз алдымда.

* * *

Һәрнәрсәгә ис китеп, исле-иссез чәчәктән исереп, уймак хәтле хәсрәттән көеп, уймак чаклы бәхеткә сөенеп, дөньяны һаман шул сабый күңел белән күргән ваемсыз чаклар чигенә барды... Тау чишмәсе дә юлындагы чуерташлардан өрчелгәч, тугайлы инешкә кушылып тынып кала. Училище белән саубуллашып, путевка алган районга аяк баскач, миңа да әллә чынлап, әллә шүрләп дигәндәй, җитди төс кереп китте. Басылдым.

Мәгариф бүлеген сорап таптым. Кучкыл карт бакча эчендә искерә башлаган озынча бина. Мөдире зәңгәр постау япкан борынгы өстәл артында утыра иде. Өстендә кара китель. Урта яшьләрдә. Күзлек астыннан каравы ошамады. Әйтерсең, ул миңа «дипломын элэктергәнсең дә бит,ниндирәк укытучы булып чыгарсың әле» дигәндәй, баштан алып аякка кадәр күзе белән сөзеп чыкты. Өс-баш һәзгә кызыллык китерә торган түгел, шунадыр, иркен тоттым үземне. Урамда җәйнең чирәмнәрне көйдерә торган соңгы чилләсе торса да, аякта оек, өстә бизәксез җәйге костюм, кулымда туфлям төсендәге көрән букча. Чәчләрем дә бүгенгә тыйнак кына, җыйнак кына.

— Кыю кызга охшатып торам әле мин сезне, чынлап шулай була калса, үзегезгә райүзәктә үк бик шәп бер эш көлеп тора. Урта мәктәпкә пионер вожатые кирәк. Райкомолга шалтыратабыз, эш бетте. Буламы?

Минем әдәпле генә, чын укытучыларга охшап сабыр гына булып күренергә тырышуым секунд эчендә юкка чыкты куйды.

— Һа!

— Нәрсә, әллә...

Ачуымнан тыела алмый, сүзенә аркылы төштем.

— Булмыйм мин пионер вожатые! Нишләп булыйм мин пионер вожатые?!

Секунд эчендә күз алларым караңгыланып, күңелем тулып китте. Ничә еллар хыялымда йөргән хезмәтем белән канатланып килдем бит мин бирегә. Быел язын тагы без дә кеше булдык бит, дип дәртләнеп йөргәндә экраннарга «Авыл укытучысы» дигән фильм чыкты. Жиде тапкыр карадым мин ул фильмны, туймадым. Бөтен максатым, бөтен уем, омтылышым әнә шул Марецкая башкарган укытучыга охшау иде.

— Укытасым килә минем. Юк, абый, мин вожатый булмыйм, авылга җибәрегез мине,— дидем.

Мөдир дәшми генә алтын кысалы күзлеген салды, кулындагы каләмен өстәл читенә этәрде.

Бу минутта ул тагын да миһербансыз — теләсә кемнең теләсә нинди хыялына селтәнеп кенә карый торган ата бюрократка охшап калды.

— Анысы безнең эш, сеңелкәш. Хөкүмәт укыткан, кеше иткән, так что без кушканга әзер бул!

Шулай да бик бөгелеп төшмәдем мин аның алдында. Әйткән иде аны Рәшит абый, шундый-шундый кешеләр дә очрар, бик югалып калмагыз, дип, дөрес әйткән икән.

Әрепләштем, телләштем, сүземне сүз иттем.

— Карап карыйк алайса,— диде мөдир иптәш Сафиуллин миңа приказ сузып,— перспективасы-ние юк ул авылның, күршедәге Кәтәмгә күчеп бетә инде шушы елларны. Так что укытып тор әле шунда.

Үземә күрә хыялларым зурдан иде минем. Ягъни, мене ничегрәк итеп күз алдыма китерә идем мин авылга яңа укытучы булып барып төшүне.

Килеп урнашам, ди, мин, берзаман, уртачарак бер авылга. Урманы, тавы, чишмәләре — табигатьтән алган бирнәләре барысы да гаҗәп ди моның. Ләкин болар белән артык хозурланыр вакытым булмаска тиеш. Сугыштан соңгы еллар гына бит. Кая карама торгызу-тергезү бара. Миңа да искергән мәктәп бинасын бик әйбәтләп сиплэтергә кирәк булыр. Аннан соң җитәкчеләр күңеленә «заманча мәктәп төзер» вакыт җитте дигән оетқы салып куям?! Керешәм инде шуннан соң мөһимрәкләренә! Ата-аналар белән тыгыз элемтә, класста идеаль тәртип, югары өлгереш һәм башкалар, һәм башкалар... Нәкъ кинодагыча да, нәкъ китаптагыча.

Ә бер уйласаң, барысы да гел син уйлаганча гына булса, тормыш дигәнең гел бер төрле — хәсрәтсез, бизәксез нәрсәгә әйләнер, ә үзең шул мәнсез дөнья түренә кунаклаган бер бистә бикәсенә әверелер идең түгелме икән?..

* * *

Олы юлдан шүрләп, читкәрәк, кызгылт сыртлы тау итәгенә елышкан икән бу Болгар дигәннәре. Авыл булудан бигрәк, моңлы бер урамны хәтерләтте ул миңа.

Басу капкасы төбендә генә, мәктәп дисәң, мәктәп түгел, өй дисәң, өйлеге чамалы, түбәсе яңа, бүрәнәләре ала-кола бер йорт янында төшерделәр.

Бу түбә астында авылдагы унҗиде хуҗалыкның берсе — Мәрьям әби Мөхәммәдиева яши булып чыкты.

Әбкәй гомер буена мәктәп караган. Авыл сирәгәеп, балалар кими төшкәч, иске мәктәп бинасы белән әбинең кыйшайган йортын бер иткәннәр. Бу мәгълүматларны миңа хуҗа карчыгым самоварына ваклап шакмак тутырганда сөйләп ташлады. Нуры кача төшкән зәңгәр күзләр, яулык читеннән бүлтәеп чыккан ак чәчләр, урт тешләрсез калганлыктан батынкыраган яңаклар аның гомер буена дөнья мәшәкатьләреннән арынмавын сөйлиләр.

Үзе каядыр чыгып киткән арада өен тагын бер күздән кичереп алдым.

Дүрт почмаклы гадәти өй. Вак өлгеле тәрәзәләр. Пәрдәләр эленмәгән. Аның каравы, өйне ярты яктылыктан мәхрүм итеп тәрәзә башларын чигешле кашагалар каплаган. Сул як стена буйлап берсе өстенә берсе берничә парта өелгән. Уң якта түшәмнән идәнгә кадәр тоташ көреләп суккан чаршау төшкән. Монысы инде мәктәпне шәхси дөньядан — икенче яктан аерып торучы нәрсә, янәсе.

Менә сиңа мәктәп, менә сиңа фатир...

Без төне буе, Мәрьям әбинең үзе әйткәндәй, бырдыр-бырдыр сөйләшеп чыктык. Аның теле гаҗәп кызык. Ишетелеп онытылган, китаплардан төшеп калган әллә никадәр «мәрхүм» сүзләрне искә төшерә. Кеше тансыклаганмы, сөйләшергә юмарт булып чыкты.

Башта авылга «кыскача күзәтү ясады».

— Әткәй мәрхүм, җаны җәннәттә булсын, сүли торганые, безнең авыл ни җитте авыл түгел, безнең бабайлар саланыкылар түгел, каланыкылар дип. Иллә мәгәр, аларның берсен дә бу якка хат артыннан хат, ат артыннан ат җибәртеп алдырмаганнар. Нужа бабаң мәҗбүр иткән. Казан артындамы, Казан катындамы, исәр кеше әйткәндәй, укыган кеше сез, беләсездер инде, шәһәри Болгар булган, ди. Аның хәрабәләре хәзер дә ята ди әле, хак булса. Менә шунда бер заман ходаның хикмәтле бәндәләре яшәгән. Җиргә типсәләр, чишмә атылып чыккан. Җаннары кура җиләге теләсә, сәке астын гына ачканнар. Шунда пешеп утыра икән ходаның бакча нигъмәтләре. Әнә безнең ындыр артында гына кеше сөйми бер үзе яши торган тик тормас телле Мәликә бар.

Син килгәнне шәйләми калгандыр, күрерсен, ишетү белән йомыш табып, кер бәләге сорап булса да керми калмас. Әлеге дә баягы менә шул Мәликәнен, аның сүзенен тулыгы да юк инде, Сакмар суына сәнәк белән яза торган нәрсә, шул якта чыбык очы-тал башы бер тумачасы бар, имеш. Изге авызга яна аш — яшелчә-мазар өлгерер алдыннан өшәнчекләрен төйнәп бер урап кайта шул тирәләрне. Күп йөреп, күпне күргәнгәдер — кушаматы да үзенә күрә. Мосафир Мәликә диләр. Менә шул, бер заман теге изге бәндәләр тибеп тишкән чишмәдән түгә-чәчә бер хушбуй шешә су алып кайта. Яшь бәрәнге житкәч, яшел кыяр авыз иткәч, халык арасында бер кизү булып ала, кемнен башы, кемнен эче дигәндәй... Менә шунда китә инде Мәликә тутанның эшләре хутка. Пунктка төшәргә иренгәне, минем күк наданы таптый башлый монын тупсасын. Шулай итеп, хушбуй шешәсендә генә кайткан өч тамчы су бик бәрәкәтле булып чыга, эчәргә дә житә, коенырга да. Яхшы атланам дип, тфү, тфү, шул хәтле кыланмам, анын гөнаһысын кая куярмын, ди. Шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, әллә кайларга кереп киттем, нәрсә сөйли идем әле, кызым?

— Бабайлар һәм Болгар дәүләте...

— Ә-э, ие, ие, менә шул шәһәри Болгари өстенә бер мәлне кара яу килгән. Коелган кан, кырылган жан, мин сина әйтим. Шул афәтләрдән соң, исән-имин калганнар, жан кыелган жирдә барыбер мантып булмас дип, төрлесе төрле якка таралганнар. Бер-икесе менә шушында килеп төпләнгән. Авылның Болгар дип аталуын бабайлар да шулай жад итәләрие.

Мин килеп төшкән елларны да, ходавәндә, олы иде әле безнен сала. Хәзер генә рәте-чираты бетте. Карт-коры гүр иясе була бара, яшь-жилбәзәк адәм рәтле жирне чамалый. Авыл сәвите, контор ишесе барысы да, басу капкасыннан кергәндә искәргәндин микән, күренеп торган Көтәм авылында. Айры-чайры яшәгәнче дип, йорт ихатасынын янасын шунда илтеп сала халык.

Аннан сон әби үз зарына күчте.

— Язмыштан узмыш юк ди, хактыр. Менә картайган көнемдә ялгызак башым утырып калдым бит әле. Нича әйтсән дә бер балык башы, һаман шул сугыш кәсафәте инде.

— Бабай да кайтмадымы?..

— Һии, ана тагын. Китеп үлсә, ичмасам, түш киереп, солдаткы булып йөрер ием. Тфү, тфү, сүзем көфер килмәгәе. Алмадылар. Туксак ул. Ятим калган солдаткыларнын да төрлесе бар, кызым, бик тә сабырлары, әнә Миннулла Фатыймасы ишеләр, бик тә тәүфикълылары бар, әнә Ибрай Хөббиләре. Ара-тирә үзен тыя алмастай ажгырып торганнары да очрый. Иләндерде шундыйрак бернәрсә абзанны. Утыз биш ел торганыек бит. Бала-чага тапмадым. Калдым бит утырып... Сугыш кәсафәте тиде инде. Шул чаклы газиз жаннар кырылмаса, минем горәбәмә кем карарые...

Әбкәйне эчтән бик жәлләсәм дә, тыштан сер бирмим, шуны телгә алып торуына исем китә.

— И, анын ише ир. Котылгансыз гына сез аннан. Менә шул!

Әби кеткелдн:

— И-и, май чүлмәгенен тышыннан билгеле, диләр. Укымышлы шул син, кызым. Күренеп тора. Бәгырьгә үтә сүзен.

Һаман шул сүз дигәнен инде. Әйләнә-тулгана торгач, минем тарафларга да борылып куйды. Сорау өстенә сорау биреп, жавабымны бишкә бүлеп минем хәлләр белән дә мәгълүматланды әбкәй. Күнеле йомшарып киттеме, өй бөркү булса да, яныма юрган китереп салды.

— Тан алдыннан тундырып ала... бөркәнерсен, бәбкәм.

Урынына барып яткач, тагын бер уфырып куйды.

— Беркемнең дә хәсрәт савытлары буш тормый шул. Бигрәк яшьли ятим калгансың икән. Әйдә, хәзер кеше булгансың инде, әҗерен күр. Ярый, бабаң торган әле. Яшь әбиеңне әйтәм, бик какмадымы, үги итмиме...

Күзләр көрмәкләнгән, йокы татысы кергән иде. Сорауларын ишетмәмешкә салыштым.

* * *

Ниһаять, килеп житте бу көн! Өлкәннәр теле белән әйткәндә, кеше булып аякка баскан көн бит инде бу.

Хәтәр бит ул хәтер дигәнең. Күпме исемнәр онытыла, ә шулар арасыннан берәүгә — исәнме ул, үлеме, синекеме ул, башканыкымы — гомерең буе дәшәсең. Шундый онытылмас көннәр дә була. Күпме вакыйгалар үтә, күпме сөенеч-көенеч кичергән буласың, ә шул көнең гомерең буе үзеңә ияреп йөри. Шул көннәремнең берсе иде бу көн.

Әбкәй көтү чыкканчы ук торды. Идәнгә тамызмый гына комганына казаннан жылы су салды да аяк башларына гына басып тышка чыгып китте. Мине «йокласын әле», ди янәсе. Апагыз күптән уяу инде. Әллә кайларга таралган уйларымны жыя алмый ятам.

Күз алдыма классташларым килә. Факиһә, Мөслимә, Гөлсинә, Нина, Сания. Нәрсә кыланып йөргән булалар икән, читтән генә карап торасы иде үзләрен. Бер генә вакытны икән бергә чаклар. Таралыштык. Факиһә — Зәйдә, Нина Себергә үк китте, Мөслимә — Минзәләдә... Алар, ичмасам, шаулап торган мәктәпләрдәдер. Ә минем... Дүрт класска жиде балам бар. Күңелгә кояшлы яңгыр тама сыман. Бер көләсе, бер елыйсы килә.

Сизелми дә үтте өч атна... Минем мәктәп Көтәм жидееллыгына карый. Барып танышып кайттым. Директор яшел гимнастеркасын да салмаган әле. Уң жиңе буш... Сүзгә саран тоелса да, әйткәне йөрәккә ята торган. Коллектив яшь. Берничә күз ятсынып, бер-икесе кызыксынып карады. Иң истә калганы — укыту бүлеге мөдире Камал апа. Күрү белән яраттым. Әллә кай төше мәхәббәтле. Елмайганда түгәрәк ай йөзе балкып китә. Калын чәчләрен үргә тараган. Кершәндәй ак блуза өстеннән юбкасы төсле зәңгәр джемпер кигән. Сокландыргыч пөхтә, игътибарлы.

— Кыен чакларда яныбызга кил,— диде ул, мине болдырга чаклы озата чыгып,— ә-ә-әнә, күрәсеңме теге купшы йортны? — диде шау бакча эчендә утырган кызыл калай түбәле йортка төртеп,— шуны үткәч, өченче өй безнеке. Яңа чагың, ямансу чагың, килеп чык. Яратам мин яшьләрне.

Кешене сабыр гына тыңлый белә, үзенекен өздереп әйтә. Менә нинди икән Камал апа. Нигәдер бик уңайсызланам мин якын иткән кешеләремнән. Каушап калдым, шулай да күңел тулып, рәхәт булып китте.

* * *

Мәктәп дигәнебезгә, Мәрьям әби әйткәндәй, бераз кот кунды. Кашагалар урынына пәрдәләр элдек. Сап-сары нарат такталардан бүлмә койдырдык. Шулай итеп, кызыл чаршау да «отставкага» чыкты. Минем бик эчне пошырып торса да, үзенә күрә әбкәйнең яшьлек истәлекләрен сеңдергән кыз чак мирасы булып чыкты әле чаршау. Ул аны шәмле кичләрдә эрләгән, өй уртасына киндер станы корып суккан, чуенда кайнатып манган, тегәрҗеп саплап кул белән теккән.

— Килен булып төшкәндә өшәнчекләремдәге иң затлы мал шушы иде,— диде ул дымлы күзләрен алъяпкыч итәге белән уып,— зофаф кичәбезгә дә шушы чаршау шаһит...

Үзе, ник әйткәненә үкенгәндәй, тотлыгып калды, кызарып кече якка борылды. Миңа калса, ул чакта «зофаф»ның нәрсә икәнен ишеткән юк иде әле. Шулай итеп, без бу уникаль чүпрәкне әйбәтләп төрдек тә, нафталинлы сандыкка салып, богау йозакны чатлатып куйдык.

Әбкәй: «Хәләл көчеңне әрәм итмәсәнә, барыбер кырык мир таптасы, ярамаган шунда сулап сөртсән», дип сөйләнеп йөрде, мин үземчә эшләдем. Шаулап торган селтеле суга бер гөнҗәлә яна мунчала салдым да идәнне шыбырдатып суладым. Басып ышкыдым. Корытып сөрттем. Сайгаклар, баскычлар сары гәрәбәдәй ялт иттеләр, өйдә яңа юкә исе, камышлы күл исе аңкыды.

— Бүгеннән алып, аяк киемнәре тупса артында кала,— дидем әбинең куньчлы галошын өйалдына чыгарып, ата-аналарның барысына да өлгеләр кисеп өләштем. Балалар класска чүпрәк башмактан йөриячәкләр.

Алты гына тулып узган. Ян тәрәзәгә баксам, ни күрим... Язны көтми очып килгән тургайлармыни... Инде берничәсе капка төбендәге өянке астында. Балалар!

Хуш киләсез, дусларым! Бер тустаган сөтле чәйне көчләп эчтем, тамакка бармый, үзем дә сабыйларым сыман кабаланам, каядыр ашыгам.

Беренче звонок! Беренче дәрес! Беренче кыенлыклар, беренче кызыклар!

Җиде бөртек — үзе бер мәктәп! Әнә үзләре — барысы да каршымда. Авыздан чыккан бер сүзне йотып алырдай булып миңа төбәлгәннәр. Парта саен бер класс. Беренче рәттә беренче классым — сипкелгә коенган Ниязым утыра. Икенче рәттә — икенчеләр. Боларына укучылар дип дәшәргә дә була, ичмасам, алар икәү. Бригадир кызы — кара кыз Сәгъдия белән күрше малай «ут чәч» Шамил. Арттагы партада мәктәптәге бердәнбер этиле малай Мәгъсүмем. Хәер, балаларым бар да танышлар, мин аларны килгән көннәрне үк барлап чыктым инде.

Дәрес башладык. Ышанасы килми. Бөтен мәктәп гел үз кулыма тапшырылган. Тулы мөстәкыйльлек. Һәр адымыңны үлчәп, һәр сүзеңне анализлап утыручылары юк инде!

Икенчеләремдә — матур язу. Өченчеләр мәсьәлә чишәләр. Тып-тын. Сирәк кенә пышылдаган яки шакылдап каләм тәгәрәгән тавышлар гына ишетелгәләп куя. Нәкъ шул чак Мәрьям апабыз дүрт классның дүрт дәресен урталай бүлмәсенме.

— Хәмидә, анаң печәнгә төшкәнче үк әбәт чиләген алып киткәнне. Сыер бозауларга йөри, иртәгә бер уңайдан тота кил әле.

Аптырап калдым. Каян килде бу тавыш, кая соң әле ул үзе? Кыңгырау шалтырар алдыннан гына өс-баш алыштырып каядыр чыгып киткән сыман иде ич... Аңлашылды. Борылып карарга яхшы түгел. Балалар алдында кисәтү килешмәс.

Гадәттә, татар өендә мич башына кече яктан казан артлап менешле. Ә боларның, нигәдер ул олы якка карый. Әбкәй шунда үрмәләгән икән. Җайлап кына ястыгына янтайган да дәресебезне тамаша кылып яткан көне.

Шамилне тапкырлаулар җәдүәле сөйләргә бастырган идем, мич башы тагын «телгә килде»:

— Томана зирәк, бу кадәр әбиеңә охшарсың икән. Алты алтың унике бит инде, шуны дә белмәскә.

Балалар чыдый алмыйлар. Китапларына капланып кеткелдиләр.

Ничек итсәм иттем, тәнәфескә кадәр түздем.

Соңыннан хәтере калды хуҗабикәмнең. Ипләп кенә төште дә, кая барасын әйтми-нитми, юкка чыкты.

Шулай итеп, беренче көн балалардан бигрәк әбкәйне көйләп узды.

Атна да узды, ай да сизелми үтте. Тормыш сыманым да әкренләп көйгә салына бара. Иртән дәрес, төштән соң дәфтәр тикшерү, кичен җәмәгать эшләре... Ут алуга газета-журнал килә. Эш күп, ямансылар вакыт юк кебек. Шулай да күңел үги, кемнедер юксына, беренче тәэсирләрне кем беләндер уртаклашасы килә. Каникулда бабай янына кайтмый булмас. Кызлар хат язган булырга тиешләр.

Чынлап та, кемнәндер хат көтәсе, җылы сүз ишетәсе, кемнедер үпкәләтәсе, кемгәдер үпкәлисе иде лә...

Нәкъ шул чакта истә тагын теге студент... Адресы да ике генә сүзлек: КГУ, Фалихову...

Язам әле!

Кыек сызыклы, кызыл кырыйлы бер табак кәгазьне алдыма җәеп салдым да уйга калдым. Ни дип башларга?

Каллиграфия кагыйдәләренә керә-чыга бик матурлап исемен язып куйдым: «Камил!»

Аннан соң шактый уйлангач, төчеләнми-нитми салкын гына сәлам әйттем. Вакытында җавап язмавым өчен нәзакәтле итеп гафу үтенгән булдым. Болай гына, форма өчен генә. Соңыннан чәчрәп торган зур хәрефләр белән өтерен, нокгасын калдырмый адресымны яздым.

Нәкъ бер атна дигәндә, миңа килеп төшмәсенме бер хат! Куануымны күрсәгез! Алай да ачарга ашыкмыйм. Бар көткәннәрем якты төшеп бозылган фотопленкадай юкка чыгар кебек.

Ләкин киресенчә булды. Авылдан, бабайдан, дуслардан, каламнан еракта, таулар артындагы кечкенә бер авылда ямансу көннәр кичерүче Назира апагыз өчен бик кадерле хәбәр булды бу хат!

Шулай итеп минем күңелемдә ерак та, якын да, акыллы да, шаян да өр-яңа Камил туды.

«Саумы, Камил!»

Икенче хатымны шулай башладым. Мин аны көндезен күңелдән берничә мәртәбә язган идем инде. Менә хәзер кәгазьгә күчерәм.

Кем соң син, Камил?! Дустыммы, егетемме, сердәшемме, туганыммы?.. Белмим. Тик шунысы бәхәссез — бу минутта син мине аңлый торган бердәнбер кешесең. Боларын ук хатка язмадым. Күңелдәгеннең барысын да түгәргә ярамый. Хәтта бик якыныңа да. Әмма бу юлы сүз сайлап, фикер үлчәп тормадым, әйтәсе килгәннең барысын да җайлап тездем. Сорауларына кайта-кайта җавап бирдем. Чөнки чын күңелдән язылган, үзенә тарта торган ягымлы иде аның хаты.

Тарихчы булуын истә тотып, авылның әби авызыннан ишеткән легендасын да яздым, күләмен дә әйттем, табигатен дә тасвирладым. Класста күпме укучым бар, нәрсә җитми, нәрсә бар — барысын да сыйдырдым шул конвертка.

Ихтыяры, шыр тиле дисә дә, гаҗәпләнмим. Кеше хисләрен төшенми торган, романтикадан мәхрүм бәндәләр азмыни. Камил аларга охшамаган. Камил башка кебек. Соңыннан «Зирәк фикерләр альбомым»нан бер өзек күчердем: «...Беренче кыенлыклар түземлек сорый — чыныгуның бер төре. Тормыш чыдамнар белән көрәшә. Көрәшә белү — яши белү ул». Миңа бик ошаган иде бу фикер. Камилнең күңел дәфтәрен баетам, янәсе. Ул да язып куйсын...

* * *

«...Очрар әле алар, күңеленне кин тот,— дип язды Камил өченче хатында...— Ләкин шуны бел, алар берсе дә күзгә күренеп, хәбәр биреп килми. Авырлык, кыенлык — кешенең гомерлек юлдашы. «Һәр тереклек нясе — көрәш нәтиҗәсе...» дигән Белинский. Син аны үзен дә сизмисең,

очраганын таптап, жимереп барасын. Ә менә әз генә йомшардын, башынны иден, түбәнәйденме, яки, киресенчә, үзенне башкалардан өстенрәк хис итеп ашыгып үрелденме, менә шунда инде ул үзен сиздертә башлый. Ул — нәкъ вируслы авыру кебек. Үзенә шундый жирлек таптымы, үрчи, котырына башлый. Аның белән көрәшә белү өчен физик яктан гына түгел, рухи яктан да, Кеше буларак та пакь, сәламәт булырга кирәк...

...Син бу юлларны китаптан эзләмә. Минем блокнотымда алар. Профессор Исмәгыйловны тынлаганда күчереп алынган».

Күпме китап укыйсын, никадәр гыйбрәт ишетәсен, гажәп тирән мәгънәле мәкальләр беләсен. Ә менә үзен шуларга дучар булдынмы, барысы да онытыла. Камилнең бу фикерләрен мин ул чакта сокланып, исләрем китеп укыган идем. Нәкъ кирәк чагында мин аларны... файдаланмадым. Акыл белән акрынлап түгел, мин-минлек белән минутында жиңмәкче булдым мин ул авырлыкларны. Ә бу миңа гына түгел, үз максаты өчен генә көрәшүчеләрнең шактыена хас.

Максатым минем күз ачып йомганчы бик яхшы укытучы булып танылу иде. Дөресен әйткәндә, мин моңа һич икеләнмичә ышана идем. Училищега тоткарлыксыз кердем һәм бик жиңел тәмамладым. Кулымда — яраткан хезмәтем. Мактала да башладым. Кәтәмдәге жидееллык укытучысы Камал апа аркамнан сөеп китте. Ишетүемчә, педсоветта минем бер дәресемне үрнәк итеп сөйләгән, ди.

Әбкәйгә нияләндем. Ул мине үз кызыдай иркәләп тота. Урамга чыксам, олылап сәлам бирәләр. Акыллыга санап киңәшкә киләләр. Шуның өстенә кызыклы хатлар... Алар мине назлый да, рухландыра да. (Һәм, әйтим әле, Камилнең кешеләр күңеленә зәге энжеләрне таный торган сизгер, кимчелекне фаш итә торган аяусыз кеше икәнен шул чактагы хатларыннан ук тоеп була иде.) Хатлар — кеше күңеленә телескоп. Кайчан гына язылмасын, кемгә генә адресланмасын — авторның акылын, холкын, гыйлемен, кыскасы, кемлеген сөйләп тора. Менә шуны сизенептер, мин ана көннән-көн якыная, көннән-көн ачыла бардым. Нинди шатлыгым бар — тотам да язам, нинди кайгым бар — зарланам.

Нинди генә хатлар озатмыйм мин ана: кайсын бандероль итеп салам, кайчак өч кенә сүз белән дә китә, еш кына күңдәлекләремне адреслыйм.

* * *

Көзге эче жил, тәрәзәм форточкасына үрелеп, кыштыр-кыштыр аңа адресланган хатларны актара. Укымый торсын әле. Тәрәзәмне ябыйм. Мин аларның өченче берәүгә ирешүен теләмим. Сердәшләр өчәү булмый. Күңелен түгәргә торган ашкынчак кешеләр өчен унау да күп түгел, әмма хакыйкать бар. Гадәттә, аларның өченчесе... бик үк ышанычлы түгел...

Сер дигәнең дә төрлечә бит ул. Унжиде яшьлек егет яки кыз үзенең беренче мәхәббәтен, ганлә кешесе үзенең кече яктагы кашыгаяк шалтыравын, фән дөньясына үрмәләүче үзен бүген я иртәгә галим итәчәк «ачышын», берәү шатлыгын, берәү зарын сергә саный. Әгәр син ул уңышыңны яки зарыңны ике-өч кеше белән бүлешсәң, мактанчык яки елак димәсләрме? Димәсләр. Мин аларны сиңа гына сөйлим, Камил.

Сөйгән эшең — сөйгән кешең кебек бит ул. Яраткан кешеңнең сиңа таба атлаган бер адымы, сиңа карап елмайган бер елмаюы үзе әллә ни, үзе бер вакыйга. Яраткан эшеңдә дә кечкенә генә уңай борылыш, бер генә атлам алга китеш тә шундый олы сөенеч ич! Мин шуларны уртаклашам синең белән.

«...Бүген беренче карлар оча, Камил! Авылда аны кырпак төшү генә диләр. Балаларга инде Кыш бабай килгән. Ишек катыбызга кайсы ак, кайсы кара кеп-кечкенә итекләр тезелгән...

Тиздән, тиздән кыш! Рәхәтләнеп карда ауный-ауный чаңгы-чана шуасылары бар әле! Без (сигезенчесе үзем) быел армый-иренми спорт белән шөгыльләнергә сүз бирдек. Ишек алдыбызда турник бар. Кәрим абый ясап куйды. Тәнәфестә, физкультура дәресләрендә зырылдыйбыз гына шунда. Атынчык көйләдек. (Кеше күрмәгәндә, кичләрен үзем дә атынам.) Чалбар кигәч, танымыйлар. Кем белә, бәлки, киләчәк дөнья чемпионы шушы мәктәптә укып йөридер.

...Их, Камил! Син безнең класска бер генә күз салсаң иде. Үзгәрделәр, матурландылар балалар. Кызларның чәчләрен үземчә үрдертәм. Баш түбәләренә ал, кызыл, зәңгәр күбәләкләр кунды. Галиянең сыңар алкасын салдырттым. Сәгъдиянең дә, көйләп-җайлап, сәйлән муенсасын чиштердек. Бәби итәкле күлмәкләр кыскарды, җыйнакланды. Ә малайларны... Укытучы башым белән кесә тентергә базмадым, дежурга тапшырдым. Нәтиҗәсе әйбәт, рогатка, пәке ише нәрсәләрне «саклау камераларына» куйдык.

* * *

Бу көн иртәгә үк Ниязның исеннән чыгачак. Ә мин аны тиз генә онытмам әле.

Каядыр борылган арада берсе тактага язган: «Тынычлык». Карыйм, карыйм, аңлый алмыйм. Укучыларымның кулъязмаларын әллә каян таныйм, ә моны ят кул язган дип тә булмый. «Т» хәрефенең элементы минеке төсле сызык кына, «ч» се дә ни «ч» түгел, ни «г» түгел, минемчә, «ыргак»лап кына җибәргән.

— Укучылар,— мин әйтәм,— кайсыгыз язды тактага?

Дәшмиләр. Ниязым гына гаепле кешедәй башын түбән игән.

— Нияз, күтәр башыңны. Бу синең эш,— мин әйтәм.

Ул тагын да сеңә төшә.

— Сөен,— мин әйтәм,— кара тактага ак эз салган көнең, беренче мәртәбә язу язган көнең булыр бу!

Сөртмәдек без бүген бу язуны. Нияз тынычлык теле икән — әйдә тели бирсен! Изге теләкләрне чикләү юк.

Дәрестән соң озак уйландым. Беренчедән, үзенә күрә бер бәйрәм иде бу көн минем өчен. Беренче мәртәбә минем беренче классым хәрефләргә хәреф ялгады. Икенчедән, шуны тойдым: синең һәр гадәтең — киемең, үзеңне тотышың, хәтта кулъязмаңа кадәр укучыларыңа йога бара. Матур язудан керүче укытучымның рәнҗешләре төшә башлады. Ялгышымны икенче кеше кабатлый. Көн саен бер сабак. Үзем өйрәтәм, үзем өйрәнәм... Бүген дәрестән соң каллиграфия дәреслеге алып хәрефләр тезеп утырдым. Камил, дөресен әйт әле, минем бүгенге язмам элеккеләреннән аерыламы? Билге куеп җибәр!»

* * *

«...Камил, бүген сиңа язасы килгән яңалыгым шул, ата-аналар җыелышы үткәрдек. Советка яңа председатель сайладык. Элеккесе акламады... Сайлый белмәгәнбез. Озак хәзерләндек моңысына. Беренче тәэсир онытылмый, ди. Оныттырасы иде шуны.

Туплар тавышы тынганга өченче ел китсә дә, яралар һаман әрнеп куйгалый. Бөтен мәктәпкә бер әти... Ярый әле, ул бар. Мәгъсүм дә ятим булса, без ата-аналар җыелышын, мөгаен, башкача дияр идек...

Мәгъсүмнең этисе Хисам абый сугыш сөремендә ысланып, каны саркып, холкы бозылып кайткан. Шулай да ул үзенең нечкә күңелләлеген җуймаган әле. Мин аның генерал Конев белән очрашкан орденлы очучы икәнен ишеткән идем инде.

Озын буйлы, чырае тутлы, һәрчак җитди, сүзсез кеше ул. Кыенсынып кына барып кергән идем, үз итеп, елмаеп каршылады.

— Әйдәгез, әйдәгез, күптән кергәнегез юк.

Күренеп тора, культура күргән, дөньяны айкаган кеше. Каршыма ике кулын күтәреп басты, пальтогызны салдырыйм дию инде.

— Юк, юк, Хисам абый, мин әйтәм, бер-ике минутка кинәшләшим дип кенә кердем иде.

— Алайса утырып сөйләшик, рәхим итегез.

— Без ата-аналар җыелышы үткәрмәкче идек. Белгәнегезчә, күпчелек аналар сугышта тол калганнар. Күңелләре бөтен түгел. Шуларны ятим иткән фашист урдасын ничек кырдыгыз — шул хакта фронт тормышыннан бер эпизод сөйләмәссезме икән.

Мин бу сүзләрне сөйләргә алдан хәзерләнеп барган идем, шуңардыр декламация укыган сыманрак килеп чыкты.

Аңладыгыз микән инде дигән сыманрак, уңайсызланып кына күзләренә карадым. Абый җитди иде.

— Ярар, уйлармын,— диде бер минут тынып торгач, кашларын җыерган килеш.

Һәм ул җыелышка беренче булып килде...»

Каләмемне куеп тордым. Камилгә барысын да энәсеннән җебенә кадәр тезү кирәкмидер. Ә үзем хатта сөйләнгән вакыйгалардан арынмыйм. Яңадан бер-бер артлы күз алдына киләләр. Хисам абый артыннан ишектә Ниязның әнисе күренде. Мамык шәленә уранган. Бигрәк тә яшь әле ул. Апа диярга уңайсыз. Унсигездә тол калган... Гөлниса апа миңа бүген бик чибәрләнгәндәй тоелды. Бит алмалары мәк чәчәгедәй ут янып тора. Озын керфекләреннән күгелҗем күләгә төшеп сөрмәләнгән күзләре куе зәңгәрләр. Кашларына каләм тисә дә «буялдым» дип чекерәеп тормый.

Аның артыннан ук тып итеп Мөнир килеп керде. Шома гына кырынган, култыгына аккордеонын кыстырган. Бер ай элек кенә армиядән кайтты әле ул. Мин аны музыкант итеп, балалар концертын алып барырга чакырган идем. Иртәрәк килгән. Ай, тартынып киттем... Башкаларга сиздерми генә Гөлниса апа белән гармунчының күзләре очрашты. Мин аларның бу карашында икесенә генә хас гаҗәеп якынлык, әчке бер сөенеч, шигърият сиздем. Шунда колагыма чалынып киткән бер әйбәт «гайбәт» искә төште. Шушы гармунчы дигәнебез Гөлниса апаны «чиртергә» йөри, имеш. Тик арада киртә бар, әнисенең яшь эти алып кайтуына малай карышып маташа, ди. Кара син аны, Ниязны әйтәм, мәктәптә мыштым гына утыра торган малай, өендә хуҗа булып, әнисенең язмышын хәл итмәкче... Бер караганда, я, кай ягы белән ким безнең Гөлниса апа кызлардан... Сыерлар сава ул. Фермаларына төшсәм, күземне алмыйм мин аннан. Халатына кадәр гәүдәсенә ятышлы. Уңганлык дисәң уңганлыгы, матурлык дисәң матурлыгы бар. Яратылыр, назланыр чагы гына. Мәхәббәтләре уртак булса, хак булса, Нияз белән сөйләшеп карыйм әле. Икәүдән икәү калып кына... иплән кенә. Бик тирәнгә үрмәләү булмаса, үзем кыен хәлгә калмасам. Югыйсә, укытучы дигәнең баланың күзенә күренеп, теленә кереп кенә түгел, йөрәгендә дә урын алырга тиеш бит... Монысы — методистыбыз Хөрия апа сүзе.

Кара тар юбка белән хәтфә пинҗәк кигән бригадир килеп җитте. Әнекәем генә! Бу кадәр дә әнисе төсле булыр икән Сәгъдия. Икесенең дә кашлары дугалы. Яңаклары елмайган сөен бата, уйнаклый, чәчләре зәңгәрләнеп торган каралар...

Ялындырып, көттереп, ниһаять, килеп беттеләр. Вакытның кадерен белмәүчеләр дә бар бит.

Сүзне шуннан башладым.

Чакырылган вакытка килмәү — вәгъдәсезлек. Бу иптәшләреңне санга сукмау дигән сүз. Мин моны хәтерләрен саклап, җайлап кына аңлатырга тырыштым. Үтемлерәк булсын өчен мисал китергән булдым, заяга үткән, әрәмгә очкан бер сәгать вакыт эчендә нәрсәләр эшләргә булыр иде — шуның бәһасен әйттем. Кешенең менә шундый кыйммәтле минутларын әрәм итүе оят эш ул, дидем.

Кайчак әнә шундый, зарарлы булса да гадәткә кереп киткән мәсьәләләрне бер ачыклык кертеп үз телең белеп мисал өстендә чишү бик тәэсирле була. Мин моның шулай икәнен соңгаручыларымның йөзләреннән үк күрдем. Димәк, икенче җыелышлар алдыннан алар моны исләренә төшерәчәкләр...

Уйларга чумганмын, күрәсең. Күкеле сәгать күкелди башлауга сискәнеп киттем. Яза башлаган хатымны алдыма кыеклап салдым да дәвам иттем.

«...Өченче көн тәртибе, чынлап та, бик тәэсирле булды, Камил. Тын алмый тыңладык без Хисам абыйны. Сүз бирелүгә плащын салып җибәрсә (юри киеп утырган), күзләр чагылып китте. Түше тулы җем-җем... Иң нурлысы Беренче дәрәҗәдәге Бөек Ватан сугышы ордены. Кешеләргә нур бирим дип йөрәгеннән ут кабызган Данконы хәтерләтте ул миңа. Без аның әнә шул орденга лаек булган онытылмас истәлеген сөйләттек. Дүртенчеләргә Бөек Ватан сугышы темасы өченче чиректә керә. Шунда файдаланырмын дим, кызыклырак урыннарын язып бардым. Бер очрашкач укырмын, яме...

Шунысы кызык, Камил, Хисам абый безгә бер үзе ничә фашистны дөмектергән, бер үзе ничә бомба ташлаганын әйтмәде. Без дошманны бергәләп кырдык, бергәләп дөмектердек, бергәләп җиңдек, тик бергәләп кенә кайтып булмады, ди. Кемнәр ул «без»? дигән сорауга — әтиләрегез, авылдашларым — исәннәр һәм корбаннар дигән җавап алдык.

Күрсәгез иде сез шунда аналарны... дошманны үз куллары белән тукмагандай, йодрыкларын йомарлап, күкрәк киереп батыраеп утырдылар.

— Рәхмәт, Хисам туган,— диде Галиянең анасы Мәрхәбә апа,— үчне ачуны басып кайттыгыз, ичмасам.

— Кеше каны җирдә ятмый, газизләребез каны тоткандыр,— диде Әдипнең әнисе Салиха түтәй.

Бер тавыштан героебызны ата-аналар советы председателе иттек.

— Риза мин,— диде Хисам абый сабыр гына.— Кемгә нәрсә, минем өлешкә исән-сау кайту чыккан. Шуның кадерен белергә кирәктер. Кулдан килгән кадәр тырышырмын. Үзегез дә үз итегез, балаларыгыз эти итеп карасыннар. Көй килгәндә кеше мин. Катылансам, йомшартырсыз. Холыкны бозды сугыш.

* * *

...Хатымны әле дәвам итәм, Камил. Календарь инде икенче сан күрсәтә. Ә мин һаман синең белән сөйләшәм.

Икенче көнне класста ниндидер үзгәреш сизеп торам. Балалар бәйрәмчәрәк киенеп килгәннәр. Үзләре җитдиләр. Өчле алучы булмады. Чатлатып җавап бирәләр. Мәгъсүмем балаларны почмакка җыйган да нидер сөйли. Тынланам. Бөек Ватан сугышы орденнары мирас булып геройларның улларына күчә икән! Ул шуны сөйли... Ә мин аны әнә шундый этигә, шундый орденга лаеклы малай итеп тәрбияли алырмынмы? Җаваплылык арткannан-арта бара.

Тәнәфес булдымы, янымда Нияз чуала... Читләтеп кенә телен ачам. Кулмәк сәдәфен бора-бора колагыма пышылдый:

— Апа, апа, минем әтием сугышка Мәгъсүмнең атасы белән бер көнне киткән булган. Хисам абыйдан сорагыз әнә...

Тамак төбемә төен тыгылды. Бала алдында үксеп җибәрә яздым.

— Юк-юк, ятимнәр өчен сугыш бетмәгән әле, бетмәгән!

И Камил, бүген үзем дә әллә нинди мин. Әйләнә-тирә тәэсиреннән качыйм дип китапка тотындым. И. Газиның «Онытылмас еллар»ы. Укыйм әле, әй.

Хәзергә хуш. Апушка миннән бераз сәлам.

Оп-озын итеп хат яз.

Ошбу хатны язучы Назира атлы кыз булыр».

* * *

«— Университет каршында әдәби түгәрәк бар дип язган идемме, иртәгә шуның киңәйтелгән утырышы. «Онытылмас еллар» романы буенча диспут! Язучы үзе дә катнашачак. Чакыру шушы. Сәгать 7 дә вестибюльдә көтәм»,— дип язды миңа Камил.

Ул үртәргә ярата. Ә мин үпкәләгәнгә сабышам. Тик тыштан гына. Үзем бик кызыгам. И, канатлы кош булып очып кына барып төшәргә. Шушы яшькә җитеп, әле минем тере язучы күргәнем юк. Үзем сер бирмим.

...Ибрай Газиларны күрәселәр алда әле,— дим эре генә. Мин дә бүген сине бер җиргә чакырам. Чынлап менә. Нурияләргә. Кем ул дисеңме? Өйләре чишмә тыкрыгы башында. Ярты сәгать срок сиңа. Бүген алтыга килеп җит. (Ә үзем хатны иртәгә генә салачакмын.)

Нурия мине кунакка, мин Камилне чакыргандай, юри шаярып кына чакырган диярсең, барып керүемә аптырап, хәтта бераз тартынып алды.

Мин моны сизмәмешкә салыштым, үз булып өсне чишенә башлагач, ачылып китте тагын.

— Кызлар, кызлар, карагыз әле, безгә кем килгән?!

Кече яктан онлы кулын алъяпкычына сөртә-сөртә Фәрдәнә килеп чыкты.

— Бәлеш, Назира!

Аның артыннан чәчен, маңгаен карлыган читле яулыкка яшергән Закирә башын тыкты.

— Әйдә, малай, бәрәңге тәкәсе ясашырга.

Нуриянең әниләре кунакка киткән, боларның аулак аш пешереп маташулары икән. Чыр-чу килеп бәләкәй генә кече якка сыеп беттек. Фәрдәнә зур гына куна тактасында җилдер-җилдер камыр баса, Закирә бәрәңге әрчи, Нурия кисәү таягы белән мич түрендә пыскып яткан кисәүләрне кыйный. Мин «елак»ка суган турарга куштылар.

Бу бәрәңге тәкәсен безнекеләр кебек тәмле итеп пешерүче кем бар икән? Кирәк булса рецебен дә язам: бәрәңгенең йомрысын, крахмаллысын гына сайлап, юка гына итеп әрчисең дә бик вак итеп турыйсың. Шуңа суган, тоз, борыч, әнис салып болгатасың да төчегә камыр басасың. Уклау белән коштабак авызы кадәр итеп бернечә җәймә җәй. Хәзер инде шул җәймәләргә берәр кушуч суганлы, әнисле бәрәңгене салып, матур итеп сырлап бөгәсең генә кала. Булдымы? Мичең бик сүрән булмаса, егерме минутта тәкәң пешә. Табага салып урталай ярып җибәр дә берәр кашык кайнар сары май сип. Хуш ис бөркеп, авызыңнан су китереп кетердәп тора. Менә хәзер рәхәтләнеп аша инде. Ит бәлешләрең бер кырыйда торсын.

Ашарга гына утыруыбыз булды, ишек шакыдылар. Биш-алты егет килеп керде. Араларында гармунчы Мөнир дә бар. Тегеләре йөрсен дә,

монысына ни калган, урап кайтсын иде ферма якларын. Минем нәрсә уйлаганны сизгәндәй, чынлап, ул кадәр озак утырмады. Бер зур тәкә ашап, бер кат биетте дә, гармунын култык астына кыстырып чыгып китте.

* * *

Чыршы бәйрәмнәре узды. Стенага яңа ел календаре менде. Урамнарда ак түмгәкләр калыкты. Суны бәкедән ташый башладык.

Ындыр артындагы Камәрияттәй Мәрьям апаның Таза Чишмәдәге сеңелесен күреп кайткан. Ямансылап торам, кышкы төннәр бик озын. Өендә калыр кешесе бар. Кул эшен алып утырмага килсен, дигән.

— Бәй, бар, апа, рәхәтләнеп ял итеп кайт,— дидем мин аңа.— Мәүлихәттәй сыерыгызны савам дип тора. Кош-кортка көрпә болгатуны ни дисең. Утын әзер. Кисеп, турап өелгән. Алып кереп ягасы гына. Башка бер эш тә юк. Ут-күздән борчылма. Анлык кына рәт беләм. Бар, апа, бар.

— Үзең дә исән-сау тор,— диде Мәрьям апа, күтәренеп чыгып киткәндә.— Урман — колак, кыр — күз булса, авылда икесе дә бар. Нуриялләр белән бик вакланма. Бетмәс андый аулак өйләр.

Аулак өй! Бу сүз мине бер мәлгә сагайтып куйса да, ишек ачып-ябылгач атылып кергән бер кочак суык шикелле, шунда ук таралып, онытылып та бетте. Әмма ишетәселәр, күрәселәр алда булган икән әле...

* * *

Авылдагы ялгызлыктан иң ямансулаган чак, әйтимме, кайчан? Кояш баеган тур, иңрәп караңгы төшкән чак. Рәссамнар кышкы кичне зәңгәргә маналар. Бүген нәкъ әнә шундый зәңгәрсу моңлы кич... Түбәле биек капкабыз эчтән бикле, ялгыз өебез кар басудан дамбага охшап калган урамнардан, авылдан, бар дөньядан аерылып торган бер крепость сымак тоела. Мондый тынлыкта ялгыз башыңа нинди генә уйлар килмәс... Кечерәеп, бөрешеп кенә унлы лампа төбендә утырам. Ак мичкә зур булып шәүләм төшкән. Учымда кулдан кулга йөреп тузып беткән Есенин шигырьләре. Берничә битен ачкач инде аннан аерылмас булдым. Ул миңа эчәргә гөнаһ саналган әчкелтем йөзем шәрабын хәтерләтә.

**Где ты, где ты, отчий дом,**<br>
**Гревший спину под бугром?**<br>
**Синий, синий мой цветок,**<br>
**Неприхоженный песок.**<br>
**Где ты, где ты, отчий дом?**

...Чү... курыкканга куш күренә диме,— капка шыгырдагандай булды. Күнелдә нниндидер шом туды. Хәмдия апа иптәшкә Гөлсинәне куна кертмәкче иде, кирәкмәс дип кыланган булдым. Укучыларым «апа куркак икән», димәсеннәр, янәсе. Ят кеше, күрәсең, келәне таба алмый... Тапты... Ачты... Япты... Тәрәзә буеннан күләгәсе үтте. Ишеккә дә җитте. Баскычка менде. Тук-тук...

Чөйдә ни бар, шуны әлдердем дә шап-шоп басып өйалдына чыктым. Ирләр тавышы чыгарам, янәсе. Тамак төбем белән генә дәшәм тегеңә.

— Кем бар?

Тез буыннарым калтырап китте. Ишек артында ирләр тавышының чып-чыны:

— Назира өйдәме?

Беркөн Нуриялләрдә миңа: «Китмә әле, утыр әле», дип ялынган, артымнан йөгереп чыккан Гайсадыр, мөгаен...

— Бу вакытта ишек ачмыйбыз, бездә йомышыгыз булса, көндез килегез.
— Юк, юк, Назира, курыкмагыз, бу мин.
— Бер әйттем бит инде. Әй, Мәрьям апа, чык әле (шүрләтәм тегене, өйдә кеше бар, янәсе), бер эрсезе ишекне вата.
— Назира, бәлки үзегез чыгып керерсез. Мин Казаннан ук...
— Ә?
— Каникулга кайтыш...
— Ә?!
— Камил генә мин!
— Ә?!
Ишекне ничек ачып, өйгә ничек атылып кергәнемне хәтерләмим. Берничә секундтан соң, беребез кече яктан башын тыгып, икенчебез ишек катында аптыраган килеш шаккатышып карашып тора идек.

Гәүдәсе... Шаляпинмыни... Каян килгән диген Себер малаена Есенинныкыдай калын салам чәч. Каш, борын, колак җәһәтләре болай әллә ни түгел түгелгә, әмма уртачадан шәбрәк. Кыскасы, бер күрүдә күңелдә кала торган сөйкемле чырай.

...Менә син нинди икән...
— Ә мин сине, Назира, икенче төрле итеп күз алдыма китерә идем.
— Мәсәлән?
— Күз чагыла торган итеп, дию пәриләреннән урлата торган йолдыз күзле, ай маңгайлы әкият кызы итеп.
— Соң...
— Соң шул, җир кызы булып, чын Назира булып чыктың. Толымнарың да, усаллыгың да, хәйләкәрлегең дә — барысы да үзеңнеке! — Хәзер син әйт?
— Минме? Мин сине Жерар Филипп белән игезәк бер кешедер дип уйлый идем.
— Соң?
— Соң шул, ул — Парижда кинога төшеп йөри, ә син төнлә кеше өркетеп әкият кызы эзләп килгәнсең.
Камил шаркылдап көлде. Ул берниндн каһкаһәсез (Тукайдан откан сүзем), эчкерсез, рәхәтләнеп көлә белә икән. Башын артка ташлый, күзләре яна, сөйкемлеләнә.

Нәрсә карап торам мин... Кунагым туңгандыр, ачыккандыр. Сүрелеп килгән мичне кисәү агачы белән шалтыратып тараттым да бәрәңге тәгәрәттем, дыңгылдатып самовар куйдым. Утлы күмер салгач, минутта кайнап чыкты. Өстәлгә аны-моны утырткач, уйлап алдым: тагын нәрсә бар әле безнең?.. Ә-э, сайгакны күтәреп базга төшеп киттем. Аннан касә белән варенье күтәреп чыгуыма, өстәлгә Казан күчтәнәчләре кунган. Мич авызыннан өрә-өрә бер коштабак кап-кайнар бәрәңге күтәреп чыккач, Камил балалар кебек кулларын «чәбәкәй»ләде.

— ...И бәрәңге! Син күренгәч әүвәле күренешкә чит, (Мин дә кушылдым)
Шаулады күргәч сине барлык мужик:
ул дип җәдит...
Стенадан безгә Тукай портреты карап тора. Әйтерсең, ул безне күптәннән күзәтә, сынамак була, я, шәкертләрем, кайсыгыз мине яхшырак укый икән, дип сорамак була.

Камил, минем кебек, көлгә тәгәрәткән бәрәңге ярата икән. Башта ул аның берсен кушучына алып иснәп утырды, аннан соң кабыгы белән ашыйм, дип куркытты.
— Куй инде, әнә ит аша, май аша...
— Һәр җан иясенә үз азыгы тансык. Укытучы апага бал-май, кошкортка җим, студентка — бәрәңге!

Башта сүзне каян башларга белмичә «ык-мык» утырган идек. Жылынып, тамак туеп киткәч, чишелде телләр. Сөйләшә торгач, дөньябызны онытканбыз, тыштә яктыра башлаган. Камилнең колакчынлы бүреген киеп ишек алдына чыксам, Мәүлихәттәй малларга азык салып йөри. «Нинди ир-ат кунды бүген сездә?» — дигәч, әсселе-суыклы булып киттем. Минә синә, мә!

— Кунумыни ул?.. Сөйләшеп утыру гына. Абый ич ул минем. (Оят алдата икән.) Каникулдан кайтышлый кагылган.

Өстәлне җыештырып, өс-баш алышуга, укучылар да җыела башладылар. Камил килеп кергәнен-берен танып тора.

— Бу сипкелле егет Нияздыр инде...

— Себер кызларына тартым булгач, Сәгъдия инде бу.

— Шамил турында мәгълүматларым аз рак минем, иптәш Мостафина (моңысы минем фамилиям). Чүт-чүт таныдым үзен.

Кунагым дүрт сәгать буе кымшанмый дәресләрдә утырды.

Бер тамчы керфек какмаган булуыма карамастан, кәефем шәп. Дәресләр ярыйсы бара. Атнаның соңгы көне. Рәсемдер, җырдыр, матур язудыр кебек ансатлар.

Сентябрь башларында икенче класслар белән груша рәсеме ясаган идек. Көньяк җимешләрен сирәк күргәннәр сабыйлар. Алга, зәңгәргә, шәмәхәгә буяп бетерделәр. Бүген мин аларга вак кына күгелҗем таплар сипкелләгән сап-сары җимеш күрсәттем.

— Менә бу грушаның үзе була инде, балалар. Хәзер шуны натурадан карап ясагыз. Үзем Камилгә «ым» каккандай иттем. Көчтәнәчең күргәзмә әсбапка әверелде ич.

Соңгы дәресләрне җыр белән тәмамладык. Кулыма мандолина тоттым. Балаларның тигезле-тигезсез нечкә тавышы «Туган тел»не күтәреп алды. Кунак абыебыз да түзмәде, хорга кушылды.

Тагын кич булды. «Абыем» дип хәбәр иткәч, фатирга чыгармадым кунагымны. Аннан соң ул үзе дә мут егетләргә охшамаган. Кыз балалар кебек әдәпле, хатларындагы төсле акыллы.

Хезмәт дәресендә балалар белән үзебез юнып ясаган экспонат эскәмиябез бар. Шуны гүлбәчтән тартып чыгардым да өстенә сырма яптым.

— Әйдә, Камил, мич каршына утырабыз. Урман уртасында учак яккан качкыннар кебек хис итик үзебезне.

Эскәмиябез аксаган. Чүмәлеп киткәндә чүт тотып калды Камил үземне. Ә мин кулга эләккән бәбкә кебек тыпырчынып алдым һәм эскәмиянең икенче башына ук күчеп утырдым. Ул уңайсызланып китте. Гафу үтенгәндәй, тавышын йомшарта төште:

— Җиде түгел, алты тапкыр гына үлчәгәнсез бу эскәмиянең аякларын...

— Мал иясенә ошый, ди безнең Мәрьям әби. Без бит сала «осталары» гына. Кала кораллары каян булсын бездә.

— Чын җәүһәрләр асфальтта ятмый...

— Шулай да күбрәк асфальттан атлаучыларда ялтырый алар.

— Таш җәүһәрләр, җан җәүһәрләр бар...— Камил шүрлек башындагы томга ымлады.— Әнә берсе...— Аннан соң ягымлы карашларын миңа күчерде:— Синең күңелең дә шундый җәүһәрдән тора сыман...

— Камил, каян килеп чыга ул синә шундый баш әйләндергеч олы фикерләр.

— Мин дәү бит инде, Назира. Солдат булдым. «Остазларым» күп. Хәзер карт шәкертмен. Малай-шалай гына булсам менә, бу көлтә чәчләреңнән тартып «чырлатыр» идем үзеңне. Үзеңнән кечкенәләргә тиярге ярамый.

— Минем синә ике генә сүз әйтәсем бар,— диде Камил, шактый уйланып утыргач. Берсен саубуллашканда ычкындырмакчы, икенчесен... хат белән язмакчы...

Тик мин аларның берсен генә ишеттем, дөресрәге, ишеткәндәй булдым. Икенчесе... килеп ирешә алмады...

* * *

Атна-ун көнгә киткән хуҗабикәм биш көннән урап та кайты. Язылып, эрләнеп, бәйләнеп бияләй буласы йоннар орчыктан ары узмаган. Төенчектәге кучтәнәч кукәй кумәчен дә самовар катына утыргач кына этәрде.

— Авыз ит. Таза Чишмә кумәче.

Гадәтем шундый, берәүнең читләтуен, кагуын-сугуын сизәм икән, аннан битәр үзем гөрбиянланам.

Анламыйм гына әбиемне. Ни булган моңа, югыйсә түземсезләнеп көткән идем бит мин аның кайтуын. Шундый олы яңалык — Камил белән күрештек бит әле. Белмимени ул аны? Хаты килгән саен сөенеч ала, сер түгел җирләрен укып күрсәтергә куша.

— Язуына караганда, акыл утырткан бәндәгә охшый, кыз чакта юләр буласың, «чибәр» булсын дисен. Олыгайгач кына искә төшә, тересәкне тешләп булмый. Уйла, тәүфыйклы кеше юлдашның юньлесен ычкындырмый,— дигән була иде әле үзе.

Капкага кемдер кагылуы булды, әбкәй бишмәтен киеп каршына чыгып китте.

Ай, бу бит аның «җене сөйми» торган теге сәфәрче Мәликә апа ич. Кичә дә жаһилләнеп кереп чыккан иде. Ишек алды уртасында очраштылар да сарай почмагына кадәр сөйләшеп бардылар. Мәликәттәй кызу-кызу нидер сөйли, әбкәй, юк сүз дигән сыман, кулын селки.

И, миңа димәгәе, бетмәгәндер әле берәр гайбәт. Суга барып кайтыйм.

Күзге каршына басып мамык шәлемне урадым. Камил миңа бүрек, беретка кимәскә кушты. Шәл үздерен килешә сиңа, ди. Гел мамык арасыннан карап торган сандугачка охшыйсың, ди. Камил, Камил... кайтып житкәндер инде. Бүген-иртән хаты килер... Күңел үрсәләнеп куйды, жырлыйсы килеп китте. Өй арасында кия торган кыскарган пальтомны кидем дә чиләкләремне дыңгырдатып тыкрыкка төшеп киттем.

Эх, бу якның су буйларын бер генә күрсәгез иде! Авыл белән бөтенләй саубуллашканчы, булдыра алган кадәр тасвирлап калыйм әле.

Киртләч-киртләч кар баскычлар... Бер генә аяк белән басарлык кечкенәләр алар. Берең менгәндә икенчең тау башында төшми көтеп тора. Чайпалган су катып, я ашалып, кителеп, баскычлар кичкә таба бөтенләй бетәшәләр... Таннан торган бер рәхмәт яугырысы яңадан киртләп менә. Нәрсә әйтсәң дә, тереклек чыганагы суда...

Шунда төшкән саен мин үземне икенче дөньяда кебек хис итәм. Алда ак юрган астыннан шыпырт кына агып яткан инеше. Көн әз генә сындырдымы, туш чыга да шул уйнаклап ката. Ара-тирә ялтырап алган, урыны-урыны белән ак түмгәкләргә йомарланган бу инешкәй миңа күзен йомар-йоммас кына, хәзер уянам, яз гына килсен... дигәндәй йокымсырап ята кебек.

Ә каршыда авыл күрке — атаклы Килә тавы. Ул бик текә. Шунадыр — аның кызыл балчыклы, комлы сыртына чирәм дә шытып чыкмый, мүк тә ябышмый, кар да кунмый. Җәен дә, кышын да гел бер төсле сары-кызгылт. Тик очлаеп менгән түгәрәк башындагы түбәтәен генә алыштыргалый. Мин килгәндә ул күгелҗем каурый кадалган яшькелт эшләпәдән иде. Кышка кергәч, врачларныкы сыман кыңгыр салып, ак беретка киде, ә итәгендә сакта торган тугры гаскәрләр сыман төз карагайлар басканнар. Авыл ягында сөзәк үрлек. Бирерән өйләр бөтенләй күренми диярлек. Тик ара-тирә анда, югарыда, моржалардан үрелгән кыйгач төтеннәр, монда, түбәндә, урыны-урыны белән уелган бәке-

ләр генә кайдадыр бик якын гына яшәү барын, тормыш кайнавы расльй.

Шул тауларга багып моңайганда колагыма кешеләр тавышы чалынгандай булды. Күрше бәкегә төшүчеләрдер. Тәэсирләремнән айнымас өчен ул якка борылмыйм.

Чү... ни... ни... ди... Бу бит тагын теге сәфәрче түти тавышы. Житешмәгән җире юк үзенең, кушаматы җисеменә бик туры килгән икән. Тукта, тукта, колак яфракларым кызышып китте:

— Кара әле син аның исәр кешедәй басып торуын гына. Суынны чумырып ал да менеп кит инде.

Аңа чәжгырып торган икенче тавыш кушыла:

— Берәрсен котәдер.

— Булыр алардан. Бөтен нәрсә шундыйлардан чыга...

— Тегесе «сабакташ» дип эзләп килгән, монысы «абыем» дип өенә керткән...

— Хи-хи-хи, көндез абый, төнлә җаный диген, хи-хи-хи...

— Шул төнге җаный белән өч көн, өч төн...

Абау... Эсселе-суыклы булып киттем. Күз алдымнан яшелле-зәңгәрле чаткылар узды. Һушымнан язып бозга тайганмын. Бер мәлгә бер нәрсә күрмәс, бер ни ишетмәс булдым. Зиһенем таралган. Көянтәм инемдә ничек кайткандыр. Чиләкләремне өйалды уртасына «лып» итеп утырттым да чишенми-нитми кече якка кереп аудым. «Зәңгәр шәл»дәге Мәйсәрә кебек, мендәр тешләп үксергә тотындым.

Әбкәйнең миһырбаны килеп, башымнан тотты, күңелем тулып, тагын да ярсырга, сулкылдарга керештем.

Төн буе саташып чыктым. Уянган саен соңгы көннәрдәге вакыйгалар искә төшә, баш очымдагы кара гайбәтне куерта тора: ике көн элек кенә Котәм мәктәбе директоры сугылып китте. Минем хакта ишетеп, күз-колак булып китүе инде. Менә ни өчен ул минем белән рәсми генә сөйләште. Әбкәйнең турсаеп йөрүен нәрсәгә дә юрарга белмәгән идем. Суга барышлый Хисам абыйлар яныннан уздым. Күрмәмешкә салышып калды...

Иртән көзгегә карасам... күз кабакларым шешенгән. Баш чатный. Тавышым карлыккан. Укучыларымның күзләренә карарга кыймыйм. Гайбәт канатлы бит ул. Балаларга барып җитешкән булса... Озын тәнәфестә бер акыллы уй килде башка. Котәмгә төшеп менәргә кирәк.

Күрим әле Камал апамны. Сөйлим әле бөтенесен үзем. Аңламасмы...

Булмады. КАИ [1] да укучы кызы бар аның. Шул трамплиннан сикергәндә аягын имгәткән диме... Камал апам кызы янына Казанга китеп барган.

Болгарга, гаепле кеше шикелле, ут алгач кына кайтып кердем. Нурияләр өен читләтеп киттем. Аулак өйдә булган дигән даным бар бит әле минем. Фәрдәнәне күрәсе килә килүен, утлары да бар, әллә керимме? Хәер, тавыклары янында — фермададыр...

Камил... Кайда син, Камил? Күңелемнең сафлыгын тик бер син генә беләсең. Мине аңлый торган тик син генәсеңдер кебек дөньяда.

Тәвәккәлләдем! Мыскалга сыймас сафлыгымны тапларга, пычратырга ирек куймам. Мин угры түгел, хыянәтче түгел. Кемнән качып, кемнән посып яшим ди әле мин. Роноага барам да икенче мәктәпкә күчерттерәм үземне. «Нигә китәсең?» диячәкләр. «Авылда күп сөйләшәләр, диярмен, гайбәт тараталар, диярмен. Әле дә түздем инде, рәхмәт әйтсеннәр әле», диярмен.

Бу юлы да мөдир үзенең ике бүлмә аша үтәсе озынча кабинетында иде. Килбәтсез зур өстәлгә терсәкләре белән таянган килеш алдындагы кәгазьләргә иелгән иде. Бу кыяфәте белән ул миңа түр башына

[1] КАИ — Казан авиация институты.

купмаслык булып ябышкан үрмәкүчне хәтерләтте. Шунда кинәт тормышка ашырыйм дип килгән максатымнан өметемне өзеп, ник килгәнемә үкенеп куйдым.

— Ә-ә-ә, әйдәгез, сенелкәш,— диде ул минем сәламемә каршы сәламсез генә. Аның тыныч йөзен күргәч, эчкә яңадан җылы кереп китте.

— Кайсы мәктәптән әле сез?

«Онытткан да инде»,— дип уйладым.

— Болгардан...

— Ә-ә, значит, Мостафина. Я, эшләр ничек бара, яңа туташ?

Сорауларына өстән-өстән генә җавап бирдем дә тизрәк йомышымны әйтергә ашыктым.

— Икенче мәктәпкә?

— Әйе...

— Һи-и, килгәндә авызлары белән кош тотардай булып киләләр дә, понимаешь, аннан соң тартәгә тибә башлыйлар. Нишләргә сезнең белән?

— Теләсә кайсы мәктәпкә...

— Нәрсә, аның башкаларына тоз сипкәннәр дисезме?

Ул, урыныннан торып, каршыма ук килеп басты. Хәсрәттән, оялудан, хурлыктан, ачудан минем яшь җанлекмеке төсле янып торган кыргый күзләремә текәлде.

— Әйт әле дөресен генә, нигә шулай бик тиз таярга уйладың син аннан? Кешеләрне бер урнашкан урыннарыннан көчләп кубарып булмый, ә сез чирек-чирек чикерткә урынына сикергәлисез.

Күңелем тулып ашкан. Аз гына чирттенме, түгелергә тора. Әмма мондый кырыс кеше алдында «бик сүтелергә» ярамаганны шәйлим. Шулай да, ачыклык керту өчен «аулак өй» кыйссасын читләтә-читләтә «ерып» чыктым.

Аңламады ла, кеше хәленә керә торганмыни соң ул!

— Бармаска иде, мало што, мине кая чакырмаслар. Авторитет бер чатнаса, замазка белән генә ябышмый, сенелкәш. Сынаткансың инде. Бар кайт. Эшеңдә бул. Штобы бүтән ишетмим аулак җирләргә чабуыңны! Булдымы?

— Кайтмыйм мин анда. Икенче мәктәпкә күчәм.

— Кара син аны, ә? Укытучы гөмбә түгел, гөлкәем, куак төбе саен үсеп утырмый. Каян табыйм мин сезнең урынга кеше?!

— Барыбер китәм. Икенче, өченче районга китәм. Сез бюрократтыр, мөгаен. Тикшерми-нитми шулай сөйләшмәс идегез. Кая ул сезгә яшь кадрларны аңлау?!

Мин ярсыдым. Күңелгә җыелган кайгысы, хурлыгы, үпкәсе — барысы берьюлы ялкын кебек ургылып чыкты. Ишекне шап иттереп яптым да ашыгып чыгып киттем. Күземә ак-кара күренмәде. Каядыр соңгармый барып житәсе кеше кебек кызулыйм да кызулыйм. Бер заман хәл бетте, әкренәя башладым. Олы юлга чыккач, землямер баганасына сөялеп ял итеп алдым. Тирә-як күз чагылдыргыч ап-ак, көн шундый җылы. Аякларымда ап-ак фетрлар. Башымда ап-ак колакчынлы куян бүрек. Бөтен нәрсә ап-ак, ә күңелдә... күңелдә кара яра. Унбиш километрлап җәяү кайтасым бар. Ярый әле, ялгызым гына, ярый әле, кайтасым ерак. Күзгә кеше күренәмени мондый чакта... Бу хәлләрне Камил күреп торса... Син мин уйлаганча ук акыллы түгел икән, Назира, дияр иде. Күңеленне дә җәүһәргә тиңләп ялгыштым, син башка икән, син усал икән, дияр иде. Дияр иде!

Кылган эшләремә хисап бирә башладым. Я, тукта әле, ни хакым бар иде минем РОНО йортында шулай буза күтәрергә? Ишекләрне шапылдатып ябарга мин кем соң ул кадәр? Әллә, әллә кайтып гафу үтенимме? Булмас! Анысы булмас! Ә аның ни хакы бар иде минем

турыда шулай уйларга? Нигә ул бөтен кешеләргә бер күзлектән карый? Һәр ике якта да булды гаеп. Үзе башлады... Юк, үзе түгел. Каян килеп чыкты соң әле бу борчулар?

* * *

Олы капка ачылган. Атлы чана эзе бар. Ишек алдына печән коелгалаган. Сарай бикле. Димәк...

Димәк, бабай килгән!

Бабакаем, башка чак булса, атылып кереп муенына асылыныр идем... Бу юлы, олылар өйдә юкта өйгә зыян китергән гаепле сабый сыман, йөзенә карамый гына, кулымны суздым.

Чыраена чыккан. Ишеткән икән. Килүе дә тикмәгә түгел. Хәзер нахак бәла хурлыгы өстенә икенчесе өстәлде. Бабайның холкы бер кузгалсамы...

Дөньяны күп күргән карт ул. Алты яшеннән үзенә азык эзләп чыгып киткән. Горький кебек Россияне аркылыга-буйга җәяүләгән. Тик аның кебек атлаган саен биеккә, югарыга күтәрелмәгән, болай гына, киләп саргандай арлы-бирле генә таптанган, нәрсә күрсә шуны, нәрсә ишетсә шуны оясына ташыган. Мулла абзыйда сабак укытышкан, сәүдәгәрдә сату итешкән, ресторанда официант булган. Дәрдмәндне күргән, Мәҗит Гафури белән очрашкан, Риза Фәхретдин белән бер мәҗлестә утырганнар, Шаляпин концертына билет сатышкан. Кыскасы, үз сүзләре белән әйткәндә, остазлардан әдәпкә өйрәнгән, бәхетсезләрдән гыйбрәт алган. Аракылы табыннан чыраен сытар, тәмәкечене янына утыртмас, ялкауны ияләндермәс, менә шундый безнең бабай. Тормышның көен табып, үзенә җайлап яшәгәнгәдер, житмеш тугыз тулган,— алтмыштан арыны бирмисең. Бөкресе юк, җыерчыгы аз, ыхламый, ухламый. Кырынып-сыпырынып кына тора. Изүенә кер кунмас, җиңе-балагы җыерылмас. Түшәк-ястыкның тышын, кием-салымының эчен ак бүздән тектерер. Акта тап тиз күренә, ди.

«Ишек алдыннан чүпне эскәкләп чүпли, карбыз суын кайнатып эчә икән Зыя бабай, дип сөйлиләр авылда. Һәм дөрес сөйлиләр. Өйдәге һәр нәрсә анынча: әйбер ул куйганча торсын, аш ул дигәнчә пешсен. Һәркем аның законын тотсын. Кычкырып көлү, шак-шок басып йөрүләр юк ул безнең өй эчендә. Ләкин бу катгый кануннарны тормышка ашыру бабакайга җиңел булмаган. Аның кайбер гадәтләренә бик буйсынырга теләмәгән әткәем җәзасын татыгач, бабама үч итеп өйдән качып киткән. Мин боларны үсеп буйга җиткәч, әбкәй янындагы туганнардан ишетеп белдем. Шул үкенечтән сине итәгендә утыртып, иркәләп кенә үстерде. Бәхетең икән, күрә алмадың син аның «гайрәтле» чакларын, диештерәләр. Итәгенә үк утыртмаса да, йөгенә керә алмыйм, меннән-мен рәхмәт, миһербанлы булды бабай миңа. Кулдан сорамады, телдән каһәрләмәде. Әйтәсен күз белән, ишарә белән генә аңлатты.

Менә шундый ул минем бабай. Сүз аның тарафларына борылган икән, картлардан көләргә ярый, үз башыңа төшәсе, шулай да берике кызыгын да сөйлим әле.

Инештән кер чайкап кайттыңмы, башта кулларымны, аннан соң керләремне иисни. Эз генә сабын исе сизсә, су буена янадан төшерә. Юган кердән хуш ис кенә килергә тиеш...

Шәһәрдә укый башлагач кич клубка чыгып керү өчен бер рөхсәт артты. Ләкин шарты бик катгый: вакытында кайт!

Унсигезенче бара... Кинодан соң кичке уен гөрли... Биисе килә, җырлыйсы килә. Хәйлә кордым — урынымны чоланга җәйдем. Өй алды аша гына «выжт» шул якка.

Бабай миннән дә уздырды, капкага шыгырдавык куйды.

Менә шундый ул минем бабакаем.. Мин аннан бик канәгать, тик ул гына бик разый түгел, «аздырдым, буле куйдым, менә хәзер алып уздын», ди.

Күрәм, бабакаемның бүгенге кыяфәте дә нәкъ әнә шуны «әйтәм-әйтәм» дип тора. Тик әби алдында гына базмый. «Кеше алдында авызында кан булса да төкермә», ди ул үзе дә. Шулай да сизелә, рәнҗегән бу мина.

— Жыен, кызый,— диде ул мина коры гына, (күңеле йомшарганда кызым ди),— килешли олы мәктәбегезгә кагылдым, рөхсәт бирделәр. Кайтып киләсен. Әбиен сырхаулап тора.

Хәсрәт хәсрәтне баса дигәндәй, күңелле юллар көтмәсә дә, кайту сүзе әз генә рухны кузгатып куйды.

Чанага утырып чыгып киткәндә хат ташучы Хәмдия апа очрады. Бүген дә хат юк икән. Башын гына чайкады.

Киткәненә ай бит инде, Камил! Ник язмыйсың хат?! Минем өскә гайбәт чыгартыр өчен генә килгән идеңмени?

* * *

«Сырхау карчыгым» каршыларга үз аягы белән чыкты. Аягында киез ката, өстендә хәтфә бишмәт. Чырае көләч.

— Хәлен ничек, әбкәем, тереләсеңме әллә?

— Томау төшкәние, узды инде. Кыймылдап йөргәнгә бик шөкер. Үзең ничек, балакай, тартылып киткәнсенме...

Тартылырсын, әбинен үзе әйткәндәй, нибуч.

Тукта әле, бер яктан әбинең саулыгы сөендергән сыман итсә дә, икенче яктан сагаеп куйдым: ни дип кузгатты соң әле бабай мине урынымнан.

Табыннан кузгалыйм гына дигәндә, кулы белән утыр әле дигән ишарә ясады.

— Карамалы базарыннан бер сүз ишетеп кайттым,— диде бабай тавышына шом кертеп,— илла-мәгәр хакка чыкса, миннән рәхим-шәфкать көтмә!

Баш очымдагы болытлар кабара, авырая бардылар. Менә-менә яшенле янгыр кояр кебек. Мин, шыкланыр жир юклыктан бөкшәйгән юлчы кебек, иннәремне жыерып, кулларымны кушырып бөгелеп төштем. Куркам да мин бабайдан, оялам да. Кая соң яшене?.. Узсын иде инде тизрәк бу кысыр «күкрәүләр».

Нәкъ шул чакны өйалдында аяк тавышлары ишетелде. Аннан кемдер тамак кырып керергә рөхсәт сорады.

Башта танымый тордым. Кеше кайгысымыни соң әле мина?! Аннан соң аптырап киттем. Әнвәр абый иң. Мин аны алтын погонлы хәрби киемнәрдән генә күрергә гадәтләнгән. Көмеш каракүл якалы пальто, якасы төсле папахасын салгач, иң башлап кулын мина сузды. Бабайлар белән күрешкәннәр инде, күрәсен.

— Назира кайткан, диләр. Күреп китим әле, мин әйтәм.

Аның йотардай булып төбәлгән әрсез күзләреннән тизрәк ычкынасым килде минем. Чыгып китәргә яхшысынмыйча, мич буендагы урындыкка постым.

Аларның өйләре безнең урам очында. Атасы ак сакаллы Мирхәйдәр абзый — бабайның ахирәт дусты. Үзләренә күрә «затлы нәселләр» дип йөртешкән булалар бер-берләрен. Алар барысы алты туган, алтысы да, бабай әйткәндәй, урындагы кешеләр. Кайсы председатель, кайсы завхоз... Әнвәр абый үзе кайдадыр көньякта хезмәт итә булса кирәк.

Былтыргы каникул вакытында да бер очрашкан идек без аның белән. Клубта булды бу хәл. Ак крепдешин кофта өстеннән клуш итәкле сарафан кигән идем. Ул килеп кергәч, чыш-пыш сүз китте. Имеш,

өйләнәсе килеп кайткан, авыл кызы булсын, эш рәте белсен, дип әйтә, ди. И, бу кызларны, мин әйтәм, каян ишетеп бетерәләр барысын... ничек оялмый шуны сөйлиләр тагын!..

Әнвәр абый гел безнең рәтне әледән-әле күзәтеп торды. Соныннан, җае чыгыпмы, янәшәмә үк килеп утырды. Кайбер күзләр безнең якка күчкәч, уңайсызланып куйдым. Биергә чыгу хәйләсе белән сәхнә артындагы запас ишектән өйгә шылдым.

Һәм, урамга чыккач, үкенеп куйдым. Нигә ашыктым соң әле мин?.. Борылып карамый гына аяк табышларын тыңладым. Ул түгел, узып баручылар гына икән. Нигәдер ул минем арттан чыгарга тиеш иде кебек. Шуның белән аллы-артлы гына, кулларны болгап кына, уртәшеп-көлешеп кенә сөйләшеп кайтасы килеп китте. Аннан соң үзебезнең турыга җиткәч, теге кунак егетен шаярткан кебек, бәләкәй капкадан гына выжт өйгә! Аптырап калсын иде... Юк, җир читеннән кайткан кешене алай мыскыллау килешмәс...

Икенче көнне Алабуганың үзенә үк машина туры килде дә өч көнгә иртәрәк китеп бардым. Гаскәриләрчә төз гәүдә, нәрсәдер әйтәсе килеп төбәлгән сөйкемле кыю караш, акыллы киң маңгай, ажаган шикелле, берничә көн күңелне уйнаклатып торды да тагын шул ажаган шикелле үк юкка да чыкты.

Менә ул яңадан горизонтта. Ләкин үзе генә түгел, алар икәү хәзер. Камил якынрак та, яктырак та кебек... Ләкин...

Бабайның «кызым» дигәненә сискәнеп киттем. Самовар куярга куша икән. Ни арада йомшарган әле ул.

Кунак түргә үк узган. Чәйләр эчми китү исәбе юк.

Алгы бүлмәгә узышлый, иренеп кенә көзгегә карап киттем. Күзләрем зураеп, сөрмәләнеп калганнар. Билем тагын да нәзегәя төшкән. Өстемдә түше чигешле кәшемир күлмәгем. Калын толымнарымны ычкындырып инемә салгач, үземне үзем кызганып куйдым.

Тагын ниләр күрәсең бар икән әле, кызый?

Менә ниләр икән:

Бермәлне күршебезгә генә башка чыккан Әхәт абыйларына Әнвәр абыйдан хат килеп төшә. Шунда: «Назираны кияүгә бирмәделәрме әле?» дигән ишарәле бер сүз бар икән. Монысына җиңги җавап бирсен, янәсе. Тәҗрибәле киленнәр кайнишкә кәләшне үзләре димлиләр, ни дисәң дә, килендәш белән сайрап яшәү күңеллерәк. Шул көнне үк ул бу хәбәрне әбигә «тишкән», әби бабайга ирештергән. Бабай мыегына бөтереп куйган: яхшы бәндә чыгып торганда кызны аткарырга кирәктер...

Кама буенда ике-өч районны «кавыштыра» торган олы базар бар. Карамалы базары. Башына бер исәп төштеме, безнең бабай шунда чыгып китә. Болгарлар очрамасмы, кызның хәлен белешим дип йөргәндә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, нәкъ кешесенә — әлеге дә баягы сәфәрче Мәликәттәйгә юлыккан. Гайбәтче телендә тулганып, тәмам чынга охшап калган әлеге «уйдырма» бабайның гел кабатлый торган бер мәкален искә төшергән: камырың кабардымы — күмәчеңне әвәлә, кызың буй җиттеме — озату ягын кара.

Бабай, базардан кайтышлый, Мирхәйдәр абзыйларга туктый.

— Түтенегезне күрдем дә, җылынып чыгыйм, дидем.

— Бәрәкалла, әйдә, әйдә, Зыя абзый, үзем дә барып чыгыйм дип тора идем, иншалла, бик әйбәт булды. Сәламәтлек ничек, мал-туарлар исән-иминме? Кызыңны кеше иттең инде, куанычын күрергә язсын.

— Кеше булды, аякка басты дип кенә торганда менә күз-башка чалына башлаган...

— Кузбасска китә, дисеңме?..

— Нинди Кузбасс? Кияүгә димлиләр икән, дим. Төрлесен төрле якка таратып әрәм-шәрәм итеп бетерәбез инде... бала-чагаларны...

Бабайның тел төбен чамалап алган ахирәте хәйләгә үк керешкән. Һәм шул да мәгълүм булсын, алтмыштан үзен аксакал итүче, кешесенә карап эш йөртүче бу карт «хәйләсез — дөнья файдасыз» сүзен телдән әйтеп тормас, астыртын оста файдаланыр. Һәм менә шулай итеп, безнен әбинең «томау сырхавы» башта аның карчыгы Гөлҗамал тутәйне еккан.

Әнвәр абыйның ике-өч көнгә, күрше Миннисаттәй әйткәндәй, ни урталай — ни пурталай кайтып төшү сәбәбе шаять аңлашылгандыр.

— Өзеп бер сүз әйтә алмыйм. Уйларга вакыт бирегез. Мәктәбемә кайтыйм әле,— дидем мин аларга.

* * *

Дөресен әйткәндә, кияүгә чыгу кайгысы юк иде миндә. Тизрәк кенә китеп ычкыныйм дидем.

Керфек тә какмый төн буе сине уйлап чыктым, Камил. Ярар, шушы икән якын итүен. Миннән чибәррәк кызларың бар синең Казанда, әллә сизми дисеңме. Хат белән язасы икенче сүзең шул булгандыр әле. Әйдә, очраш, бие, озат...

Ай, үз уйларымнан үзем оялып киттем. Нигә шулай тирәнгә кереп киттем соң әле мин... Без бит... без бит кинолардагыча үбешеп, вәгъдәләшеп аерылышмадык. Я, нигә шул кадәр шаштыргыч хисләр өмет итәм әле мин синнән, Камилем...

Әйтә генә алмыйм бит, Камил, хәзер... Кай ягың белән иләсләндердең син минем күңелемне. Акыллы хатларың, бронзадай саргылт калын чәчләрең, уйчан, сабыр карашларың — барысы да шундый кадерлеләр кебек... Юк, юк, алар өчен генә түгел... әйтә генә алмыйм бит, белмим, ни өчен шулай якын әле син миңа? Төш кенә кебек узган шул ике көнлек истәлек игътибарсыз укылган китабыма яңадан әйләнеп кайткандай яңара бара. Күзләреңә туры карарга тартынсам да, рәнжеткеч үртәү сүзләре әйтергә оялмадым мин синнән... Хәтерең калмады гына түгел, игътибар да итмәдең син аларга. Димәк, якын күрүең шулай гына булган... Ә нигә соң алайса, тизрәк синең йокыга китүеңне көтеп, кече якта эш тапкан булып йөргән чагымда шулай дидең: «Йокың кала бит, урыныңны җәй дә ят инде, Назира. Әллә якын итүемә ышанмыйсыңмы?..» дидең?.. Ә нигә соң китәсе иртәндә тутырып бер карадың да: «Назира...» дидең? Әү, дигәч, дәшмәдең... Әллә чынлап яратып каравың, яратып дәшүең идеме?.. Шулай икән, нигә аны телдән әйтмәскә, өйне яңгыратып бер «яратам» дип кычкырмаска?!

Инде киенеп бетеп, баскычка чыгып саубуллашкач та кинәт кенә перчаткалы кулларың белән ике яңагымнан учлап тоттың да шунда ук кирегә этәрдең. Әллә: «Хуш инде, матурым, көтәр булсаң, тагын килермен», дигән идеме? Нигә шуны сүз белән әйтмәскә, «Көт мине, килермен!» димәскә...

Ул чакта әле миңа унсигез генә иде... Ул чакта әле минем ачык төсләрне генә таный, телдән әйтелгәнне генә аңлый торган самими чак, юләр чагым иде. Мәхәббәтнең тылсымлы көче яратып караган күзләрдә, әйтелмәгән яшерен сүзләрдә икәнен сизми торган олы сабый чагым иде бит.

* * *

Ашыгып, ашкынып кайттым мин Болгарга. Узган шул ике-өч көн эчендә әллә никадәр яңалыклар бардыр шикелле тоелды.

Камилдән хәбәр булырга тиеш. Тиеш! Барыбер нәрсә булса да язмый калмас Камил.

Аннан соң бәлки районга чакыртып алырлар. Алырлар! Дипломлы укытучы гөмбә түгел, агач төбендә үсеп утырмый, диде мөдир.

Кем белә, моны ишеткәч, ата-аналар аякка басарлар. Җибәрмибез сине, ышанмыйбыз без гайбәткә, диярләр. Диярләр! Актан караны яхшыдан яманны аера торганнар да бар дөньяда!

Ләкин күз өстендә каш түгелмен икән шул. Кайтуыма Камилне тыны да юк.

Көтәмгә узышлый мөдир белән инспектор сугылган. «Дүшәмб көнне алмаш укытучы килә», дигән язу калган.

Ни уйларга да белмичә аптырап торганда телефонга чакырдылар.

Өзелергә торган өмет кыллары тагын бер чынлап күйды, бәлк районнандыр, ә? Бәлки Казаннандыр, ә?

Трубкадагы металл сеңгән яңгыравыклы тавыш Әнвәр абыйның иде.

— Назира, Назира, исән-сау кайтып җиттеңме?

Мин дәшмәдем. Бу минем өчен сорау билгесе түгел, нокта иде Сүнә барган соңгы өметләрнең ноктасы, тәмамлануы бу.

— Назира, Назира, мине ишетәсеңме? Хәлләрең ничек?

Күнелем тулып, эреп киттем. Бу минутларда миннән хәл-әхвә сораучы бердәнбер кеше шул гынадыр шикелле тоелды.

— Ишетәм, ишетәм, Әнвәр абый.

— Менә әйбәт. Я, уйладыңмы, каршыларга барыйммы?!

Мин үземне дәрья уртасында чайкалган көймәдә калган кебек хи иттем. Ярсулы агым мине айкый-айкый каядыр сөйри... Менә шунд кемдер миңа кул изи, коткармак була, үз көймәсенә дәшә. Әнә ул. якыная, каршыма килә. Нишлим? Башым әйләнеп китте. Күземне йом дым да ишкәгемне ташлап, кулларымны суздым.

* * *

Карасана... Бөтен урам озатырга чыккан.

— Китәсеңмени инде, җаныем? — ди Салиха апа, ачынып,— бала лар ияләшеп беткәннәр иде үзеңә...

Шатлыгым-кайгым булып әверелгән укучыларым минем! Әнә үзлә ре дә... Сәгъдиямнең күзләрендә моң... Кечкенә генә кыз шундый итег карый белсен инде. Ниязымның нәп-нәни бармакларын катырак кыс тым, авырттырмадым микән?..

Хисам абый Әнвәргә ат җигешә.

— Кызның шәбен эләктердең, кияү, кадерен белеп тот...

Атны олы капкага каратып боргач, Мәрьям апа баскычтан бер төр тәк күтәреп төште.

— Мәле, кызым, урәчә башындагы чемоданына тык моны...

Әсәрләнеп киттем. Бу теге көреләп суккан чаршау иде.

Нишләдем мин! Шулай якын итәсегезне белсәм, төкереп тә бирми идем гайбәтләренә.

Алты гына тапкыр улчәдеммени соң?..

Басу капкасына җиткәндә тагын туктаттылар. Хәмдия апа...

— Көчкә куып җиттем үзегезне,— ди ул өзек-өзек сулап.— Яңа гына почта кайтты.

Букчасыннан берәм-берәм өч конверт чыгарып сузды. Кулларым, токка кагылгандай, кире тартылдылар.

Хатлар — көтә белгәннәр, түземнәр өчен генә языла лар. Бу юлы мин аларга лаек түгел идем инде. Үпкәсе, укенече-көенече барысы бергә болганды. Үз тавышымны үзем танымадым:

— Иясенә кире салыгыз...

* * *

Адашмый, афәт күрми, ару-талусыз кичтек без ул язгы карурманны. Тик мин анда үз сукмагымны салмадым. Ул сапкан юлдан әнә иярен, аның эзенә басып, анә таянып атладым мин тормышым түренә.

Бәхетне әйбәт ир белән тату торып, күркәм киенеп, тәмле ашап яшәүдә генә күргән кешеләр, белегез, мин аларга тулысынча ирештем. Ләкин әнә шул бар яктан түгәрәк килгән мөбарәк тормышның матурлыгын күреп, рәхәтен тоеп яшәү өчен рухи яктылык кирәк. Ул нурның чыганагы — яраткан хезмәтең!

Бар иде бер заман минем шундый хезмәтем. Җитәрлек иде минем аңа энергиям.

Әнвәр мине башта дөнья шигърияттен баеткан Каф тау якларына — Кавказга алып китте. Ике елдан грузинча Мцване Концхи, безнеңчә Яшел култык дип аталган, дөньяның искиткеч гүзәл почмагында яшәдек. Ләкин Кара дингезнең күз явын алырдай язгы зәңгәрлеге дә, күзләрен кара янып шаукымлы дулавы да минем мәктәбемә булган мәхәббәтемне, балаларны сагынуымны баса алмады. Сабыйлар бирелә дә бар, якты класслар чакырып торалар, ләкин укулар аларның ана телендә — грузин телендә бара иде.

Аннан соң Карпат аръягына чыктык. Украин телен үзләштерә башладым дигәндә генә Урта Азиягә кайттык. Ике путевканы бер көнне тапшырдылар. Берсе мәктәпкә булса, икенчесе...

Шулай итеп, без менә өченче ел инде Байкал артында яшибез.

Әлбәттә, мин өйдә генә кул кушырып утырмадым. Китапханәдә эшләп йөрдем, кисү-тегү түгәрәкләре оештырдым.

Ләкин күңел сызган саен нечкәрә, нечкәргән саен сизгерләнә бара. Яраткан хезмәт кенә хезмәт, имеш. Мәктәптән башка эшкә кул бармый, имеш. Нигә шулай иркәли әле мине бу тормыш?! Колакта алтын тамчылы алкалар, бармакта бриллиант кашлы йөзек, муенда энҗеләр. Аяк астында кыйммәтле келәмнәр.

Я, мәрҗәннәргә катып йөрерлек кем соң әле мин ул кадәр? Дөньясын шау иткән актрисамы, халык лауреатымы, әллә соң... затлы мехка төшкән «көябикә»ләрнең берсе минме?..

Атам-анам кушкан, кемдер яратып дәшкән исемем дә уңа, онытыла башлады. Алдымда рәхсәтсез-нисез күземә карап, бала-чага исеме тагалар, «Надька», диләр, «Наденька» диләр, тагын әллә кемнәр, диләр. Артымда анысын да әйтмиләр, майор хатыны гына дип йөртәләр.

Я, кайчандыр Мокамайларны укып йөргән, ал галстуклы Назира сиңме инде бу?

Я, кайчандыр комсомол ялкыны кабынган, балаларны Тукайча эшкә өндәгән Назира синме бу? Бабакаем, «почмакка яна тәрәзә тиштек, шуннан бөтен дөнья күренеп тора»,— дип язган. Телестудия Зәй буйларын да мишеньгә алган. Күршедәге олы авыл кадәр генә район үзәге таш кала булып калыккан. Китапханә шүрлегенә яңа китаплар, яңа исемнәр менделәр. Зима станциясендә туган сибиряк Евтушенко, татар егете Юзеев, башкорт кызы Фәүзия һәм тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр. Кичкә кердекме, бинокль күтәреп балконга чыгабыз. Офык буйлап тере йолдыз тәгәри. Галәмгә юл салынды.

Күптән түгел әткәсе ят кунак иртәп кайтты. Җинелчә ыспай гәүдә. Сөйкемле дә соң... Әллә кай төше якташ егетләребезгә тартым. Кул бирештек. «Мин — Вил»,— диде. Татарча дәштем. Вилем елмаеп куйды, Әнвәрем аптырап калды:

— Липатов булыр бу! Калышасын дөньядан. Бер шәһәрдә яшәгән язучыны тану кирәк.

Җәрәхәткә тагын тоз. Ул моны «кимсетим» дип әйтмәде, кунак алдында үзенчә аклануы гына иде... Ә мин аны үземчә кабул иттем,

күрденме, эшләр кая барып җитте... Хурлануымнан каушаганмын, залга әзерлисе табынны кухняга әзерләгәнмен. Елмаеп йөрергә тырышсам да, ясалма чыга. Каты басып атлыйм. Кулдан савытлар төшеп шалтырый. Кунак әз утырыр, күп сынар, әдипләр гаеруча үткерләр. Сизмәмешкә салышуы булгандыр.— Телегез гаҗәп матур яңгырый, Нязира,— диде ул саубуллашканда кечкенә, ләкин кысса җиленне өзәрлек, алмаз кебек үзе нәфис, үзе каты кулларын сузып,— аңламавымны кимчелегем дип гафу итегез...

* * *

Акыллы кеше гомере буе үзенең кимчелеген эзләр. Ә берәүләр аны тоеп та күрмәмешкә салышыр, өченчеләре... Аларына мин керәм. Гомерем буе сыкранып яшәргәме, аннан кемгә ни файда?..

Язмыш җаена ятып, тынычланып барганда миңа бу вакыйга миңе йокымсырый башлаган сыкраулы тормышымнан уятып, ниһаять, аякка бастырды.

Кайчан һәм кайда гына яңгырамасын, шул көмеш кыңгыраулы алтын сентябрь күңелне җилкетми калмый. Онытылмас булып уелган бала чак, яшьлек хатирәләре яңара. Быел без бу көнне өчәүләп көттек. Кызыбызга җиде яшь тулды. Ак якалы, ак беләзекле кара кәшемир күлмәгенә канатлы ак алъяпкыч япкач, ул менә-менә очып китәрдәй карлыгач баласына ошап куйды. Беренче талпыныш көне бу... Чигәсенә кунган тасма чәчәген төзәтим дигәндә тып итеп яшем тамды. Күңел коргаксып килә, күптән елаганым юк иде минем. Болытсыз аяз көнне күкрәүсез тамган яшь иде бу. Тыелырга теләп иренемне тешләдем. Йөрәктә бушлык, авызда тоз тәме...

Озаттым кызымны. Кайтышлый турыбыздагы киоскага тукталып, өебезгә килми торган берничә журнал алдым.

Журналлардан алтын көз исе аңкый. Сабыйлар, яшьләр тавышы яңгырый. Тышлыкларда да, эчке битләрдә дә көзге чәчәкләр кочаклаган шат балалар елмая. Тәбрикләр, шигырьләр, гәрәбә яфракларга чорналган истәлекләр. Журналист блокнотыннан күчкән чын хикәяләргә туктыйм, берсе «Күңел балкышы» дип атала.

Кызыл юллар аша өстән-өстән күз йөгертәм: «...Кайберәүләр талант сүзенең мәгънәсен тарайталар. Эфирда яңгыраган, китапларда язган, экраннарда чалынган, ачыш ясаган кешеләр генә мактала бу яңгыраулы сүз белән. Сәнгать йолдызлары, шагыйрьләр, галимнәрдән башка төр профессия кешеләренә сокланганда икенче дәрәҗәдәге сыйфатлар кулланыла. Шәп врач, оста тегүче, тынгысыз җитәкче, акыллы тәрбияче, тәҗрибәле укытучы дибез. Минемчә, шагыйрь тумыштан шагыйрь икән, врач яки укытучы булып та туарга кирәктер...

Мин шундый укытучыны беләм. Аңа унсигез яшь иде. Бер дәресендә утырдым. Укытучы булып кыланмады, укытучы булып яшәде ул анда... Кая күчсәм, шунда җыйнап китә торган истәлекләрем бар. Шулар арасында аның хатлары, көндәлекләре...»

...Мин сискәнеп киттем. Бу язмалар миңа бик танышлар... Үземнекеләр ич. Югалган бер кыйммәтле әйберен тапкан кешедәй, журналны тулгандырып карыйм. Төшем дә түгел шикелле. Меңләгән тираж белән таралган популяр журналның соңгы саны. Авторы... Авторы кем булды соң әле? Эзләп кенә таба торган икән. Язманың иң ахырында тыйнак журналистларга хас имза: К. Фалих.

Көндәлектән соңгы юлларны кайта-кайта укыйм. Укыган саен бер яңалык ачыла, тагын бер фикер туа...

«...Хезмәтенә гашыйк кеше генә әнә шундый канатлы була һәм шулай яза ала. Ул — талант иде. Андыйларның күңелендә җәүһәр бар кебек.

Ул кайчан да булса барыбер бер балкыр сыман тоелды. Шуңа күрә мин аның истәлекләрен дә сакладым һәм шул якка юл төшереп эзләп тә карадым. Ләкин соңлаган идем инде...

...Кайчандыр салам шәл астыннан җем-җем карап утырган вактөяк өйләр урынында бер совхозның алма бакчасы җәйрәп ята.

— Монда кайчандыр Болгар авылы бар иде түгелме?..

— Ә-ә-ә-әнә,— диде янәшәмдәге юлдаш, алдыбызда шәһәр сыман калкып утырган зур гына авылны күрсәтеп — безне көтә торган Көтәмгә күчеп беттеләр алар.

...Унъеллык зур мәктәпнең икенче катына менгәндә олы бер күзге бар. Мин шунда аның силуэтын күргәндәй булдым. Озын буй, калын толымнар. Ялт борылдым да исемен дәштем. Төшеп баручым әйләнеп туктады. Бу ул түгел иде, әмма бик таныш иде миңа аның йөзе.

— Нигә җавап бирәсез, сез бит башка...

— Бик яраткан укытучымның исеме белән дәштегез...

— Кайда ул хәзер?

— ?

Кемдер синең юлың белән киткән һәм күңелендә сине кадерләп саклый, кемнеңдер тәүге кызы синең исемеңне йөртә, кемнәрдер синдәй сәләтле укытучыны көтә... Ә син үзең кайда соң, ә?! Тирәнне бер әйләнәле, нурмы син, әллә күләгәме инде... Тормышта үз талантларының яктысыннан чагылып сукырайганнар да очрый. Син алар арасында түгелсең, әлбәттә. Таулар кичәрлек куәтле булып та түмгәкләргә абынганнар да бар... бәлки...»

Бу юллар арасыннан мин каты шелтә, соңгы кисәтү укыдым, сүнә барган якты хыялларыма, ерагая барган изге максатларыма чакырган көмеш кыңгырау чыңы ишеттем. Ишеттем, Камил! Ишеттем!..

* * *

Үзәк мәйданны аркылы чыктым да ике катлы таш йорт каршына бастым. Ниндидер бер өмет белән хәтерләп үткән идем мин бу тирәне. Шәһәрнең мәгариф бүлеге шушында инде. Бусаганы атлаганчы, башта тирә-ягымны барладым. Әйтерсең, мин чынлап мәйданда, тормышым мәйданында. Әйтерсең, мине бирегә еракта калган кадерле бер кешем чакырып чыгарды. Әйтерсең, мин бүген биредә соңгы тапкыр көчемне, ихтыярымны сыныйм. Хәер, «әйтерсең»ләп торасы юк, дөресе шулай ла!

— Безгә укытучылар бик кирәк,— диген булды мөдир урынында калып торган инспектор, юк дип җырт кына әйтәсе килмичә,— ләкин сез нигә химик яки географ түгел соң?

Минем аптырашлы карашым аның гөнаһсыз елгыр күзләре белән очрашты. Гадәттә мин мәктәпләр инспекторын урта яшьләргә җиткән, тәҗрибәсе-ние булган рәсмирәк кеше итеп күз алдына китерергә күнеккәнмен. Егерме җиде, егерме сигездән арыны бирмәслек житез гәүдәле бу чандыр егетнең хәлгә керергә тырышып үз итеп сөйләшүе төшенке күңелемне юатып куйды.

— Бәлки адресымны калдырыймдыр...

— Үзем дә шуны әйтмәкче идем,— диде ул тагын да җанлана төшеп, мөмкинлек чыгу белән хәбәрләшербез.

Вәгъдәсендә торды егет. Атна-ун көн үтүгә мине дәштереп алды.

— Риза булсагыз,— диде ул монголча тар маңгаен җыера төшеп,— бер әү дүрт-биш айга ялга китмәкче...

Ул сүзен очлаганчы ук мин аңа ризалык биреп баш кактым.

— Булды алайса,— диде ул шунда ук ачылып китеп,— эшләп торыгыз, тора-бара күз күрер тагын, күз күрер.

Кешеләргә ягымлы мөгамәләсе, житез хәрәкәте йөзенә чыккан бу егетнең каш араларыннан мин шуны укыдым: мине бер балага тарган-

дыр дип уйлый иде ул. Мине кызгана иде, ярдәм итәсе, мине юатасы килә иде аның.

Шулай итеп, мин яңадан мәктәп дөньясына атладым. Ниһаять, күңелне алгысытып торган морадыма якынаям, ахры. Ләкин белмим, озаккамы?.. Авызы пешкән — өреп эчкән, ди. Әмма вак-төяк каршылыклардан өркергә ният юк. Тик шуны әйтми булдыра алмыйм, мәктәп кочагына беренче тапкыр атылган чактагы татлы хыялларым сүрелгән икән инде. Талпынып түгел, сабыр гына атладым мин бу өч катлы күксел бина бусагасыннан. Иртәрәк иде әле. Укучылар берәм-сәрәм генә күренә. Укытучылар бүлмәсе дә буш. Плащымны элеп, чәчләремне төзәткәләгән арада җыела башладылар. Куе шәмәхә күлмәгенең түшенә челтәр күбәләк япкан Раиса Марковна да, Камилнеке төсле салам чәчләрен артка тараган Валерий Исхакович та, хәтта модный актрисаларны да җәлеп итәрдәй киенгән инглиз теле укытучысы Ария Иосифовна да (бу фәнне алып баручыга шулай көязләнү рөхсәт иteләдер, күрәсең) миннән бәхетлерәкләрдер шикелле тоелды. Мин аларның бирегә үз йортларына кайткандай, бернинди церемониясез күрешүләрен, үз шкафларын ачып, үз кабинетларына килеп сарып йөрүләрен кызыгып күзәттем. Аларның артык исләре китмәде миңа. Вакытлы кеше булуымны да сизгәннәрдер инде. Күңел әз генә сыкрап алгандай итте. Ләкин дәресләргә чакырып звонок яңгырауга, килделе-киттеле шикләр, кимсенергә маташулар һәм үткәннәр өчен үкенүләр барысы берьюлы юкка чыкты. Мин классыма кердем. Балалар дәррәү тәпи бастылар. Бүлмә эче яп-якты. Парталар дүртәр рәт булып тезелгән. Түшәм биек. Стенада зәвык белән сайланган педагогик иллюстрацияләр. Әйләнмәле кара такта басып тора. Беренче күзгә ташланганнар шулар булды. Укучыларым яшьләренә караганда дәүрәк буйлылар. Ни әйтсәң дә, сугыш чорында ачлы-туклы үскән сабыйлар түгел шул. Аннан соң сибиряклар тумыштан гәүдәлеләр, тазалар. Исемлек озын. Үзләре белән танышып чыктым. Болгардагы балаларга караганда кыюлар. Ләкин шунсы хак — нинди генә шартларда һәм нинди генә чорда үсмәсеннәр — балалар балалар булып калалар. Мин алар өчен нибары ун-унбиш минутка гына яңа, ят кеше булып тоелдым. Шул билгеле секундлар үткәнче экранга төбәлгәндәй башымнан аягыма кадәр күзәтеп, хәрәкәтләремне үлчәп, авыздан чыккан һәр сүземне йотып алырдай тын утырган булдылар да киеренке халәттән ардылар, ахры, янадан кыймылдый, пышылдаша башладылар. Исемемне дәшәселәре килеп, бер-икесе кул күтәреп вак-төяк сорау биргән булды. Арттан икенче рәттә утыручы киң яңаклы бурят малае янәшәсендәге сары ефәктәй юка чәчле кызчыкка сугылып язуын сыздыртты. Әләкләтәсе килде инде. Тактага көнлек числоны язгач, тагын бер кузгалып алдылар, йөзләрендә канәгатьсезлек сиздем. Соңгы еллардагы каллиграфия үзгәрешләрен искә алмаганмын икән.

Санаулы дүрт сәгать сизелми үтте. Һәм мин шушы кыска вакыт эчендә үземне төрле яклап үлчәргә өлгердем. Күп нәрсә онытылган. Үзгәрешләр шактый икән. Өйрәнәселәр байтак. Шунда мин үземне инештә генә йөзәргә өйрәнгән хәлсез кочакларым белән диңгезгә сикергәндәй хис иттем. Үзе абынган — үзе еламый, ди. Булдыра алмадым, елаган чаклар да булгалады. Ә бу юлы ыңгырашырга исәп юк инде. Дулкыннар көчләрне батырмыйлар, күтәрәләр генә. Миңа әнә шулай көч җыярга кирәк иде. Тынгысыз көннәр башланды. Бер караганда кыен да, кызык та кебек. Ничә еллар инде бер түбә астында, бер ояда яшибез. Икебезнең канын, холкын, кыяфәтен берләштергән кызыбыз үсә. Арабызда хыянәт юк, тиргәшер сәбәп юк. Шулай да нигәдер аңламый мине Әнвәр. Ул үзен акыллы, сабыр һәм һичкайчан да күңелендәге кешегә чыгарып тукмәс кешегә саный. Моны башкалар да раслый һәм ул чынлап та шундый кеше. Ләкин нинди генә шартларда

һәм кайчан гына булмасын, үтәли күрәм мин аны. Ә менә мине — җыласам яшемә буылып үксеп елый торган, куансам шашынып сөенә белә торган артык беркатлы кешене ул аңламый. Ул мине олы сабыйга саный. Дәртләнеп укыта башлавымны да үзенчә хөкем итә, янәсе, эч пошканнан эшкә кереп йөргән булуым. Янәсе, мин тормыштан кызык эзлим. Янәсе, мин рәхәткә «чыдый» алмыйм, михнәт эзлим. Мин аңа үпкәләмим. Мин аңа күнеккән. Ә менә кызкаем Галимә әнисен күбрәк аңлый шикелле. Беркөнне ул үзенең күбәләк канатыдай юка учлары белән яңакларымны сыйпады:

— Кызларга бүген, минем әнием дә укытучы, дидем.

— Кайда эшләвемне сораганнар идемени?

— Юк. Тик торганда гына әйттем. Белсеннәр, дидем.

Чытлык кызыемны кочагыма кысам да маңгайларыннан, бантикланган чәчләреннән пәп итәм. Ә ул миңа шундый назланып сыена, күңелдә әниләр генә тоя торган әллә нинди татлы рәхәтлек җәелә. Мин барысын да онытам. Рух кинәя.

Табыннарын җыеп, урыннарын җәям дә тагын эшкә чумам. Мин тормышымның бар тәмен хезмәттән табам, ди торган иде миңа яраткан укытучым Камал апа. Нигәдер соңгы көннәрдә минем исемә ул еш төшә башлады. Һәм менә бүген дә.

Бүлмәм ишеге ачылды. Ул икән. Урындыкка сугылып узды да кире борылды. Әз генә урындык янагына басып сөялеп торды.

— Тыныч йокы,— дим мин аңа, китаптан башны күтәрми генә.

Ул дәшми. Ул гадәттәгечә җитди. Мин аны борылып карамый да күреп торам. Калын кашлары тоташа язып җыерылган. Зур матур күзләре кечерәеп калган. Маңгайдагы сырлар тирәнәйгән. Юк, ул ачулы түгел. Үзенә күрә хәл белүе, арыгансың, йокларга кирәктер дию инде ул аның. Һәм шунда ук үзенен авыр адымнары белән яңадан чыгып китә. Шуңа да рәхмәт. Ләкин миңа ул гына җитми. Әйтсен иде ичмаса бер генә сүз. Эшләр барамы дип сораганнан теле калмас иде бит. Юк әле, дияр идем мин аңа. Иртәгә балалар белән Азия ландшафтын үтәбез. Гади генә итеп ничек аңлатып бирергә икән шуны үзләренә.

Нәкъ дүрт ай тулганда мине яңадан район мәгариф бүлегенә дәштеләр. Һәм бөтенләй башка мәктәпнең икенче классларын кабул итүемне сорадылар. Мин монысына да шатланып риза булдым. Тынгысыз кызыклы көннәрем озыная бара. Тагын шул бар, мондый борылышлы үзгәрешләр, кыенлыкларына карамастан, файдага гына иде. Мин көчемне һәм ихтыярымны сынадым. Ә икенче яңа уку елы миңа мәңгелек шатлык алып килгәндәй булды. Ул елны мин тулы хокуклы укытучы булып өр-яңадан беренче классларны кабул иттем.

Урра! Урра! Сер сандыгыма әверелеп килә торган кызчыгым Галимә белән аналы-балалы әйлән-бәйлән иткәндә әтисе кайтып керде.

— Балалар бакчасы,— диде ул сирәк ачыла торган калын иреннәрен кыйшайтып.

— Бүген бәйрәм көнебез безнең,— дидек без аңа икәүләп.

— Алайса бәлеш пешкәндер,— диде ул, борынын тарткалап.

Дөньяда уртак шатлыктан да олы сөенеч бармы соң! Минем истә калачак ямьле көннәремнең берсе шушы көн булгандыр. Кичке ашны без кухняга оешып түгел, иркен залда утырып ашарга булдык. Өстәлгә хуш исле йөзем бәлеше дә чыгып утыргач, табын тагын да түгәрәкләнеп киткәндәй булды. Булган-булган икән, әйдә тагын бер булсын дип, яңадан кухняга чыктым. Ләкин көмеш бөкеле шешә бәлеш янына кунды да шунда ук купты да. Чөнки Галимә «бәйрәм суы» диган булып иәни учлары белән авызын каплады. Бу аның үзенчә пырхылдавын яшерүе иде. Бу аның үзенчә, мине бәләкәйгә санамагыз, мин аның су түгеллеген күптән беләм инде дип, бездән көлеп утыруы иде. Мин

шунда әйдә дә үземнең педагог булырга тиешлегемне искәреп алдым. Шешәне яңадан суыткычка утыртып килгәндә, сыңар күзләрем белән генә Әнвәргә бактым. Һәм мин аның карашында ниндидер ягымлы сагаю сиздем. Миңа беркайчан булмаганча рәхәт булып китте. Шунда мин аның баһадирдай киң җилкәләренә сарыласым, күкрәгенә башым куеп, тотлыга-тотлыга шуны пышылдыйсым килде:

— Соң син үзең әйбәт кеше бит, җаныем. Тик син минә бераз гына тупасрак, тупас та түгел, ничек дип аңлатыйм инде, хисләргә саранрак син, тойгыларың сай синең.

Ләкин чү-чү... ярамый! Мин тыелып калдым. Ул матур кашларын яңадан ямьсезләп куырып да иләп кенә кулларымны салкын инңәреннән куптарыр сыман. Хурлануың ни тора! Әмма мин аңа карап күңелемне төшермим. Хыялланып, тансыклап көткән бу көнем ул тойгылардан өстенрәк һәм гомерлерәк. Бу көн минем баш очымда тормышымның яртысын яктыртып торачак Казык йолдызына әйләнер сыман иде.

Һәм мин бу юлы чынлап та ялгышмадым. Көн артыннан көн, ай артыннан ай узды. Аткан һәр таң, каршыланган һәр ел миңа барысын да,— көенечен дә, сөенечен дә, борчуын да, рәхәтен дә өеп алып килде. Килә-китә торган хәсрәттән ачынсам да, боекмадым. Унышларымны күреп куансам да, җилкенмәдем. Вакытым әрәм иде минем алар өчен. Тормышка мәхәббәтем артты минем. Башым-аягым белән мәктәп дөньясына, балалар арасына чумдым. Икенче-өченче еллар гадәти генә узгандай итсә дә, минем бу яраткан хезмәтемә тумыштан гашыйклыгым тора-бара яхшылык итәргә теләүчеләрнең күзенә чалына башлады. Алар миңа рухи канат бирде һәм мин шулар белән тагын югарырак талпынмакчы булып яңа өметләргә багланып яшәгәндә шундыйрак бер кызыклы очрашу дөньямны тагын да киңәйтеп, уйларымны тагын да тирәнәйтеп җибәргәндәй итте. Күңелне әледән-әле алгысатып, каядыр әйдәп торган бер нур йөрәгемне пешереп алгандай булды. Аралар ераклашкан саен күңелгә якыная гына барган, беребез мәгърибтәге, беребез мәшриктагы Камил белән безне өченче бер яшерен көч күрештергән сыман булды.

Читадан көнчыгышка табарак үзенең шифалы сулары белән дөньякүләм әһәмияткә ия Машук һәм Карловы Варылардан аерылгысыз курорт бар. Дарасун диләр аны. Каникул алдыннан сәгатьләр бушый төшә. Шундый бер көнне укучыларымны җыеп Дарасунга экскурсиягә алып киттем. Байкал артында, соңга калып килсә дә, гүзәллеге белән берәгәйле, кояшлы, ләйсәнле яз иде. Табигатьнең соклангыч саф чагы. Саян сыртлары сыек зәңгәр рәшә бөркәнгән. Сопкаларны алсу куаклар чуарлаган. Яфрак ярганчы ук чәчәк ата торган тубылгылар алар. Себер назлысы Ингода елгасы ташып болыннарга җәелгән. Курорт дигәнебез карт карагайлар, көяз каеннар, яшь имәннәр белән катнаш урман куенында. Без анда озак тукталмадык. Көмеш улаклардан челтерәп аккан әчкелтем тозлы суларын авыз иткәндәй булдык та чыр-чу килеп ачык аланлыкка сибелдек. Укучыларым миннән Тукайның яраткан Кырлай урманнары, Идел буендагы Берсут наратлыклары, Батумидагы кипарислар, Карпат артындагы колмаклыклар турында сөйләттеләр. Йомшак, яшь сәрдәләр өстендә рәхәтләнеп аунагач, көлдә көйгән бәрәңгеләрне чупли-чупли шаярып, көлеп тамак ялгагач, кояшка күз салсак, көн кичкә авышып бара. Йөгереп-йөгереп карасак та, шәһәр-ара поездга өлгерә алмадык. Ерак Көнчыгыштан Мәскәүгә узучы составларның берсенә тәялергә туры килде. Көр күңелле тиктормас балалар юлдан ялыккан пассажирларны җанландырып җибәрделәр. Куе кофе төслерәк бик килешле чалбар һәм шул ук төстәрәк нейлон кофта кигән җыйнак кына гәүдәле, ябыграк ханым, стенагарак сыена төшеп, яныннан урын бирде,

— Рәхим итегез, Назира Хамитовна,— диде ул, күптәнге танышлар сыман елмаеп.— Укытучылар — әйбәт юлдашлар. Сезнең белән уртак тел табу җинел.

Тәкъдимен рәхәтләнеп кабул иттем дә, мактавын аклыйм дигән булып, сүзенә кушылдым:

— Шул арада исемемне дә откансыз?

— Шулай булмыйни,— диде ул балаларга таба ишарәләп,— әнә ич, бөрәмләп кенә дә түгел, хор белән дәшәләр үзегезгә. Төшәсе станциягезгә кадәр сезнең исем янгыраячак купеда.

Нидер әйтмәк булып борылган гына идем, түшендәге яшькелт значогына күзем төште. Игътибар итсәм, тез буыннарым калтырап китте. Нәни генә көмеш хәрефләрдән Камилләр чыгара торган журнал исеме язылган. Куршем минем сискәнеп китүемне сизепме, сынаулы карашын күзләремә текәп, башлаган сүзен дәвам итте:

— Истә кала торган янгыраулы исем. Безнең дә бер журналистыбыз кызына Назира куйган.

— Ә?!

Бу аның миңа бик сонлап ишетелгән авазы иде.

Бөтен тәнем буйлап тетрәткеч ток йөгерде. Йөрәк кысылды, сулыш туктагандай булды һәм мин сабырлыгымны җуеп, аның маникюрлары куба төшкән озын бармакларына орындым.

— Сез Фалихов белән бергә эшлисез мәллә?

— Әйе шул,— диде ул миңа, карашларын чарлап,— менә нинди кызык, танышыгызмыни?!

Гөрләп торган купе тып-тын калды. Кисәктән туган бу аңлашу үзенә башкаларны да җәлеп итте булса кирәк. Шунда күзләрен дүрт итеп миңа төбәлгән укучыларымны абайлап алдым. Юк, юк, артык тугарылырга ярамый монда. Үзеңне кулга ал, Назира...

— Укып кына беләм,— диган булдым ясалма тон белән. Ә үзем янымдагы журналистның сизгер карашларыннан качарга теләп, тәрәзәгә борылдым...

Поезд вокзалга якынлашкан иде инде. Укучыларымны вагоннан саный-саный төшереп бетердем дә купеда утырып калган яңа танышым янына яңадан атылып кердем.

— Сезгә бер амәнәт бар,— дидем мин аңа целлофан кәгазьгә төргән ике ботак сузып,— шуны Камилгә генә тапшырмассызмы икән?

— Бик теләп,— диде ул. Чәчәккә бөреләнгән генә тармакларны сыйпап,— бу бит тубылгы.

— Әйе, теләсә кайда, теләсә кайчан, теләсә нинди шартларда да чәчәк ата торган Себер умырзаясы. Аңа нур белән су гына кирәк.

— Мәгънәле бүләк,— диде ул сузып кына, серенә төшенергә теләп,— кемнән дип әйтермен?

— Назира исемле укытучыдан дисәгез, үзе аңлар.

Поезд кузгалды. Мин аңа балдаксыз кулымны болгап калдым. Ул мина нидер калдырып, нәрсәмнедер алып китте. Ямансу да, рәхәт тә тоелган бу минутларда бөтен җаным, тәнем, рухым белән мин шуна төшендем: кавышулардан азат, очрашулардан пакь, сагышлардан өстен мәхәббәт тә бар бит әле дөньяда!

## Әхмәт Рәшитов

# БУЫННАР ЭСТАФЕТАСЫ

### 1

### Һәйкәл

Урам уртасында һәйкәл тора —
Үлгәннәргә соңгы истәлек.
Салган аны авыл агайлары,
Кырык бернең җәен искәреп.
Монсуланып карап шушы ташка
Яшь йотуы әллә җиңелме?
Таш булып таш кайчак телгә килә,
Таш түгел бит кеше күңеле.
Чытылса да кайчак нурлы йөзләр,
Таш түгел бит безнең бәгырьләр;
Ул һәйкәлнең тирән тамырлары —
Европада калган каберләр.
Тантаналы тынлык сарган аны —
Сагышын ул эченә яшергән.
Йөз унсигез газиз исем анда...
Өчтән бере безнең нәселдән.
Дошман явын канлы юллар буйлап
Көнбатышка таба куганда,
Тереләргә җанлы калкан булып
Ятып калган бик күп туганнар.
Алсу гөлләр җилдә тирә-юньгә
Хуш ис бөркеп талгын тирбәлә;
Нәселдәшем булган Ильяс абый
Шәһит киткән ерак илләрдә.
Гариф абый туган илне сагынып,
Сугышларның үтеп дәһшәтен,
Кайткан да, гел элеккечә итеп,
Авылдашлар! диеп дәшә күк...
Кемне генә искә төшерсәм дә,
Әрнү булып баса юлыма.
Нәселем агачының ботаклары
Ботарланган сугыш елында.
Бәхтиярым сәерсенеп карый —
Ана бабай тиеш кеше дә
Кайталмады туган якларына,
Янып калды утлар эчендә.

Ике буын (гүя чылбыр өзек!)
Берсен берсе күреп белмәде,
Оныгының, бабай, дигәне юк,
Бабасының, улым, дигәне.
Күпме ләгънәт, күпме каргыш сүзен,
Күпме ачыну, күпме күз яшен
Эченә җыйнап тып-тын басып тора —
Туган якның изге ак ташы
Урам уртасында ялгыз гына.
Үлгәннәргә соңгы истәлек —
Һәйкәл салган авыл агайлары,
Җиңеп кайткан елны искәреп.
Зур исемлек анда.
Утлы юллар
Тезелеп киткән тәртип-җай белән.
Миһербансыз көндәлеге сыман
Һәрбер йортта йөргән кайгының.
Сагайгандай,
Тора тып-тын гына,
Уйдан кичереп илләр шаулавын.
Шөбһәләнеп тавышын тыңлый сыман
Еракларда барган яуларның.

2

## Әтием истәлеге

Нигә моңсу әле җырның башы?
Аһ-зарларым юкка түгелме?
Югалту һәм юксынулар хисе
Гомер буе борчыр күңелне.

Ата-баба узган данлы юллар
Бүгенгегә килеп тоташкан.
Алар каны хәзер безгә күчкән,
Җир нур җыйган кебек кояштан.

Халык хәтерендә бүгенгедәй
Исән алар,
Исән,
Абайла.
Һәйкәл янңарында сүз башланса,
Шул елларны сөйли агайлар.

Алар сөйли...
Габдулла абый миңа
Әйтә иде, кысып кулымны:
«Әхмәт энем, укыдың-укыдың инде,
Атаң хәтле әле булдыңмы?
Ай-һай, башлы иде Габделәхәт,
Булмаса да диплом-фәләне,
Шул дүрт сыйныф белем белән дә ул
Аңлый иде дөнья хәлләрен».
Ул давыллы еллар канатында
Югарыга менгән, янәга.

Егермебишменче Зыятдиннар
Дус һәм сердәш булган аңарга.

Ул финагент булган,
Эшен белгән,
Оста ачкан байлар ялганын.
Кызык итеп сөйли авыл халкы
Бер кулакка налог салганын.
Сарык тиресе япкан бүре сыман,
Бөеренә ачуын яшереп,
Ул ялагай, мескен чырай белән
Сельсоветка килгән баш иеп.

— Артык түләр чамам юк,— ди икән—
(Заманалар авыр, янәсе) —
Тагын күпме налог?.. Әти исә:
— Двадцать пять — бөтен бәласе!
— Син бигрәк тә инде, Габделәхәт...
Туган телне онытып барасың.
Бер мөселман белән икенчесе
Русча сөйләү нигә ярасын...
— Ә алаймы?..
Ә соң теге елны,
Становой тентеп бар йортны
Недоимка җыеп йөргән чакта
Туган телне нишләп оныттың?..
Гаепсезгә ярлы-ябагайны
Тал чыбыгы белән суктырдың.
«Ничә тапкыр сугыйк?» — дип сорагач,
«Двадцать пять!» — диеп утырдың.
Татарчаны белми идеңмени?
Син онытсаң, безнең хәтер шәп.
Дөнья куляса — әйләнә дә бер баса ул,
Менә шуңа «опять двадцать пять!»

...Исемен әйтеп тормыйм, ярар инде,
Туганнары рәнҗер, дус-ише —
Ул атаклы Чүти карагына —
Шәкүр картка кардәш тиешле.

Янаулар да булган, кыйнаулар да,
Тернәкләнгән ләкин колхозлар.
Бер «Үзәк»кә [1] җыйнап ярлыларны,
Үтә торган шулай яз-көзләр.

Аннан сугыш...
Ул фронтка киткән.
Ачуы килеп елы авырга,
Өлгермәгән йорты матчасына
Сугеңү сүзе язып калдырган.

Сагына идек аны өчәүләп без —
Аз килде шул сәлам хатлары.
Әллә кайтыр юлын кар каплады,
Әллә язар вакыт тапмады.

---

[1] «Үзәк» — колхоз исеме.

Кызу чаклар иде — Мәскәү яны
Кургаш белән тулган чак иде.
Сугыш учагында яшь гомерләр —
Алсу гөлләр сулган чак иде.

Тик Смоленск кына белә булыр
Аның ничек җиргә ауганын.
Канлы илбасарлар бу ир затның
Гәүдәсе аша атлый алмавын.

Мәскәүләргә барсам, изге җир, дип
Озак йөрим, чумып уема.
Ә билгесез солдат кабергндә
Әти ята төсле тоела.

3

## Нәсел агачы

Без бер бүген генә тумаганбыз,
Әле кешелекнең таңында
Бүгенгене көтеп яшәгәнбез
Бабайларның ерак канында.

Алар дәрте безнең җилекләргә,
Алар акылы безнең миләргә,
Гасыр фильтрларын үтә-үтә,
Тормыш өчен куәт җибәргән.

Унбер бабам тик билгеле миңа —
Унбере дә кара халыктан.
Калкан булып алар Идел-йортка
Болгар чикләрендә калыккан.

Әзгәриләр суккан Әтрәч[1] аша
Иравыллар[2] булып бу якка
Килгән алар Кайбыч тирәсеннән,
Һөнәрчеләр булып Чәчкаптан[3].
Яңа Чәчкап[4] авылы шулай туган.
Иген иккән монда бил бөгеп,
Кылый, Бүре, Мыек кушаматлы
Әзмәвердәй таза өч егет.

---

[1] Әзгәриләр суккан Әтрәч — Апас районындагы бер авыл. Тарихи мәгълүматларга караганда, бирелә шәһәр булган һәм анда «әзгәри» дип йөртелгән озынча көмеш акчалар сугылган.

[2] Иравыл — гаскәрнең алды, авангарды.

[3] Элекке Кайбыч районы Иске Чәчкап дип йөртелгән бу авылның исеменнән үк күренгәнчә, анда хатын-кыз бизәнү әйберләре эшләп чыгарганнар булса кирәк.

[4] Хәзерге Буа районының Яңа Чәчкап авылы күздә тотыла.

Мыек Йеркэй мина баба тиеш,
Шэжэрэмнең — ул иң түрендә,
Аннан соңгы буын аралары
Артык сирәк булып күренә.
Мыек Йеркәйнен дә ятим йорты
Озак еллар буе буш торган.
Ә өйләнеп, аннан улы тугач,
Чура батыр төсле булсын дипме,
Чурай диеп исем куштырган.
Аннан — Бикмәт,
Аннан — Ишмәт туган.
Катлаулана барган замана;
Туры килгән иген игәргә дә,
Аннан торып яуга чабарга...

Нинди давыл дулап үтмәгән дә,
Нинди җилләр улап исмәгән,
Ләкин авылым үзбаш булып калган,
Нәсел-ыру һаман ишәйгән.

Наданлыкны китап мактамый ул,
Танысаң да хәләл нан[1] тәмен,
Белем кирәк илгә,
Белем — нур, дип,
Мәдрәсәсен ачкан, мәктәбен.
Дөньяви фән анда булмаган да,
Бирелмәгән дә бит зур исем,
Тик әлифне таяк диеп белгән
Бабамнарны ничек хурлыйм соң?
Колгали дә безнең дипломсыз бит —
Тик ул язган «Йосыф китабы»
Күңелләрдән күңелләргә сеңеп,
Гасырларны ерып үталды.
...Ераклардан килә таныш аваз,
Колагымда чынлый моңлы саз:
«Кара гына урман, караңгы төн...»
Кылганнарга кагылып йөгерә яз.
Тапкыр сүзле бабам Бәхтияр ул,
Өне килә сыман үткәннән,
Күңелләргә ак нур өстәсен дип,
Юллар аны читкә илткәннәр.
Бөктәрдәге бәет, дастаннарга,
Думбыралар чыңы кушылган;
Арык атын илгә куа-куа
Ул язмышын уйлап пошына.
Кайтасы иде тизрәк туган якка —
Җир куены орлык сорыйдыр;
Ил картлары намаз арасында
Бәрәкәтле еллар юрыйдыр.
Ара-тала кыргыз даласына
Барып чыкты икән нилектән?
Хәер, безнең Акмуллалы халык
Бәйнәлмиләл элек-электән.
Көнчыгышта гына түгел эзе...

[1] Н а н — икмәк.

Наполеонга каршы зур яуда
Уртак Россиянең ирегe өчен
Башын салган безнең бабайлар.
Пугачевлар чорын искә төшер
Һәм телгә ал батыр Канкайны.
Бабайларның булат кылычлары
Хөрлек даулап байтак айкалды.
Ил каршында йөзе ачык аның,
Хыянәттән, сатлык чиреннән
Мәңге азат.
Барча милләткә ул
Дус һәм туган борын-борыннан.
Ир язмышы — ил язмышы икән,
Тарихны да саклау кирәктер,
Башкаларга бәлки гыйбрәт булыр —
Туар буыннарга өйрәтер.
Бәхтиярдан туган Батырша да,
Батыршадан туган Гаделша
Бабалардан күчкән акыл белән
Яшәгәннәр хәле-хәленчә.
Аннан эстафета итеп аны —
Бабасы һәм үзе белгәнне
Улларына биргән... Менә шулай
Алга илткән тормыш җилкәне.
Гаделшадан туган Габдерәшит —
Соңгы бабай безгә — һәм шуңа,
(Хәзер инде беразкыскартылып),
Фамилия ул безнең буынга.
Кабере аның ерак туган җирдән.
Халык уен байрак италган
Унжидедә,
Башкаларга кушылып
Патшаларга күсәк күтәргән.
Питер шаһит гүзәл язмышына —
Сайлаган ул авыр юлларны,
Ә авылда сагынып
Еллар буе
Көткән аны ятим уллары.
Каюм абыем көткән...
Әтием көткән...
Ул кайтмаган...
Янган авылда;
Ике ир һәм ике имән үскән
Аңа дәвам булып авылда.
...Урам уртасында һәйкәл тора —
Үлгәннәргә соңгы истәлек,
Салган аны авыл агайлары,
Кырык бернең җаен искәреп.
Йөз унсигез газиз исем анда...
Әрнү саркый һәрбер юлыннан.
Нәселем агачының ботаклары
Ботарланган сугыш елында.
Зур агачның кайбер үрентесен
Куырса да еллар кыравы,
Илгә баһадирдай ир бирерлек
Исән калган нәсел-ыруым,

4

## Кызыл кар

Шәҗәрәм минем кара халыктан,
Бер сынык икмәк өчен бил бөккән
Һәм хыялында яшерен уй йөрткән,
Манный боткасы явар, дип, көткән.
Ярлы бабайлар, гидай кардәшләр,
Алдагы көнгә өмет булмагач,
Язмыштан ачы көлеп әйткәннәр:
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
— Таңнан таңгача, төннән төнгәчә
Түнә газиз баш, түгелә кайнар яшь,
Туярмынмы бер кара икмәккә?
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
— Кыйшык йортымда җилләр уйнаклый,
Кайда торырмын, ул ишелеп аугач,
Бирерме ходай сипләрлек агач?
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
— Елый өемдә илереп сабыйлар,
Елый өемдә илереп каракаш,
Йөзләрдә кайчан елмаю балкыр?
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
— Бердәнбер атым — тормыш канатым,
Нәрсә җигәрмен ул арып аугач?
Арык атыма алмаш булырмы?
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
— Чәчтем тарысын, чәчтем арышын,
Күңелем зар булды, игенем уңмагач,
Елмаермы бер бәхет кояшым?
— Кызыл кар яугач, кызыл кар яугач...
Карындык тәрәз, салам түбәләр,
Ниһаять, хыял иткәнен алды;
Җилгә китмәде илләр көткәне
Һәм... теге әйткән кызыл кар... яуды!

5

## Нәсел дәвам итә

Авыл уртасында һәйкәл тора —
Истәлеге соңгы зур яуның;
Кырыс хәтирәсе ил каршында
Ир башына төшкән сынауның.
Тирә-ягын сарган ал чәчәкләр —
Батырларның сулмас юлдашы;
Шунда туган иде җырым башы,
Шуннан башлап киттем юл башын.
Инде буйлыйм авылым урамнарын —
Күп тарихлар сеңгән аларга;
Кай арада әле барысы да
Танымаслык булып яңарган.

Кая киткән хәзер борынгының
Ач әрвахы, Кутыр урамы?[1]
Һәрбер йорты шифер түбәле дә,
Һәрберсе дә яңа буралы.
Барыр юллар такыр булсын өчен,
Килер еллар матур килсенгә,
Балкып тора урам башларында
Яңа заман кушкан исемнәр.
Алсу булсын, диеп, атар таңнар,
Аяз булсын, диеп, иртәләр,
Кайсын «Тынычлык» дип атаганнар,
Кайсын «Совет» диеп йөртәләр.
Кичте баштан ачлык, авырулары,
Кичте баштан хәтәр чорлары,
Ил табыны хәзер бәрәкәтле,
Ил түрендә — бәхет җырлары.
Нәселем корый, диеп сукранмыйм мин,
Һич бирелмим юк-бар хисләргә;
Йөз илле йорт идек сугышкача,
Хәзер тагын йөзләп өстәлгән.

6

## Соңгы бәхәс

Гасырларны иңләп атлап килэм,
Үлми,
Сүнми,
Армый,
Ялыкмый,
Бабамнарны барлыйм.
Мин — бер улы
Кыю, батыр, тырыш халыкның.
Юлбасар да, илбасар да түгел —
Шаһит әнә — Ватан-анабыз;
Европада илнең ирке өчен
Башын куйганнарны санагыз.
Габдуллалар анда бик күп булыр,
Шәрәфетдин, Нәфикъ, Барыйлар...
Каберләре яңа туган көнгә
Ал чәчәкләр аша карыйлар.
«Кем идең син, мескен татар?» диеп
Кемдер әйтсә, бәлки хак тадыр.
Ул халыклар төрмәсеннән инде
Йолып алды безне Октябрь.
Республикалы итте,
Илле итте,
Ире итте уртак Ватанның;
Дошман юлына атам аркылы ятты,
Кирәк булса мин дә ятармын.
Без — Тукайлы,
Без — Җәлилле халык.

[1] Ач әрвах, Кутыр урам — авыл урамнарының иске исемнәре.

Тарихыбыз меңәр еллардан
Дөнья алдында йөзне кызартмаган,
Мәйданнарга батыр чыгарган.

Авылым минем илнең бер кисәге,
Бердәм атлый кешелек язына;
Кичәгесе, бүгене, иртәгесе
Олы язмыш булып языла.

Урамында мәрмәр һәйкәл тора —
Соңгы сынауларга истәлек.
Салган аны авыл агайлары,
Каһарманнар данын искәреп.

Һәр зәңгәр көн саен
Ал чәчәкләр
Тирәсендә шау-гөр балалар;
Бабалардан калган зур эшләрне
Арсеналга гүя алалар.

Сүзләренә колак салам.
Әнә:
— Бусы безнең бабай,— ди берсе;
— Ә мин бабай кебек танкист булам,—
Дип кушыла аңа энесе.

Әйе,
Кайсы танкист,
Кайсы галим булыр,
Кайсы иңләр иген басуын...
Урамнарда илнең ышанычы —
Сугыштан соң туган яшь буын.

Еллар уза,
Ирләр үсә тора —
Тарих дәвам итә һаман да;
Малайларның ал хыялы аша
Киләчәккә карый замана.

*1969*

Газиз Мөхәммәтшин

# ЙӨРӘКТӘГЕ ЭЗЛӘР

ПОВЕСТЬ[1]



Чәчкә дәүләт имтиханнарын биреп бетергәнче көтик, дисә? Ул чагында ни кылырга? Ни кыласың? Риза буласың. Бер карасаң, анысы да әллә ни олы каза түгел. Гомер буе көткәнне язга хәтле кәтәр Айзат, укасы коелмас. Ямьле җәйдә туй итәрләр. Авылдан әти-әниләрен чакырырлар. Күнелле генә булыр...

Соңгы фикерләре егетнең күнеленә башкаларыннан хушрак килде. Ләкин ни гаҗәп: әллә үз-үзенә һәм Чәчкәгә артыграк ышанганга, әллә инде мондый катлаулы мәсьәләләрдә тәҗрибәсе булмаганга күрә, Чәчкә миңа барырга риза булырмы, аның әти-әнисе ризалыкларын бирерме дип уйламады...

Сигезенче бүлмәнең ишек төбендә генә — коридорда — бер тәрәзә төбе бар. Аның баскыч ягы томаланган, ә бу ягы киң һәм утырырга бик җайлы. Студентлар йоклап, бүлмәләрдә ут сүнгәч, парлыларга серләшергә менә дигән урын! Шуна күрә бу «изге» тәрәзә төбе бер кичне дә буш булмый иде. Икенче көнне кич, монастырь шау-шуы сүрелә башлагач, Айзат белән Чәчкә шунда чыгып утырдылар. Айзат кызны, бик тә, бик тә әһәмиятле сүз әйтәсем бар дип, кызыктырып чакырып китергән иде.

— Я,— диде Чәчкә,— нинди серле сүзең бар?

— Сиңа бәлки алай серле һәм җитди тоелмас та ул. Эш менә... Мин әйтергә телим ки шушы минутта...— диде Айзат кипкән иреннәрен ялап, үзе, фу-у, җен, надан лектор шикелле нәрсә бытылдыйм дип уйлап куйды.— Без инде, Чәчкә, синең белән, әйтергә кирәк, утлар-сулар һәм җиз торбалар аша үтмәсәк тә... бер-беребезне шактый беләбез. Танышлар, аллага шөкер... Ни инде... Чәчкә, яратышып йөргән кешеләр нишләләр инде бер көн килеп... Мин сиңа әйтергә телим ки бик зур, мөһим һәм важный мәсьәләне... Син...

[1] Ахыры. Башы 3, 4, 5 саннарда.

— Тукта әле,— диде кыз, көлемсерәп,— тирләп чыктың, кая әле...— һәм аның кайнар маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп алды.— Инде дәвам ит. Ләкин ашыкма, кеше аңларлык итебрәк сөйләргә тырыш.

— Мәнә.... кыска гына әйткән чакта... ни инде, парин, ни, Чәчкә... э-э-э... Син миңа..:

— Ярый, җитте, интекмә,— диде Чәчкә, тагын көлемсерәп.— Мин — риза!

— Чәчкәм, матурым!

— Мин сине яратам, Айзатым! Өзелеп яратам! Мин синнән башка икенче берәү белән яши алуымны башыма да китерә алмыйм.

— Бәгырем, Чәчкәм, сандугачым, карлыгачым, аккошым!

— Кысма, кешеләр карый.

— Карасыннар! Без бик бәхетле яшәрбез, бәгырем!

Айзат моңа кадәр кичермәгән татлы бәхетеннән чак кына кычкырып җибәрмәде: янында сыенып утырган Чәчкәсе аңа моннан ун минут элеккегә караганда хәзер йөз мәртәбә, мең мәртәбә якынрак һәм үз иде. Тәне һәм үз җаны кебек кадерле, бөтен, бер иде...

Алар иңнәрен иңгә, башларын башка куеп сөйләшеп-киңәшеп урамнар, тыкрыклар буенча бик озак йөрделәр. «Чыршы»да коктейль эчтеләр, «Черек күл»нең ышыграк урынына кереп иреннәре уелганчы үбештеләр... Оҗма-ах!..

Шулай итеп, ике яшь йөрәк — ике саф йөрәк — язмышларын бергә бәйләргә тәвәккәллек итте. Тәвәккәл тау ега, көймәсе туфан яра, диган шикелле, эш чынга китте, һәм бер айдан кияү белән кәләшкә ЗАГСның алтын күзлекле, түгәрәк битле, көлеп кенә торган чибәр апасы, мәңге бетмәс татулык, олы бәхет теләп, акыл һәм киңәшләр биреп, «Язылышу турында таныклык» тапшырды.

Туйны ду китереп сигезенче бүлмәдә ясадылар. Туй буласы көнне иртә белән егетләр тулай торак коменданты Зоя апаларын әләктереп алдылар. Салпы ягына салам кыстыра-кыстыра яңа гаилә, туй турында сөйләп бирделәр. Кайгылы кыяфәт белән, башларын чайкый-чайкый:

— Бөтен нәрсәсе шәп, тик бер пүчтәк нәрсә әзрәк эчне пошырып тора, Зоя түтәй,— диделәр.

Зоя түтәй дә — карт чыпчык — кибәккә алданыр чаклары үткән, сагая калды:

— Эч пошарлык ни бар?

— Бар түгел — юк. Кунар урыннары юк. Туйдан соң кая бара инде алар? Беренче төннәрен кайда йоклыйлар? Сау бул дип, кәләш — өенә кайтып китә, кияү үз бүлмәсенә кереп китәме?

— Кереп китәрлек бүлмәләре дә булмагач, өйләнмәсеннәр иде. Кем кушкан!

Егетләр башларын кашыдылар.

— Хәзер соң шул инде. Эш узган.

— Бәлки яшьләргә бәләкәй генә бүлмә табарбыз, Зоя апа, ә? Бирәр кельня?

— Юк-юк-юк-юк! Подсуд китәр хәлем юк. Өйләнешкәннәр тулай торагы түгел бу. Авызыгызны да ачмагыз.

— Зоя түткә-әй! Кара әле, үзеңнең дә шундый көнең булган лабаса?

— Ә-ә-ә, кара син нинди хәйләкәр! Әлки төлкесе! Ялынычы төшсә: «Зоя түткәй!» Ә кичә генә караватына сузылып ятып кем тәмәке пыскыта иде әле, ә? Мин кергәч, йоклаганга салынып гырлый башлады.

— Мин чыннан да йоклый идем, билләһи менә.

— Тәмәке тарта-тартамы? Йоклаган кешенең авызыннан тәмәке төтене порхып торамыни? Сорамагыз да. Булмый, малайлар!..

— Зоя апакаем, соң... сез булдыра аласыз бит, табыйк инде бер бүлмәчек?

— Ә-ә-ә-ә, синмени әле бу, Шөгер Камыр батыры? Үткән атнада танца көнне, КАИ[1] малайларын куып чыгарыйк дип, егетләрне кем котыртып йөри иде, ә?

— Кермәсеннәр безнең кызлар янына. Хужа шикелле масаеп йөргән булалар.

— Кызларыбыз чибәр булгач нишләсеннәр?

— Чибәр кызлар безнең үзебезгә дә кадерле. Өф-өф итеп саклап кына тотабыз. Әнә, үз кызлары белән биесеннәр.

— Аларда кызлар әз бит... Карагыз аны, малайлар, таяк ике башлы була, юаны үзегезгә төшмәсен — ашханәләренә кертми башласалар, нишләрсез? Аннан жылап минем янга килмәгез, ашханә ачарлык урыным юк...

— Әй, борчылмагыз, алтындай нервыгызны бетермәгез юк өчен, Зоя ханым. Менә тегеләрне, мин әйтәм, җаен таба аласыз инде сез аның...

— Ә-ә-ә-ә, син дә мондамыни әле, төн ябалагы, Питрәч чәүкәсе? Нишләп төнге сәгать икедә ишек дөбердәтеп кеше мазасызлап йөрисең, ә? Шыпырт кына кереп ятарга булмыймы?

— Бәй, ишек бикле булгач ничек кереп ятыйм да мин? Энекәшне вокзалга озатып куйган идем, поезды төн уртасында гына китте.

— Һа!.. Әкият сөйләмә, малай! Киткән чагыгызда тәрәзәдән күреп калдым: «энең» башына зәңгәр яулык бәйләгән иде...

Бүлмә яулау «операциясе» ике-өч сәгатькә сузылды. Ахырында егетләрнең зур җиңүе белән тәмамланды.

Яшь кияү «бабай белән әби ни әйтер, ни кыланыр» дип хафаланып торган иде. Чәчкә алар белән сөйләшүне үз өстенә алды. ЗАГСка гариза биргәндә, борчылма, мин яхшылап сөйләштем, риза булдылар, диде. Айзат, моны ишеткәч, әзрәк тынычланып, Ким Риазович белән Ләбибә апасының туйга килүен өмет итеп йөрде. Тик туй көнне Ким Риазовичның Алма-Атага ниндидер халыкара конференциягә очканлыгы мәгълүм булды. Ләбибә апа, авырыбрак торам дисә дә, килде. Ул Айзатның әти-әнисе белән бергә рәттән утырды.

Туй нәкъ туй төсле узды. Сигезенче бүлмә шыгрым тулды. Туй башы Нариман үзен бик әре тотты. Кем икәнен уйлап, белеп кенә эш йөртте. Ләкин бүтәннәр дә хәттин ашып киртә сикертмәделәр. Яшьләргә, аз булса да күп итеп алыгыз дип, ике авторучка, китаплар, имезлек, пластмасса ат белән җилем курчак, арзанлы чәй сервизы, кижеле ашъяулык, бәрәңге кыргычы, Илья Ильф белән Евгений Петровның биш томлыгын, өч аяклы ике табуретка, Саратов химзаводының бер пачка ясалма сүсен һәм «Литература в школе» журналының былтыргы подшивкасын бүләк иттеләр, тамагым-кунагым дип, кыстаганны-ниткәнне көтми, ялындырмыйча гына өстәлдәге ризыкны сыптырдылар, туйда тавык та эчә дип, буйларына сеңдереп кенә күтәрә тордылар, скрипкә белән гармун икесе ике төрле булса да көйләре бер дип, алмаш-тилмәш туйның башыннан азагына кадәр сыздырдылар да сыздырдылар. Кунаклар, җырлы туй — бәрәкәтле туй дип, өздереп җырладылар, туйда тукмак та бии дип, сайгаклар сыгылганчы биеделәр, хәмерләр ачы булса да иреннәре татлы дип, әледән-әле «ачы, ачы!» кычкырдылар һәм кияү белән кәләшнең үбешкәнен карап көнләшеп, уфтанып тордылар, төн буе җимертеп бәйрәм иттеләр, күңел ачтылар, таң атканда гына чыр-чу килеп, сыйлы булды туйлары дип, бит сыпырдылар, кияү белән киленне шаулап-гөрләп теге кечкенә бүлмәгә китерделәр, кертеп җибәргәч, икәү булып ятыгыз, өчәү булып торыгыз дип кычкырдылар да залга төшеп кәлә-кәлә биергә тотындылар...

Айзат өчен әкияттәгедәй серле, гүзәл һәм татлы тормыш башланды.

---

[1] КАИ — Казан авиация институты.

Бал ае үткәнен ул бөтенләй сизми дә калды. Төштә күргән кебек кенә булды. Группа кызлары шаяртып та, җитди итеп тә аңа үпкә әйттеләр:

— Айзат, син, малай, безне оныта башладың түгелме?

— Хәзер үз кызларың белән сөйләшергә дә теләгең юкмы?

— Нишләдең син? Өйләнүең ярый инде анысы, тик без дә бар бит әле дөньяда, үлеп бетмәдек...

— Их, кызлар-кызлар, аңламыйсыз ла, мин сезне ничек онытыйм! Ләкин сез күп — җан сөйгәнем бер генә!

— Көне-төне хатыныңны уйламыйсыңдыр инде?

— Көне-төне шуны гына уйлыйм, бәгырькәйләрем?

— Аһ! — дип көрсенделәр кызлар.— Бәхетле кешеләр бар дөньясында! Безнекеләр ни уйлый торгандыр — белмәссең. Әллә буйдак булып картаерга телиләр, әллә эшләсе җирләренә үзләре генә ычкынмакчы булып йөриләр — өйләнү турында авыз ачып бер кәлимә сүз әйтсәләр иде!

Менә яңа ел да үтеп китте. Яңа гаилә үзенең күгәрчен оясыдай бәләкәй бүлмәсендә, вакыт үткәнен бөтенләй тоймыйча, бәхеттән исереп яшәвен белде. Бу «күгәрчен оясында» карават, өстәл, тумбочка белән ике урындыктан башка бер ни дә юк иде. Алары да дәүләтнеке. Ә алар моны сизмиләр дә, башларына да китермиләр иде. Акча мәсьәләсендә генә бераз кыенлыклар туды. Ким Риазович кызы белән кияве янына бер тапкыр да килеп карамады. Ләбибә апа килгәләгән чакларында, әтиегезнең эше тыгыз шул, һич вакыт таба алмый дисә дә, Айзат моның төп сәбәп түгеллеген яхшы аңлый иде. Чәчкә, мин аларны ризалатам дип әйтүенә дә карамастан, әтисенең каты күңелен йомшарта алмаган иде, күрәсең. Бу, әлбәттә, кияүне борчыды. Ул, өегездән бер кайчан да бер сум акча да, бер әйбер дә алмыйсың дип, Чәчкәне бик нык кисәтеп куйды. Яшәрбез әле, язга хәтле түзәрбез, илдә чыпчык үлми, диде. Үзенең әти-әнисеннән дә акчалата ярдәм сорамады. Ләкин авылдан ит өзелмәде. Әле казын, әле үрдәк, күркәсен, сарык ботын җибәреп тордылар. Чәчкә, куанычка каршы, тырнак лагым куба дип, бәрәңге әрчүдән, идән юудан баш тарта торган кыз булып чыкмады. Үз чәчеп эшли, ялт иттереп бәләкәй бүлмәләрен җыеп куя иде. Ашны да бик тәмле пешерә. Айзат аны гел мактый. Чәчкәнең моңа түбәсе күккә тия иде.

Ләкин акча дигән каһәр суккан кәгазьнең такы-токы чаклары ешая барды. Акчаның йөгәне юк шул, күпме керсә, шулай чыгып бара. Өчәр көн бәрәңге һәм ипи белән генә торган чаклары булды аларның. Шигырь, хикәя язып маташучы иптәшләре газеталардан гонорар алгалый. Ходай Айзатны ул сәләттән дә мәхрүм иткән. Ул да язар иде — булмый. «Ямь-яшел үлән арасына кап-кара тавык кереп китте»дән артыгын булдыра алмый. Җилкәсе киң, көче җитәрлек. Ләкин бу көч белән нишлисең?! Ә элек булган заманалар! Моннан ун-унбиш ел элек кенә студентлар пристаньнарда, вокзалларда баржа, вагон бушатып акча эшләгәннәр. Иртүк торып, аркасына бөятен кия дә — финиют пристаньгә. Шалага артеленә берләшәләр дә илле-алтмыш кеше бер баржаны сөйләшеп алалар. Я күмер, я цемент, я бүрәнә, я шунда бүтән нәрсә бушаталар. Эш «кайнар» булса, шул ук көнне кич эшенә күрә әҗерен дә алып кайталар. Ә хәзе-ер?!. Хәзер ме-ха-ни-зация!

Февраль ахырлары иде. Сыер мөгезен сындырырлык суык көн. Канализация коелары өстендә тәпиләрен җылытып утырган төркем-төркем күгәрченнәргә карый-карый, колакларын уа-уа, Айзат институттан кайтып керде. Чәчкә аннан алданрак кайтып моңсу гына тәс белән өстәл янында утыра иде.

— Ник көлмибез әле без? Ханбикәнең нинди кайгысы бар? — диде Айзат һәм килеп аның маңгаеннан үпте.

Чәчкә читкәрәк тартылды һәм, кит әле, дип куйды.

— Ни булды, Чәчкәм? Нәрсәгә кәефең кырылды? Нинди теләкләрең бар? Боер гына, барысын да күз ачып йомганчы үтим.
— Синдә Галәветдиннең сихерле лампасы бар бит, үтәмчә...
— Дөп-дөрес, дөньяның иң гүзәл ханбикәсе! Минем кесәмдә сихерле лампа бар. Җеннәр һәм диюләр — минем колларым. Каршымда ләббәйкә дип җидегә сыгылып торалар.
— Син һаман шаяртасың, ә минем.., ә минем ашыйсым килә,— диде Чәчкә һәм сулкылдап җылап җибәрде.
Айзат шып булды. Әкрен генә аның янына барып утырды.
— Кара әле, Чәчкә, нишләп ашамадың соң? Әле безнең стипендиягә кадәр җиде сум акчабыз бар иде. Кичә үзең җитә дип әйткән идең бит.
— Театрга барабыз, дип Ризаның сөйгән кызы килгән. Өч сумын шуңа бирдем.
— Дүрт сумы калган иде әле.
— Сәлим кереп алды. «Зоомагазинга» заграничный бакалар кайткан, ди.
— Тфү, бу зоологлар белән биологлар да йөри эшем кешеләре булып! Бу җуләре бөтен бүлмәсен кәлтә, бака, әкәм-төкәм белән тутырган, икенчесе, ничә керсән, керәч чәшкегә салып туфрак төеп ята, яна төр чүп үләне таптым дип шатланып йөри... Тфү!.. Тинтәк! Чүп үләне тапканга түгел — беткәнгә шатланса бер хәл иде. Заграничный бака, имеш!.. Тфү!..
— Кирәк булгач, нишләсен инде.
— Кирәк нәрсә күп булыр. Менә хәзер безгә стипендиягә хәтле торырга кирәк... Син тукта, җылама. Хәзер рәтлибез аны. Мин дә берәрсен, магазинга заграничный нәрсә кайткан дип, төпсез чуманга утырта алам иә. Һмм, кем баерак икән, кемнәрнең янчык төбендә әзрәк калды икән әле?!
Өченче катта аның районлашы, «р»ны катырак әйтә торган Мөҗәһит Дәүләтуллин яши иде. Шигырьләр яза. Марсель Давай дигән псевдоним белән газета-журналларда вакыт-вакыт бастыргалый да иде. Бер мәлне хәтта, мәхәббәт турындагы шигыремне «Юность» журналында русча басалар, дип тә мактанып йөрде. Тик менә ике ел үтте инде, ләкин шигыренең журнал битләрендә күренгәне юк...
Айзат шуның янына менеп китте.
Бәхетенә каршы, Марсель Давай өйдә иде. Җәймә генә ябынып караватында ята.
— Әссәләмегаләйкүм, Давай! Нишләп ятыш? Авырмыйсындыр бит?
— Вәгаләйкем әссәлам! Авыррыйм, малай. Ангина.
Давай, сүзен раслау өчен, караватъ янында торган банкага төкереп куйды.
Айзат читкә карап елмаймый булдыра алмады. Давай, үзе группа старостасы булса да, иптәшләреннән авырыйм дип кала да, көндез тынычлап шигырь язып ята иде. Институт ашханәсенә дә кешеләр лекциядә вакытта гына йөгереп барып кайта, тәнәфескә звонок булганчы чыгып тая. Группа журналын да, килмәгәннәрне билгеләү өчен, бер көнне бер, икенче көнне икенче кызга биреп җибәрә. Ә хәйләкәр кызлар моннан Давайның үзенә сиздермичә генә ифрат оста файдаланалар: көн саен лекцияләрдә өч-дүрт кыз булмый, алдан төзелгән расписание буенча киноларга йөриләр. Ә журнал-мескенкәй чип-чиста — бөтенесе килгән. Кызлар да шат, Давай да шат... Ә Давай — башлы малай, зачет кенәгәсендә гел «отлично» да «отлично». Имтиханнан кайтып керә бу. Ишекне ачуга, я, ничек? дип сорыйлар. Давай кулын селти дә:
— Гадәттәгечә! — ди һәм чишенеп урынына менеп ята.
Давай Айзатка карап-карап торды да, әллә ышанмады инде бу

дигәндәй, тагын банкага төкерде. Айзат үгезне мөгезеннән алырга булды.

— Карале, стипендиягә хәтле миңа бераз акча кирәк,— диде.

Давай түшәмгә карап ятты-ятты да җәймәсенә төренеп торып утырды.

— Авторучкаң бармы? — дип сорады.

— Бар.

— Алайса, әнә кәгазь, ал да яз.

— Ни языйм?

— Мин әйткәнне. Әйдә, әйдә, язуыңны бел. Тә-эк. Стипендия аласым барр — 35 сум. Булдымы? «Татарстан яшьләре»ндә берр ррейд мәкаләсе чыкты. Ну, биш сум биррсеннәр ди. Куй 5 сум. Үткән айда «Азат хатын»да берр шигыррем басылды. Куй 12 сум. «Совет Татарр-станы»нда яңа спектакльгә берр ррецензиямне һәм берр мәсәлемне бирделәр. Куй 25 сум. Булдымы? Тукта. Тагын «Чаян»ның ике хатын татаррчага тәрржемә итеп бирргән идем. Өченче сан чыкты микән әле, күррмәдеңме? Чыкты? Ул чагында ведомость баррдыр, соррарга була. Яз, ну 10 сумны. Тә-эк. Бетте бугай инде... Мизхәттән 4 сум аласым барр. Ике ел биррми йөрртә, стипендия көнне булмәсеннән чыгып кача. Ну, бу юлы мин аны эләктеррми калмам. Өстәп куй шунда тагын дуррт тәңкәне. Хәзерр сана, ничә сум аласым барр? Туксан беррме? Әйбәт! Шәп! Моның белән яшәрргә була! Искечә почти мең сум, сизәсеңме, бррат?..

Я, хәзер тагын сана инде. Монысы икенче чут. Икенче җирргә, шуның карршысына яз. Тә-эк. Яз — Асиягә биррәсе барр 17 сум. Куйдыңмы? Габдуллага — 3 сум. Алганыма ел яррым баррдырр инде, һаман турры китерргә алмыйм. Кояшка 10 тәңкәне төрртеп куй. Мәдинәгә — 15 сум буррычым барр. Диләррәгә ничә микән? Әллә ничә тапкырр алдым бугай инде аннан. Соррасаң, биррми калмый, юмаррт та кыз инде. Тә-эк, куй әле Диләррәгә чама белән 20 не. Венеррага — 8, Әлмиррага — тоже 8, Хәбирргә 2 сум дип куй, Абдуллага — 18, Ррозага — 20, тагын... тагын... Әллә бетте микән инде? Юк, бетмәгәндерр, оныткан-мындырр гына. Я, яррый, әкрренләп искә төшәрр әле. Боларрын чутлый торрыйк. Сана әле, күпме буррычым барр икән?

— Йөз дә кырык бер сум,— диде Айзат.

— Ә?!.

— Йөз кырык бер.

— Ә аласым күпме?

— Туксан бер.

— Ах-хах-хах-хах-хай!.. Менә сиңа мә! Әле бөтенесен бирреп бетеррсәң дә, илле тәңкә буррыч кала икән. Булмады бу, бррат! Бу юлы тагын кррышка!

Давай, шулай диде дә, җәймәсенә баштанаяк төренеп, урынына сузылып ятты. Айзат аның янында тавыш-тынсыз әзрәк утырды да, юк, бу кешедән дә рәт чыкмады дип ишеккә юнәлде. Шул чакта Давай битен генә ачып аңа дәште:

— Әй, карра әле, Айзат дус, син миңа берр өч сум акча бирреп торра алмыйсыңмы? Бүген ашамаган әле. Куррыкма, түләррмен, бу юлы аласыларрым күп.

— Аласыларрың күп булса, биррәселәррең аннан да күбррәк шул, дустым,— диде Айзат.— Мин бит үзеңнән сорарга кергән идем, оныттың дамени, алланың тинтәк бәндәсе?

— Әй, шулай бит әле,— диде Давай һәм тагын да ныграк бөркәнеп ятты...

Давайда булмаса икенче кешедә табылды. Айзат Чәчкәсе янына коры кул белән кайтмады, әлбәттә. Бик һәйбәтләп ашадылар-эчтеләр. Иртәгә дә калды.

Ләкин бу вакыйга аларның тормышларын үзгәртеп җибәрергә бер сәбәп булды. Әйтергә кирәк, беренче сәбәп. Ул көнне алар төн авышканчы йокламадылар. Ике арада бик мөһим сөйләшү булды. Дөресрәге, күбрәк Чәчкә сөйләде, Айзат тыңлады. Әнисе дә, этисе дә аларны инде бик күптән, имтиханнар беткәнче генә, үзләрендә яшәп торырга чакыра икән. Кияүләренең ризалыгын гына көтә икән. Алай иткәндә әлек бу бүлмәчектә яшәгән аспирантлар каршында да уңайсыз булмас иде. Ким Риазович моны яхшы белә. Чәчкә белән Айзатка аларда бик яхшы булачак. Өй иркен, комачау итүче юк. Үзләренә аерым бүлмә бирәчәкләр...

Айзат башта бу тәкъдимгә бик нык каршы килде. Уйлама да, андый хәлнең гомергә булачагы юк, я — мин, я — алар, дип, мәсьәләне кабыргасы белән китереп куйды. Әмма сәгатьләр үтү белән Айзат йомшарды. Ләкин монда Айзатны үзсүзсез дип гаепләргә кирәкми. Яшь һәм чибәр кәләшләрнең җылы һәм йомшак кочагы, кайнар сулышы, колакларны иркәләгән өзек-өзек пышылдавы кемнәрнең генә җанын эретеп камыр ясамады инде, егетләр, һәм күпмебезнекен эретәчәк әле! Без дә адәм баласы бит, нигез ташы түгел — гади кеше!..

Менә Айзат та эреде һәм язга кадәр бабаларында яшәргә риза булды.

Алар икенче көнне, их, шунда яшәп карасаң иде дип, Айзат үзе кызыккан — Воровский урамындагы кирпеч йортның өченче катына күчеп килделәр.

## 24

Нәкъ ике сәгать үтүгә, алан тагын кинәт кузгалды. Машиналар, фара утлары белән караңгы урман кочагын айкый-айкый, бер-бер артлы тезелешеп олы юлга чыга башлады. Көннәр коры чагында да тәүлек буе бара торган юлны бер көндә үтеп, көндезге бердә Аю-Ятар урамына килеп керделәр. Машиналар да, юлаучылар да баштанаяк пычранып, сыдырылып, бәрелеп, тәмам йончып беткәннәр иде.

Петр Петрович Аю-Ятарның үзәк урамында райисполком һәм роно белән янәшә йортта тора икән. Машиналар аның капка төбенә килеп туктадылар. Капкадан шунда ук юка гәүдәле, ялан башлы хатын йөгереп чыкты һәм аптыраулы күзләре белән боларга текәлде. Петр Петрович, әрҗә читенә тотынып, аякларына басты.

— Исәнме, Марианна! Әни ничек? — диде.

Хатынның йөзе ачылып китте.

— Исәнме, Петя! Әнинең хәле ярыйсы.

Халык тирән сулап куйды:

— Исән!.. Өлгердек!.. Өлгердек!..

Бу төшкә арттагы машиналардан да җыелып өлгергәннәр иде. Куанычлы хәбәрне ишеткәч, кычкырып сөйләшә, көлешә башладылар.

Петр Петрович шофер алдына килеп басты да аңа берничә секунд карап торды. Аннан соң кочаклап алды.

— Рәхмәт сиңа, дускай! — диде. Алар ашыкмый гына өч мәртәбә үбештеләр.

— Рәхмәт?! — диде Петр Петрович.

— Сәламәт калыгыз! Әнкәгезнең тизрәк терелүен телим! — диде шофер.

— Сезгә дә бик тә, бик тә зур рәхмәт, туганнар! Һәммәсе, һәммәсе өчен!

— Исән-сау булыгыз! Әнигез тизрәк аякка бассын! — дип җавап кайтарды халык. Машиналарга утыра башладылар.

— Сез хәзер гостиницага бара торгансыздыр бит?

— Әйе, шунда барабыз. Чистарынырга, ашап-эчеп алырга, ял итәргә кирәк.
— Озак торырсыз микән?
— Өч сәгатьсез китеп булмас,— диде шоферлар.
— Бик әйбәт! Ул чагында мин сезнең белән саубуллашырга, озатырга өлгерәм икән.
— Бик әйбәт булыр, Петр Петрович.
Машина моторлары кабынды.
— Ә син, дускай, кая барасың? Төш! — дип кычкырды Петр Петрович Айзатка.
— Гостиницага дигән идем, Петр Петрович.
— Ярамый, дускай, төш! Мин сине хәзер үк поликлиникага илтәм. Кулыңны күрсәтмичә ярамый. Бик каты бәрелдең бит. Уен түгел. Төш-төш!
— Петр Петрович, юкка мәшәкатьләнмәгез. Пүчтәк ул. Мин аны оныттым инде.
— Карагыз әле бу бәндәгә,— диде Петр Петрович,— эшләгән урынына килеп, җиргә аяк басарга өлгермәгән, ә мәдиренә карыша башлады инде. Берәр ел эшләсә, ни күрсәтмәс бу миңа... Дускай!?.
Айзат машинадан төшеп калырга мәҗбүр булды. Гаепле төс белән юлдашларына карап:
— Больницага кереп чыгармын да озатырга мин дә барырмын,— дип кычкырды. Машиналар кузгалды. Дуслары боларга кул болгыйболгый китеп бардылар.
— Әйдә, Марианна, керик!
— Әйдә, Петя! Әйдәгез...
— Менә Айзат белән таныш, Марианна. Казанның үзеннән. Бөгелә-Талга тел укытучысы булып килде.
— Бик әйбәт, бик әйбәт! Әйдәгез, Айзат энем, өйгә рәхим итегез!..
Алар, аяк һәм өс киемнәрен өй алдында салып, алгы бүлмәгә керделәр. Уңда пәрдәле бер ишек, каршыда буяулы икенче ишек бар иде. Шунсыннан ак халатлы, түгәрәк кара сакаллы яшь кенә ир чыкты.
— Исәнмесез, Петр Петрович! Кайтып өлгерүегез искиткеч шәп булды. Мин борчыла башлаган идем.
— Исәнме, дускай! Әниең хәле ничек? Чын дөресен генә әйт!..
— Чын дөресе — өметсез. Ул, сезне күрмичә үлмим дип, мин дә аңламаган нindидер серле көчләр табып кына яшәде.
— Ни белән авырый?
— Гап-гади адинамия[1].
— Ник мин кайтканчы ук больницага салмадыгыз?
— Файдасыз, Петр Петрович. Медицина картлыкны бөтенләй үк җиңә алмый әле. Бәхилләшегез, Петр Петрович.
Петр Петрович башын иеп эчке бүлмәгә атлады. Аның артыннан әкрен генә бүтәннәр керде. Петр Петровичның әнисе бик пөхтә һәм зәвык белән җыештырылган зур, якты залның түрендә биек караватта ята иде. Күзләрен аның йөзеннән алмыйча, тавышсыз гына үксеп, баш очында эре сөякле бер карчык утыра.
Авыруның өстенә ак тышлы одеял япканнар. Ул шуның өстенә таяк шикелле нечкә беләкле, карандаш кебек нечкә бармаклы саргылт кулларын сузып салган. Ак мендәр өстенә ак чәчләре тузгып таралган. Битләре бәләкәй, борыны очлайган, ак кашлары астыннан җемелдәп кара күзләре карый. Килеп кергән кешеләрне күргәч, ул күзләр тагын да ялтырап китте. Әби күксел иреннәре белән елмайган сымак итеп куйды:

[1] Картлык, көчсезлек, зәгыйфьлек.

— Менә рәхмәт, улым!.. Кайтыр дип ышанган идем...

Петр Петрович караватъ янына барып тезләнде, әбинең нечкә бармакларын сыйпады.

— Авырып киткәнсең икән, әни!.. Кизү генәдер. Үтәр!.. Тирләгән килеш ишек алдына чыккансыңдыр, җил бәргәндер... Мин бик әйбәт дарулар алып кайттым... Әчәрсең дә төренеп ятырсың. Иртән торганда тап-таза кеше булырсың... Борчылма, үтәр...

— Ялганчыдан кояш бизгән, улым. Ләкин синең бу ялганың изге ялган. Терелмәм инде мин, Петя. Карт кешенең сәламәтлеге иске кием шикелле ул: бер җирен ямыйсың, икенче төше ертыла, анысын ямыйсың — өченче урыннан сүтелә...

— Әни!..

— Кем бу?.. Нинди егет?.. Беренче күрәм... Кемгә охшаган дип әйтим...

Айзат тетрәп бер адым алга атлады:

— Мин — татар егете, апа! Татарстаннан килдем...

— Рәхмәт... рәхмәт, балакаем!.. Спасстан түгелме?

— Түгел шул, апа... Минзәлә районыннан.

— Без үзебез Спасснықылар... Килүебезгә күптән инде... кырык ел... Бу җирләр дә туган җиргә әйләнде... Кызым... безнең картечке ерак микән?.. Булмаса, куйчы минем каршыма...

Марианна шкафтан тиз генә бер фоторәсем алып, аны өстәл өстенә сөяп куйды:

— Менә, әни!..

— Рәхмәт, Марианна кызым!.. Соңгы тапкыр үзләренә карыйсым килә. Саубуллашасым килә...

Әби, фотога карап, уйга чумды. Фоторәсемдә бер семья иде. Уртада күперенке мыеклы ир белән алдына бала утырткан мөлаем хатын, алар янында унике-унөч яшьләр тирәсендәге ике малай һәм бер кыз.

— Ата белән ана... тырышып-тырышып бала үстерә...— диде ул хәсрәт белән.— Ә балалары... үсәләр дә, ата-ананың икесен генә... ялгыз калдырып... кайсы кая таралып бетәләр... Ялгыз калган ата белән анага иптәшкә картлык килә... Картлык инде аларны ташламый. Каберга хәтле бергә бара...

— Әни, зинһар өчен!.. Сезгә дулкынланырга ярамый!..

— Миңа хәзер бөтен нәрсә дә ярый... Кызым... Хөршидә бәбекәем!.. Нинди моңлы иде синең тавышкаең!.. Син җырласаң, сандугачлар, оялып, сайрауларыннан туктый иде... Кояш баеган чакларда күл буенда җырласаң, күңелләрем тулып мин жылый идем... Моңлы бала гомерсез була шул, кызым!.. Синең дә гомеркәйләрең булмады... Белорус туфрагында синең кабереӊ, Хөршидә бәбекәем!.. Күлмәк кигәннәр бер кайта, кәфен кигәннәр кайта алмый шул...

Вахит улым!.. Оя башым!.. Өйне почмагыннан тотып күтәрә торган егет идең бит син!.. Аюлар да ябешеп җиңә алмый иде, оланым! Немец танкы сине ничек җиңде соң, улым?!. Күрми, сизми калдыңмы?.. Йоклаган идеңме әллә?.. Син ясаган агач сәнәкләрне үзеңнән башка... берәү дә күтәрә алмады... Чиннектә сөялеп тордылар да тордылар... Мин... аларны үзең кайтырсың дип саклаган идем... Кайта алмадың... батыр кошым!.. Мәскәү янында синең кабереӊ... Авыр туфрагың җиңел булсын... балам!..

Давыт улым!.. Акыллы да булып үстең соң. Бу бала зур кеше булыр, укымышлы булыр, диләр иде... Бөтен тирә-як... сиңа сокланып карый иде... Без атаң белән... куана идек... Төннәр буе серләшеп чыга идек... Безнең фамилияне бөтен... дөньяга яңгыратачак безнең бу баласы, дип атаң куанып бетә алмый иде. Кулыңнан бер дә китап төшмәде. Ашаган чакларда да... йоклаган чакларда да... Мин, күзеңне бетерәсең бит инде, житәр, дисәм... атаң, укысын, укыган кешенең гомере...

үкенечсез үтәр дип әйтә иде... Ул үкенечсез булмый шул... Акыллы адәмнәр дә җиңә алмыймыни... соң сугышны, улым?.. Укыган китапларың да... файда итмәделәрмени!?. Сине фашистлар үтерде... ә син укыган китаплар исән. Мин аларны синнән соң туган балаларга бирдем. Укып акыл җыйсыннар. Бәлки сугыштан көчлерәк бирәр әмәлне алар табарлар... Син, Давыт бабкаем, фамилиябезне бөтен... дөньяга шаулатырга өлгермәсәң дә... аны намус белән ил читенә кадәр илтеп җиткердең. Молдаван җирендә синең кабереңң... Мәңгелек йокың тыныч булсын, тыныч... булсын... сөекле балакаем!..

Ә синең гүрең кай төштә... соң... төпчегем, Уралым!? Белмибез бит, белүчеләр табылмады. Суларны бик ярата идең — әллә суларга актыңмы!?. Утларны бик ярата идең — әллә утларда яндыңмы? Җирләрне бик ярата идең — кайсы җирләрдә синең кабереңң... шаян төпчегем... Кай дәүләтләрдә?.. Үзебезнең изге туфрактамы?.. Әллә чит-ят илләрдәме?.. Кабер өстеңнән чит-ят җилләр исәме?.. Әллә ялгыз гүрләрең дә юкмы синең... балакаем!? Дүртегезнең арасында иң наяны, иң... шаяны син булдың... Бәбекәем, төпчек балам, кайларда ягуыңны, кайларда егылуыңны... немец-мәлгунь кайларда яшь гомереңне өзгәнен белсәк тә атаң белән... анаңның ачы хәсрәте бер мыскал кимрәк булыр иде... Бер тамчы күз яшебез кимрәк... тамар иде... Белеп булмады... Урал улым... Атаң белми үлеп китте... Мин бүген... китәм... Хәзер... Белмим!.. Ни үкенеч!.. Ни үкенеч!..

Карт!.. Мөслимҗан!.. Сиңа әйтәм, кеше-күлән арасында яман балалар... үстермәдек, әйе бит?.. Балаларыбыз, аллага шөкер, ким-хур булмады... йөзебезгә кызыллык китермәде... Шатлык бу, аталары! Икебезгә дә... Без синең белән тату тордык.. Куанычларыбыз да, хәсрәтләребез дә... бергә булды... Син яртысын күтәрдең... мин яртысын... Шулай менә гомерләр дә үтеп китте... Тыным кысыла... карт... Артык сөйли алмыйм... Мин дә хәзер синең янына... балалар янына... сезнең яныгызга китәм... Хушыгыз!...

— Мәрзия! Мәрзия!.. Җитәр, хәл җый, дулкынланырга ярамый! — диде аның баш очында утырган карчык.

— Әни! Тыныч кына, әйбәт кенә ятарга кирәк. Врач куша,— диде Петр Петрович.

— Ярый, картечкәне алыгыз,— диде әби әкрен тавыш белән.— Җитә бугай. Бәхилләшик, туганнар!.. Руфина Германовна, кадерлем. Хуш!.. Бәхил бул!..

— Мәрзия дустым, син ни сөйлисең? Кирәкми!..

— Кызым! Марианна!.. Марианна Фадеевна! Бәхил бул, балам! Бик зур рәхмәт сиңа!.. Үз анаңдай күреп карадың, тәрбияләдең... Мин сиңа бик бәхил! Үзең дә бәхил бул!..

Марианна Фадеевна яшенә тыгылып сүзен дә әйтә алмады:

— Әнкәй!.. Әнкәй!..

— Я, хуш, улым. Сау бул, Петя!.. Үз улым шикелле булдың... Рәхмәт сиңа! Бәхил бул!..

Петр Петрович аның нәни кулларына битен куеп, хәрәкәтсез калды.

— Син дә исән-сау бул, Татарстаннан килгән улым!.. Кайтсаң, Себер урманнарында карт сөякләре ятып калган Мәрзия әбиеннән Иделгә сәлам әйт!.. Тәүфыйклы бул. Әйбәт эшлә, әйбәт яшә. Бу илләр сине рәнҗетмәс. Ул да үзебезнеке... Минем дә гүр туфрагым йомшак булыр, алла боерса. Ник дисәң, шушы туфрак өчен шәһит киткән арыслandaй... өч ул белән таң йолдызыдай сылу, ут чәчәге шикелле тере кызны мин табып үстердем бит... Дүртесен дә... Ә хәзер...

Әбинең соңгы үтенечен тыңлап, барысы да җылый-җылый чыгып тордылар да җылый-җылый кире керделәр. Җан бирү газабын якыннарына күрсәтергә теләмәгән нык ихтыярлы Мәрзия әбинең сулышы киселгән, гомер елгасы кипкән иде. Ул, нәкъ баягы шикелле, нечкә

кулларын ак җәймә өстенә куеп, ак чәчләрен ак мендәргә таратып күнелле төш күрә-күрә йоклаган сабый шикелле сабыр һәм тыныч кына ята.

Ул матур һәм горур үлде!..

...Айзатның хәле үзе уйлаганнан катлаулырак булып чыкты. Авыр ящик төшеп бәрелгәч, кулының беләзек сөяге чатнаган иде. Гипсларга туры килде. Аны марля белән муенына асып кайтып кергәндә, Петр Петрович алгы якта телефоннан кем беләндер бәхәсләшеп ята иде.

— Абсурд[1] бу, әйе, әйе, абсурд,— дип кычкыра иде ул.— Без аны эшеннән дөрес алдык... Ул — абруе чыланган кеше. Тәрбияче түгел... Әйе, әчкече... Буынсыз урынга пычак салмагыз, иптәш Иванов, кабыргасы белән дөньяга килгән ул адәмне мин барыбер кире алмаячакмын... Әйе. Өлкәгә булмагае, Мәскәүгә барсын. Юк!.. Аның авруг[2] бәндә икәнен шундук сизеп алачаклар. Тагын да яхшы булачак. Безнең өчен... Әйе, мин каршы һәм үзем мөдир чакта аны мәктәпкә якын да җибәрмәячәкмен... Әйе, катгый сүзем!.. Өркетмәгез, иптәш Иванов. Әйе, өркетмәгез дим. Сез алай икән, мин дә райком бюросы члены! Аннан соң шуны онытмагыз — мин коммунист, карт коммунист!.. Хушыгыз!..

Петр Петрович, трубкасын куйгач, Айзатның кулына карап торды.

— Эшләр шуңа ук киттемени-и? — диде.

— Зыян юк, Петр Петрович.

— Авыртмыйммы?

— Сизелми дә. Энә очы кадәр генә чатнаган, кызлар алдында яхшырак кына. Урам буйлап яралы солдат шикелле кәпрәеп кайттым.

— Алайса, ярый. Вакыт җитә, юлдашларыбызны озатырга барыйк. Менә бит, менә бит нинди бәхетсезлек,— Петр Петрович өзлексез кереп-чыгып торучы әби-бабайларга, бер бүлмәдән икенче бүлмәгә үтеп-сүтеп йөрүче, пышылдап кына сөйләшүче хатын-кызларга карап, башын чайкап куйды.— Болар йоласын китерсеннәр инде. Без комачауларбыз гына, без ни беләбез. Бик авыр хәсрәт, дускай, авыр, авыр...

Алар чыгып киттеләр.

Бәләкәй агач гостиница, аның ишек алды, хәтта урамы да машина, трактор, жигуле ат, кешеләр белән ярминкәдәй гөр килеп тора иде. Ләкин Петр Петрович белән Айзат үз колонналарын бик тиз таптылар. Машиналар чистарган, адәм рәтенә кергән, кешеләрнең дә ашап-эчеп, ял итеп алган күңелләре күтәрелгән иде. Алар, кузовта үзләренең нәкъ элекке урыннарына утырып, машиналарның кузгалуын көтәләр иде.

Менә саубуллашу минутлары җитте. Петр Петрович белән Айзат кадерле юлдашларының барысы белән дә берәм-берәм кул кысып күрешеп чыктылар, аннары, машиналар урам чатына кереп югалганчы, янәшә басып кул болгап калдылар...

Яңадан кара урманнарга кереп киттеләр. Юллары озын әле, юллары авыр! Ай ул юллар! Кешеләрне интектерер өчен яратылган юллар — сезне каргамыйча булмый. Кешеләрне дуслаштыра, берләштерә, туганлаштыра торган, авырлыкларны җиңеп үтәргә, егетләрне егетлеккә өйрәтә торган юллар — сезне мактамый нишлисең! Менә Айзат та өч көн юл килде. Шул көннәр эчендә алар белән гомер буе бергә яшәгән шикелле якынаеп өлгерде. Киттеләр. Озын юллар буйлап тагын еракларга — еракларга киттеләр. Үзләре белән татар егетенең дә уй-хисләрен, йөрәгенең бик кадерле бер кисәген алып киттеләр, ә үзләрен — сагынмакка истәлек итеп калдырып киттеләр. Гомер юлларында очрашырлармы тагын бер?..

Хәерле юл Сезгә, туганнар!..

---

[1] Мәгънәсезлек, акылга ятышсыз нәрсә.
[2] Алдакчы, шарлатан.

## 25

Каранғы төшә башлады. Кырый урамнан, тулы имчәкләрен салмак кына чайкый-чайкый, көн буе ашап авырайган сыер көтүе кайтты. Ике катлы өйләрнең аскы катларында утлар кабынды. Һавадан, канатларын җәһәт кага-кага, бер оя чүрәкәй үрдәк үтте.

Петр Петрович яртылаш агарган куе озын чәчләрен сыйпады. Сул кулындагы «Сибирь — моя Родина» дигән сүзләре бер сузылып, бер җыерылып алды.

— Эһе-һе-һе... Менә, яңа дусларыбыздан аерылып та калдык. Ай күрде, кояш алды. Кайтыйк, Айзат.

— Ямансу!.. Нигә алай икән, Петр Петрович? Моннан өч көн элек мин аларның дөньяда яшәгәнен дә белми идем. Ә бүген ямансу.

— Шулай булуы әйбәт тә, дускай. Кеше, дусларыннан аерылгач, ямансуларга тиеш.

— Петр Петрович!..

— Атлыйк, дускай... әни янына...

Алар кире борылып киттеләр. Мөдир район мәгариф бүлеге янынннан башын аска иеп уйланып үтте. Ниндидер СМУны үтеп, чаттан борылгач, аларның юлын бер төркем яшьләр бүлде. Алар тротуарны тутырып басканнар да, шаулашып, кемнәндер нәрсәдер үтенәләр, нидер исбатлыйлар. Ә ул «кем» — кыршылган песи якалы озын пальто кигән, чуалчык сакалына мендәр йоны кереп адашкан, озын кашлы, кечкенә күзле, усал чырайлы карт — кулларын болгый-болгый кычкыра:

— Эш сәгатем бетте. Все! Ишекне бикләдем. Иртәгә килерсез. Юл бирегез дим мин сезгә, басурманнар!.. Милиция чакырам!.. Мили-ци-яәә!..

Яшьләр дә төшеп калганнардан түгел бугай: картның янавына борын очларын да селкетмиләр, уны белән җавап кайтаралар:

— Хакыгыз юк!.. Мондый чакта эш сәгате бетте дип тормыйлар!..

— Әгәр өчкә кадәр санаганчы ачмасаң, райком секретарена шалтыратабыз. Министрга! Өйләнешү министры бармы?.. Мәскәүгә телеграмма сугабыз.

— Уйнап йөрибезме әллә?

Петр Петрович тыңлап-тыңлап торды да, теге агай һаман киреләнеп торгач, төркемгә якынрак килде.

— Исәнмесез, иптәшләр! Ни бүлешәбез?

Аның калын тавышын ишеткәч, тилгән күргән чебешләр шикелле, яшьләр шым булдылар. Карт, шатланып, озын куллары белән яшьләрне аралый-аралый болар янына килә башлады.

— Петр Петрович! Хөрмәтле Петр Петрович!.. Карагыз әле... Закон бозалар, басурманнар, закон хәтле законны бозарга батырчылык итәләр...

— Курыкмагыз. Без беркемгә дә закон бозарга юл куймабыз.— диде Петр Петрович.— Ә сез, дуслар, ни телисез, рәтләп кенә аңлата алмыйсызмы? Кемнәр сез?

— Без Башкортстаннан, Салават шәһәреннән. Унны бетергәч, таралмадык, классыбыз белән Себергә килдек. Нефтькә. Иртәгә иртән катер булыр, диделәр. Төньякка китәбез.

— Бик яхшы! Котлыйм! Безнең өлкәгә сезнең шикелле белемле яшь эшчеләр бик күп кирәк. Чөнки бездә нефть үзе дә күп бит... Ә менә монда, хәзер ни даулыйсыз?

— Тимербикә белән Дим язылышырга тели.

— Хәзер үкме?

— Әйе, хәзер үк. Ник аңа исегез китә? Ун ел бергә укыдылар. Бер-берсен беләләр. Өзелеп яратышалар. Алар Салаватта ук гариза биргәннәр иде инде. Бүген айлары тулды. Документлары бар.

— Шулаймыни? Карарга мөмкинме?

— Тимербикә! Дим! Килегез әле, ник анда качып торасыз?

Егетләрне, кызларны аралап, Айзатлар янына зур гәүдәле, киң күкрәкле, чем-кара чәчле, сызылып кына килүче кара мыеклы башкорт егете чыгып басты. Ул, иң кирәкле, иң житди вакытта гына качып китмәсен дигән шикелле, үзе кебек үк сылу гәүдәле кызның кулыннан тоткан иде.

— Менә, без инде ул, агай.

— Бүген язылышырга телисезме?

— Бүген дигән идек. Менә Салаватта биргән документ.

— Әйе-е, болай бар да тәртиптә шикелле.

Кияү белән кызның сабакташлары, моны ишеткәч күңелләре күтәрелеп, шаулаша башладылар:

— Алай булгач, абый, язылышырга ярый, димәк?

— Ну, абый, ничек? Ачсын инде ишеген, бассын инде пичәтен!..

Петр Петрович теге кире кешегә карап:

— Аркадий Борисович, нишлибез? Минемчә, яшьләрнең теләкләренә каршы килеп булмас,— диде.

— Петр Петрович! Эш сәгате беткән бит инде... Сынау вакыты үтмичә. Закон бозып... Күрмәгән-белмәгән халыкны? Ай-һай, белмим, белмим. Мона кадәр туры килмәде, Петр Петрович, әйтә алмыйм...

— Мона кадәр нефть һәм газ чыгарырга да туры килгәне юк иде безгә, Аркадий Борисович. Европадан шушы кадәр халыкны кабул итәргә дә туры килгәне юк иде.

— Аңлыйм, тик...

— Сүз чыга калса, гаепне миңа аударырсыз.

— Сезнең өчен генә, Петр Петрович, сүзегезне тыңлап кына эшлим бу эшне.— ЗАГС мөдире шалтыратып йозакны ачты.— Әйдәгез, яшьләр, язылышырга рәхим итегез!

Яшьләр ура кычкырдылар, ләкин кереп китәргә нишләптер ашыкмадылар. Петр Петрович ягына карый-карый пышылдашырга тотындылар һәм уртадан сары чәчле бер егетне этеп чыгардылар.

— Сез, абый, гафу итегез! — диде сары чәчле егет.— Без белергә теләгән идек... Сез кем булып эшлисез?

— Мин РайОНО мөдире,— диде Петр Петрович, елмаеп.

— Ә-ә-ә,— диде сары чәч, өмете өзелгән тавыш белән.

— Ник алай күңелегез төште, дускай? РайОНО мөдире булу начар эш түгел.

— Түге-ел. Бу кире бабайны да тыңлаткач, без сезне әллә...

— Бүтән берәр зур кеше дип уйлаган идегезме?

— Әйе. Ярдәм итмәссезме дигән идек. Чөнки безнең куңарга урыныбыз да юк бит әле. Урамда әле без. Ятакта урын юк. Баш тыккысыз. Төрле бригада, артельләр тулган. Сөйләшеп тә тормадылар.

Айзат Петр Петровичка карады да, үзе дә сизмәстән, нык тавыш белән:

— Ә сез аларны, Петр Петрович, берәр мәктәпкә кертегез,— диде.

— Һм, чыннан да...— диде Петр Петрович, Айзатка мәгънәле елмаеп,— туйны урамда ясап булмый инде аны. Бигрәк тә көзге салкын төндә. Яшь кәләш белән кияүгә дә, туй итәргә дә жылы һәм якты бина кирәк. Айзат әйткәнчә, мин сезгә мәктәп бирә алам.

— И-и, абый, рәхмәт!

Петр Петрович кесә дәфтәрен алып нидер язды да язган битен ертып сары чәчле егеткә тоттырды. Аннан соң шушы урамның башында — ачык яландарак торган мәктәп бинасын күрсәтте.

— Әнә, мәктәп артында бер катлы яңа интернат булыр. Интернатта Суворов гренадерларына охшаган озын мыеклы Степан абый булыр. Язуны шуңа тапшырыгыз. Интернатның ашханәсе иркен. Туйны шунда ясарсыз. Йоклавын ике кечкенә бүлмәдә йокларсыз. Караватлар кыска

инде кыскасын, тик бер төнне аякларыгызны аякләрегезгә терәп булса да түзәрсез. Ләкин бер шартым бар: иртән иданнәрне юып, һәр нәрсәне тәртипкә салып китегез. Чөнки интернатны комиссия кабул итте инде.

— Ялт иттереп китәбез!

— Патша сарае шикелле булыр!

— Болай булгач, бар мәсьәлә дә хәл ителеп бетте,— диде Петр Петрович.— Ә сезне шушында гына тәбрикләргә рөхсәт итегез! — Ул Тимербикә белән Димнең кулларын кысты.

— Туйга килегез, абый? Туй дип инде... теге ни... үзебезчә, юлдагыча... Импровизация [1]...

— Ничек булса да туй күңелле инде ул. Ләкин килә алмам, бәлки ахырынарак барып урарга тырышырмын. Ә хәзергә бәлки менә Айзат дус сезгә кушылыр? Сезнең якташыгыз. Шулай ук бүген генә килде. Укытучы.

— Кайдан?

— Татарстаннан. Минзәләнеке мин.

— Һа-а! Татар егете алайсаң! Исемең ничек, якташ?

— Айзат.

— Айзат туган, киттек! Сау булыгыз, Петр Петрович! Туйга китәбез!

Яшьләр шау-гөр килеп, уйнап-көлеп ЗАГС ишегеннән кереп киттеләр.

Унбиш минуттан интернат ашханәсендә сәер туй башланды. Бәләкәй өстәлләрне бергә кушып озынны ясадылар. Түргә килен белән кияү утырды. Кияү янына кияү егете, килен янына тагын бер кыз урнашты.

Өстәлдә күмәч, балык, салкын ит, казылык, кильки, суган, кыяр, помидор, берничә төрле консерва, печенье, ирис конфеты һәм, бик мул дип әйтерлек булмаса да, вино бар иде. Степан абзый әллә кайдан бер чиләк сыешлы чын самовар табып кергәч, һәм ул тиз арада бөтен бүлмәне пар белән тутырып, чын паровоз шикелле уф-уф итеп кайнап та чыккач, кешеләр икеләтә җанланды, туй күңелләнде. Һәркем үзе үзенә туйбашы һәм табынчы булды.

Бераздан туй кызып та китте.

Интернационалистлар туе икән бу, дип уйлады Айзат. Чөнки монда башкортлар да, татарлар да, руслар да бар. Һәм алар, әлбәттә, башкортча да, татарча да, русча да сөйләшәләр иде.

— Гаҗәп,— дип куйды Айзат.

Янындагы дусты аның сүзләрен икенче төрле аңлады бугай: өстәлдәге нигъмәтләргә күз йөртеп алды да:

— Нишләйһең, бик капыл уйланды бит. Вакытына күрә түе, далаһына күрә күе,— диде. Аннан соң көрсенеп:— И-их, бына хәзер һыуһындар кангансы кымыд эсһәң ине!.. Әйдә, күтәрдек! — дип өстәде.

Кинәт кемдер:

— Ачы! — дип кычкырып җибәрде. Аны гөрләп күтәреп алдылар:

— Ачы!.. Ачы!..

Аннан соң кинәт тын калып, кияү белән килен үбешүен кызыгып карап тордылар. Айзат күршесенең күзләре мәзәк кенә ялтырап китте. Ул көрсенде һәм:

— Кыз бала нәзек була,
Кочмагыз, язык була;
Кыз баланы суырып үпсәң,
Өч айлык азык була,—

дип моңаеп алды.

---

[1] Бу очракта тиз генә, хәзерлексез эшләү мәгънәсендә.

Бераздан, гелән җырлау булмас, әйдәгез биибез, дип кияүне биергә кыстый башладылар. Дим ялындырмады. Торды, киемнәрен рәтләде, күршесенә дәште:

— Агаем, давай «Перовски»ды!

Тегесе кай төшеннәндер жиз курай тартып чыгарды да өздереп уйнап җибәрде. Дим «һоп!» дип бер аягы белән идәнгә китереп басты, кош тотарга барган шикелле әз генә иелә төште, сул кулын өскәрәк, уң кулын аскарак сузып җибәрде. Һоп!.. Тагын һоп!.. Һоп! Аяк табаннары идәннән аерылды. Ут чыгара торган бу биюне туй исе китеп карады, биючене дә дәртләндереп, үзе дә дәртләнеп, кул чабып, кычкырып торды.

Киленгә чират житте. «Иыуасалы»ны йырла әле» диделәр. Анысы җырга дигәндә оста булып чыкты. Аннары күмәк җыр, биюләр китте...

Айзат бер җай туры китереп баскычка чыкты. Төн карангы, җылы иде. Аңа бөркү бүлмәдән соң рәхәт булды. Күкрәген тутырып иркенәеп сулый башлады. Шул чагында карангы күктән монсу гына кангылдашып киек казлар үтте. Егетнең кинәт эче пошып, йөрәге сикереп куйды. «Менә мин дә шул казлар шикелле кыйнгылдаша-кыйнгылдаша күрмәгән-белмәгән илләргә киттем түгелме соң? — дип уйлады ул.— Күзгә карангы төн, моңарчы күрмәгән-белмәгән кешеләр арасында утырам. Ә туган-үскән илләр еракта калды. Сөйгән яр да, әти-әниләр дә, туганнар да, дус-ишләр дә. Кайчан кайтырмын, кайчан күрермен аларны? Кыйнгылдашырсың! Кыр казларыннан арттырыбрак та җибәрерсең әле!..»

Шул чагында тавышсыз гына ишек ачылды. Юеш сукмакка, төн каралыгын кисеп, ут яктысы төште. Дим икән. Кияү, тирләгән маңгаен сөртә-сөртә, уфф! дип куйды. Әзрәк җилләнгәч:

— Көчкә качып котылдым, секундка да күзләреннән югалыр хәл юк,— диде.

— Кәләшеңнән бик иртә качарга ниятләгәнсең әле син,— диде Айзат көлеп.

Дим дә аңа кушылып кеткелдәде.

— Юу-ук! Качаммы соң, җүләр! Һәр ирнең үз Зөһрәсе бар, диләр. Минем өчен Тимербикә — Зөһрә. Без аның белән бер авылдан. Күршеләр. Яшьтән үк яратышып йөрибез... Ә хәзер Тимербикә — ир хатыны. Димнең законный бичәсе! Во! Янына килергә маташучы нахаллар күренсә — иманнары җиде кат булып, алтысын суырсам, җиденчесе калырлык булса гына килсеннәр...

— Рәте бар икән шул.

— Бу дөньяда бер эшне дә уйламыйча эшләргә ярамый.

Эчтә, гармунга кушылып, моңлы тавыш белән бер егет җырлап җибәрде.

— Мин керим,— диде Дим, җыр кабат ишетелмәгәч,— Тимербикәм мине югалтып, аптырап утырмасын, бахырым. Син керәсенме?

— Юк әле, бераз торам.

Дим атылып кереп китте. Айзат ямансулап «ә Чәчкә мине озаккарак югалтмагае әле» дип уйлады...

## 26

Капка ачылган тавыш аның уйларын бүлде. Берәү әкрен генә атлап баскычка якынлашты. Тәрәзә яктысына килеп кергәч, Айзат аны таныды — бу Петр Петрович иде.

— Петр Петрович, мондарак килегез, монда коры,— дип дәште Айзат.

— Ә-ә, синмени бу, дускай! Нишләп урамда торасың?

— Эчтә бөркү, әзрәк тир катырыйм дигән идем.

— Туй ничек үтә? «ЧП» лар юкмы?

— Туй менә дигән! Ул-бу юк. Уйныйлар, көләләр, җырлыйлар.

Петр Петрович баскычка килеп утырды.

— Туй шулай күңелле үтәргә тиеш тә. Гомер буена истә кала торган кадерле көн бит ул.

— Ә сезнең хәлләр ничек? Анда... өйдә? — диде Айзат, моңа кадәр сорамый торуына уңайсызланып.

— Кеше үлә, эше мәңге кала,— диде Петр Петрович, әкрен генә,— начары да, яхшысы да. Ә минем әнине яхшы яктан гына телгә алып, озак сөйләрләр, бик озак онытмаслар. Мин дә... Барыбыз да... Җиргә киләләр, җирдә көләләр, ахыр килеп, җиргә керәләр. Без дә аны иртәгә җиргә күмәчәкбез... Һәм аларның нәселе шуның белән бетәчәк. Мөслимҗан бабайның җирдә нәселе калмады...

Озак кына сүзсез утырдылар.

— Гитлер аларның нәселен кисте-е...

— Петр Петрович, сез үзегез рус инде, әйеме?.. Ә әниегез Мәрзия исемле. Татарстаннан килгән... Аннан... Аннан соң сезнең залыгызда биш портрет бар... Рәттән тезелеп торалар... Иң башта мәрхүм Мәрзия әби, аннан аңа охшаганрак бер кыз... Хәрби киемдә. Аннан сезнең портрет. Сездән соң хатыныгыз Марианна Фадеевна, Марианна Фадеевна янында — бу як читтә сезнең тагын бер әниегез Руфина Германовна. Сез уртада, ике ягыгыздан сезгә ике кыз һәм ике әби карап тора... Бишәү. Ике әниегез!..

— Аңлашылды, Айзат, дәвам итмәсәң дә була.

Тагын тынып калдылар. Урманнар артында озын итеп пароход кычкыртты. Эчтә такмак әйтә-әйтә биергә тотындылар.

— Руфина Германовна минем үз әнием түгел,— диде Петр Петрович.— Ул Марианнаның әнисе, хатынымныкы. Бүген дөньядан киткән Мәрзия әнием дә үземнеке түгел. Ул — Хөршидәнең әнисе. Вахитның, Давытның, Уралның һәм Хөршидәнең сөекле әнисе. Ләкин минем өчен дә бик сөекле кеше...

Мин үзем төп Себернеке түгел. Белоруссиядән. Гражданнар сугышы чорында, энем белән икебезне ачлыктан коткарып калу өчен, Себергә алып килеп, балалар йортына урнаштырганнар. Әти-әниебез кемнәр икәнен, аларның исәнме-үлеме икәнен без белмәдек. Мин аны әле дә белмим. Ул гына да түгел — мин үземнең чын милләтемне дә, чын исемемне дә, фамилиямне дә белмим. Петр Петрович Петров дип теркәгәннәр дә куйганнар. Истә калдыру өчен унай бит. Ул болганчык елларда аны кем тикшереп торсын. Ярый әле, ач үлем тырнагыннан йолкып калганнар. Шунысына гомер буе рәхмәт укыйм...

Шулай итеп үстек. Безне аермадылар. Бергә яшәдек, бергә укыдык. Соыннан шәһәргә күчтек. Үз көнебезне үзебез күрә башладык. Озакламый энекәш зоотехникум тәмамлады һәм туган-үскән якларга кайтып китте. Анда бәлки әти-әни турында берәр хәбәр ишетербез, бәлки туган-тумачаларны очратырбыз дип уйладык.

Мин педтехникумда укып калдым. Аннан пединститутка кердем. Тулай торакта яшәдем. Ил ни күрсә, шуны күрдем.

...Һәм утыз тугызынчы елның егерме өченче февралендә сәгать унда Хөршидәне беренче мәртәбә очраттым. Бик якты, кояшлы иртә иде ул. Бер иптәш малай белән шәһәр паркындагы катокка киттек. Кеше күп түгел иде. Биш-алты әйләнеп чыккан идем инде. Кызу гына шуып барганда, каршыга килүче кыз, читкә тайпылып өлгерә алмыйча, миңа

килеп бәрелде. Мин дә ничектер, бәхетемә каршыдыр инде, борыла алмый калдым. Кукрәккә кукрәк килеп бәрелештек тә, егылмас өчен, бер-беребезне кочаклап алдык. Бөтерелеп киттек. Ләкин барыбер егылдык. Кузгә-куз карашып тик утырабыз боз өстендә. Башта кыз көлеп җибәрде, аннан — мин.

Шушы секунд хәтеремә һич җуелмаслык булып гомерлеккә кереп калды. Аның башында куперенке ак йон башлык, өстендә кукрәген һәм билен кысып торган костюм иде. Кашы-кузе кара, бит очлары суыкта алма кебек кызарып киткән, башлыгыннан чыгып куренеп торган кара чәчләре бәсләнгән, ап-ак тигез тешләре энҗе шикелле ялтырый. Мин аны менә купме ел инде, гел шулай итеп төшемдә курәм. Ул сагышлы төш гомерем буе гел шулай кабатлана, һич кенә дә, аз гына да узгәрми, тоныкланмый. Яп-якты көн, каток, Хөршидәнең елмаюдан чокырайган бит очлары... Ул чакта радиодан бик матур көй уйнаталар иде. Ләкин анысы хәтердә калмаган. Нинди көй булгандыр — белмим. Гомер буе уйлыйм, гомерем буе исемә төшерергә тырышам — юк, булмый, булмый. Ә узе өметләндереп тора. Тел очымда гына шикелле. Менә-менә исемә төшәр дә шатландырыр шикелле.

Хөршидә белән танышкан көнне мин, кинәт кенә дөньяның ифрат матур икәнен куреп, таңга калдым.

Ул медицина институтында укый иде. Кырыгынчы елның язында Хөршидә мине узләренә кунакка алып китте. Мин, билгеле, куанып риза булдым. Минем барыбер, әнемне чутламаганда, җәй уткәрер урыным юк иде. Аннан соң бу якларда элек-электән ук төрле милләт халкы бергәләшеп, дус булып яшәп килгәннәр. Бөтенесе бергә. Шуңа курә рус кызы татар егете, татар кызы рус егете белән дус булып йөрсә дә, кунакка алып кайтса да гаеп итеш юк.

Хөршидәнең әтисе Мөслимҗан абый, әнисе Мәрзия апа, абыйлары Вахит белән Давыт, энеләре Урал безне кая утыртырга да, ни белән сыйларга да белмичә, шатланып каршы алдылар. Ул җәй минем гомеремнең иң бәхетле, иң якты җәе булды. Каникулны шунда уткәреп, көз көне уку башланганда гына шәһәргә кайттык...

Кичә син мине Ширбәт инеше янынnан эзләп таптың. Үлән арасында кумелеп яткан ак нигез ташларын да курдең. Бу — аларның нигезе. Хөршидә туып-ускән йортның нигезе. Алар шул тугәрәк кул янында узләре генә яшиләр иде. Мөслимҗан абый урман саклый, балык тота, киек-җәнлек аулый, улллары аңа ярдәм итә. Биш чакрымда гына зур авыл. Кирәк-әйбер алырга кибете, укырга урта мәктәбе бар. Җәй көне кул аша көймә белән, кышын чаңгы киеп турыдан гына йөриләр. Ялгыз яшәсәләр дә, кешеләрдән, дөньядан аерылып тормыйлар. Гомер буе дачада яшәгән шикелле.

Гомеремнең иң матур айлары шул җәйге айлар булды. Без: Вахит, Давыт, Урал һәм мин — бөтенебез бер туган, агалар-энеләр шикелле яшәдек. Иң иркәсе — Хөршидә! Ул — Вахит белән Давытның сеңелесе, Уралның апасы, минем сөекле ярым иде. Без йөзек булсак, ул каш булды, ул — ай, без ай тирәсендәге йолдызлар идек...

Бер кичне, тулган айга һәм аның кулдәге көмеш шикелле ялтыр юлына карап, узебезнең өянкеләр төбендәге эскәмиябездә утырган чакта Хөршидә җилкәмә башын салды да:

— Петя, мин мәңгегә тарихта калырдай батырлык эшләр идем, кешеләргә файдасы тиярлек булса, гомеремне дә кызганмас идем, тик ничек эшләргә икәнен генә белмим,— диде.

Мин чын куңелемнән көлдем.

— Бөтен кешенең дә исеме тарихта калса, тарихта урын житмәс,— дидем.

Хөршидә дә көлде.

— Ә шулай да Жанна д' Арктан көнләшәм мин,— диде. Аннан соң көрсенеп өстәде:— Без синең белән гади батырлар булырбыз, яме? Киләсе елны тайга уртасындәук, ерактәук бер авылга китәрбез. Мин больницада, син мәктәптә җиң сызганып эшли башларбыз. Белгәнебезне, чирек гасыр җыйган тәҗрибәләребезне кеше белән уртаклашырга да вакыт җитәр. Аннан соң мин баш врач, баш врачларның да башрагы булырмын. Ә син, Петя, Мәгариф халык комиссары булырсың. Мин — комиссар хатыны. Бу өянкеләр төбенә автомобиль белән генә фырр иттереп кайтып туктарбыз.

Без — ике сабый — аның бу сүзләрен кызыкка санап тагын көлдек...

Элек ул урыннарда без кайткан олы юл юк иде әле. Хәзер Ширбәт инешенең янынннан гына үтә. Елына ике-өч мәртәбә, юлымнан туктап, өянкеләр төбендәге шул кадерле эскәмиядә утырам, нигез ташларына карап, монда кайчандыр гөрләп торган тормышны искә алам, уйланып утырырга яратам. Алар миңа нигез ташлары түгел — мәңгелеккә куелган һәйкәл ташлары кебек тоела. Дусларымның һәммәсен берәм-берәм күз алдыма китерәм.

Кырык беренче елның сигезенче июнендә энемнән телеграмма алдым. Бәхетсезлеккә очрадым, хәлем әйбәт түгел, кайтып күреп кит, дигән иде. Эш бик тыгыз, кызу чаклар. Өстәвенә, җәй көне туй буласы, хәл кадәренчә шуңа әзерләнеп йөрибез. Хөршидә практикага китәргә җыена. Рәтләп күрешә дә алмыйбыз. Институттан җибәрәләр. Кич Хөршидәләрнең тулай торагына бардым. Ул миңа коридорда ук очрады. Йөгерә-йөгерә факультет җыелышына бара иде. Ике-өч минут кына сөйләшеп тора алдык. Хөршидә мине юатты:

— Кайгырма, энең терелер, тазарыр. Әгәр андагы врачларның кулыннан килмәсә, мин аны үзем дәваларрмын. Мин тиздән доктор буласы кеше бит,— диде.

— Ә мин — Мәгариф халык комиссары,— диеп шаярттым.

Без көлеп җибәрдек.

— Кайчан кайтасың? — диде.

— Июньнең егерме-егерме берләрендә дип уйлыйм, бераз соңгаруым да мөмкин...

Шул китүдән миңа «бераз» гына түгел — биш ел тоткарланырга туры килде.

Җүләрләр — аерылганда кочаклашмадык та, үбешмәдек тә. Кем белгән! Ниләр буласы башыбызга ничек килсен!

Аны бүтән исән килеш күрмәячәгемне кем белгән?!

Хәер, ялгышам икән, мин аны исән килеш тагын күрдем әле. Ике генә минут. Анысы соңрак. Фронтта. Бомбежка вакытында...

Энемнең авыруы куркыныч булып чыкмады. Җитмәсә, мәзәк тә: зоотехникны үгез сөзгән иде. Шулай да коты очкан. Беттем дип уйлаган һәм, тәпи сузганчы абыйны күреп калыйм дип, телеграмма суккан. Билгеле, ачуланмадым, җиңел шелтә белән котылды. Чөнки үзем дә сагынган идем, үземнең дә күрәсем килгән иде.

Мин аның янында — Пинск өлкәсендәге бер авылда — өч көн булдым. Кайтып китәргә тиешле дүртенче көннең таңында сугыш башланды. Пинск чик буеннан ерак түгел. Тиздән фашистлар кул астында калдык. Себергә юл киселде. Шул көннәрдә үк авыл укытучысы, карт коммунист, элекке подпольщик партизаннар отряды оештырды. Барлыгы егерме өч кеше, ни тапсак шуның белән коралланып, авылны ташлап урманнарга күчтек. Энем аягына баса алмый иде әле. Аны носилкага салырга туры килде.

Безнең бу кечкенә отряд Белоруссиядә оешкан партизан отрядларының беренчеләреннән булды. Ул бик тиз үсә башлады, бригадага әйләнде. Тагын бераздан партизан отрядларының зур берләшмәсенә кушылдык.

Ләкин энемнең партизан тормышы озак булмады. Август ахырларында бер операциядән кайткан чакта аның группасы засадага очрады һәм ул шунда һәлак булды. Гәүдәсен күрмәдем, күмәргә туры килмәде.

Мин ялгыз калдым. Бөтен сугыш буена бер кемнән дә бер хатхәбәр алмадым. Үземә дә язарга туры килмәде. Хөршидәне сугышта дип уйлый идем мин. Медицина институтының дүртенче курсын тәмамлаган хирург фронтта булмый — кайда булсын. Дүрт ел буена Кызыл Армияне көтеп яшәдем. Фронт юлларында Хөршидәне очратырмын кебек тоела иде.

Менә ул бәхетле көннәр килеп житте. 1944 елның сигезенче июнендә безнең бригадага Белоруссия Коммунистлар (большевиклар) партиясе Үзәк Комитетыннан радиограмма килде. Анда 20 июньдә «рельс сугышын» башлап җибәрергә диелгән иде. Рельсларны шартлатып өзү дигән сүз. Төнлә белән Пинск — Брест тимер юлын сафтан чыгардык. Телләрдә һәм уйларда «башлана, башлана»! дигән куанычлы хәбәр йөргән чак иде. Чөнки «Үзәк» армиянең немец-фашист группировкасын тар-мар итү өчен һөҗүм операцияләренең менә-менә башланасын беләидек. Ул һөҗүмне 22 июньдә иртән 1 нче Балтик буе фронты башлап җибәрде. Безнең гаскәрләр, көчле давыл булып, фашист яуларын кырып-себереп, безнең өлкәгә бик тиз якынлаштылар. Немецлар Пинск районыннан чигенә башлады. Безнең өчен «урак өсте» башланды: дошман чигенгән тимер юлларына, шоссесына ударлар ясадык. Пинск тулысынча азат ителде...

Тагын бераздан мин, бәхетсезлегемә каршы, сөекле кәләшемне очраттым. Комбаттан боерык алып, разведвзводка бара идем. Көн әйбәт, җылы. Олы юл читеннән чәчәкләр арасыннан атлыйм. Яка ычкынган. Пилотка — бил каешында. Рәхәт. Тыныч. Үлән араларында чикерткәләр чырылдый, куакларда кошлар чыркылдаша. Олы юлдан машиналар колоннасы агыла. Мин — көнчыгышка, алар — көнбатышка. Колонна арасында кайвакыт кызыл хач төшерелгән санитар машиналары да күренгәли. Мин, ирексездән, күздән югалганчы алар артыннан карап калам. Кем белә, бәлки... Ике-өч урынга хат та язып җибәрдем инде. Җавап көтәм. Хат-хәбәр көтәм, адрес...

Менә тагын кызыл хачлы машиналар бара. Мин тагын, адымнарымны әкренәйтеп, аларга карыйм. Бәлки... Нәкъ шул минутта бүтән вакытта күзгә дә чалынмый торган бөрек кадәр генә болыт артыннан дошман самолетлары килеп чыкты да, чебешкә ташланган козгыннар төсле, ярдәмчесез колоннага ташландылар. Бомба шартлауларына пулемет тавышлары килеп кушылды. Машиналар яна башлады. Әле генә күкрәп яткан тын җир киерелергә-сузылырга, тере нәрсә шикелле ыңгырашырга тотынды. Шоферлар, солдатлар юл читендәге урманга, канауларга йөгерделәр.

Шунда бер кыз санитар машинасыннан чыкты да, тирә-якта үкереп кайнаган җәһәннәм утына әһәмият бирмичә, башы ак марляга чорналган бер сугышчыны күтәреп төшерә башлады.

— Ятыгыз!.. Монда килегез! — дип кычкырдым мин. Шул кадәр тавыш һәм шау-шу эчендә, билгеле, кычкырганны ишетмәгәндер. Ләкин кыз минем якка борылып карады. Минем түбәмә бомба төшеп ярылгандай булды: ул — Хөршидә иде!

Мин сикереп тордым да:

— Хөршидә!.. Хөршидә!.. — дип шашып кычкыра-кычкыра аңа ташландым. Шул чакта бомба төшеп ярылды. Һава дулкыны мине җиргә

күтәреп бәрде. Ләкин мин ыңгыраша-ыңгыраша тагын сикереп тордым. Хөршидә, кулларын як-якка җәеп, юл читендә ята иде. Йөзендә, тәнендә бер җәрәхәте дә юк шикелле. Шул ук кадерле көләч йөз...

— Хөршидә! — дип илереп кычкырдым һәм янына тезләндем.

Ул зур кара күзләрен ачып туп-туры миңа карады.

— Хөршидә! Таныйсыңмы мине, Хөршидә?!. Бу мин — Петя!

Хөршидәнең керфеге дә селкенмәде, йөземә туп-туры карап үлеп китте...

Менә инде ничәмә-ничә еллар үтте, күпме сулар акты — ә мин һаман белмим, һаман уйланам, моңланам, үзәкләрем өзелә: таныды микән Хөршидә мине ул чакта?! Хәтта төннәрен торып утырам: белде микән Хөршидә янына кем тезләнеп торганын?!

Аның кабере Пинск шәһәреннән ерак түгел, олы юл буендагы яшь агачлар үсеп утырган калкулык итәгендә. Хәер, ул агачлар зур инде хәзер...

Илленче елны барып, мин аның каберенә яңа таш куйдым. Кабер ташына:

**Хәрби врач**
**Заһидуллина Хөршидә Мөслимовна.**
**23/12—1920—18/7—1944.**
**Ватаны өчен корбан булды,—**

дигән сүзләр яздырдым.

Ә мин үзем сугышны Рейхстаг залларында немецларның иң әшәке, иң усал автоматчылары белән атышып тәмамладым...

Илле икенче елны гына өйләндем. Марианна — тыныч холыклы, сабыр, әйбәт хатын. Хөршидә кебек үк, башыннан ахырына кадәр сугыш юлларын үткән. Медицина сестрасы. Ул да сугышта сөйгән егетен югалткан. Икебезнең дә күңелләрдә бер үк җәрәхәт. Малай бар. Урал исемле. Кыз бар, Марина.

Мөмкинлек чыгу белән Мөслимҗан бабайларга бардым. Алар икәү генә иде инде, картайганнар иде. Кайчандыр шатлык авазлары гына шаулап торган семья тынып калган иде. Шуннан соң мин аларга гел барып йөрдем...

Алтмышынчы елның кышында телефон шалтырады. Алдым. Мәрзия әби тавышы:

— Петя улым, мин монда. Сезгә кереп чыгарга мөмкин булмас микән? — ди. Мин аны гостиницадан барып алдым. Мөслимҗан бабай үлгән икән. Без аңа, бездә кал, әниебез булырсың, дидек. Ул калды. Бераздан стенага син әйткән биш портрет эленде. Менә шулай күп еллар буе, үткәннәрне искә төшереп, бишебез рәттән эленеп торабыз. Хөршидә белән Марианна да, әнием дә, мин дә...

Мәрзия әби батыр иде. Тыңгысыз иде. Мәктәпләрдә, пионер отрядларында уллары һәм кызы турында сөйләп, сугышны каһәрләп, тыныч тормыш өчен кулыннан килгән кадәр тырышып йөрде. Ул берничә пионер дружинасының почетлы пионеры иде. Оныклары аны онытмас. Ил иминлеге өчен өч ул һәм бер кыз үстереп биргән ананың кабереннән чәчәкләр өзелмәс...

Мин дә Хөршидәне мәңге оныта алмам инде. Онытырга да теләмим. Марианнага да, өлкән лейтенантыңны оныт, дип ничек әйтим! Аларның ни гаебе бар? Яшибез шулай. Эшлибез. Ни генә димәсеннәр, беренче мәхәббәт онытылмый. Онытылмый беренче мәхәббәт! Онытырмын димә! Классларга килеп керәм, бәләкәй кызларга күзләремне йөртеп чыгам: Хөршидәгә охшаганнарын эзлим. Очратсам, вакыт-вакыт сиздермичә генә аңа күз салып, укытучының ни сөйләгәнен дә белмичә, үткән тормышымны уйлап тын гына сагышланып утырам... Юк, онытылмый, онытылмый беренче мәхәббәт!..

Сөйләп бетергәч, Петр Петрович озак кына уйланып утырды. Айзат та, күңелен биләп алган көчле тәэсиреннән айный алмыйча, тын гына басып торды.

Менә Петр Петрович урыныннан калкынды.

— Шушыны белергә теләгән идегезме, дускай? — дип сорады.

— Әйе, шушыны. Рәхмәт сезгә, Петр Петрович! Сез минем күңелемне кузгаттыгыз.

— Тормышта күңел кузгалган чаклар еш була. Үзем дә азрак жинеләеп киттем. Вакыт-вакыт шулай кирәк. Юкса кешене уй басуы мөмкин... Я, нишлиләр безнең яшьләр, кереп карыйк.

— Петр Петрович, мин монда кунсам, ничек булыр икән? Яңа дусларым да кыстый.

— Теләсәң, кал. Рәхим ит! Үзеңә ничек ошый, шулай эшлә. Ә иртәгә Бөгелә-Талга барып кайт. Мин ат караучыга әйтеп килдем. Иртән туп-туры бар да ал. Иярләп бирер. Мәктәпне кара. Директор белән сөйләш. Атлан да кит.

— Рәхмәт, Петр Петрович, китәрмен.

Айзат интернатта кунды. Иртүк катер килде. Салават яшьләре ашханәне, бүлмәләрне ялт итеп юып чыгардылар, гөл итеп жыештырып куйдылар һәм капчык-чемоданнарын күтәрделәр дә, уйнап-көлеп, кияү белән киленгә шактый ук икеле-микеле сүзләр әйтә-әйтә, елга ярына төшеп киттеләр. Янәшә басып торган Айзат һәм Степан агай белән саубуллаштылар да катерга төялделәр. Катер тип-тигез елга өстеннән шуып кына китеп барды. Яңа дуслар күксел томаннар артына күмелеп, күздән югалды...

Районның ат караучысы Айзатка иярләнгән ат бирде. Шикләнебрәк:

— Атка атланганың бармы? — дип сорады.

— Мексиканың Чиуауа штатында уникe ел ковбой[1] булып йөрдем,— диде Айзат, шаярткан булып.

Ат караучы аның сүзләрен аңламаса да, сынатасы килмичә:

— Ә-ә-ә, алай булгач ярый, әйбәт,— диде һәм лапаска кереп китте.

Айзат капка төбенә житкәч борылып кычкырды:

— Бу кара алашаның исеме ничек соң?

Лапас эченнән:

— «Каныт»,— дигән тавыш ишетелде...

Айзат Аю-Ятардан чыгып, Бөгелә-Тал юлына төште. Өзәңгеләре озынрак иде, бер каен төбенә туктап, аларны кыскартып бәйләде. Аннары юл буйлап жинел генә юыртып китте. «Каныт» иярге өйрәнгән икән, пырдымсызланмады. Башын аска иеп, үзенең ниндидер яшерен уйларын уйлый-уйлый, салмак кына юырта бирде.

Айзат Казаннан чыгып китканнән бирле күпне күрде, күпне ишетте. Дөнья белән ныклап таныша башлады. Башында мең төрле уйлар туды. Ләкин алар әле чуалчык иде, аларны рәтлисе, кайсын кая урнаштырасы, тәртипкә саласы бар иде. Айзат уйга чумды.

Иң элек аның күз алдына Мәрзия әби килеп басты. Әнә, ак чәчләрен ак мендәр өстенә таратып салган да тыныч кына, курыкмый гына дөньядан китеп бара. Үзе тапкан, үстергән кызы да, батыр уллары да, гомер иткән ире дә юк. Бөтенләй чит-ят кешеләр аның күзләрен йомдыра, аның өчен яшь түгә. Үз уллары исән булып, баш очларында торса, алай гына булыр идемени!..

---

[1] Төньяк Америкада атлы көтүче.

Айзат менә — исән. Ул үлмәгән. Ул исән һәм бәхетле яшәсен өчен, укысын өчен бүтән егетләр үлгән. Юк, юк! Ул әнисенең үлүен дә, аның баш очында елап утырыр көнне дә теләми. Күрергә язмасын ул кара көннәрне! Тфү, тфү!.. Рәхәт яшәсен, мәңге исән булсын! Исән чакта кадерләрен белергә кирәк әти-әниләрнең! Соңыннан, болай итә алмадым, тегене эшли алмадым дип уфтанып йөрергә калмасын.

Ана — кәгъбә! Анага исән чакта табынырга кирәк!

Ләкин ана балага бакса да, танага баккан балалар әзмени бу дөньяда?

Менә ул үзе — Айзат шундый түгелмени? Анасы, чемодан, капчыгына каз-үрдәк, сарык итләре, майлар тутырып, аны күрер өчен өч йөз чакрым җирдән азапланып килде. Исәнләшкәндә салкын учлары белән аның кулларын җибәрми торды, йотылып-йотылып күзләренә карады. Сагынган, күрергә тилмергән иде. Ә улы, бабасы белән әбисеннән уңайсызланып, кулларын тартып алды. Менә, минем әни авыл хатыны инде ул — авылча, гафу итегез дигән шикелле, читкәрәк тартылды. Кичен залда Ким Риазовичның Ләбибәгә әйткән сүзләрен ишетеп калды.

— Юк, аның белән сөйләшеп булмый, уртак темабыз юк. Аннары аннан сөт исе дә килә. Бөтен өй тулды. Син аңа урынны прихожидагы сандык өстенә җәй. Андыйлар упкәли торган булмыйлар,— диде.

Шуннан Айзат нишләде? Күрмәсәләр ярар иде дип, тиз генә кабинетка кереп китте. Нигә күзләренә карап кычкырмады? Ник, ялгышасыз, уртак тема бар, кешеләрне уртак иткән нәрсә — хезмәт! Ул гомере буе иртәнге дүрттән-биштән торып төнге уннарга-уникеләргә кадәр эшли. Сезнең өчен, кешеләр өчен эшли. Ул, сез сөт эчсен өчен, гомер буе сыер сава, аңардан шуңа күрә сөт исе килә. Кибетендә бер көн сөт булмаса, кычкырасыз бит, балаларыгызга сөт эчерәсез бит! Шулай булгач, ник аның исеннән куркасыз? Сөт исе түгел — ризык исе, хезмәт исе килә аннан дип әйтмәде, сорамады. Авызын йомып калды. Әнисе тәки сандык өстендә йоклады. Йоклады микән?..

Сөекле кызларыннан аерым яшәмәс өчен генә яшәттеләр бит алар Айзатны. Әнисен кимсеттеләр, ә ул анасын яклый алмады, яклап сүз әйтергә йөрәге җитмәде.

Ананың яхшылыгын авырсаң белерсең, диләр. Ул авырды, белде. Бишенче класста укыганда ай буе чирләп ятып, бер көнне авыраеп китте. Тыны да бетте, кан тибеше дә сизелми башлады. Үлде дип белделәр. Өйгә халык җыелды. Әтисе җылый-җылый басудан кайтты. Күрше бабай баш очына утырып ясин чыкты. Анасы «үлгән» улын кочаклап, сулышы белән өреп җан кертергә теләгәндәй, җылый-җылый күтәреп йөрде. Үлгән малаен күкрәгенә кысып җылап йөрде! Ә ул үлмәгән иде. Бөтенесен белеп, ишетеп ятты. Күзен генә ача алмады, телен кыймылдатып сүз әйтә алмады. Кич белән рәткә килде. Куанычларын күрсәң иде! Анасы ике көн янынннан китмәде. Ике көн, ике төн аның янында утырды...

Ә ул, юньсез Айзат нишләде?!. Кунакка сагынып килгән әнисенең сандык өстендә йоклавына риза булды. Яшь хатынының күкрәгенә күкрәге тиюгә әнисенең хәзерге минутта Казанда икәнен дә, үзләренең өендә, аннан ике генә ишек аша, бер фатир һавасын сулап моңаеп ятуын да, ә үзенең җылы булмәдә мамык мендәргә чумып, мамык юрган ябынып йоклавын да онытты. Онытты! Үзен тәүфыйклы балаларның берсе дип чутлап йөри әле житмәсә!..

Айзат йөрәгенә чыдаша алмады, атыннан сикереп төште. Аны тезгененнән тотып җәяү китте. Юлда аунап яткан буш консерва банкаларын тибеп җибәрде:

— Какой тәүфыйк! Сволочь!..

Тагын типте:

— Җирбит!..

Анасының йөрәге көйгәнен белмәдемени? Бишек тирбәткән кул — дөньяга хуҗа! Туган ана бер, туган Ватан бер!.. Ә без ник, сөтен имеп туйгач, аларның күкрәкләрен тешләргә тиеш?! Гомер буе кулларыбызга гына күтәреп йөртсәк тә, иң татлы сүзләр генә әйтеп, иң тәмле ризыклар гына ашатып, иң гүзәл урыннарда гына яшәтсәк тә — боларның һәммәсе аналарның бер тулгагына да тормый бит!

Ә без, мәсәлән — мин, моны, кирәк нәрсәләрне, дөньяны бик аз беләбез әле. Тирәнтен уйламыйбыз да...

Без мәктәпләрдә «биш»ле алабыз, институтларны «диплом с отличием» белән тәмамлап чыгабыз. Без Тукайларны, Чернышевскийларны, ия-хәбәрләрне, синус-косинусларны, машина моторларын, үләннәрне-бөҗәкләрне, материкларны, тагын мең-мең төрле әллә нәрсәләрне беләбез. Болар бар да фән булып керә. Өйрәтәләр. Белмәсәң, икеле куялар. Ә тормыш турындагы, кешеләр, мөнәсәбәтләр турындагы фән, яхшы һәм начар нәрсәләр, яхшы һәм начар кешеләр турындагы фән нигә юк? Унбиш ел укып чыкканнан соң ник моны тагын беренче класстан тотып өйрәнә башларга туры килә?..

Айзат өченче курста укый иде инде. Үзен бик белемле кеше дип йөри иде. Көз көне кече апасы кияве һәм өч баласы белән, йорт-җирләрен сатып, акчаларын ире исеменә аккредитивлап[1], Казанга кайтып төште. Ире бераздан аккредитивларны алып сызды. Апасы өч бала белән бер тиенсез торып калды. Аның янына килде. «Әйт, миңа нишләргә? Әйт, син беләсең, син укыган кеше бит?» диде. Айзат нишләсен? Бу инде шигырь төзелеше түгел — бу тормышның үзе иде, һәм Айзат моны, укыган кеше булса да, апасыннан күп өлеш ким белә иде. Ул бер нәрсә дә эшли алмады, апасын юата, аңа ярдәм итә алмады. Дөрес, барлык батырлыгын җыеп, республика прокурорының ярдәмчесе янына керде. Прокурор ярдәмчесе дә берни дә эшли алмады. Чөнки аккредитив кем исеменә язылган булса, акчаның хуҗасы да шул булып чутлана икән. «Җизнәгез — җинаятьче, ләкин җавапка тарттыра алмыйбыз, закон юк», диделәр.

Ә законнарны кешеләр үзләре чыгара, үзләре яза түгелме соң?

Явызлыкны аркасыннан сөеп түгел — кычкырып, камчы белән җиңәргә кирәк. Ләкин башта үз-үзең белән сугышырга кирәк, үзеңдәге начар гадәтләрне, ярамаган уйларны җиңәргә кирәк. Шунда гына җәмгыятьтәге ярамаган бәндәләрне, җәмгыять белән бергә атларга теләмичә, аның чабуына ябышып, алга атларга комачаулап барган әшәкелекне селкеп төшерергә, алып атарга, җиңәргә була.

Айзат — ир-егет. Ул, гомер буе ялгышмаслык итеп, дөрес юл сайларга тиеш. Үзе дә үкенмәсен, кешеләр дә рәхмәт әйтсен. Ул дөрес юлны сайлый башлады да бугай инде. Менә шушы берничә көн эчендә дә күпме кеше, күпме язмышлар белән очрашты, күпме яңа нәрсәләр ишетте, күпме яңа җирләр үтте. Ул гомерендә беренче мәртәбә «тормыш» дигән зур һәм авыр, бәхетле һәм кайгы-хәсрәтле, сөенечле һәм көенечле, бәхетле һәм шатлыклы фәннең беренче битләрен ача башлады түгелме соң? Аның беренче битләре үк аңа кайбер нәрсәләрне өйрәтте дә инде: тормыш көн дә бәйрәм, көн дә туй түгел, тормыш катлаулы, җирдә күпме кеше булса, шулкадәр язмыш бар. Алар, яфрак белән яфрак охшамаган шикелле, бер-берсенә һич тә охшамаганнар. Кеше үзенчә туа, үзенчә яши, үзенчә үлә.

---

[1] Бер кассага түләгән акчаны икенче каладан алырга мөмкин икәнлеккә акча документы.

Айзат «зур тормыш» дигән китапның беренче битләрен ачып укый башлады. Кызык һәм авыр фән бу. Авыр булсын! Ул моңа куана гына. Ул аның яңадан-яңа битләрен ачып өйрәнер, тормыш авырлыкларын җиңәргә берәм-берәм өйрәнер!

Шушы тормыш кирәк шул! Шундагы кешеләр кирәк!..

Зур тормыш, кайбер кешеләр уйлаганча (Айзат тагын ачу белән бер балчык кисәген тибеп җибәрде), Казанның Бауман, Ленин урамнарында, театр, ресторанннарда, җылы һәм якты кабинетларда, келәм җәелгән кояшлы бүлмәләрдә генә түгел — ул кешеләр, язмышлар арасында. Зур тормыш, мәсәлән, ул менә монда — бу каен урманнары арасында, элек «караңгы» дип яманаты чыккан шушы Себердә дә кайный! Ул — төзелеш чыны, ургыч кетердәве, кешеләр көлүе яңгырап торган һәр урында кайный! Айзат — кеше! Аның да урыны кешеләр көлгән җирдә. Ул яшь, көчле. Тормышның авыр юлларын сыгылмыйча, ыңгырашмыйча үтәргә тиеш. Тормыш юлларында яхшылыклар белән бер рәттән яманлыклар да бар шул. Ә яманлыкларны аска алып, яхшылыкларны өскә күтәрергә аның көче бар!..

Чәчкәнең дә көче бар. Айзат моны белә. Ул аңа бүген үк хат язар, кил, дияр. Аның Чәчкәсе аңларга тиеш. Гомер юлын Айзат белән бергә бәйләгән икән — өзәргә теләмәс. Әгәр теләсә?!.. Әгәр өзсә?.. Әгәр?!. Әгәр?!.

Айзат үз гомеренең туры сукмагын тапты. Ни генә булса да, ул аннан читкә атламаячак!..

— Улым, сәгать ничә?

Айзат, уйларыннан бүленеп, сискәнеп китте һәм туктады. Юл читендәге төп өстендә, бүреген янына куеп, бер бабай хәл җыеп утыра иде. Айзат аңа сәгатьне әйтте һәм үзе дә:

— Бөгелә-Талга еракмы әле, бабай? — дип сорады.

— Якын гына,— диде бабай.— Менә бу үрне менгәннән соң нарат урманы булыр. Урман артыннан манара күренеп торыр. Безнең авыл шунда...

Айзат бабайга рәхмәт әйтеп саубуллашты да атына атланды. «Канат» йөрәк кагып үргә каршы чапты...[1]

*1967—1969*

---

[1] Әсәр кыскартып басылды.

## Рәис Риян

### Еракларлан киләм

Мин ерактан киләм...
Ачулы җил
Бу юлларны нинди себерә...
Кемнәр генә каһәр язмыш белән
Үтмәгән соң моннан Себергә!?
Юл читендә үскән бер карт каен
Тузын кубыз итеп уйната.
Ә усал җил шул «кубыз»ны каерып,
Карт каенны нигә елата?!.
Таный икән тарих хәбәрчесе
Бабаема мине охшатып:
Бу юллардан минем бабаем да
Үткән икән туңып кыш,
катып.
Шул чакта ул каен тузларына
Язып киткән олы васыятен.
Менә укыйм әле шул васыятьне,
Кем өнәмәс аның хасиятен?!.
«Безнен каннар юды бу туфракны,
Ирек өчен күпләр баш салды.
«Без дә кеше. «Ирек!» диючеләр
Маңгаена ядрә-таш алды.
Аяк-кулга — богау, гел нахакка
Без сөрелдек туган җирләрдән.
Килер буын, Туган илне уяу
Саклап кал син явыз җилләрдән!»
Ил елаган, хәтәр ул елларда
Булганмыни кеше кадере!
Ул бабайның кайда — дингездәме,
Вулканнарда микән кабере?!.

Мин ерактан киләм.
Изге мирас —
Борынгылар йөргән юллар бу.
Күп кешеләр ата-бабасының
Туган йортын тапкан еллар бу.

1968

## Салчы сүзе

Салчы эше кемгә җиңел күренә?
Сал агызган кеше яшьли без.
Ярты гомер бабайкада[1] үтте,—
Сал агызып чыкты тешебез.

Бездә романтика кечкенәдән,
Ләкин тормыш шундый катлаулы:
Җирдә күпме сулар ярсу, ташкын,
Һава зыкы, юллар таш-таулы...
Замананың авыр чагы иде,
Шуңа яшьли «камыт» кидек без.
Юкса, башны салга салып кына
Агып китәр төсле идек без.

Әйтә идек: яшь буыннар нишләр?
Бабайкалар сынмый түзәрме?
Сайлык-перекатлар кызлар ишкән
Юкә арканнарны өзәрме?

Сал таралып, кайчак төшә идек
Тирле көйгә бозлы суга да.—
Кар ярганда хәзер буын сызлый,
Түзә икән кеше шуңа да!

Кирәк булса — без бүген дә салчы.
Бик арысак ярга туктарбыз;
Салны талга бәйләп, яр буенда
Ташны ястык итеп йокларбыз.

1969

## Иртәнге музыка

Зур тау кадәрле
бер кораб
Оеп якорьда тора.—
Аңа дингезчеләр яңа
Антенна, мачта кора.
Акчарлаклар оча.
Шаулап
Мактыйлар диңгез күген.
Ерактан
Көмеш яфраклардай
Күренә алар бүген.
Музыка!..
Ярсып кылларга
Капитан кызы кага.

Дулкыннар!
Анда дельфиннар
Биниләр музыкага.
Нәрсә бу!?
Бүген дельфиннар
Китерер нинди хәбәр?![2]
Көн имин булыр!
Кешеләр
Сынатмасалар әгәр!..
Мин торам диңгез ярында
Киң, иркен сулыш алып,
Тынычлык моңнарын тыңлыйм
Бирелеп, таңга калып.

---

[1] Бабайка — сал ишкәге.
[2] Дингездә давыл булырын сизеп, дельфиннар яр буенарак килəләр икән.

Сафа Сабиров

# ХӘТӘР СӘФӘР

хикәя



Бүген флотилия төнге походка чыгасы түгел. Атна буе өзлексез сугышып, дозорда йөреп тәмам алҗыган, керләнеп беткән командаларга, ниһаять, бераз ял итәргә, мунча кереп өс-баш алмаштырырга мөмкинлек бирделәр.

Әмма безнең «Олень» бронекатерына бүген дә ял эләкмәде. Ниндидер зур начальник белән каядыр барасы бар икән. Ул килеп җитү белән шундук кузгалып китәргә әзер торабыз.

Безнең команданың күпчелеге — Паратск кешеләре. Һәркем эштән бушаган арада өенә кайтып, семьясы, туган-тумачасы белән күрешеп килергә атлыгып тора.

Затонда минем семьям да, туган-тумачам да юк. Кайчандыр баржада бергә эшләгән якын танышым Шакир агай гына бар. Кышларын мин аларда фатирда торам. Өйләре бик кечкенә, маякчы өчен салынган будка гына булса да, Шакир агай үзе дә, кызы Зөлфия дә һич тарсынмыйлар, без, бер семья кебек, тату яши идек. Тик кинәт алар икесе дә югалдылар. Күршеләрнең әйтүенә караганда, Шакир агай Чистайга йөк илтә барган чакта үзенә ярдәмгә Зөлфияне дә алып киткән булган. Нәкъ шул көннәрдә Идел, Кама буйларына ак бандалар килеп керде. Шакир агай да, Зөлфия дә баржалары белән, мөгаен, дошман кулына эләктеләр булса кирәк, шул китүдән үзләре дә, хат-хәбәрләре дә юк.

Менә бүген ял бирәләр дигәч, мин дә затонга чыгып алар турында белешеп кайтырга уйлаган идем. Ләкин туры килмәде бит. Затонга чыгу урынына, мин башка матрослар белән бергә катерга снаряд, патрон төйим. Комендорлар берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра тупны чистартып, майлап маташалар.

Тиздән мине рубкага чакыртып алдылар. Барып керсәм, анда безнең кораб командиры Дубинин миңа таныш түгел бер дингезче белән ни турындадыр җанланып сөйләшеп тора иде. Дингезче зәңгәрсу китель, кара фуражка кигән, салынкы кара кашлары астыннан зур соры күзләре игътибарлы елмаеп карыйлар иде.

— Ефим Григорьевич, сез чакырткан Закиров менә үзе,— диде Дубинин мине күрсәтеп.— Бездә койрыкчы булып хезмәт итә. Һаман шулай тырышып өйрәнсә, киләчәктә менә дигән лоцман булачак.

— Шулаймы?.. Алайса бик әйбәт...— Дингезче мине игътибар белән баштанаяк күздән кичерде.— Иптәшләр, менә нәрсә. Бүген безгә бик мөһим хәбәр килеп төште: Казанка елгасы тамагында дошманның снаряд һәм патроннар тулы баржасы тора, ди. Безгә бүген төнлә ничек тә шул баржаны базага алып кайтырга кирәк.

Мин аны-моны уйлап тормастан, гажәпләнүемне яшермичә:

— Казанда аклар ич,— дидем.— Ничек аласың ул баржаны? Дошман аны безгә болай гына бирмәс бит.

— Ничек тә алып кайтырга, көч белән булмаса, хәйлә белән алырга кирәк.

— Устьеда баржалар һәрвакыт күп була, карангыда безгә кирәген ничек табасың аның...

— Менә шуңар күрә сезне чакырттык та инде. Паратск затонында кышлый торган баржа ди ул. Бу хәлне без баржаның шкиперыннан белдек. Ә ул сезне күрсәткән, сез ул баржаны карангыда да танып табарсыз дип хәбәр иткән.

— Әһә, алайса аңлашыла,— дип, шатлыгымнан көлеп җибәрдем мин.— Ул, мөгаен, Шакир агай баржасыдыр. Ул баржада минем матрос булып эшләгәнем дә бар иде.

— Әйе, шул үзе булса кирәк, тикмәгә генә сезне атап әйтмәгәндер.— Дингезченең йөзе яктырып китте.— Алайса сез монда әзер торыгыз. Хәзер мин штабка кереп чыгам да юлга кузгалырбыз...

Ун минут та үтмәгәндер, ул әйләнеп керде. Әмма бу юлы аны һич танырлык түгел иде. Өстендә төз, таза гәүдәсенә килешеп торган зәңгәрсу китель, иңнәрендә сары укалы погон, фуражкасының кызыл йолдыз таккан урынында офицер кокардасы ялтырый, үзен зур түрәдәй үтә тәкәббер тота, әйләнә-тирәгә чыраен сытып кына карый иде. Безнең гажәпләнеп карауга ул:

— Бер дә исегез китмәсен, иптәшләр, шулай кирәк,— дип хәйләкәр елмаеп куйды һәм барыбызга да бескозыркадан кызыл йолдызларны бүгенгә алып торырга, аның үзенә ваше высокоблагородие дип эндәшергә кушты.

Бу хәл матросларга ничектер сәер тоелды булса кирәк, алар берберсенә сораулы карашып алдылар. Бик аптырап калган бер матрос ул каютага кереп киткән арада:

— Кара син бу түрәне, элекке офицер икәнлеге әллә кайдан күренеп тора,— дип, ямап сүгенә башлады.— Элек безнең братны ничек җиксәләр, хәзер дә муенга шулай менеп атланырга торалар түгелме... Их, былтыр переворот көннәрендә үземә очраса, мин аның погоннары белән бергә башын да өзеп ташлаган булыр идем...

— Бернинди түрә дә, офицер да түгел ул,— дип, Дубинин аның сүзен бүлдерде.— Фирсов белән бергә мин бер корабта дүрт ел хезмәт иттем. Нәкъ безнең кебек гади матрос, большевиклар партиясе члены һәм шуның өчен ике ел сөргендә йөреп кайтты. Хәзер ул флотилия штабында хезмәт итә... Белер-белмәс лыгырдауның кирәге юк...

Хәер, озак сөйләнеп торырга вакыт юк. Нинди эш белән, кая барасын ачык белмәсәләр дә, походның хәтәр буласын бөтен команда сизеп алды. Гадәттә палубада матрослар арасында була торган берберсеннән шаяртып көлүләр басылды, кешеләр җитдиләнеп тынып калдылар.

Инде кояш баеп барган вакыт. Без тавышсыз-тынсыз якорьдан кузгалып киткән арада эңгер-меңгер куера башлады һәм тиздән әйләнәтирәне, шул исәптән кораб белән бергә безне дә, карангылык каплады. Без су өстеннән түгел, күзгә төртсәләр дә күренмәслек төн карасыннан

барабыз. Менә-менә берәр таш кыяга яки утрауга килеп бәрелербез шикелле.

Әмма үз гомерендә Иделдә күп йөргән карт лоцман юлны яхшы белә. Шуның өстенә алгы палубадагы матроска наметка белән тирәнлекне үлчәп барырга кушылды. Юл аеруча хәтәр урыннарны үткән чакларда лоцман, штурвалны миңа калдырып, үзе дә алгы палубага чыгып баса һәм судноны кирәгенчә әле уңга, әле сулга борырга команда бирел бара иде.

Печищи белән Югары Ослан арасындагы биек тау башларында акларның күзәтү пунктлары, куәтле батареялары сакта тора. Әгәр күреп алсалар, алар шундук ут ачып, безне батырачаклар. Әмма төн карасы берни күрсәтми. Бу тирәдә ике як яры да дошман кулында булган караңгы елга уртасыннан агым уңаена зур тизлектә шылт та итмичә һаман алга барабыз.

Фирсов рубка алдындагы күперчектә басып тора һәм озак-озак бинокльдән алга карап бара да, үз алдына сөйләнгәндәй: «Шулай... Әйбәт барабыз»,— дип әйтеп куя. Аның хәвеф-хәтәргә исе китмәвеннән, басынкы сабырлык белән әйтелгән хуплау сүзләреннән мин дә тынычлана башлыйм, штурвалны ныграк тотам.

Бу тирәләрне Фирсов үзе дә яхшы белә икән, Маркиз утравы турыннан үтүгә ул корабны сулга борырга кушты. Тиздән без Бакалтайга, пристаньнар урнашкан якка килеп чыктык һәм, кирегә борылып, сул як яр буйлап үргә менә башладык.

Төн һаман дөм-караңгы, әйләнә-тирәдә ник бер генә ут әсәре күренсен! Кайда су чите, кайда яр кырые — һич аерып хәл юк. Көтмәгәндә берәр дебаркадер яки баржа борын астыннан калкып чыга да һәм, без, барып төртелмәс өчен, кабаланып читкә ташланабыз... Ничек тә кыен... Сак булам дип, яр буеннан читтәрәк барсаң, берни күрер хәл юк, якынрак тотсаң, берәрсе сизеп тавыш куптаруы бар...

Шулай яр буйлап, төрле суднолар арасыннан саклык белән байтак вакыт баргач, ниһаять, берсе таныш сыман күренде. Фирсов белән Дубинин, нидер сизенгәндәй, шунда төбәлделәр. Мин дә, әле тәмам ышанып җитмәсәм дә, нәни баладай тыела алмыйча:

— Менә шул түгелме?.. Шәүләсе ничектер бераз таныш кебек,— дип әйтеп салдым һәм штурвалны шуңа таба ашыгып бора башладым.

Әлегә ачык күреп булмаса да, аны бераз төсмерләргә мөмкин: каюталары койрык якта, көймәсе кран-балка белән арткы палубага күтәртеп куелган. Шик тә юк, без эзләгән баржа нәкъ шул үзе.

Без машинаны акрынайтып тагын да якыная төшкәч, аның палубасында кемнеңдер кул изәгәне күренде һәм акрын гына:

— Монда килегез,— дип эндәшкәне ишетелде.— Чалкагызны менә монда эләктерик. Каютада ял итүчеләрне борчырлык булмасын.

Мин бу кешенең Шакир агай икәнлеген шундук тавышыннан танып алдым. Катер баржа янына килеп туктау белән ул да мине таныды, күзенә ышанмагандай, хәтта бер мәл гаҗәпләнеп карап та торды. Әмма телдән үзе берни дә әйтмәде, таныганлыгын да никтер сиздермәде. Тик шунда гына мин аннан бераз арттарак тамбур күләгәсендә караңгыда мылтыклы сакчы белән тагын кемдер берәүнең басып торганын күрдем. Күрәсең, Шакир агай алар алдында мине белгәнлеген сиздертергә теләми.

Матрослар чалкаларны эләктереп бетергәч, Фирсов күперчектән палубага төште һәм, зур түрәдәй, буйсындыручан нык тавыш белән:

— Әй, баржада,— дип кычкырды,— начальстводан кем бар анда, монда чакырыгыз...

Шакир агай аның погоннарын күрүгә аптырап калды. Миңа таба борылып, ямьсез итеп бер карады. Дәшмәде. Ә аңардан арттарак сак-

чы солдат янында торучы каравыл начальнигы кубрик баскычына иелә төшеп кычкырды:

— Комендант әфәнде, чыгыгыз әле. Начальство килде, сезне чакыралар...

Дагалы күн итекләре белән трапка дөп-дөп басып палубага урта буйлы, базык гәүдәле офицер күтәрелде һәм вакытсыз уяткан өчен:

— Кем килгән?.. Төнлә борчып йөрмәсәләр, көн бетканмени!? Нигә юкка-барга уятасың? — дип, каравыл начальнигын тирги башлаган иде, әмма безнең Фирсовны күрү белән шундук тынды, тиз генә бил каешын, наган кобурын рәтләде һәм хәрбиләрчә честь биреп исәнләште.

— Сугыш булгач, вакытлы-вакытсыз уятырга да туры килә... Ватанны фетнәчеләрдән азат иткәч, тынычлап йокларбыз,— диде Фирсов.— Комендант әфәнде, монда рәхим итегез, сөйләшеп алырга кирәк... Әй, вахтенный, комендант әфәндегә юл күрсәтегез...

Бу сүзләрне ул шөбһәләнергә һич тә урын калдырмаслык катгый рәвештә әйтте һәм командир каютасына керергә борылды. Комендант, аз гына да икеләнеп тормастан, тәбәнәк фальш-борт аша атлап, безнең палубага төште һәм, матрос кесә фонаре белән яктырткан араны тиз генә үтеп, Фирсов артыннан кереп китте. Дубинин матросларга, тышкы якта калып, әзер торырга кушты да мине үзе белән каютага алып керде.

Баржа коменданты артык симереп киткән калын таза гәүдәле, бик ачык чырайлы, күп сөйләшүчән яшь офицер икән. Фирсов өстәл янындагы урындыкта папирос тарта-тарта чак кына янтаеп утырган хәлдә аңар:

— Кайчан төяп бетердегез? — дип сорау бирде.— Документларыгыз үзегез беләнме? Күпмесе патрон, күпмесе снаряд? Нинди калибрлар?..

Комендант үз эшен бик тырышып башкара торган хәстәрле хуҗа булып чыкты. Баржадагы товарларын документсыз да күңелдән яхшы белә икән.

— Инде иртән иртүк төяп бетергән идек,— диде ул юма телләнеп.— Патроннар килеп житмәде, юлда эшелонны партизаннар шартлаткан бугай. Бөтен баржа тулы снаряд, төрле калибрдан. Теге яктагы гаскәрләргә дип төяткәннәр иде. Иртәдән бирле буксир көтәбез, никтер һаман күренми әле...

— Без сезне алмага килдек. Тиз генә кузгалыгыз, хәзер Осланга китәбез. Иртәгә һөҗүмгә снарядлар әзер булырга тиеш.

— Шулаймы!.. Иртәгә һөҗүм булачакмыни?!. Кызыл томаналарга әләгә икән. Хи-хи-хи...— Комендант куанычыннан кеткелдәп көлеп җибәрде һәм ишекне яртылай ачып шат тавыш белән баржадагыларга кычкырды: — Әй, ишетәсезме?.. Егетләр, хәзер кузгалабыз, якорьны күтәрә башлагыз...

Комендант ачылып сөйләп торган арада, Дубинин каютадан акрын гына чыгып юк булды, аның урынына минем белән янәшә бөтен корабта иң көчле кеше боцман Гаврилов кереп басты. Тышкы якта аяк тавышлары, шакы-шокы шпиль әйләндереп якорь күтәрүләре ишетелде һәм, түбәндә машина эшли башлау белән, кәрван акрын гына кузгалып китте. Ә шатлыгы чиктән ашкан комендант әле һаман туктый алмыйча:

— Һи, болай булгач, яшибез икән әле... Хәер, мондый баһадирлар белән теләсә нинди шайтанның муенын сындырырга була,— дип сөйләнә-сөйләнә боцман Гавриловның таза иңбашына кагылып ала иде.

Шул мәлне ул күзен ачыбрак карады бугай, түр почмакта ян иллюминатор белән китап киштәсе арасына сөяп куелган Кызыл байракны күреп алды һәм баскан җирендә таш кебек катып калды. Аннары, исенә килеп, корт чаккандагыдай чинап җибәрде һәм кинәт кобурына ябышты.

— Я, я! Коралыңны бир монда,— диде Гаврилов сабыр гына һәм кобуры белән наганын салдырып алды.— Иптәш командир, нишләтергә, расходкамы? Муенына таш асып суга салыргамы?

Боцманның моны өркетү өчен генә әйткәнлеге күренеп тора иде. Ләкин коты чыккан комендант аңламады. Куркудан зур ачылган күзләре белән әле Фирсовка, әле безгә карый-карый:

— Туганнар, карт анам хакына калдырыгыз, харап итмәгез,— дип ялварырга тотынды.

Хәзер инде вакыт әрәм итеп маташуның кирәге юк. Комендантны чылбыр ящигына ябып куйганнан соң, без рубкага менгәндә йөкле баржаны уң бортына таккан «Олень» инде байтак юл алып өлгергән иде.

Баржада каравыл командасы, әлбәттә, хәзергә аны-моны сизми әле. Шакир агай, берни дә белмәгәндәй, алгы яктан наметка белән тирәнлекне үлчәп бара. Палубада каравыл начальнигы күренми, тыныч күңел белән кубрикка төшеп киткән булса кирәк. Ябык люклар янында мылтыклы солдат тыныч кына ары-бире йөри. Хәзергә бар да нәкъ без теләгәнчә бара.

Ләкин иң хәтәре алда әле: Югары Осланда торучы дошман кораблары каршыга чыгып юлны кисүләре бар. Таң беленгәнче Печищи тауларындагы батареяларны үтеп өлгерергә кирәк, юкса, өермәдәй каты утка эләгәсеңне көт тә тор. Без моны барыбыз да ачык аңлыйбыз һәм тавыш-тынсыз гына барабыз. Һәр минут озак үтә. Кәрван гаять акрын кыймылдый; вакыт-вакыт ул агымга каршы бара алмыйча һаман бер урында таптанадыр кебек тоела башлый.

Авыр тынлыкта шулай озак кына барганнан соң, карт лоцман елганың уң ягындагы тау күләгәләренә карап хәлдә, гадәтенчә сабыр тавыш белән:

— Менә Печищины да үтеп барабыз... Ниһаять, котылдык бугай,— диде.

Әмма бу шатлыклы хәбәр бөтен судноga таралырга өлгермәде, шул чак һич тә көтмәгәндә караңгыдан ике кораб килеп чыкты: берсе кораллы буксир пароходы, икенчесе бронекатерга охшаган иде. Берниндн сигнал-фәлән биреп тормастан, алар безнең белән янәшә бара башладылар һәм, безне абордажга кысып алырга җыенгандай, шундук икесе ике яктан бик тиз якынайдылар.

Дошман оясыннан инде бәла-казасыз котылдык, ниһаять, дип эчкә җылы кергән чакта бу көтелмәгән очрашу күңелгә шом салды. Моны башка сыйдыра алмыйча бер мәлгә барыбыз да аптырап калдык. Баржада сакчы солдат мылтык затворын шалтыратып алды. Алгы палубада безнең тупчылардан берсенең түземсезлек белән:

— Ут ачарга ник приказ бирмиләр инде!.. Тегеләр ачканчы, атып өлгерергә кирәктер ләбаса! — дип ачынып әйткән сүзләре ишетелде.

Фирсов үзе белән янәшә басып торган Дубининга карап алды да:

— Нинди паника ул анда!?. Безнең кораблар ич алар, безгә ярдәмгә килгәннәр. Алдан шулай сүз куешкан идек,— дип көлеп җибәрде һәм мөмкин кадәр шау-шусыз гына баржадагы каравыл командасын коралсызландырырга приказ бирде.

Кешеләргә шом салган бу аңлашылмаучанлык шулай күңелле ачыклanudан барыбыз да, өстән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куй-

дык. Шул арада боцман Гаврилов бер төркем матрос белән баржа палубасына сикереп төште һәм шундук башта сакчыны, аннары кубрикта әле һаман берни дә сизмичә гамьсез йоклап яткан каравыл командасын коралсызландырды.

Бу вакытта инде без дә дошман батареялары турыннан үтеп, үзебезнең алгы отрядлар урнашкан базага — Морквашка якынлашып килә идек. Фирсов, трюмнарны карап чыккач, иңнәреннән погоннарын алып ташлады һәм нәкъ безнеңчә гади дингезче булып калды.

— Баржа коменданты дөресен әйткән, трюмнар тулы снарядлар,— диде ул.— Безнең гаскәрләр өчен бик кирәкле товар. Бер атусыз ни хәтле трофей кулга төшердек. Барыгыз да молодцы! Бигрәк тә баржа шкиперы Шакир агайга зур рәхмәт, аның тырышлыгы белән башланган эш бу...

Нинди зур эш башкарылганын барыбыз да яхшы аңлыйбыз. Төн буе дәвам иткән хәтәр киеренкелектән уңышлы котылуга һәркем шат. Шакир агай әле һаман тынычлана алмыйча үз алдына сөйләнгәндәй:

— Әйе, анысы әйбәт булды, нәкъ Зөлфия белән без уйлаганча килеп чыкты,— дип әйтеп куйды һәм, тик шунда гына абайлап алды булса кирәк, тиз генә трюмга төшеп үзе генә белгән аулак урыннан кызын чыгарды.— Теге комендант бик төчеләнеп йөри башлагач, өйгә кайтып китте дип, качырган идем,— диде ул.

* * *

Казанны азат иткәннән соң, бер карт грузчик сөйләвеннән безгә ишетелгәне шул булды: иртәгесен снаряд тулы баржа урынында булмагач, башта беркемнең дә исе китмәгән, командование кушуы буенча Идел аръягына алып кителгән дип уйлаганнар. Күрше баржалардан һәм яр буенда склад сакчыларыннан хәтта моны күрүчеләр, ишетеп торучылар да булган, имеш. Әмма бөтен сакчылары һәм командасы белән баржаны шулай бернинди каршылыксыз борын астыннан кызыл матрослар әләктереп китәр дип берсенең дә башына килмәгән.

Илдар Низамов

# ҖИЛКӘНЕ КИЕРЕЛГӘН КӨЙМӘ

хикәя



Иптәш судья! Башта ук үтенеп сорыйм, сез мине, зинһар, гафу итегез, ник дигәндә, сизеп торам, бу гариза сезгә килә торган гаризаларның берсенә дә охшамаячак. Ул, мөгаен, озын булыр. Ялыктыргыч юл кебек. Бик буталчык булыр. Ярга чыгарып ташланган юеш ятьмә кебек. Тик гозерләп сорыйм, сез инде ничек тә түзегез, монда язылганнарны берүк азагынача укып чыгыгыз.

Кем икән бу дип аптырашта калмагыз тагын. Юныс Кәримуллин мин. «Дозор» пароходы кочегары. Бәлки онытмагансыздыр да әле. Моннан берничә ай элек хатын белән, дөресрәге, элекке хатыным Вәсилә Кәримуллина белән судта каралдык, күз көеге булып, сезнең каршыда басып тордык. Бу чиккә килеп житкәнче үк әле, хәтерлисез микән, сезнең белән берничә тапкыр сөйләшеп утырдык. «Бер дигән гаилә корырлык яшь кешеләр бит әле сез, низагларыгызны онытыгыз да килешегез»,— дидегез сез. Олы башыгызны кече итеп, акыллы-акыллы сүзләр белән безне үгетләдегез.

Өлкәннәр киңәшенә бик каршы дәшеп бармыйм баруын, әмма, күрдегез, бу юлы аяк терәп каршы тордым. Бер акыллы язучы әйтмешли, ватылган савытны беркайчан да бөтен итеп булмый, ябыштырсаң да анда барыбер эзләр кала. Ә без инде ябыштырырлык хәлдә түгел идек. Хәтта мактаулы БФ-2 келәйләре дә ярдәм итмәс иде. Сез моны, күрәмсең, аңладыгыз һәм безне аердыгыз.

«Кочегар ходны артка бирә башлаган түгелме, суд карары дөрес булмады микәнни?» дигән шиккә төшмәгез тагы. Юк, кире чигенмим. Сез иң гадел карар чыгардыгыз, аның өчен сезгә рәхмәттән башка берни дә әйтергә теләмим.

Ләкин аерылышу белән генә безнең дөнья түгәрәкләнмәгән икән. Бер сайлыкны үтүгә пароходны икенчесе көтеп тора. Тагын да шомлырагы, куркынычрагы. Шуның кебек, минем алда да яңа перекат, иптәш судья. Менә ни өчен сезгә янә мөрәҗәгать итәргә, шушы озын гаризам белән сезне бимазаларга мәҗбүрмен.

Тик гозеремнең асылын бер-ике сүз белән генә төшендерә алмаячакмын, сезгә ачык аңлашылсын өчен миңа озын итеп, барысын да бәйнә-бәйнә язарга туры киләчәк. Ә бу, белмисез генә, минем өчен өч вахта рәттән эссе казан янында торудан да яманрак. Минем бит үз гомеремдә мондый хикәятләр түгел, ярты битлек хатны да юньлебашлы итеп язганым, бер тапкыр да болай җитди итеп, башны тырныйтырный, азаплана-азаплана уйланып утырганым булмады.

Гомумән, мин үз-үземне мәҗбүр итеп, төпле итеп уйларга өйрәнмәгәнмен. Бүтәннәргә файдасы тиярдәй кечкенә генә булса да берәр ачыш уйлап чыгардым микән үз гомеремдә? Буламы соң! «Башында аның җил уйный», дип, минем кебекләргә әйтәләрдер инде. Мәктәптә үк: «Мәсьәләләр күп, ә мин бер үзем, алар миңа тимәсеннәр, мин аларга тимим», дип, кыен сораулар белән күзгә-күз очрашмау ягын караган кешедән рәт чыгар дисезме? Чыкмады. Кеше кушканга карышмыйча, әмма үз башымны ватмыйча яшәргә күнегелде. Гамьсез булуга, кеше салган курстан баруга җитәмени?! Иделдәге пароходларны күргәнегез бардыр, иптәш судья, тик игътибар иткәнегез булды микән: зур буксир пароходларының койрыгына кечкенә генә көймә тагылган була. Буксир кая барса, теге дә шунда ияреп, боргаланып тик йөри.

Унбиш яшьтән «Дозор» пароходында кочегар булып эшли башлаган идем, хәзер утызны үтеп киттем инде, әле һаман шул рейдовыйда, һаман да шул «тәнлек начальнигы», ягъни, әлеге дә баягы, кочегар. Тәмәке тартырга, аракы эчәргә, тозлап-борычлап сүгенергә өйрәндем өйрәнүен, әмма алга берәр төрле план сызып, үз белдегем белән, акыллы итеп яшәргә өйрәнмәдем. Койрыктагы көймә ни әйтсәң дә көймә инде, буксир түгел, дулкыннарга йөз куеп, юл ярып бармый, авыр сәфәрләрнең җаваплылыгы да, кыенлыгы да аның җилкәсенә бик төшми.

Вәсиләгә өйләнү дә, кем әйтмешли, уптым илаһи гына, бүтәннәргә ияргәдән генә булды. Ул Сания дигән кыз белән затон складында эшли иде. Тегесен-монысын кертеп, чыгарып торалар, җыештыралар, пароходтан килгәннәргә кирәк-ярак биреп җибәрәләр.

Дөресен әйтергә кирәк, төс-кыяфәте ягыннан Вәсилә ахирәтеннән күпкә калыша иде. Авыз зур, борын тупык, карашы да ничектер авыр, чәнечкеле. Шулай да ул махы бирмәскә тырыша, бөтен теләге, ничек кенә булса да, Сания белән бер дәрәҗәдәрәк йөрү, аннан калышмау.

Сүз юк, тегесен-монысын алырга килгән безнең ише агай-эне Сания эргәсендә генә бөтерелеп калмый, Вәсиләгә дә бәйләнә. Складның карангырак почмакларында кысрыклап, матур сүзләр сайрарга тырышалар. Йомшак төшләренә кул сузып интектерәләр. Җай туры китереп, мин дә шаяргалыйм. Кордашлардан калышып буламыни, мыек төртеп килә ич инде.

Тик шунысы бар, Вәсилә тирәсендә складта этәчләнеп, матур сүзләр, тау-тау вәгъдәләр сайраган ыспайлар, клубка килеп кергәч, тавык күзгә әйләнәләр, Вәсиләне бөтенләй күрмәс булалар. Кайда чибәр утыра, шарлары шул якка текәлә. Биюләр башландымы, ни арададыр парлашып та бетәләр. Вәсилә генә, юан аякларын эскәмия астына яшерергә тырышып, үзен-үзе кочаклаган килеш ялгызы утырып кала. Сизеп торам, ачудан аның йөрәгенә кан сава, бирешмәскә тырышса да, күзләренә буылып-буылып яшь килә. Бик аңлыйм мин аның хәлен. Үземнең төс-бит тә ташка үлчим түгелмени: искерә башлаган щетка кыллары кебек тегендә-монда чуалган, тарасаң да рәткә кертеп булмый торган кап-кара чәч, ялтыр-йолтыр кара күз, тик кенә торганда да ерылырга әзерләнгән калын иреннәр. Кыскасы, юньлерәк кызларның ничек кенә булса да минем белән биемәскә тырышулары, йөз чөерүләре җанны аз әрнеткәнмени! Шулай булгач, чиләгенә күрә капкачы дим дә китәм Вәсилә каршысына. Бичарага ни чара, ул да карышмый.

Аннан соң, эшнең икенче ягын да онытмыйк, нинди генә акылсыз, нинди генә максатсыз җан булсам да, мин каты бәгырьле түгел, үз гомеремдә бер тапкыр да бүтәннәргә начарлык эшләмәдем бугай. Берәрсенең йөзендә борчу күрүгә үк әллә нишләп китәм. Билләһи дим, төптәнрәк уйлаган булсам, Василәдән акыллырак, чибәррәк кызлар белән йөрерлек тә җай бар иде анысы, әмма бер башлагач ташларга, кызга борчулар китерергә күңел бармады. Мин армиягә киткәндә без хатлар язышырга, бер-беребезгә мәңге турылыклы булырга вәгъдәләр бирештек.

* * *

Армия димәктән, хезмәт итеп кайтышлый мин көтмәгәндә генә бер кызык мажарага тарыдым. Сүз озынга сузыла инде сузылуын, иптәш судья, шулай да бу турыда язмыйча булмый. Аңлагыз берүк, кызык өчен түгел, сезгә кирәк булыр дип язам.

Срокны тутырып, туган якларга кайтып киләбез шулай. Бер көнне поезд Тайга дигән станциягә килеп туктады. Пассажир халкы, кояш чыкканны көткән бал кортларымыни, шунда ук вагоннардан сибелде. Мин дә нардем. Папирос эзләп, тегендә-монда сугылгалаганчы берничә минут вакыт үтеп тә китте. Кешеләрен чакырып, паровоз пошкыра да башлады. Йөгер тизрәк вагонга. Тик шунда киоск почмагында елап торган бер кыз күзгә чалынмасынмы.

— Ни булды? — дим,— нигә елыйсың?

Капыл дәшүдән кыз сискәнеп китте. Карашында борчу, кызыксыну бергә буталды. Шулай да ул тикмәгә генә сорашмавымны, кирәк булса ярдәм итәргә ташланачагымны әллә кайдан сизеп алды бугай, тырт-пырт килеп маташмады.

— Билетка дигән акчамны алдылар, шушы поездга утырмаммы дигән идем,— диде ул.

— Д-а-а,— дип суздым, нишләргә белмичә бер урында таптанып,— өегез еракмы соң, кая юл тоту?

— Балалар йортыннан мин, моннан өч йөз чакрым чамасы. Юдинода апам табылды, шунда кайтадырыем.

Кинәт, икебезне дә сискәндереп, паровоз кычкыртып җибәрде. Кыз вагоннарга, тыгыла-тыгыла аларга тулырга кабаланган кешеләргә карады. Шомырт бөртегедәй кап-кара, чип-чиста күзләре кинәт ялтырамас булдылар, юка иреннәре дерелдәп куйды. Түзмәдем, аның төенчеген эләктереп алдым.

— Әйдә вагонга, шунда уйлашырбыз.

Кыз артка тайпылды, башын чайкап, төенчеген кире тартты.

— Юләрләнмәгез, поезд китә бит,— дип, кулыннан ук тоттым,— курыкма, минем кешеләргә әшәкелек эшләгәнем юк, ышаныгыз!

Вагон көпчәкләре авыр гына кузгала башлады. Әллә шул тәэсир итте инде, әллә минем сүзләр башына барып җитте, кыз карышудан туктады. Йөгердек вагонга.

Безнең вагонда күпчелеге солдатлар, матрослар. Кызны шунда ук чорнап алдылар, кыстый-кыстый пальтосын, шәлен салдырдылар. Кайдан алганнардыр, өстәл ашамлыклар белән тулды. Ләкин кызыбыз аларга үрелү түгел, күтәрелеп тә карамый, урманнан адашып ишегалдына килеп кергән болан баласымыни, менә-менә тәрәзәгә сикерердәй булып, суларга да куркып тик утыра. Берсеннән-берсе уздырып, егетләр аны өстәл янына кыстадылар, ничек тә күңелен ачып җибәрергә тырыштылар. Кызыбыз акрынлап эри башлады. Люция исемле икән. Вокзалда аны бер хатын төп башына утыртып киткән. «Чиратта кысып үтерерләр, китер, билетны үзем алып бирәм», дип акчасын эләктергән дә, ф-ю-ю, җилләр искән.

Карак хатынны ботарлап ташлардай булып нәфрәтләндек тә бит, аннан ни файда, йодрыкларны төмәрләү белән генә акчаны кире кайтарып буламыни.

Шунда мин үз гомеремдә беренче мәртәбә бер инициатива күрсәтеп ташладым.

— Булган хәл булган инде, братцы,— дим,— үткән эшкә салават, ә бит кызга ничек тә ярдәм итәргә кирәк.

Шулай дидем дә, бескозырканы салып, тез башына куйдым. Кесәдә күпме акча бар, барысын да учлап чыгардым да, нәкъ урталай бүлеп, яртысын шунда салдым. Егетләргә аңлатып торасы юк, шунда ук төшенделәр, күршем бескозырканы сүзсез генә үзенә алды, башкалар да кесә төпләренә төшеп менделәр. Китте, мин сиңа әйтим, кулдан-кулга күчеп бескозырка, дулкын өстендә чайкаламыни. Безнең купедан икенчесенә күчте, шуннан бөтен вагон буйлап китте.

Озак та үтмәде, билетка житәрлек акча белән тулып, кире дә кайтты. Мин аны кызга тоттырдым. Люция әле акчага, әле безгә карап, ни әйтергә дә белмичә торды да, күнеле тулып, кинәт елап җибәрде.

Кичен мин аны үз урыныма яткырдым. Өстенә бушлатымны яптым. Сверхсрочник ефрейтор Южков, күзләрен майландырып, кыз янында бик юмаланган иде дә, Люциянең ана әллә ни исе китмәде. Шулай да ефрейтор, төнлә торып, теге акчага Новосибирскида аңа билет алып менәргә булды. «Шундый чибәр дигәндә станциягә түгел, жир астына төшәргә дә әзер!» диде ул, Люциягә каш сикертеп. Ялагайлана тасма тел, чыннан да кыз өчен генә төшә диярсең. Новосибирскида аның барыбер төшеп менәсе бар, чөнки үзенә дә билет алырга кирәк, бер-ике станциядән ул үз ягына, бүтән поездга күчеп утырырга тиеш.

Кыстый-кыстый ул мине үз урынына яткырды, өстемә шинелен дә япты. Йоклап киткәнне сизми дә калганмын. Күпме йоклаганмындыр, белмим, салкынга дереләп уянып киттем. Өстә ефрейторның шинеле юк. Вагонда яртылаш караңгы. Барсы да йоклый, армас көпчәкләр генә, «кайтасыз, кайтасыз» дип тукылдый бирәләр. Торып утырдым. Үз урыныма караган идем, йөрәк «жу» итеп китте: Люция юк. Тревога сукты-лармыни, сикереп тор тизрәк. Карыйм, ефрейтор да юк. Бу нинди мәзәк тагы? Икесе бергә билетка төшкәннәр дияр идем, поезд әле туктамаган. Кайда соң алар?

Йөгереп тамбурга чыктым һәм үз күзләремә үзем ышанмыйча аптырап калдым: икесе генә басып торалар. Ишек ачылгач та читкә атылган Южков кулларын бер-берсенә чалган да, бер нәрсә булмагандай, тәрәзәдән карап бара.

— Нишлисез сез монда, Люция, ни булды? Туңып беткәнсең ич! — дим.

Люциядән элек ефрейтор телгә килде.

— Ә син нәрсә кысыласың? Ул үзе безгә кайтырга теләде, билетны да шунда алырга сорады, хәзер менә, ник алдың, сезгә кайтмыйм, дип кәжәләнеп маташа.

— Ышанма, зинһар, Юныс,— дип өзгәләнеп елап җибәрде Люция,— бер нәрсә сораганым юк, әле менә чакырып чыгарды да үзләренә кайтырга кыстый башлады. Нишләп мин аларга кайтыйм ди, Юдинода апам көтә ич мине.

Монда нинди шухыр-мухырятьмәсе салынганын аңлар өчен әллә ни күп акыл кирәкми иде. Люцияне кертеп җибәрдем дә озак уйлап тормадым, көчем житәме, юкмы, тегенең изүенә ябыштым. Каты гына тәпәләштек тәпәләшүен, әмма акчаны барыбер кире кайтарттым.

Станциясендә төшеп калган Южков, шаярткан булып, миңа бармак янады.

— Элэктердем дисең инде калҗаны, ә, кара аны, бугазыңа аркылы килмәсен,— диде.

Бу сүзләрнен төбенә башта тиз генә төшеп житә алмый тордым. Аңлагач инде, бозлы су коелгандай, әллә нишләп киттем. Минә ни уйлаган бит, паразит! Бүтәннәр дә шулай уйласа, Люциянең дә күңеленә шундый чит-ят уй килсә нишләрсең?

Юлның калган өлешендә мин шиңгән үлән кебек боегып калдым. Люция белән бик сөйләшәсем килсә дә, шомырттай күзләренә бик карыйсым килсә дә, аның белән ялгыз калырга, күзгә-күз очрашып сөйләшергә кыймадым.

Казанга килеп житкәч, ул миңа адресын бирде. Кунакка чакырды. Мин төшеп калганда перронга озатырга чыкты. Бик чибәр, ифрат якын, туганым кебек кадерле иде ул миңа. Шул турыда аңа әйтим дип талпынып-жилкенеп куйсам да тел әйләнмәде. Намус бармак янап торды, күрәсең. Ник дигәндә, Южковның астыртын кинаясе, мәкерле елмаюы әле һаман күз алдында иде. Бүтәннәр дә миңа шикләнеп карыйлардыр, Люция үзе дә шундый ягымлылыгы белән сынап кына торгандыр кебек тоелды.

Хезмәттән кайтып, эшкә урнашкач та Люцияне бик еш искә төшердем. Аны күрәсе килде, берничә тапкыр хәтта әллә барып чыгыйммы дип жыенып та беттем. Әмма һаман да шул мәкерле елмаю күз алдына килеп баса да канатлы уй-теләкләрне богаулый да куя иде.

Әмма озак уйлану, берәр хәлиткеч карарга килү, беләсез, миңа ят нәрсә. Бу юлы да мин Люциягә кул селтәдем, биргән вәгъдәләргә турылыклы булмауны яхшысынмыйча тагы Вәсилә белән якынаеп киттем. Ә ул мине түземсезләнеп көтә иде инде. Аның, әлбәттә, үз кайгысы, үз исәбе бар иде: мин кайтыр алдыннан гына Сания кияүгә чыккан. Тешетырнагы белән аннан калышмаска хәл кылган Вәсиләнең шундый вакытта күзенә ак-кара күренәме соң. Ике сүзнең берендә өйләнешергә ым ясады, тел төбендә шул гына иде. Тагын берәр елга сузарга тартышканда яхшы буласы икән дә, ул алтмыш яшьлек картка булса да ябышып чыгып китәсе икән, минем шул, әлеге дә баягы, акыл дигән нәрсә кайдадыр читтә йөргән. Каршы дәшмәдем, иптәшләр дә парлы була башлады, вакыттыр, ахрысы, дидем дә, әллә ни уйланып, кемнәндер киңәш-фәлән сорап тормадым, барысына да кул селтәдем дә чумдым упкынга. Менә шулай яшәп киттек.

Әмма нигез ташы нык салынмаган йорт озак торамыни. Кызганыч, без тормыш арбасының пар тартасе була алмадык. Беренче көннән үк хатын миңа күтәрә алмаслык йөк өя башлады. «Сания тегеләй киенгән, алар шунда барганнар, алар тегене алганнар, ә мин, ә без?» Көн саен менә шулай туку, көн саен үпкәләү. Миңа, болай да ваемсыз, артык мәшәкать алуны яратмый торган кешегә шаярып авыз ерудан, инде күп булса кул селтәп өйдән чыгып китүдән башка ни кала. Хатын түзгый дип Иделгә пират булып урлашырга чыгып китмәмдер лә инде.

«Саниянең ире әнә укый, ә син һаман кочегар, ике бүлмәле квартир алдылар, ә без һаман барак бүлмәсендә», дип колак итен ашый да ашый бу. Дөрес анысы, минем белән кочегар булып эшли башлаганнар арасында механиклар да бар инде, кешеләр укыйлар, үсәләр, хаккамы, нахаккамы дигәндәй, ничек кенә булса да квартирын да алалар. Ә мин гел бер урында таптанам. Тик бу мине бик борчымый, Вәсиләнең нервыларда уйнап, кабызырга теләвенә дә янып китмим; барыбыз да механик булып бетсәк, казанны кем карар, чүп-чарны кем җыештырыр?

Мине камчылый хатын камчылавын, ә бит үзе дә бик ерак китмәгән. Сания әллә кайчан инде бухгалтерлар курсын бетерде, ә ул әле һаман склад идәнен себерүдән билен турайта алмый. Кулдан килмәгәч, бугазын киермәсен иде, ичмасам, булганына шөкер дип, тыныч кына яшәсен иде. Бүтәннәр яши бит әле, без дә ким-хур булмас идек. Юк шул, буе житмәскә үрелде, аягын юрганына карап сузмады.

Саниядән көнләшүе тәмам чиргә әйләнде. Аңардан калышкан саен чыгырыннан чыга барды. Эшләр бозылуга китте. Сүгенүен дә миннән ким куймый, стаканын да бик кыстатып күтәрми. Барысын да мина ачу итеп эшли. Миңа ачу итеп бүтәннәр белән чуала башлады. Кәгазьне пычратып, язуы да уңайсыз: мин рейсларда чакта Саниянең ирен ничек тә юлдан яздырырга маташып, үзе аның муенына сарылган. Эшләре тирәнгә китә башлагач, Саниясе моның чәчен йолкырга ябышкан, сугышып киткәннәр. Әйтергә оят: унбиш тәүлек утырып чыкты бит. Төрмәдә утырды утыруын, акылга гына утырмады.

Мин дә бизгәннән-бизә бардым. Рейстан соң өйгә кайтасы килми. Малайны күрер өчен генә кереп чыгам. Аңа да йөрәк кенә әрни. «Юньләп карамый, малаең төннәр буе берүзе кала, ач, пычрак йөри»,— дип күршеләр зарлана. Шундый йортка ничек кайтасын килсен, барысына төкерәм дә китәм дус-иш эзләп. Эчәбез. Акча бар. Барыбер тегендәмонда тузгыта, малайны да юньләп карамый, ичмаса, дип, хатынга хезмәт хакын да бирмәс булдым. Премия-фәләнен әйтсәң дә юк инде.

Күрәсең, бу хәлгә мин бик борчылмадым, атылып бәрелмәдем, өзгәләнү минем характерда түгел, азмыни этле-мәчеле яшәгәннәр, очраган бер ташка башны бәреп буламыни, рәтләнер әле бер, дип тик йөрдем. Ләкин шторм һич көтмәгәндә башланды. Алимент даулап, Вәсилә минем өстән судка биргән булып чыкты. Ваемсыз дигәч тә мин дә ул кадәр күзле бүкән түгел, эш инде алайга киткәч, мин дә форсунканы полный ходка ача беләм: алимент белән бәйләнеп торган семьяның барыбер рәте-башы булмас, үзелә башлаган икән, тәмам өзелсен әйдә дидем дә, «бөтенләй аерыгыз алайса», дигән гариза язып, судка илтеп бирдем.

Калганын үзегез беләсез, иптәш судья, барысы да сезнең күз алдыгызда үтте. Тик бер генә нәрсәне искә аласы килә; беренче тапкыр килгәндә сезнең бер соравыгызга мин дөрес җавап бирмәдем. «Өйләнергә ниятләгән, яңа гаилә корырлык якын кешегез бармы?» дигәч, мин: «Бергә яшибез инде, бар, әлбәттә», дидем. Ялганладым, чөнки шулай дисәң эшенне тизләтәләр дип өйрәтеп куйганнар иде. Ә чынлыкта юк иде әле ул вакытта яңа семьям, бер кемем дә юк иде.

Ә менә сез шундый сорау биргәч тә нишләптер күз алдына ялт итеп Люция, хәтерлисезме, теге вакытта поездда бергә кайткан кыз килеп басты. Яшермим, станциядә аерылышканнан соң берничә ел үткәч, мин аны тагын бер очраткан идем. Һич уйламаганда, көтмәгәндә генә.

Бервакыт шулай ниндидер бер эш чыгып, «Дозор»дан калдым да аны пассажир пароходында куып җитәргә туры килде. Шунда очраттым Люцияне. Олыгаеп киткән, гәүдәгә дә элекке чикерткә түгел, тулылана төшкән. Ә күзләр һаман да шул шомырт бөртекләре, мөлаемнәр, якын итеп карыйлар, аз гына моңсулар.

— Ә мин сине теге вакытта бик көткән идем, апам белән бергәләп тагын бер тапкыр рәхмәт әйтәсе килгән иде, нишләптер килмәдең,— диде ул, башын иеп.

Мин нәрсә әйтергә белмичә торататш кебек җансыз калдым, үзем дә сизмәстән, аның итәгендә яткан кызчыкның сап-сары йомшак чәчләрен сыйпадым. Кызчык, минем Харисым кебек, өч-дүрт яшьлек кенә иде бугай. Люция дә аны сөеп алды.

— Ә апам юк инде, үлеп китте. Шуның кызы бу. Гөлсем. Хәзер инде минем кызым,— диде Люция һәм минем бу хәбәрдән аптырап, берни аңламыйча телсез калуыма җавап биргәндәй, акрын гына сөйләп китте.

— Тормышлары көйле булмады, ызгышып яшәделәр. Апа еш чирләде, җизни шуңа да яратмады бугай, гел читкә китеп йөрде. Вербовка белән. Бу юлы Кама якларына, урман кисәргә киткән иде. Апа бик бетерешкәч, телеграмма суктык. Соңга калды. Күмәргә генә кайтып

китте. Кире киткәндә өлкән энекәшне үзе белән алды, ә Гөлсем минем белән калды. «Җае чыккач та алдыртырмын», дигән иде җизни.

Бик озак көттек, ярты ел узгач кына чакыртты. Өйләнде микән әллә дип барсам, юк икән, Гөлсемне балалар йортына урнаштырырга хәл иткән. Әллә ниләр күз алдыма килде дә аның бу карарына каршы төштем. Апаем авызыннан чыккан соңгы сүзләр искә төште. «Балаларны ташлама, сеңелем», дигән иде ул. Гөлсем белән аерылышмаска булдым.

Менә кире кайтып киләбез. Без хәзер бер-беребезгә шул кадәр ияләндек, ана белән кыздан бер җиребез дә аермалы түгел. Охшаганбыз бит бер-беребезгә? Яшәрбез әле ничек тә, бирешмәбез. Безнең фабриканың детсады бар. Әйбәтләп үстерермен, урын бирми калмаслар.

Аның әчкерсез сүзләреннән минем дә күңел нечкәреп китте, үзем дә сизмәстән ана Харисым турында, аны яратуым турында сөйләдем. Хатынны яманлап маташмадым, ул вакытта безнең тормыш түзәрлек кебек иде әле. Болай ук чәлпәрәмә килербез дип көтелгәнмени.

Төнге пароходта тыныч иде. Безне йокы алмады, тик сөйләшеп утырдык. «Үзебезнең» вагонны, усал Южковны искә алдык. Икебез дә вакыт-вакыт көлгәндәй иттек. Әмма сизелеп тора: беребезнең дә чынчыннан көләсе килми, икебезнең дә күңел төбендә әйтелмәгән сүзләр кала бирә. Ә ул арада миңа төшәргә дә вакыт җиткән иде.

Ярда бер үзем торып калдым. Пароход шунда ук караңгылык эченә кереп югалды. Мин аның артыннан карап, сүнгән маяк баганасы кебек җансыз басып тордым. Якын кешеңне алып киткән пароходның тоныкланганнан тоныклана барган утларына карап торудан да күңелсез, моңсу нәрсә бар микән дөньяда!?

* * *

Мин аны янә берничә ел күрмәдем. Ә менә сезнең теге соравыгызга җавап биргәндә ул күз алдына шулкадәр якын булып, кадерле булып килеп басты, мин шунда тормышта бик зур хата ясаганымны аңладым. Нишләгәнмен мин!? Бәлки, ул беренче мәхәббәтем булгандыр, чын бәхетем, бәлки, ул гынадыр. Инде соңлаган булсам нишләрмен?!

Судка биргән гариза Васыйлә белән араны шатырдатып өзде. Ул көнне мин үземне читлектән котылган кош кебек хис иттем. Икенче, өченче көннәрне инде кая барып бәрелергә белмичә минрәүләнеп тик йөрдем. Люция бер генә минутка да күз алдыннан китмәде. Дүртенче көнне түзмәдем, киттем Юдиногә, Люцияләрне эзләп.

Җан атып, ут йотып эзләгәч ник табылмасын, таптым. Апасының кечкенә генә квартирында торалар икән. Гөлсемне бакчага урнаштырган, үзе тегү фабрикасында эшли, кичке мәктәптә укый.

Ул көнне мин аларда озак утырмадым, ашыккан булдым. Янәсе, бер иптәшне эзләп йөрешли, очраклы гына кергән кешемен, китәргә кирәк. Хәтта бергә утырып чәй эчәргә дә кыюлык җитмәде. Гөлсемгә дип алып килгән алманы, Люциягә әйтергә дип көннәр-төннәр буе күңелдә шомартып йөрткән матур-матур сүзләрне дә кире алып китәргә туры килде. Әмма алар янының мин ярсу акчарлак кебек чыгып киттем, ник дигәндә Люциягә әле «ул-бу булмаган», ул миңа элекке кебек үк ягымлы карый. Озата чыкканда да: «Шулай килеп йөрегез, сез бит минем туганым кебек якын кешем», диде.

«Дозор» — кечкенә пароход. Әллә ни ерак йөрмибез. Рейс саен күп дигәндә ике-өч көн вакыт китә. Әмма бу юлы ике көн миңа әкияттәге сират күперләрен үтү кебек озак та, азаплы да булды. Ин кызу йөргән поезд да Юдиногә бик акрын бара кебек тоелды.

Рейс саен шулай ашкынып, кабаланып кайта торган булып киттем. Кайвакыт шулай әтәчләнеп, дулкынланып барам да йортлары янына

килеп житкәч, тукталып калам. «Еш йөрисен бит, Юныс, яхшы түгел, биздерә күрмә үзләрен», дим. Сәгатьләр буе шул тирәдә йөрим дә кире кайтып китәм.

Ә минем килүемә алар сөенәләр иде кебек. Акрынлап без якыная, бер-беребезгә иярәшә бардык. Гөлсем аеруча яхшы дус булып китте. Бата башлаган чакларда коткаргыч божраны ул ташлый. Әйтик, «ике көннән тагын киләсен ничек әйтим икән инде», дип азапланып торганда бөтерчек кебек килеп житә дә: «Безгә тагын кайчан киләсең?»,— дип сорый. Әчкә жан кереп китә, ә шулай да сер бирәсе түгел. «Кайчан килим соң?» дигән булам. «Иртәгә кил»,— ди. «Юк, мин әйтәм, иртәгә булмый, ике көн буе миңа пароходка пар биреп торырга кирәк, ату ул йөрмәячәк, ял көнне килермен, яме»,— дим. Үзем, ни әйтерсең дигәндәй, тарсынып кына Люциягә карыйм. Ул Гөлсемгә бармак яный. Ә үзе, сизәм, канәгать. Күзләре елмая.

Люциянең йөргән егете барлыгын беләидем. Армиядә, быел кайтырга тиеш. Аны көтүен, аннан хатлар килүен Люциядан башка ук яшермәде. Гөлсем аркасында араларының көннән-көн суынуын да әйтте ул. Беленеп тора, ул моны бик авыр кичерә, егетне югалтасы килмәүдән бигрәк, якын итеп йөргән кешесенең әчке кичерешләрен аңлый алмавына өзгәләнә иде бугай ул. Шул азаптан егеткә кискен-кискен, биздерерлек хатлар да язып ташлый иде, күрәсең.

Бер көнне мин килгәндә алар бүлмәсендә бик күңелсез иде. Гөлсем дә сәбәпсез-нисез көйсезләнеп йөрде, Люция аны яткырырга мәжбүр булды, моңлы гына сузып көйли-көйли, аны йоклатырга кереште, үзе миңа карамыйча гына өстәлдәге хатка ымлады. Солдат хаты иде. Озын иде, урыны-урыны белән ачулы да, ягымлы да иде. Күренеп тора: егет нишләргә дә белми, азаплана, актык чиккә житеп икеләнә. Әмма ни язса да тел төбендә бары бер сүз: мин балалы хатынга өйләнә алмаячакмын, я ул, я мин.

Гөлсем йоклап китте. Люция минем янга килеп утырды. Хатны алды да андагы: «Апаң баласы өчен синең шулай өзгәләнүен һич аңлашылмый», дигән жөмләгә калын итеп сызып куйды. Аз сүзле, әмма гажәп нечкә күңелле Люция өчен бу юлларның үткен хәнжәр икәнен мин шунда гына аңлап алдым. Беләм, мондый киная өчен ул егетне бер вакытта да кичермәячәк.

...Иптәш судья, гариза биргәннән алып, суд булганчы бик күп вакыт үтте. Аерылышу турында рәсми документ алганда минем, чыннан да, яңа семьям булырга тора иде инде. Элекке хатын белән эшне өзгәч тә Люция миңа кияүгә чыгарга ризалык бирде.

Дөресен әйтим, суд та, аерылышу да мине артык тетрәтмәде. «Борчылма юкка, бер без генәмени, күрдең ич күпме кеше аерылыша, тормыш шулайдыр инде ул», дидем үз-үземә, уйланмаска, борчылмаска тырышып. Хәтерлисез микән, судта да үземне бик ваемсыз тоттым. Каушау, дулкынлану юк иде. Сез: «Киләчәктә ничек яшәрсез соң, яңа семьяларыгыз таркалмасмы, шул турыда кайгыртасызмы?» дип сорагач та авыз ерып, «алла белсен инде, күзебез бар, күрербез әле», дидем.

* * *

Менә, ниһаять, миңа үз квартирымнан бөтенләйгә чыгып китәр көн дә житте. Әйтәсе сүз әйтелгән, бүленәсе әйбер бүленгән. Чемодан-капчыклар әзер, тирән итеп бер сула да чык та кит. Әмма мин кузгала алмыйча тик торам, палубага мәңгегә беркетелгән корыч түмәр кебек катканмын да калганмын. Менә кузгалам дим, тик нәрсәгәдер бәйләнгәнмен, шул тота. Сулый алмыймдыр, бөтен тәнем яшәүдән тукталгандыр сыман. Өстемә әллә нинди хәвеф киләдер, менә-менә ул мине үзе белән мәхшәрле упкынга өстерәп китәр кебек. Һәм кинәт азак чиккә

житеп киерелгән бу тынлык чәлпәрәмә килә, аяз күнне чалтыратып җибәргән аяусыз яшен кебек үткен, мәрхәмәтсез сорау башка, бөтен тәнгә чәнчелә: «Ә улым, Харисым!?»

Җанны телгәләрлек иде бу сорау, яшен кебек көйдергеч иде. Мин айнып киттем. Әйтерсең, утыз ел буе йоклаганмын да менә хәзер генә төртеп уятканнар. Уянып торып басканмын һәм миңа хәзер тормышта беренче тапкыр атлап китәргә кирәк.

Хәтерлисезме, иптәш судья, мин үземне буксир койрыгына тагылган көймә белән чагыштырган идем. Ә бит килә бер көн: көймәнең дә буксирга бәйләнгән баулары һич көтмәгәндә шартлап өзелә. Бу инде синә шаяру түгел, ә чын сынау. Нишләрсең, көймә, шул мәлдә? Усал дулкыннар белән йөзгә йөз очрашканда югалып калмассыңмы, мөстәкыйль юлга чыккач ишкәкләрең чыдармы, монарчы давыллар зәһәрен белмәгән җилкәнең нәкъ кирәкле вакытта киерелеп, сине кирәкле урынга китереп житкерерме?

Харис уянган иде инде. Мин, атылып килеп, аны күтәреп алдым, күкрәгемә кыстым. Бугазга авыр таш килеп утырды, күз алдым томач белән капланды. Малай да нәрсәдер сизенеп дерелдәп куйды, әмма миннән тайпылмады, сагынып, яратып сыена гына төште, биткә аның җылы сулышы бәрелде. Онытылып, тәэсирләнеп, мин аны тагын да катырак кыстым: «Бәгырем, җан алмам син минем, бирмим, беркемгә дә калдырмыйм сине! Җир йотсын, Иделебез кирегә ага башласын, барыбер сине әтисез калдырмыйм!» — дип пышылдадым. Күз алдына дымлы пәрдә эленгәндәй булды. Хариска текәлеп карыйм, тик, аптырарсың, берни күрмим. Аның урынына үзем, үз тормышымның төрлетөрле сурәтләре чагылып-чагылып киткәндәй була.

...Әтидән калганда дүрт яшьлек малай идем. Аны белгән, аның белән бергә булган бары бер генә көнемне хәтерлим. Бөтен гомеремдә нибары бер көн. Теге мәрхәмәтсез июнь иртәсе иде ул. Хәзер ул иртә хәтердә ташка уелган рәсем кебек кенә инде: елый-елый шешенеп беткән әни, әледән-әле моңсу итеп, әллә кая өстерәгәндәй сузып-сузып кычкыртка пароход, аның эченә берсе җырлап, берсе елап агылган кешеләр.

Һәм әти. Менә ул капчыгын аркасына асты. Мине күтәреп алды. Шуны гына хәтерлим: ул минутта мин әти күзендә яшь күреп бик тә, бик тә аптырадым, әтиләр дә елый микәнни! Тагын шул истә, күтәреп алып, әти мине күкрәгенә бик каты кысты. Аның китель төймәсе, тәнемә батып, бик авырттыра башлады. Шуңа түзә алмадым, сыкранып елап җибәрдем.

Тукта, менә әле дә, теге аяусыз иртәдән соң инде дистә-дистә еллар үтеп киткән булса да, күкрәк һаман сызланып тора түгелме? Я дөнья, утлы тимер белән баскандай, якорьлы төймәнең эзе калды микән әллә!? Бик кыен булгандыр, әтием, мине ташлап китүләре.

Ә миңа синнән башка яшәве җиңел булды дисеңме? «Их, әти булса», дип әрнегән уйлар аз килдемени башка. Ярар инде, аларны искә төшереп, күңел яраларын яңартмыйк, бүтәннәрнең башына төшмәсен. Класста берәр тәртипсезлек килеп чыкса — укытучылар, шайба тиеп, тәрәзәләре коелса — күршеләр ачулы, усал карашларын иң әүвәл миңа текиләр иде. «Үксездән юньле кеше чыгармы, әтисе булса болай йөгәнсезләнер идемени», дигән шәфкатьсез сүзләр кыйнап ташлаудан да битәррәк әрнетә иде. Әнине дә артык гаепләп булмый, аның үз кайгысы кайгы иде, тормышның авыр арбасын тартышырга юлдаш эзләде. Тапкач инде мин ничектер онытылдым диярлек.

Чыннан да, әти исән кайткан булса, тормыш бәлки икенчерәк курстан киткән булыр иде. Алда зуррак, яктырак маяк кабызган булсалар, ягъни яшәү өчен олырак максат куелган булса, шуңа барырга көч табылмас идемени. Семья корганда да берәр төплерәк киңәш биргән булсалар, бәлки мин дә әлегедәй ут, ялкын эчендә янып тормас та идем.

Кыен, бик кыен этисез яшәве. Хариска да шундый тормыш әзерләү зур җинаять саналыр иде. Юк, моңа юл куймас өчен мин барысын да эшләячәкмен.

Минем нинди хисләрдә януым Василәгә дә барып житте бугай, ул, күзләрен акайтып, миңа карады.

— Куй баланы, синнән башка да яшәр әле!

Харис әнисенең карашыннан куркып, үзе үк миннән аерылды. Җайлап кына, иркәләп кенә урынына салдым. Аны алырга, даулашып торырга бернинди хакым юк иде инде. Тикшереп-төпченеп тә тормадыгыз, закон Василә ягында дидегез дә малайны аңа калдырдыгыз бит, иптәш судья.

...Ул көнне пароходка кайтып төшкәндә күңел күтәренке, кәеф шәп иде. Чөнки исерек идем. «Бирешмә, кочегар, парынны маркада тот,— дидем мин үз-үземә минут саен,— нигә әле безгә борынны салындырырга: яшь хатын, квартир бар, үземнеке булмаса да, мөлаем гына кызчыгым бар. Мине алар яраталар, көтеп торалар. Ә малаймы? Законны бозып булмый инде, браток, алимент түләячәкмен, бер мин генәмени, күп кешенең башыннан үткән хәл ич бу...»

Ләкин иртән, төнге фәлсәфәм искә төшкәч, алама эш өстендә тотылган кеше хәлендәрәк калдым. Моңарчы минем үз-үземә болай нәфрәтләнеп караганым юк иде әле. Уйларым тагын да ачыклана төште. Юк, юк, бүтәннәр теләсә нишләсеннәр, алимент түлим дип үзләрен мең тапкыр юатсыннар, ә миңа улым кирәк, аның чын кеше булып үсүе кирәк.

Рейстан әйләнеп кайтуга бүтән вакыттагы кебек Юдинога кабаланмадым, улым янына йөгердем. Тик ишек бикле иде. Билгеле урынга, ачкычка үрелдем. Юк. Әзерләгәннәр ди, тот. Бу квартирга хәзер ни катнашым бар минем, шуны да оныткансың, исерек чабак.

Күршеләргә шакыдым. Миңа шатлык, Харис шунда икән. Туксан яшьлек ярым сукыр әби белән калганнар. Әби аны күлмәк итәгеннән бау белән караватаягына бәйләп куйган. Малай пычрак, тагын да ябыккан. Кабалана-кабалана бауны чишеп ташладым, күтәреп алдым.

— Ике генә көнгә дип калдырганые, менә бер атна була инде, кайтып күренгәне юк, теге матрос Гатау белән пароходка утырып киткән диме... Ни ашарына, ни эчәренә дигәндәй, сабыйны нишләтергә дә белгән юк, барысы да эштә, ә мин, беләсең, үзем дә ярты гына кеше.

Малайның нәрсәсе бар — барысын җыйдым, әбидән бер капчык сорап алып, шуңа тутырдым да чыктык та киттек.

Чыгып бераз киткәч кенә туктап калдым. Җыендык җыенуын, ә кая барырга соң әле бу сабый белән. Люция янына бармассың ла. Үземне сыендырганга рәхмәт. Бер үзенә икешәр ятимне тагарга детдом нянкасы түгел лә ул.

Бер генә юл кала түгелме: пароходка. Нужали «Дозор»да шушы кеп-кечкенә бәндәне сыйдырырга урын табылмас икән. Кумаслар әле. Капитанга ничек тә аңлатырга тырышырмын. Көзгә кадәр яшәрбез, аннан күз күрер.

Нишлисең, килеп бастык капитан алдына башны иеп. Аңлаттым нинди сайлыкка төртелгәнне. Александр Егорович — кырыс кеше, нәрсә дияр инде, дип ут йотып торганда, ни күрим, капитаным елмаеп җибәрмәсенме. Бер-беребезгә бик охшавыбыз күңеленә хуш килде, ахрысы. Малай да нәкъ минем кебек җен баласы: керпе энәләредәй тырпаеп торган шундый ук кап-кара чәч, сагайган көчекнекедәй үрә баскан зур колаклар, ерылырга әзер торган авыз.

— Ярар, яшәгез,— диде капитан,— ләкин, кара аны, ул-бу була күрмәсен.

Без чыгып китүгә ул кок апаны чакыртып, кайбер күрсәтмәләр дә бирергә өлгергән. Анна тутәй кереп, малайны юындырырга алып китте. «Хәзер һәйбәтләп коенабыз да флотский борщка ябырылабыз. Ә син

бар, йөрисең булса, эшләренне җәһәт кенә юллап кайт, үзем күз-колак булырмын», диде.

«Нинди олы җанлы кеше син, Анна түтәй, ничек син бер сүзсез барысын да аңлап, белеп торасың. Ничек кенә рәхмәтләр әйтергә инде сиңа». Шулай уйлый-уйлый мин вокзалга очам, Юдинога китәм. Анда да бит минем кадерле кешеләрем бар, тәп йортым анда иң минем хәзер.

...Әмма икенче көнен кайтып төшкәндә пароходта Харис юк иде. Мине күргәч, Анна түтәй, инде ничек аңлатырга дигәндәй, хәлсезләнеп, камбуз бусагасына утырды. Ярый әле егетләр бар иде, бер-берсен бүлә-бүлә сөйләп киттеләр:

— Ничек тордың син ул хатын белән, Юрка. Пароходны чак әйләндермәде бит кичә. «Законны бозып, кеше баласын яшерәсең, кочегарыңны гына түгел, үзеңне дә төрмәгә утырттырырмын»,— дип капитанның да бугазына ябышты. Бирдек малаеңны, нишләр идең...

Бер генә булмады инде мондый бушлай комедияләр, иптәш судья. Мин ач-ялангач малайны урамда, я күршеләрдә табып, түзә алмыйча, «Дозор»га алып кайтам. Инде тыныч кына яшәп китәбез, малай кешеләргә, пароходка ияләнеп бетә генә дигәндә әнисе күзләрен бичура кебек акайтып килеп төшә дә акырта-бакырта аны алып китә.

Җан телгәләнсә дә мин боларның берсен дә Юдинодагы кечкенә квартирда сиздермәскә, хәсрәт-мәшәкатьләрне үзем белән анда алып кайтмаска тырышам. Тик күңелдәге борчу йөзгә чыкмый каламыни.

Люция сизенә, әлбәттә, әмма ул төпченүдән үзен тыеп тора. Минем ачылып китүне көтә. Ә мин эчтән янам да янам. Бу яну, агач үзәген кимергән корт кебек, минем тазалыкка да сукты, күрәсең, ябыктым, баш авыртуга сабыштым, кайбер төннәрне саташып чыга башладым. Бер төнне Люция хәтта уятырга мәҗбүр булган.

— Уян әле, Юнысым, саташасың бит, тынычлан,— дигән тавышына күзләрне ачтым. Аның йомшак, җылы кулы маңгаемда иде. Тавышы калтырап, дулкынланудан буылып чыга.— Телеңдә Харис кына синең. Сизәм мин барысын да, Юныс, ник үзең генә янасың, ә? Әйдә бергәләп уйлашыйк, киңәшләшик. Кысылмыйм дигән идем дә булмый болай, ярамый болай. Мөмкин булса, мин аны хет хәзер барып алып кайтыр идем. Миңа ул синең кебек үк кадерле. Әйт, нишлим?

Бу сүзләрнең чын мәгънәсенә төшенеп, мин капыл айнып китәм. Кинәт таша башлаган шатлык хисен авызлыклап буламыни. Люцияне кочаклап алам, күзләрен үбәм, яшемне күрсәтмәс өчен, битемне мендәрдә таралып яткан чәчләренә яшерәм.

— Мин бит шикләнеп йөрдем, Люция.

— Мин дә сүз башларга кыймадым шул. Кавышсак та без бит моңарчы ничектер тиң түгел идек, аңлыйсыңмы, барыбер нәрсәдер җитми иде. Харис җитмәде. Безгә аңсыз яшәү мөмкин булмаячак.

* * *

Иптәш судья, мин кичә «Дозор»дан бөтенләйгә киттем. Бер-бер хәл булганга түгел, туеп та түгел. Аңлагыз, улым хакына мин яраткан эшемне, ияләнгән урынымны ташларга мәҗбүр. Беләм, пароходка, Иделгә мин гомерлеккә бәйләнгәнмен, тормышлар рәтләнгәч, ана барыбер кире кайтачакмын. Әмма хәзер китеп тормыйча булмый. Харисказ бит тормышны өр-яңадан башлап җибәрергә кирәк.

Бу көннәрдә мин Юдинода эш эзләп йөрим һәм менә сезгә хатгариза язам. Хәер, аны очларга да вакыт җитте бугай инде. Тел төбем, гозерем, алай гына түгел, аталарча таләбем аңлашылды микән инде сезгә? Барысын бергә җыеп әйткәндә, мин үз малаемның үз янымда булуын телим, аны дөрес тәрбияләргә, чын кеше итәргә телим. Зинһар,

тагы шуны игътибарга алыгыз, бу гариза минеке генә түгел, Люциянеке дә, ул да аңа кул куя.

Люция турында монда күп язылды. Аның миңа кадерле кеше булганы өчен генә шулай эшләнелмәвен аңлыйсыздыр. Харисның әнисе кем булачак, ул ышанычлы кешеме — сезгә менә шуны төшендерәсе килде. Кичә шул турыда озак кына тагы бер мәртәбә уйланып утырдым. Кинәт карашым аның кулларына төште. Кечкенә Люциянең куллары зур, бармаклары кытыршы. Фабрикада ул машиналар ремонтлый, ирләр белән бер эш башкара. Шул куллары белән ул кичә Гөлсемне шундый йомшак, шундый кадерле итеп күтәреп алды, кулларның җылысын, йомшаклыгын үз тәнемдә тойган кебек булдым. Юк, элекке хатынымның баланы болай итеп күтәргәнен, аңа шулай яратып, дөньясын онытып караганын бервакытта да күргәнем булмады минем.

Әйе, сез һич икеләнмичә Харисны безгә бирә аласыз һәм бирергә тиешсез. Дөрес, законның төрле пунктлары бар, әмма аларның барысы да гаделлекне генә якларга тиеш. Зинһар, ачуланмагыз, ләкин минем сезгә, һәм, сезгә генә түгел, барлык судьяларга да бер сорау бирәсем килә: үзем күрдем, семьялар таркала әле, һәркайсында диярлек балалар әниләре белән калдырыла. Бәхәсләшмим, шулай кирәктер дә бәлки, әмма һәр семьяны, һәр кешене законның бер үк пунктына яратырга, барысын да бер чыбыктан сөрергә мөмкинмени? Әйтик, берәр судьяның еллар үткәч, үзе хөкем иткән семьяларны исенә төшереп, язмышларын үзе хәл иткән балалар белән кызыксынып караганы бар микән? Әниләренә бирелгән балаларның барысы да бәхетле булыр иде микән? Ник әтисенә бирмәдем дип үкенеп куймасмы берәр судья?

Усал сүзләрем өчен гафу итегез, бүтәнчә әйтү мөмкин түгел. Гамьсез, ваемсыз яшәвем аркасында мин күп хаталар ясадым. Киләчәктә аларның кабатлануын, улымның да аларга дучар булуын теләмим. Җитәр! Шуңа күрә мин бу эшкә кул селтәмәячәкмен, барыбер аның очына чыгачакмын. Әгәр инде сез ярдәм итмәсәгез, шәһәр судына, анда да булмаса, республика судына язачакмын. Мәскәүгә чаклы барып җитәчәкмен.

Ләкин андый мәшәкатьләр булмасын иде инде, бу азаплар озакка сузылмасын иде. Сезнең кулдан да килердәй эш бит бу, һәм безнең үтенечебезне, һичшиксез, җиренә җиткерерсез дип ышанып калабыз.

Соңгы сүзем шул, иптәш судья, сез миңа шикләнеп карый күрмәгез. Ышаныгыз миңа. Мин сезнең йөзгә кызыллык китермәм. Белегез, кочегар Юныс Кәримуллинның җилкәне нәкъ кирәкле минутта киерелде. Гади бер көймә булса да, ул беркинди штормга да бирешмәячәк, тиешле урынына, һичшиксез, барып җитәчәк...»



*Михаил Львов — безнең якташыбыз һәм тугандашыбыз. Аның төп исеме һәм фамилиясе — Рифгать Маликов. Аңа бала чактан әтисеннән аерылып, рус гаиләсендә тәрбияләнергә туры килә. Ул рус телендә яза һәм танылган рус шагыйре булып әдәбият мәйданына чыга. Михаил Львов татар поэзиясен русчага тәрҗемә итүдә, шул эшне оештыруда бик тырышып эшләде һәм шуны хәзер дә дәвам итә. Без аның кайбер шигырьләренең тәрҗемәләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

## Михаил Львов

### Шагыйрьләр

Бу дөньяга безме чит, ят кеше?!
Булдыксызлар безме?
                    Гомергә
Без, янәсе, бер эш кыралмыйбыз,
Табынабыз фәкать шигырьгә.
Юк, юк!
Безне һичкем болай хәтерләмәс,
Без мондый ук түгел булдыксыз.
Без кулларда пистолет та тоттык,
Кирәк чакта ата беллек без.
Тәхетләргә менде күп «бөек»ләр...
Ләкин
Империяләр бетә бардылар.
Таҗ һәм хакимнәрдән бөегрәк,
Гомерлерәк булды шагыйрьләр.
Поэзия итеп зур тормышны,
Шигырь итеп һәрбер яшәүне,
Биекләргә очып, тиран төшеп,
Ирек даулап,
Намус колы — шагыйрь яшәде.
Шагыйрь!
Байрон булып, Грециядә син
Корал иттең утлы шигырьне.

Буркан ябынып, давыл булып йөрден
Кавказларда — Демон шикелле!
Күкрәк белән бәреп бетонны син,
Җәлил булып,
Моабитта яндың, күкрәдең...
Тарих бетми, яңа башлана ул
Спутниклар айкый күкләрне!
Шагыйрь!
Килер еллар башында да бар син,
Җимер артка тарткан юлларны,
Син, бүгенге шагыйрь, бүгенгедә
Оч син әйдә биек, югары!!

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН тәрҗемәсе

## Апрель аенда

Әйе, язын, шаулап боз акканда,
Әйе, язын, апрель аенда,
Саубуллашып кышны озатканда,
Бөре шыткан чакта каенда;

Әйе, язын, үлән калыккан чакта,
Шау чәчәкле майны көткәндә,
Сахраларга күнел тарткан чакта,
Яз кояшы җирне үпкәндә;

Әйе, язын, төренеп томаннарга
Кош сайраган чакта тирәктә,
Күңелләрдә хисләр уянганда,
Җыр яңарган чакта йөрәктә;

Әйе, язын, җирне капшагачда
Игенченең тырыш куллары,
Күксел күккә караш ташлаганда
Зәңгәр күзле Идел уллары,—

Җир шарында яңа даһи туды,
Ленин туды Сембер җирендә —
Бетмәс жылы, сүнмәс кояш нуры
Булсын өчен тормыш түрендә.

## Сыйфатлар

Нәрсәдер бар миндә тилгәннән —
Белегез, бар шундый бер ягым:
Кирәк — өстән, кирәк түбәннән
Очып үтәм юлның ерагын.

Күпне күргән тапкыр, зирәк карт,
Нәрсәдер бар миндә синнән дә.
Нәрсәдер бар миндә солдаттан,
Нәрсәдер бар хәтта диннән дә.

Мин, әйтерсең, нәни иярчен —
Бик күп йөрим, бик күп юл беләм.
Кайчакта мин юаш күгәрчен —
Тотып була коры кул белән.

Бала булып коча алам мин —
Нәрсәдер бар миндә оланнан.
Ләкин шуны яхшы белегез:
Бер нәрсә юк миндә еланнан.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре

## Дуслар юлга дәшә

Дуслар мине тагын юлга дәшә,
Онытылды ару-йокылар.
Поезд ыргый тагын бар көченә,
Күздән кичә таулар-чокырлар.

Картаерга миңа иртә әле,
Тиз кузгалам юлга дигәндә,
«Тормыш плацдармы» кинәя күк
Яңа җирләр күреп йөргәндә.

Хыялларым миңа ирек бирми
Гамьсез ялга туктап калырга,
Ватанымның бөтен матурлыгын
Телим җырыма күчереп алырга.

Волгоград та Казан, Казагыстан...
Таныш җирләр, сез һәрберегез,
Бухталарга диңгез ничек кирсә,
Җырларыма шулай кирәгез.

## Салават былбыллары

Салават туган җирдә мин
Яшәдем малай чакта:
Әй елгасы буйларында,
Курайлы-җырлы якта.

Истә, истә инешләре,
Ямь-яшел болыннары;
Тирә-якны моңга күмгән
Салават былбыллары.

Тәүге таңнарыбыз шунда
Нур сипте безнең эзгә,
Тик анда озак яшәргә
Туры килмәде безгә.

Хәтта сайрар кошларга да
Урын тар иде анда.
Җыр сыймый иде күңелгә
Быргылар уйнаганда.

Олы җанлы кешеләргә
Юлыктым менә шунда.
Мин үксез малайны алар
Чыгарды тугры юлга.

Әй, киң күңелле аналар,
Уйларым сезгә тарта.
Ләкин әлегә мин бик аз
Җырладым сезнең хакта.

Әйталмадым: «Барысы өчен
Зур рәхмәт сезгә»,— диеп.
Кайткач гафу итүегезне
Сорармын, башым иеп.

Ялга тукталмам, юлларым
Булса да борылмалы.
Сездән яңа җыр отармын,
Салават былбыллары.

РӘШИТ ГӘРӘП тәрҗемәләре

## Сырбай Мәуленов.

Казакъ шагыйре

### Нурлы яңгыр, җылы җил

Саумы! диеп тауларга,
Болыттай кичтем илләр,
Мин Казанга барганда
Истеләр җылы җилләр.

Дуслар каршы алганда
Түбәм күкләргә тиде,
Мин Казанга барганда
Явымлы яшел яз иде.

Тукай, Такташ иленә
Алып килде мине юл.
Һәм үткәрде түренә
Ямьле Казан, Кабан күл.

Керә иде төшемә
Казан — зур, данлы кала,
Гүзәл кала өстендә
Җылы җилләр исә дә
Нурлы яңгырлар ява.

Сибәләп тора яңгыр,
Мина сәлам урынына:
Охшап Тукай җырына,
Охшап Такташ җырына,
Охшап Җәлил җырына.

### Агыш

Алтын табак — җиренне
Балкытасың, Ай Идел,
Үз улыңдай күр мине,
Кочагыңны җәй, Идел.

Чиксез киң бар ягың да,
Якты Идел, зур Идел,
Балкып тора яңгырда
Аппак таңдай Кремль.

Каравылда торалар
Карагайлар, каеннар,
Хәят биреп кырларга
Җәелеп ятар җаең бар.

Котлы булды куеның,—
Бер ул таптың бак [1] өчен:
Алдың фикер-уеның
Дулкынын һәм агышын.

Алай ашыкма, чапма,
Бераз ял ит, юл алыс! [2]
Сине ерак-еракка
Алып барыр бу агыш.

Ай-һай Идел, Ай Идел,
Чынлап торган җыр —
Идел.
Кочагыңны җәй, Идел,
Изге Идел, зур Идел.

---

[1] Бак — бәхет.
[2] Алыс — ерак.

## Тукай кабере янында

Киттең, Тукай,
Үттең, Тукай,
Йөрәкләрне яндырып.
Инрәде ил,
Тетрәде жир,
Каплады кара болыт.

Кыска булды,
Иртә сүнде
Яшь гомрең, моңлы-зарлы.
Утка атып,
Кан елатып
Ташлап киттең Казанны.

Үтте еллар,
Үсте жырлар —
Син яңадан уяндың —
Озын гомерең!
Кабат меңнең
Биегенә кыяның.

Тукай — япь-яшь,
Абай — ак-чәч,
Үлмәс жаннар булдыгыз.
Берегез — монда,
Берегез — анда,
Йөрәкләрдә урыныгыз.

## Кабан күле буенда

Күл өстенә карый-карый
Күңелем күлгә әйләнде.
Жир төсенә карый-карый
Жаным гөлгә әйләнде.

Күлдәй дулкынланыйм диеп,
Жирдән давыл сорадым.
Жирдәй чәчәк атыйм диеп,
Күктән явым сорадым.

●

Казанның нәкъ уртасында
Кабан дигән бер күл бар,
Утыр да син яр ташына,
Аз гына ял итеп ал.

Күл өстендә болыт йөзә,
Сәфәргә чык бергәләп,
Күл өстендә жилләр исә,
Каекларны иркәләп.

Бу жир булыр нәкъ уртасы
Казан урамнарының.
Өздереп иштелә моңы
Тальян уйнауларының.

Һавалардан күлгә төшеп,
Канат кага тулган Ай.
Элекке замандагыча
Гел карап тора Тукай.

## Татар кызы Галиябану

Тургайда күрдем мин сине,
Күптән — бала кизләрдә [1].
Күлләр гиздек буйлы-инле,
Кыр рәшәдә йөзгәндә.

Тордык күкрәкләрне ачып,
Шат жил уйнауларына.
Шаян тайлар булып чаптык
Тургай урамнарында.

Кайнар учак яннарында
Корыт-кужә [2] бүлештек.
Сабый чак хыялларында
Бер күгәндә [3] берләштек...

...Бик үскәнсең инде син дә,
Акчарлагым — илһам-кош.
Сабый булып тагын кил дә
Иделгә мине алып төш.

---

[1] Кизләрдә — чакларда.
[2] Корыт-кужә — корытлы шулпа.
[3] Күгән — яшь малларны бергә бәйли торган урын — күп элмәкле аркан.

Галиябану, аман тор.
Мин яшим сагышым белән.
Язар идем сиңа җыр
Янгыр тамчысы белән.

Өметләнгән идем бер,
Сонгардым шул, үкенәм...
Язар идем сиңа җыр
Яшен утлары белән.

— Карагайны каләм ит,
Кәгазь яса каеннан,
Җыр яз! — дип син иден бит
Төн йокымнан аерган.

Җырлар дәшә таңнарда,
Уянам — иртә торам.
Сиңа җырлар язарга
Хыял кошын чакырам.

Галиябану кордашым,
Җырларымда яңгыра.
Сиңа сәлам юлладым
Яңгыр тамчыларында.

●

Оялаган өй алдында
Туган җирнең сандугачы,
Әле һаман хыялымда
Сабый чакның җан кордашы.

Безнең көннәр бик тиз очты,
Киләчәк дип хыялландык.
Бергә бүлдек куанычны,
Бер-беребездән кызганмадык.

Син очтың, мин гиздем
җирдә —
Өзелмәс дуслык арасы,
Уртак булды гомерлеккә
Безнең өйнең бусагасы.

Бергә үтте яшьлек чагым,
Җан кордашым, замандашым,
Иң беренче җыр өйрәткән
Сандугачым, сандугачым!

●

Син күрмәдең әле минем тауларымны,
Табар идең шул тауларда арманыңны [1],
Биеклеккә үрли-үрли кыялардан,
Сизмәс идең күккә житеп калганыңны...

Үз җиреңдә ятасың ни түзем белән!
Алып китәм сине бергә үзем белән,
Далаларым карар сиңа, барган чакта,
Маралллар һәм үзәннәрнең күзе белән.

**НУРИ АРСЛАНОВ** тәрҗемәләре

[1] Арман — теләк, омтылыш.

Мәхмүт Хәсәнов

# ИСӘНМЕ, КЕШЕ!..

Район үзәк больницасының атаклы акушер-гинекологы Газифә апа Хәсәншинаның яше хәзер илленең аргы ягында. Көннең көн буе операция бүлмәсендә аягүрә басып торулар соңгы елларда шактый сиздерәләр.

Бүген дә бик авырга туры килде аңар, дүрт операция ясады. Соңгысы, патология дип атала торганы, шактый катлаулы булды, киеренкелектә үтте. Аның каравы операция уңышлы тәмамланды, яшь ана да, әле яңа гына дөньяга килгән нәни граждании да яшәячәкләр...

Газифә ханым көндәлек эшен тәгәлләп кабинетына керде. Менә ул авыз-борынын томалап торган марля-маскасын ияк астына төшерде. Бары тик шуннан соң гына иркен сулыш алып, өстәле янында торган креслосына килеп утырды. Арыган-талган аякларын, язарга теләгәндәй, хәрәкәтләндереп алды. Кинәт авыраеп калган кулларын креслосының култыксаларына салды.

Эштән соң менә шулай биш-ун минут чамасы хәл җыеп утырырга ярата ул. Андый вакытта коллегалары Газифә апа янына кермәскә, аны борчымаска тырышалар.

Шулай чак кына хәл алганнан соң, Газифә апа, ашыкмыйча гына өс-башын алыштырып, өенә кайтып китәргә җыена башлый. Соңгарак калса, яки менә бүгенге кебек көн начар булганда, гадәттә аны өенә машина белән озатып куялар. Бүген дә, әнә, тышта февраль бураны котырына, ыргып-ыргып, тәрәзәгә килеп сарыла ул.

Кинәт, искәрмәстән генә, Газифә апаны сискәндереп, яман чырылдап телефон шалтырап куйды.

Газифә ханым җәһәт кенә тураеп телефон трубкасын алды.

— Әйе!..

Каяндыр, тәрәзә артында котырынган бураннар аша, кемдер ярдәмгә чакыра иде.

— Әйе, әйе!.. Мин тыңлыйм... Хәсәншина,— диде Газифә апа.

Ул бер мәлгә тынып калды. Урыныннан торды. Йөзе җитди иде аның.

— Үлем хәлендә?..— Кинәт җикеренгән кебек тавышын күтәреп куйды.— Кабаланмыйча, җайлап кына аңлатыгыз әле... Пульс? Температура? Бала тапканнан соң дисеңме? Ярәр. Аңладым. Көтегез, хәзер юлга чыгам...

Газифә ханым телефон трубкасын куйды. Кабинетының ишеген ачып кемгәдер дәште, машинаның кайдалыгын белергә кушты.

Минут та үтмәгәндер, дежур сестра йөгереп кереп, Газифә апаны өенә илтеп куярга тиеш машинаның шунда, парадный ишек янында көтеп торуын әйтте.

— Мин Тымытыкка киттем,— диде Газифә апа һәм җәһәт кенә киенә башлады.

Бераздан инде җиңел машина көчле фара яктысы белән караңгылыкны һәм алдындагы тоташ кар бураны пәрдәсен бораулап асфальт юл буйлап алга ыргыла иде. Юл бөтенләй диярлек күренми. Шофер егет, чак кына алга таба иелә төшеп,



машинасын бик сак алып бара. Шулай да тизлекне күрсәтә торган стрелка 80—90 цифрлары тирәсендә хәрәкәтләнә...

Күп тә үтмәде, машина гөжелдәп Сәпәй тавына күтәрелә башлады.

Сәпәй!..

Юк, Газифә апа өчен гади авыл исеме генә түгел ул. Аның бөтен тормышы, бөтен гомере шушы кечкенә генә авыл белән бәйләнгән. Институтны тәмамлаганнан соң, япьяшь Газифә шушы Сәпәй авылы больницасына кайткан иде.

Уйласаң хәйран калырлык! Ниләр генә кичерелмәгән дә, нинди генә юллар үтелмәгән. Бер тапкыр шулай, нәкъ менә шушындый буранлы төндә, аңар җаяүләп Илбәк авылына чыгып китәргә туры килде. Җилкәдә медикаментлар, төрле инструментлар тутырылган авыр сумка. Илбәк борылышында аны трактор көтеп торырга тиеш. Шулай сөйләшенгән иде. Ә буран аяктан егарга теләгәндәй котырынмы котыра... Менә юл чаты. Трактор күренми. Тавышы гына да ишетелми бит ичмаса. Газифә сыңар кулы белән йөзен каплап һаман алга атлый. Туңуның соңгы чигенә җиткән аяклары күптән инде берни дә сизмиләр...

Газифә Илбәк авылына бары тик таң алдыннан гына барып җитте. Сумкасын көч-хәл белән өстерәп авыру өенә кергәндә, анда инде бар да беткән була — сәкедә ике мәет ята: ана да, бала да...

Күп кенә очракларда ана белән баланың язмышын минутлар хәл итә.

Менә ул яңадан юлда. Көне дә нәкъ элеккеге вакыттагы кебек...

Караңгылыкны ярып, җил-буран белән тартыша торгач, ниһаять, Тымытыкка килеп җиттеләр.

Менә Тымытык больницасының балалар тудыру бүлеге. Газифә апаны баскыч төбендә үк каршыладылар. Көтеп торучыларның борчылу-киеренкелеге йөзләренә чыккан.

Минут эчендә Газифә ханымны урап та алдылар. Пальтосын салырга ярдәм иттеләр. Шунда ук халат та китереп бирделәр.

Газифә апа киенгән, юынып әзерләнгән арада сораулар да биреп куйгалады,

— Хәле ничек? Үзгәреш бәрмы?..

Кемдер:

— Шәптән түгел...— диде.

Ә икенчесе тагын да яманрак сүз ычкындырды:

— Бик начар... Өметсез...

Газифә Хәсәновна соңгы сүзләрне әйтүчегә таба күз төшереп алды да сүзсез генә палатага юнәлде. Аңа башкалар да иярделәр.

Аны палатада тәмам каушап калган врач-педиатр Рәйханә Мусина каршылады.

— Кайдан?

— Башкортстаннан, Карповка авылыннан...

Газифә ханымның мондый җавапка әллә ни исе китмәде. Яхшы фикер еракка җитәр дигәндәй, атаклы врач Хәсәншинаның һәм аның коллегаларының даны бик күптән инде күрше тирәдәге районнарга таралып өлгергән. Җитди катлауланулар булганда авыруларны Сарман, Мөслим, хәтта тагын да ераграк районнардан Азнакайга китерү хәзер инде гадәти бер күренешкә әверелеп китте,

Тагын сорау.

— Баласы исәнме?

— Исән...

— Диагноз?..

— Канын бик күп югалткан булса кирәк... Пульсы йомшак... Өметсез. Шуңа күрә сезгә мөрәҗәгать итәргә булдык...

Газифә ханым бала тудыру бүлмәсендә яткан яшь ана янына килде. Шул тирәдә мәш килгән акушеркаларга читкәрәк китәргә кушты. Иң элек тормыш халәте калмаган хатынның йөзенә карап торды, күз кабагын күтәреп күз алмаларын карады.

Яшь ананың җансыз беләген кулына алып пульсны капшады... Торган саен йөзе җитдиләнә барды.

Тагын берничә сорау:

— Канына анализ ясадыгызмы?

Җавапны Рәйханә Мусина бирде.

— Ясадык.

— Группасы?

— Беренче.

Бары тик шуннан соң гына катгый карар кабул итте Газифә Хәсәновна. Бары тик бер сүз әйтте:

— Операция...

Врач операциягә әзерләнә башлады. Кемдер су салып торды, икенче берәве битлекләр киderде. Кемнәрдер кирәкле инструментлар әзерләделәр...

Операция әллә ни озак бармады. Әмма шул 20—30 минутта бөтен больницаны сәер бер тынлык билап алды.

Операциядән соң ук, Газифә Хәсәновна авыруның кабат йөрәк тибешен тыңлады, пульсын санады, кан басымын үлчәде.

Аннары үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Ай-һай, канын күп югалткан. Кан бирергә кирәк... Һәм мөмкин кадәр тизрәк.— Шунда ук тезелешеп торган коллегаларына бик әһәмиятле сүз әйтергә җыенгандай, сорау бирде.— Авыруны нинди транспорт белән китерделәр?

— Ат белән.

Шушы гади генә сүз аша ниндидер тирән мәгънәгә төшенгән кеше сыман, Газифә ханым телефон янына килде. Азнакай балалар тудыру бүлекчәсен сорады ул.

— Рәйсә ханым, сезме? Вакытыгыз ничек? Ул-бу юкмы?.. Алайса менә нәрсә. Хәзер үк Тымытыкка килеп җитсәгез иде. Биш йөз грамм кан алып килегез. Беренче группа. Әйе, әйе, баладан соң... Хәле бик тә авыр. Ясадым... Канын туктаттым.

Хәсәншина яңадан авыру янына керде. Кабат пульсларын тикшерде. Бер-ике төрле укол ясатты. Ул арада районның өлкән акушер-гинекологы Рәйсә ханым Сафина да килеп җитте.

Ләкин ул алып килгән 500 грамм кан гына авыруның хәлен җиңеләйтмәде. Йөрәк тибеше үзгәрмәде, һаман да: менә туктыйм, менә туктыйм дигәндәй, сизелер-сизелмәс кенә тибә иде.

Бераздан авыруның хәле күзгә күренеп начарая башлады. Бу хәл тирә-юньдәгеләргә дә тәэсир итте. Күпләренең йөзендә өметсезлеккә охшашлы халәт чагылып киткәндәй булды.

Газифә ханымның да йөзе җитди иде.

— Кан кирәк!..— диде ул, ничектер әмер биргәндәй итеп.

Хәсәншина янына акушерка Галина Щербакова килде.

— Газифә апа,— диде ул,— минем дә каным беренче группа... Алыгыз.

— Рәхмәт, үскәнем...

Әмма канны турыдан-туры бирү өчен кул астында кирәкле препаратның — натрий-лимон ачы тоз сыекчасы юклыгы билгеле булды. Аның исә бары тик кан алу станциясендә генә булуы мөмкин.

Газифә ханым аптекага шалтыратып карарга кушты. Кемдер бу вакытта аптеканың эшләмәве турында әйтте. Врач, вакытның шактый соң икәнлеген онытканлыгына чак кына уңайсызланып куйды кебек, аптека мөдиренең кай тирәдәрәк торуы турында сорады,

— Берничә йорт аша гына...— диде кемдер.

Ул арада инде яшь кенә бер медсестра чыгып йөгерү өчен киенә дә башлаган иде.

Ә вакыт уза. Авыруның хәле яхшырырга һич кенә дә охшамаган. Тагын укол ясап карадылар. Ул да ярдәм итмәде.

Газифә ханым, ярым үлгән яшь ананың беләген кулыннан ычкындырмыйча гына, сорап куйды:

— Исем-фамилиясе билгелеме?..

Беренче карашка бик гади генә булып яңгыраган бу сорау барысын да аптырашта калдырды. «Өметсездер... аена хәбәр итәрү өчен сорый торгандыр...» дигән берсеннән-берсе яманрак уйлар чагылып китте.

— Билгеле...— диде Рәйханә Мусина. Тавышы да, ничектер, калтыранган сыман булып чыкты.— Фамилиясе Кострова... Исеме Валентина. Бакалы районының Карповка авылыннан...

Шул вакыт аптека хуҗасының өенә йөгергән медсестра кайтып керде. Асыл кош тоткан диярсең, шатлыгы йөзенә чыккан аның.

— Булды!..— диде ул, кирәкле препаратны өстәлгә китереп куеп.— Аптекага барып, тиз генә әзерләдек...

Турыдан-туры кан бирү эше башланды. Гаять дәрәҗәдә мәшәкатьле эш бу. Әмма Галя биргән 250 грамм кан да җитмәде. Авыруның хәле һаман да начар иде.

Әле генә торып утырган акушер Галина Щербакова:

— Тагын алыгыз...— диде.

Тик врачлар аның бу тәкъдименә каршы төштеләр. Бер кешене коткарып, икенчесен куркыныч астына куясылары килмәде аларның.

Инде нишләп карарга? Машинаны кабат Азнакайга җибәрергәме әллә? Ә вакыт сыйдырмый... Бәлки авыл кешеләренә мөрәҗәгать итеп карарга дыр?..

Шул вакыт Галина Щербакова, бу бәладән чыгу юлын тапкан кеше сыман итеп, телефон трубкасына ябышты.

— Кечке мәктәпкә шалтыратып карыйк... Анда әле занятиеләр бетмәгән...— диде ул телефон трубкасына кирәк номерны әйтеп. Чыннан да трубканы кемдер алды.— Кечке мәктәпме?.. Бик һәйбәт!.. Иптәшләр!.. Безгә ярдәм кирәк... Әйе, әйе, больницадан... Менә нәрсә, бәлки арагыздан кан бирүче табылыр. Бер яшь ана үлем хәлендә ята... Беренче группа. Зинһар, ярдәм итегез!..

Күп тә үтми, больницага укытучы Габделхаков иптәш йөгереп килеп керде.

— Миндә беренче группа. Минем донор булганым да бар. Рәхим итегез, алыгыз! — диде ул.

Аңардан алынган 250 грамм кан да Валентина Костровага бирелде.

Юк, укытучы иптәшнең каны да авыруның хәлен яхшырта алмады.

Ахыр чиктә Тымытык врачы педиатр Рәйханә Мусина авыру белән янәшә кушеткага үзе ятты.

— Миннән алыгыз,— диде ул, катгый итеп.

...Валентина Кострованың гомере өчен көрәш төнге икеләргә кадәр дәвам итте. Ниһаять, иреннәре күгәреп, бит-йөзенә җир төсе кергән, яшәү өмете калмаган яшь ана аңына килде. Билгеле, хәзергә әле аның телен әйләндереп сүз әйтерлек хәле юк иде.

Шул вакыт Газифә ханымның йөзе дустанә самимиләнеп, хәтта пакьләнып калганга охшаган иде. Мондый мөлаемлек, мондый халәт Газифә апада авырулар белән сөйләшкәндә генә була. Кемдер мондыйрак фикер әйткән: әгәр дә доктор белән ун минут сөйләшкәннән соң теге яки бу авыру, үзендә аз гына булса да җиңеллек тоймый икән, димәк, ул начар врач. Ә инде Газифә Хәсәновна белән сөйләшкән авыруның алдан ук рәхмәт әйтәсе килә башлый кебек. Хәер, андый тойгы бер авыруда гына түгел, врачның күңелендә дә туа, аның бөтен барлыгын җәлеп итә. Бу турыда Газифә апа:

— Үзең караган, үзең дәвалаган авыру белән шул кадәр якынаясың, бәхетле ана син кабул иткән нәниен күтәреп больницадан чыгып киткәндә, үзеңне иң якын кан туганың белән аерылышкандай хис итәсең,— ди.

Газифә ханым әле яңа гына аңына килгән яшь ананың кулын үзенекенә алды һәм күңеле тулган кеше сыман йомшак кына сорап куйды.

— Я, Валя... хәлләр ничек?..

Яшь ана озын керфекләрен кагып: «яхшы» дигән сыман итеп, башын селкеп куйды.

Барысының да иңнәреннән авыр йөк төштемени! Һәммәсе дә, ниһаять, иркен сулыш алдылар.

Кайтып китәргә җыенгач, Газифә ханым соңгы әмерен бирде.

— Шулай да, бер-ике көннән, чак кына ныгу белән, Азнакайга китерегез,— диде ул.

Газифә апа яңадан юлда. Күк йөзе бераз аязган. Ертык-пыртык болытлар арасыннан сирәк-мирәк кенә булса да йолдызлар җемелдәп күренгәлиләр.

Машинадагылар ниндидер бик зур эш башкарганнан соң гына туа торган тәэсиргә бирелгән.

Газифә апа үзалдына сөйләнгән сыман итеп:

— Менә бит безнең кешеләребез нинди! — дип куйды.— Сокланып туя алмассың.

Юлчылар яңадан тынып калдылар. Машина алга ыргыла. Алда, шофер янында утырган Газифә апа, башын чак кына кырын салып, күзләрен алга таба төбәгән. Тигез асфальттан җил уйнатып, буран вакытында ятып өлгергән карны тузгытып томырылып алга очкан машина сикереп алганда гына Газифә апа алга таба иелеп, чайкалып куйгалый. Шәле астыннан, бәсләнгәнгә охшаган чал чәчләре сытылып чыккан. Бик килешә бу чәчләр аңа.

Машина һаман алга ыргыла...

Менә шундый чакта Газифә апа уйга бирелергә, үзенең үткәненә, тормыш юлына каерылып күз салырга ярата. Юк, җиңел булмады аның тормыш юлы, сикәлтәләре, кискен борылышлары күп булды.

Шулай үткәннәрен искә төшердеме, аның күз алдына, аягына чабата киеп, култыгына төенчек кыстырып: «Казанга, духтырлыкка укырга!..» дип, зур юлга сәфәр чыккан бер яшүсмер кыз бала килеп баса. Бу — Чистай районының Наратлы авылында туып-үскән, буйга җитеп килә торган Газифә үзе иде.

Пароходка билет алырга җитәр-җитмәс акча белән, бер кат җәйге кием-салым белән, Чистай ягына бара торган олауларга иярәп чыгып китәргә нәрсә мәҗбүр итте соң тәвәккәл кыз Газифәне? Моның сәбәбе шул иде: җаныннан да артыграк күргән газиз әнкәсе, бала китергәндә, аның күз алдында вафат булды... Тыз-быз килеп йөргән кендек әбиләре ярдәм итә алмадылар аңа... Алты бала үкерешеп елап калдылар. Менә шунда Газифә кешеләрне үлем тырнагыннан йолкып алучы булырга үз-үзенә сүз бирде.

Максат, теләк булганда кеше теләсә нинди авырлыкларны да җиңеп чыга ала. Яшь кыз Газифә дә башта махсус курсларда белем алды, аннан инде Казан медицина институтының педиатрия факультетына кереп, аны тәмамлады. Ә үзенең практик врач эшчәнлеген Азнакай районының Сәпәй участок больницасында, күренекле доктор Вячеслав Васильевич Смирнов кул астында башлады. Зур ихтирам белән телгә ала Газифә ханым үзенең беренче остазын.

Ай-һай, авыр чор булган ул елларда. Ике врачка бер ат. Юл әзекләрендә авыллардан авылларга җәяү йөрергә туры килгән. Соңгы елларда Газифә ханымның аяклары сызлый. Тикмәгә түгел бу. Билдән кар сулары ерырга да бик еш туры килгән аңа. Башкача чара юк. Чөнки сине үлем түшәгендә газапланучы кеше көтә...

Авыл өйләрендә керосин лампасы яктысында бик күп катлаулы операцияләр ясарга да тәвәккәлләгән ул.

Хәер, авырлыклар бер ул елларда гына булмады. Мисал өчен дәһшәтле сугыш елларын гына ал. Кемгә җиңел булды ул чакта? 1941—44 елларда Газифә ханым Ерак Көнчыгышта госпитальдә хезмәт итте. Аннары Көньяк Сахалинда эшләде.

Тагын Азнакайга кайтты. Газифә апа, районда иң беренчеләрдән булып, «Сәламәтлек саклау отличнигы» значогы белән бүләкләнде. Ә инде 1966 елның 19 июнендә аңа «Татарстанның атказанган врачы» дигән мактаулы исем бирелде.

Ләкин бүләкнең иң зурысы, иң олысы — халык рәхмәте, халык мәхәббәте булды аның өчен. Әйе, берниндн авырлыклар белән исәпләшмичә, үзе турында уйламыйча,

халыкның ихтирамын яулап алды ул, Хәтта үзенең шәхси тормышы турында да уйламады. Ялгыз ул, Казанда финанс-экономия институтында укучы Люция исемле кызы гына бар аның.

— Хәзер инде яңа оя, яңа гаилә кору турында хыялланасы да юк, соң инде,— ди ул, картлык көнендә ялгыз булуына чак кына уфтангандай итеп.— Ә баштарак, ничектер, мөмкинлек булмады...

«Мөмкинлек булмады...» Тирән мәгънә ята бу сүзләрдә. Әйе, баштарак чыннан да мөмкинлек булмаган Гәзифә ханыма. Ул гына да түгел, хәтта корылган оясын да саклап кала алмаган. Ире түзгән-түзгән дә, ахыр чиктә: «Мин дә кеше бит, ниһаять! Миңа да бераз дикъкать-игътибар дигән нәрсә кирәктер ләбаса!.. Я эшең, я мин!..» — дип ультиматум белдергән. Шулай итеп Газифә ханым ике ут арасында кала. Сайлый, әлбәттә. Нәтиҗәдә — ялгызлык. Әйе, үз хезмәтенә гомерен багышлый ул. Ул чорларда Газифә ханым бөтен районга берданбер тәҗрибәле врач була. Больницадан чыга алмый ул. Көнен-төнен авырулар янында булып, тәмам хәлдән таеп өенә кайта. Бераз ял итәргә утырса, яки кызы Люциянең ничегрәк укуы белән кызыксына, аш-су тирәсендә булыша башлауга, я телефон шалтырый, я исә: «Тизрәк булыгыз, Газифә апа... Харап анда... Авыру китерделәр»,— дип, машина килеп җитә торган иде.

Җиде төн уртасында капка төбенә машина килеп туктау белән Газифә урынынннан сикереп тора, ут кабыза, җәһәт кенә киенә башлый... Алырга килүләрен ул машина тормозларының ямьсез чыелдавыннан ук белеп ала. Яшерен-батырын түгел, яшьрәк чагында Люциянең дә төп өе — күрше-күлән булды. Әнисенең икешәр, хәтта өчәр көн буена кайта алмаган чаклары күп иде.

Хәзер инде заманалар үзгәрде, кадрлар да житәрлек. Газифә ханымның үз шәкертләре генә дә хәзер санап бетергесез. Үзенең бай тәҗрибәсен яшь белгечләр белән бик теләп уртаклаша ул. Бары тик соңгы дүрт ел эчендә генә дә 50 дән артык акушер хәзерләде.

Өстәп тагын шуны әйтәсе килә: аның янына бик күп практикантлар киләләр. Чөнки ул югары квалификацияле акушер-гинеколог буларак диагноз куюда һәм дәвалауда шактый гына яңа методлар файдалана. Акушерлык-гинекология учреждениеләрендә Газифә апаның алымнарын бик теләп кабул итәләр, үз практикаларында кулланалар.

Әйе, Газифә апа гаять зур, гаять бай тәҗрибә туплаган врач. Елына ким дигәндә 150 шәр катлаулы операция ясарга, шул кадәрле үч ана белән баланың тормышын саклап калырга туры килә аңа.

Еш кына: «Елына күпме бала кабул итәргә туры килә?» — дигән сорау бирәләр. Газифә апа гадәттәгечә мелаем генә елмаеп: «1100 дә 1500 гә кадәр» дип җавап кайтара. Ә инде 32 ел акушер-гинеколог булып эшләү дәверендә күпме булды икән, дип сорасаң, моңа да җавабы әзер аның.

— Мин тормышка «путевка» биргән нәниләр хәзер инде үзләре әти-әниләр...

1969 елның февраль ае башларында Газифә апа Хәсәншинага Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелүе турында Указ игълан ителде. Яшен тизлеге белән таралып өлгерде ул хәбәр. Районның кеше сәламәтлеге сагында торучы ак халатлы хезмәтчәннәре, Газифә ханымның якын коллегалары, санэпидстанциянең кызыл почмагына җыелдылар. Зал халык белән шыгрым тулы иде. Шул вакыт ишектән Газифә ханым үзе күренде. Чакырганнар. Эштән генә килгән ул. Өстендә гап-гади пальто, башында мамык шәле. Ул күренү белән кинәт әллә нәрсә булды. Яше-карты бер кешедәй аягүрә басты һәм барысы да тирә-якны дер селкетеп кул чаба башладылар...

Газифә ханым бермәлгә каушап калды. Аны көчле алкышлар астында сәхнәгә, президиумга утырттылар. Районыбыз өчен чиксез зур бу куанычлы хәбәрне ишетүгә багышланган митингны больницаның партоешма секретаре иптәш Р. Тимергалиева ачып җибәрде. Трибунага бер-бер артлы Газифә ханым белән күп еллар буе бергә эшләгән, аны яхшы белгән иптәшләре күтәрелделәр. Район больницасының баш врачы иптәш Х. Шәмсетдиновтан соң сәхнә алдына 3 нче урта мәктәп укытучысы Н. Лапшина килеп басты. Ул Газифә ханымны зур исем — Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелүе белән тәбрикләде һәм мәктәп коллективы исеменнән кыйммәтле бүләк тапшырды.

Газифә Хәсәновнаның иң якын коллегаларыннан Р. Сафина, Х. Әминов иптәшләренең чыгышларын да дулкынланмыйча гына тыңларга мөмкин түгел иде.

КПСС райкомы секретаре иптәш Ш. Шәрәфетдинованың котлау сүзләре дә көчле алкышлар астында күмелеп калдылар. Иң соңыннан Газифә ханым Хәсәншинаның үзенә сүз бирделәр.

— Дусларым!.. Чиксез дулкынлану сәбәпле бәлки сүзләрем ятышсыз чыгар. Гафу итәрсез. Бу кадәр зурлау әллә нишләтте мине. Үземне Ватан алдында тагын да зуррак бурычлы кеше итеп хис итәм. Хөкүмәтебез һәм партиябезнең совет медикларының халык алдындагы хезмәтләрен лаеклы бәяләве — безнең турыда зур кайгыртучанлык күрсәтүе бу. Кыскасы, кадерле хезмәттәшләрем, минем хезмәтемә шундый зур бәя биргән өчен Ленин партиясенә, хөкүмәтебезгә чиксез зур рәхмәт,— диде ул.

Ул көннәрдә халык телендә Газифә апа гына иде. Редакциягә уннарча һәм йөзләрчә хатлар ява башлады. Хатларның күпчелеге аның таныш-белешләреннән, якын дусларыннан һәм пациентларыннан. Менә халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты хатын-кызлары язган хаттан берничә юл. «...Безнең күпләребезне үлем тырнагыннан алып калган Газифә апабызга Герой исеме бирелүе безгә иксез-чиксез куаныч китерде. Без үзебезнең халык арасында дан һәм хөрмәт казанган врачыбыз белән бик хаклы рәвештә горурланабыз. Аңа озын гомер, какшамас сәламәтлек, хезмәтендә тагын да зуррак уңышлар телибез. Сәбихә Сабирова, Ләлә Усманова...» Барлыгы утызга якын имза.

Газифә апа кайтып килә торган машина халык телендә «Пугач тавы» дип аталган Чатыр тавының итәгенә күтәрелде. Алда, тоташ утлардан торган диңгезне хәтерләтеп, Азнакай күренде.

Азнакай!

Аның күз алдында үсеп чыкты бу яшь кала. Газифә беренче тапкыр бу якларга аяк басканда, Азнакай кеше күзенә күренергә оялгандай, тау битенә посып утырган бәләкәй генә салам түбәле бер авыл иде. Хәзер киң экранлы кинотеатр торган урында сазлык-баткаклыклар иде. Ул тирәгә аучылар үрдәк атырга йөрилар иде.

Халыкка медицина хезмәте күрсәтү өлкәсендәге үзгәрешләргә генә күз сал син! Хәйран булырлык. Әйе бит революциягә кадәр хәзерге район территориясендә 35 койкалы берданбер больница булган. Хәзер исә 600 койкалы 7 больница бар. Аларда югары белемле, зур тәҗрибәле уннарча врачлар эшли. Һәр авылда, предприятиедә һәм цехларда сәламәтлек пунктлары бар. Хәзерге вакытта районда эшләүче врачларның саны йөзгә якын. Поликлиникалар әр-яңа медицина приборлары белән җиһазландырылганнар. Моннан ике генә ел элек заманча итеп, бөтен шартлары китерелеп салынган больница файдалануга тапшырылды. Гинекология бүлеге бер үзе ике катлы зур бинаны биләп тора.

Газифә ханым менә шундый уйларга чумып кайтып килә.

Уйлар, уйлар!..

Ә машина һаман алга ыргыла.

Азнакайга иртән дүртенче яртыда кайтып җиттеләр. Менә өе. Газифә апа саубуллашып машинадан төшкәндә, шофер егет аңардан:

— Газифә апа, сезне алырга ничәләрдә килсеннәр? — дип сорап куйды.

— Гадәттәгечә, җидедә,— дип җавап кайтарды врач.

...Газифә ханымның әле яңа гына дөньяга килгән бәбине биләүгә төрәп, иплә генә итеп кулында тотып торганын күргәнем бар минем. Йөзләре нурланып, күзләре очкынланып киткәндәй була аның. Андый вакытта Газифә ханым әлмәеп, сөйләнеп тә алгалый.

— Я, исәнме, кеше! Яңа кеше... Ник күзләреңне ачмыйсың? Чагылалармыни? Зарар юк, тиздән ике күзеңне тутырып карарсың бу дөньяга... Кара-кара, ничек итеп иреннәрен кыймылдаткан була... Яшәргә дип тудым, дисең әллә? Бик шәп. Бәхетле бул!..

*БЕЗНЕҢ ИНТЕРВЬЮ*

*Татарстан хезмәт ияләре республикабызның 50 еллыгын бәйрәм итәләр. Шул уңай белән «Казан утлары» журналы үтенүе буенча М. Зарипов, М. Хәмитов һәм Г. Шәрәфетдинов Татарстан АССРның авыл хуҗалыгы министры Фатих Хәлил улы Минушев, сәламәтлек саклау министры Иршат Закир улы Мөхетдинов, социаль-тәэминат министры Фаизә Гани кызы Хәкимова белән әңгәмәләр үткәрделәр һәм аларны язып алдылар. Түбәндә без шуларны укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

# ИГЕНЧЕ ХЕЗМӘТЕ

**— Фатих Хәлилович, әгәр рөхсәт итсәгез, үгезнең мөгезеннән алыйк әле. Әйтсәгез иде: хәзерге вакытта республикада ашлык, ит, сөт, бәрәңге, яшелчәләр җитештерү ни хәлдә тора! Бу бик гади сорауны бирүемнең сәбәбе шунда: үзегез беләсез, иң беренче, иң объектив күрсәткеч — җитештерү күләме, җитештерелгән продукция күләме.**

**— Дөрес әйтәсез. Ләкин мин бу мәсьәләгә бүтәнчәрәк карыйм. Эш шунда: продукцияне без ничек алабыз — җитештерүнең күләме артуның төп сәбәбе шул. Чорларның нәрсә җитештерү белән түгел, ә ничек җитештерү белән аерылып торулары турында Карл Маркс та әйткән. Әгәр без бүген бөек даһиның сүзләрен искә төшерәбез икән, димәк, шуны күз алдына китерәбез: узган ярты гасыр эчендә керәк, сука чорыннан машина, электр энергиясе чорына аяк бастык.**

**Шуны да искә төшерик: вакытында сука белән ат та барлык крестьян хуҗалыкларында да юк иде. Кайбер саннарга күз салыйк. Революциягә кадәр Казан губернасында крестьяннарның дүрттән өч өлеше җирне сука белән эшкәрткән, бары тик 17 процент хуҗалыкта гына, башлыча кулак хуҗалыкларында, сабан булган. Һәр өченче крестьян семьясының аты булмаган, һәр дүртенченең — сыеры...**

**Инде бүтән саннарга күчик. Республикабыз колхозларында һәм совхозларында хәзер 50 меңгә якын трактор, 10 меңгә якын комбайн бар. Быел республикадагы һәр авыл, тулаем, Мәскәү, Ленинград, Казан белән бергә, дәүләт энергия системасына тоташтырыла. Сугыштан соңгы елларда гына да, конкретрак әйтсәк, соңгы егерме елда, колхозларда һәм совхозларда электр энергиясен куллану 40 тапкырга якын үсте.**

**— Иптәш министр, без төрле категорияләр белән эш итәбез кебек. Әйтик, революциягә кадәр һәр крестьян хуҗалыгына бәя биргәндә, аның аты бармы яки юкмы икәнен истә тотканнар. Ә хәзер бүтән үлчәү — киловатт-сәгатьләр, колхозларның һәм совхозларның энергия белән тәэмин ителүе. Чагыштыру өчен уңайрак булган гомум үлчәү берәмлеге табарга мөмкин түгелме!**

**— Мөмкин, әлбәттә. Хәзерге авылларның энергия куәтен — аларга электр двигательләре дә, тракторлар да, автомашиналар да, комбайннар да керә — барлык кешегә аңлаешлы ат көченә күчерсәк, колхозларда һәм совхозлардагы һәр кешегә җиде ат туры килә...**



— Хәзер, минемчә, җитештерү турында да сөйләшергә мөмкин. Шундый бай техника куллану белән уңыш алуның үсеше арасындагы бәйләнеш турында берничә сүз әйтсәгез иде.

— Уңыш алуның үсеше күп факторларга, беренче чиратта, авыл хуҗалыгында продукция җитештерүнең характерына, аның формаларын оештыруның үзгәрүенә бәйле.

Әгәр Россия крестьяннары элеккечә кечкенә хуҗалыкларда утырсалар, гәрчә алар җирдә ирекле граждааннар булсалар да, барыбер илгә, һичшиксез, һәлакәт куркынычы туган булыр иде. Бу турыда В. И. Ленин да әйткән. Күрәсезме,— һичшиксез, һәлакәт! Аерым хуҗалыклар эре, көчле хуҗалыкларга — колхозларга һәм совхозларга берләштеләр. Крестьян тормышы яңа формада, коллектив хезмәт принциплары нигезендә оешты.

Моның нәтиҗәләренә күз салыйк. Мин ашлык җитештерү турында гына әйтәм. Мәсәлән, 1913 елда Казан губернасында ашлык 2 миллион 404 мең гектар мәйданда чәчелгән. Хәзер без ике ярым миллион гектарда чәчәбез...

— Гафу итегез, сүзегезне бүләм. Гомүмән, безнең халык, журналистлар, саннардан качарга, аларны математикларга, экономистларга, электрон-хисаплау машиналарына калдырырга тырышалар. Без бу традициядән читкә китмибезме!

— Китсәк ни! Саннардан куркырга кирәкми. Саннар — абстракт математик берәмлекләр генә түгел. Иң элек, аларда кеше хезмәтенең һәм иҗатының нәтиҗәсен күрә белергә кирәк. Иң матур сүзләр дә, иң эмоциональ сурәтләүләр дә гади арифметика берәмлекләрендәге ачыклыкны, тегәллекне алыштыра алмыйлар. Саннардан башка яшәү мөмкин түгел. Алар — танып-белү ысулы да, идарә итү коралы да. Партия пропагандасы да алардан башка мөмкин түгел. Танылган крестьян язучысы Глеб Успенский саннарны «тормышның асыл хакыйкате» дип атаган...

Менә шулай, әйтеп үткәнемчә, ашлык чәчү мәйданы 57 ел эчендә бик аз артты, утыздан бер өлеш чамасы гына. Әмма, уңыш алу... Әгәр 1913 елда 1 миллион 906 мең тонна иген уңышы җыеп алынган булса, узган елда без 3 миллион 096 мең тонна җыеп алдык. Ике тапкыр артыграк! Узган ел Татарстан дәүләткә икмәк сатуның бишьеллык планын вакытыннан бер елга алданрак үтәде. Юбилей елында да уңыш былтыргыдан ким булмас, дип ышаныйк. Бер ел вакыт оту — әйбәт нәтиҗә бу. Вакытка экономия мәсьәләсе — бөтен кешелек дөньясы алдында торган зур проблема.

— Крестьян тормышында ел белән ел арасында аерма зур була. Бер ел коры килә, ә икенчесе, киресенчә — әйтерсең, алдан бирелгән заказ буенча, шагыйрь әйтмешли: «Җил дә вакытында исә, яңгыр да вакытында ява». Шуңа күрә уңыш та елына күрә була. Бәлки, сез китергән мисал шуның нәтиҗәседер!

— Мин алай димәс идем. Һич юк. Узган ел һава шартлары әйбәттән булмады. Кышын кар аз яуды, җәен дә яңгырлар булмады. Август аенда уК кырау төште, күп кенә бодай, карабодай, тары басуларына зыян килде. Шуңа карамастан, уртача һәр гектардан 16,4 центнер уңыш җыеп алдык. Мондый уңышның моңа кадәр Татарстанда булганы юк иде. Уңыш алу, бернинди һава шартларына карамастан, елдан-ел үсә бара. Мәсәлән, һәр гектардан 1963 елда — 8, 1964 елда — 9,4, 1965 елда — 10,1, 1966 елда — 10,9, 1967 елда — 13,4, 1968 елда — 15,5 центнер уңыш алынды.

— Мондый даими үсешнең сәбәбе нигездә нәрсәдә дип әйтәбез инде!

— Экономистлар моны җир эшкәртүнең югары культурасы, бай техника белән тәэмин ителү белән аңлатырлар. Соңгы елларда безнең дәүләтебез авыл хуҗалыгына торган саен күбрәк материаль һәм техник ресурслар бирә. Бишьеллыкның дүрт елы

эчендә генә дә Татарстан авыл хуҗалыгы өчен 828 миллион сум акча тотылды. Бу шуннан алдагы дүрт елга караганда бик күпкә артык. Шуңа күрә экономистларның мондый аңлатмалары бик дөрес. Шул ук вакытта дөрес тә түгел. Ченки монда бары тик экономик сәбәпләр генә ачыклана. Ә төп сәбәп — кешеләр — кешеләрдә. Чәчү әйләнешләре турында, тракторларны, сабаннарны ничек көйләү турында, уңдырышлырак яңа сортлар чыгару турында кешеләр баш вата, кешеләр кайгырта. Хәзер инде игенче, электрон машиналар өчен математик мәсьәләләр әзерләгән кебек, уңыш алу программасын да, һава шартлары нинди килүенә карамастан, алдан ук әзерләү мәсьәләсе алдында тора. Шуңа күрә, тагы бер кабат, ассызымлап әйтәсем килә: иң төп көч — кешеләрдә, аларның гомуми интеллектуаль һәм профессиональ осталыкларында, гражданлык сыйфатларында һәм политик аңлылыкларында.

Республикабыз колхозларында һәм совхозларында биш ярым меңгә якын белгеч, кырык меңнән артык механизатор эшли. Бу — зур армия.

Мондый очракларда фамилияләр атау, аларга характеристика бирү гадәткә кергән. Бу зур хезмәт армиясе составындагы һәр кеше турында, бигрәк тә, фидакарь хезмәтләре өчен орденнар, медальләр белән бүләкләнгән, иң зур хезмәт данын билгеләп торган дәрәҗәгә — Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган кешеләр турында күп сөйләргә мөмкин. Мәсәлән, Балтач районының «Правда» колхозы тимерчесе Сәрвәр Нәфикова, «Красный Восток» совхозы дуңгыз караучысы Александра Бескалова, Арча районы «Үрнәк» колхозы председателе Нургали Бариев, КПССның Минзәлә район комитеты секретаре Мәгъсүм Хөсәенов, «Тернәс» совхозы баш зоотехнигы Валентин Ефимов һ. б. лар, һ. б. лар. Алар характерлары, гадәтләре буенча да, омтылышлары белән дә бер-берсенә охшамаган. Ләкин бәрысына да уртак сыйфатлары бар: алар җир балалары, тирән белемле кешеләр, ачык һәм төгәл карашлы, югары гражданлык сыйфатларына ия булган, үзләреннән тормыш нәрсә таләп иткәнен һәм тормыш аларга нәрсә биргәнен белә торган акыллы кешеләр. Бүгенге уңышларның, киләчәккә өметләребезнең нигезе шуларда.

— 1913 ел белән чагыштырганда ике тапкырга артыграк уңыш алу бик гыйбрәтле. Бөек галим, табигать белгече К. А. Тимерязов бер бөртек үскән җирдән ике бөртек уңыш алучыга кешелек дөньясы мәңгелек рәхмәт укыячагы турында әйткән иде. Хәзер бездә дә шулай булып чыга түгелме!

— Әйе, үткән чор белән чагыштырганда, бу шулай. Мәсәлән, беренче бөтендөнья сугышына кадәрге ун ел эчендә Казан губернасында бер дисәтинә җирдән һәр елны уртача кырык потлап уңыш алынган. Бу — гектардан биш ярым, алты центнер дигән сүз. Ә соңгы ун ел эчендә, уртачага бүлгәндә, без һәр көзне гектардан уртача 12 центнер ашлык җыеп алдык. Ләкин безне мондый үсеш кенә канәгатьләндерми. Әлбәттә, кичәге белән чагыштырганда, бу — казаныш. Ә киләчәккә күз салсак — яңа казанышлар өчен чираттагы баскыч кына әле бу.

— Рус мәкалендә әйтелгәнчә, аппетит ашаган чакта килә, дигән сүздер инде бу. Шулаймы!

— Юк, эш бер аппетитта гына түгел. Эш шунда: безнең республика экономик үзгәреш чорын кичерә. Энергетика, нефть, машина төзү, химия промышленносте гигант адымнар белән үсә. Димәк, бу — шәһәрләр, эшче поселоклары үсә дигән сүз. Ә аларны азык продуктлары белән, икмәк, ит, сөт, яшелчә, бәрәңге белән тәэмин итәргә кирәк. Мәсәлән, салынып бетә торган Түбән Кама химия комбинаты, салына башлаган Чаллы автозаводы кебек промышленность гигантлары авыл хезмәт ияләре алдына хәзер үк инде үз таләпләрен куялар. Исәпләүләр буенча, 1975 елда алар өчен 54 мең тонна сөт продуктлары җитештерергә кирәк булачак. Бу житди проблема.

— Ә авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүдә нинди үзгәрешләр булачак!

— Кабатлап әйтәм: бу җитди, киң колачлы проблема. Хәзергә республикада авыл кешеләре барлык халыкның якынча яртысын тәшкил итә. Берничә елдан, бәлки, барлык халыкның бары тик чиреге генә авылда яшәр. Ә продукция алуны хәзергә караганда ике тапкырга арттырырга кирәк булачак. Иң мөһиме: моңа ничек ирешергә! Моның өчен, бер яктан, җир эшкәртү культурасын үстерергә, терлекчелек технологиясен күтәрергә, икенче яктан, күп көч куела торган эшләрне комплекслы тестә машинага һәм автоматика көйләргә кирәк. Мәсәлән, кечкенә фермалар урынына эре, специальләшкән, күп санлы терлек һәм кош сыйдырышлы комплекслар булдырыла-

чак. Аларда продукция җитештерү промышленность системасына нигезләнә, барлык төр эшләр машинага көйләнәчәк. Мондый комплекслар инде төзелә.

— «Промышленность системасына нигезләнү» дигән сүзне, гадирәк итеп әйткәндә, ничек аңларга! Минемчә, сыер савучы, терлек караучы дигән атамалар бетәчәк, алар урынына завод-фабрикалардагы кебек һөнәр иләре басачак!

— Әйе, техник прогресс нәтиҗәсендә борын-борыннан килгән авыл хуҗалыгы һөнәрләренең кайберләре бетә, алар урынына яңалары туа бара. Сыер савучыны оператор алыштырачак, терлек караучы урынына азык ташу, фермаларны чистарту өчен көйләнгән катлаулы машина белән идарә итүче механизатор эшләячәк. Хәзер үк инде һәр колхоз, һәр совхоз өчен электриклар, механиклар, инженерлар, кочегарлар, киң профильле механизаторлар кирәк.

— Партиянең XXIII һәм колхозчыларның III Бөтенсоюз съездында кабул ителгән авыл белән шәһәр арасындагы аермлыкны бетерү турындагы карарларны тормышка ашыруга да зур игътибар юнәлтелде. Саф һава сулау, урманнар, елгалар, матур табигать белән хозурлану, гөмбәгә, җиләккә йөрү белән бергә, авыл кешеләре шәһәрдәге уңайлыклар белән дә файдаланырга тиеш бит.

— Бу, әлбәттә, шулай. Республика авылларында яшәүчеләрнең шәһәр культурасына омтылышлары зур. Гадәти клуб ачылу күптән түгел генә авыл халкы өчен зур вакыйга булып саналса, хәзер инде культура сарайлары, зур китапханәләр, мәктәпләр, кибетләр, бөтен уңайлыкларын булдырып салынган торак йортлар да беркемне гаҗәпләндерми...

— Әйе, тормыш яхшырган саен яңа хастәрләр, яңа борчылулар да арта.

— Шулай булмый мөмкин дә түгел. Тормыш һәм ваемсызлык — бер-берсенә капма-каршы мәгънәләр. Хәтта идеал җәмгыять булачак коммунизмда да кеше өчен бик күп эш һәм борчылулар булачак. Алар, мөгаен, хәзергегә караганда да җитдирәк һәм катлаулырак булырлар. Тормышка ашкан хыялның иң кыю хыяллар өчен яңа грандиоз перспективалар ачуы турында В. И. Ленин юкка гына әйтмәгән.

— Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фатих Хәлилович. Авыл хуҗалыгы армиясенең матур хыяллары, зур планнары тормышка ашсын, реаль чынбарлык булып бөтен илгә күренсен!

— Нәкъ шуның өчен тырышабыз да инде! Рәхмәт. Хушыгыз.

# ИҢ МӨҺИМ БУРЫЧЛАРНЫҢ БЕРСЕ

— Иршат Закирович, һәрберегезгә мәгълүм: революциягә кадәр татарлар арасында авыруларны башлыча им-том итүчеләр генә «дәвалаган». Хәзер инде республикада участок больницасы яки фельдшерлык-акушерлык пункты булмаган бер генә авыл да юк. «Казан утлары» журналын укучыларга арты гасыр эчендә республикабыздагы хезмәт иләренә медицина хезмәте күрсәтүнең үсеше турында сөйләсәгез иде.

— Дөрес әйтәсез: революциягә кадәр Казан губернасы санитария масьәләсе буенча иң артта калган урыннарның берсе булган. Халыкның күпчелек өлеше ярым ач хәлендә яшәгән, наданлык, хөерчелек хакимлек иткән, квалификацияле медицина ярдәме булмаган. Шулар нәтиҗәсендә йогышлы авырулар киң таралган, үлем-җитемнәр бик еш булып торган, бигрәк тә балалар күпләп үлгән.

Халык тиф, ашказаны-эчәк, чәчәк, бизгәк, туберкулез һәм күп төрле балалар авыруларыннан җәфа чиккән. Әлбәттә, им-том итүчеләр ул авыруларга каршы көч-



сез булган. Менә бер факт. 1913 елгы тикшеренүләр Казан губернасындагы халыкның 25,5 проценты трахома белән авырганлыгын күрсәткән.

Авыруларга медицина ярдәме күрсәтү юк дәрәҗәсендә аз, бар кадәресенең дә квалификациясе түбән булган. Бөтен губернада бары тик 89 больница, аларда 379 врач, 346 урта белемле медицина хезмәткәре эшләгән. Профилактика чаралары авылларда булмасын, шәһәрләрдә булмасын бөтенләй диярлек үткәрелмәгән. Хәтта Казан шәһәрендә дә су үткәрү трубалары бары тик берничә километр гына булган. Тирес-торысны, ашамлык калдыкларын кайда туры килсә, шунда ташлаганнар. Яз көннәрендә һәм көзләрен урамнар, шунлыктан, үтеп булмаслык пычрак белән тулган. Бөтен Казанга бары тик 10 больница (барысы бергә 750 урынлы) булган. Аларның да биштән бер өлешендә аерым практика белән көн итүче врачлар эшләгәннәр.

Кыскача гына әйткәндә, революциягә кадәр Казан губернасында халыкка медицина хезмәте күрсәтү әнә шул хәлдә торган.

— Моны хезмәт күрсәтү дип түгел, күрсәтмәү дип атасак, дөресрәк булыр кебек. Чөнки, булган больницалар, булган хәтле врачлар да хезмәт кешеләрен түгел, ә баймөлкәт ияләрен дәвалаганнар бит.

— Әлбәттә, шулай. 1917 елда Бөек Октябрь революциясенең җиңеп чыгуы хезмәт ияләрен үз дәүләтләрен, Совет дәүләтен төзү өчен көрәшкә күтәрде. 1917—20 елларда, илебездәге барлык халыклар кебек үк, татар халкы да авыр сынаулар кичерде. Гражданнар сугышы һәм интервенция нәтиҗәсендә экономика бик нык какшаган иде. Ачлык һәм эпидемия контрреволюциянең союздашлары булды.

Әмма Ленин партиясе җитәкләгән халык энтузиазмы дошманнардан да, ачлык һәм җимереклектән дә көчлерәк булып чыкты.

1920 елның сентябрендә Татарстан республикасы Советларның I съезды җыйналды. Бу съездда татар халкының күренекле дәүләт эшлеклесе С. Сәетгалиев җитәкчелегендә республиканың беренче Халык Комиссарлары Советы сайланды. Шунда ук Татарстан сәламәтлек саклау Халык Комиссариаты да оештырылды.

Татарстанның автономияле республика хокукы алуына инде 50 ел вакыт үтте. Республикада экономика, культура, кешеләрнең тормыш, көнкүреш шартлары яхшыруы нәтиҗәсендә Совет Татарстанында хезмәт ияләренең сәламәтлеге дә яхшыра бара. Аларның сәламәтлеген саклау өчен елдан-ел күбрәк мөмкинлекләр тудырыла. Хәзер инде бездә, Татарстанда, холера, чума, чәчәк, тиф, бизгәк, полиомиэлит, трахома кебек авырулар бөтенләй бетерелде. Туберкулез, тире авырулары, эчәк авырулары, балалар авырулары да бик нык кимеде. 1970 елда дәүләт, сәламәтлек саклау өчен, 1913 елга караганда 42,5 тапкыр күбрәк акча тотты. Больницаларның саны 1969 елда 285 кә җитте (30 меңгә якын урынлы). Һәр мең кешегә республикада 10 га якын больница, ике врач, җиде урта белемле медицина хезмәткәре туры килә. Хәзерге вакытта республикада җиде меңгә якын врач эшли. Медицина кадрлары белән тәэмин ителү буенча Татарстан барлык эре капиталистик илләрне инде күптән узып китте.

— Бөтенсоюз һәм республика матбугатында, аерым җыентыкларда илебез авыр еллар кичергәндә Татарстанда белем алган, эшләгән, тәрбияләнгән медицина работникларының күрсәткән батырлыклары турында еш кына языла. Шулар турында берничә сүз әйтсәгез иде.

— Без гражданнар сугышы һәм интервенция чорында, Бөек Ватан сугышы елларында Совет сугышчыларының, хезмәт ияләренең тормышларын саклап калу өчен

һәлак булган медицина хезмәткәрләрен зур горурлану һәм хөрмәт белән искә алабыз. Әйе, аларның исемнәре безнең күңелләрдә мәңге яшәр!

Медицина хезмәткәрләренең фидакарь хезмәте халкыбызның зур мәхәббәтен һәм ышанычын казанды. Утыз бер кешенең «РСФСРның атказанган врачы», йөз илле ике кешенең «ТАССРның атказанган врачы», биш йөз медицина хезмәткәренең «Сәламәтлек саклау отличнигы» значогы белән бүләкләнүе һәм күпләренең Советлар Союзы орденнарына, медальләренә лаек булуы — әнә шул турыда сөйли. Ә акушер-гинеколог Газифә Хәсән кызы Хәсәншина Ватаныбызның иң зур бүләге — Социалистик Хезмәт Герое исеме алды.

Медицина кадрларын тәрбияләүдә, аларның квалификацияләрен күтәрүдә, сәламәтлек саклау органнарына оештыру-методик һәм практик ярдәм күрсәтүдә Хезмәт Кызыл Байрак орденлы, С. В. Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина институты, В. И. Ленин исемендәге Казан врачларның белемен күтәрү институты, травматология һәм ортопедия фәнни-тикшерену институты, шулай ук эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшерену институты зур роль уйный.

Казан шәһәре борын-борыннан илебезнең фәнни медицина үзәкләреннән санала. Казан медицина мәктәбе илебезгә бик күп атаклы галимнәрне бирде. Алар арасында В. И. Ленин шәкерте, беренче сәламәтлек саклау Халык Комиссары Н. А. Семашко, аның урынбасары З. П. Соловьев, медицина фәннәре Академиясе член-корреспонденты С. В. Курашов, академиклардан К. М. Быков, А. Д. Сперанский, В. А. Энгельгард, СССР Фәннәр Академиясе член-корреспондентлары Н. Г. Колосов, Б. И. Лаврентьев, медицина фәннәре Академиясенең действительный членнары А. Д. Адо, А. В. Вишневский, Социалистик Хезмәт Герое А. А. Вишневский, В. И. Иоффе, В. В. Чирковский, В. Н. Терновский, П. Ф. Здродовский, И. П. Розенков, медицина фәннәре член-корреспонденты А. В. Кибяков, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Н. А. Миславский, В. Л. Боголюбов, Н. К. Горяев, М. Н. Чебоксаров, В. С. Груздев, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе А. Б. Терегулов, А. Ф. Самойлов, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе В. В. Милославский, Р. А. Васильев һ. б. лар бар.

Хәзерге вакытта Казанда медицина фәнен үстерүдә профессорлар П. В. Маненков, И. Ф. Харитонов, З. И. Малкин, Н. П. Медведев, Л. И. Шулутко, Р. Г. Бакиева, М. А. Ерзин, Р. М. Рахлин, И. Н. Волкова, М. Х. Фәйзуллин, Х. С. Хәмитов, Ю. А. Ратнер, И. В. Данилов, Н. Е. Сидоров, С. М. Вяселев, И. М. Рахматуллин, Н. Н. Спасский, В. Е. Анисимов, М. Х. Вахитов, З. Н. Якупова, А. Х. Хәмидуллина, Д. А. Зөбәеров, З. Ш. Гыйләҗетдинова, З. Х. Кәримова һәм башка бик күпләр зур эш алып баралар.

1964 елда үзенең 150 еллык юбилеен билгеләп үткән Хезмәт Кызыл Байрак орденлы, С. В. Курашов исемендәге Казан дәүләт медицина институты һәр елны 500—550 югары квалификацияле врач әзерләп чыгара. Аның 40 проценты татар белгечләре.

Республикадагы сигез медицина училищесында (Казанда, Чистайда, Бөгелмәдә, Алабугада, Зеленодольскида, Буада, Минзәләдә, Түбән Камада) меңнән артык белгечләр тәрбияләнә. Казанда фармацевтика мәктәбе эшләп килә. 1920 елда ачылган В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт врачларның белемен күтәрү институтында ел саен ике меңгә якын врач махсус курслар уза.

Республикабызда сәламәтлек саклау буенча җитәкче кадрлар турында да берничә җылы сүз әйтәсе килә. Татарстанда сәламәтлекне саклауны оештыруда һәм үстерүдә элекке Халык Комиссарлары Ф. Т. Мөхәммәтьяров, К. Х. Мәһдиев, И. Беганский, Э. И. Прокушев, министр урынбасарлары Т. Д. Эпштейн, Ш. В. Бикчурин, Н. А. Немшилова, Казан шәһәр сәламәтлек саклау мөдире П. Красильников һәм башкалар зур роль уйнадылар.

— Республикада аналарның һәм балаларның сәламәтлеген саклауның торышы турында берничә сүз әйтмәссезме!

— Совет дәүләте аналарның һәм балаларның сәламәтлекләрен саклауга гаять зур игътибар бирә. Билгеле булганча, революциягә кадәр хатын-кызларга һәм балаларга нинди дә булса оештырылган, аерым медицина хезмәте күрсәтү юк иде. Казан губернасында йөкле татар хатыннарының йөздән туксан алтысы балаларын медицина ярдәменнән башка өйләрендә табалар иде.

Революциягә кадәр бөтен губернада — Казанда бер, Чистайда бер һәм Алабугада бер балалар тудыру йортлары булган. Бик табигый: мондый шартларда балаларның һәм аналарның үлеме бик еш булып торган.

Хәзерге вакытта Татарстанда 110 хатын-кыз консультациясе, 11 бала тудыру йорты, 133 колхозлар карамагында балалар тудыру йорты һәм һәр участок больницасында бала тудыручылар өчен койкалар бар. Хәзер 96 процент балалар тудыру йортларында туа. Шулар нәтиҗәсендә бала тудыручы аналарның үлеме 10 тапкырга кимеде.

— Шул уңайдан профилактика мәсьәләләрендә дә тукталсагыз иде.

— Профилактик юнәлеш совет сәламәтлек саклау учреждениеләренең генераль линиясе булып тора. Хезмәт иярәренең көнкүреш, хезмәт һәм ял итү шартларын яхшырту авыруларны булдырмауда, кешеләрнең сәламәтлекләрен ныгытуда төп роль уйный. Зур дәүләт хокуклары белән тәэмин ителгән санитар-эпидемиологик органнар торак пунктларында, предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә гигиена чаралары үткәрү белән җитәклиләр һәм бу чараларның гамәлгә ашырылуын күзәтәләр.

Хәзерге вакытта республикада 49 санэпидстанция, аларда 400 гә якын врач, мең ярымга якын урта белемле медицина работниклары эшли.

— Медицина учреждениеләре авыруларны дарулар белән ничек тәэмин итә?

— Совет властеның беренче елларында ук, сәламәтлек саклау буенча беренче Халык Комиссары Н. А. Семашко тәкъдиме белән, барлык аптекалар национальләштерелде һәм хезмәт ияләрен медикаментлар белән тәэмин итүне дәүләт үз кулына алды. Совет власте елларында аптека эшендә, дарулар җитештерүдә, медикаментлар белән тәэмин итүдә бик зур үзгәрешләр булды. Моны безнең республика үрнәгендә ачык күрергә мөмкин. Мәсәлән, 1969 елда Татарстанда 273 аптека, авылларда 1826 аптека пункты, 8 кибет эшләде. Ә революциягә кадәр хәзерге Татарстан территориясендә бары тик 43 аптека булган.

Хәзер Татарстанда зур химия-фармацевтика заводы бар. Аның продукциясе илебезнең барлык почмакларына җибәрелә. Казанда, шулай ук, медицина аппаратурасы заводы, кетгут заводы, медицина кораллары заводы кебек зур медицина промышленносте предприятиеләре эшли. Медицина кораллары заводында ясалма бәер, тамырларны тегә торган аппарат һ. б. лар кебек уникаль аппаратуралар җитештерелә. Алар илебездәге медицина учреждениеләренә генә түгел, чит илләргә дә чыгарылалар.

— Хезмәт ияләренең сәламәтлекләрен ныгытуда ял шартларының, санаторий һәм курортларның да роле зур. Бу өлкәдә ниләр эшләнә?

— Революциягә кадәр Казан губернасында ял йортлары, санаторийлар һәм курортлар бөтенләй булмаган. Хәзер Татарстанда туберкулез белән авыручылар өчен 8 санаторий, башка профильдәге 5 санаторий һәм 4 курорт эшли. 1969 елда аларда 15 мең 300 кеше дәваланды, ә ял йортларында 50 меңгә якын кеше ял итте. Шуны да әйтергә кирәк: бездә санаторийлар һәм ял йортлары минераль чыганаклар, шифалы баткаклыклар тирәсенә, матур табигать кочагына урнашкан. Шуңа күрә республикадан читтәге өлкәләрдән дә безгә бик телəп киләләр.

— Республикада санитар мәгарифе ни хәлдә?

— Бу өлкәдә шунысы характерлы: санитар мәгарифе эшенә халык бик актив катнаша. Алар белән оештыру-методик җитәкчелекне Казандагы, Әлмәттәге, Зеленодольскидагы Санитар мәгарифе йортлары башкаралар. Соңгы елларда оештырылган сәламәтлек университетлары һәм мәктәпләре халык арасында зур популярлык казанды. Хәзер 320 университет һәм мәктәпкә 20 меңгә якын кеше йөри.

Кызыл Хач җәмгыяте членнары сәламәтлек саклау органнарына зур ярдәм күрсәтәләр. Бу җәмгыятьтә хәзер 850 меңнән артык кеше член булып тора.

Сәламәтлек чараларын һәм сәламәтлек көннәрен үткәрүгә дә халык бик актив катнаша. 11 июль — сәламәтлек саклау буенча Халык Комиссариаты оештыруга В. И. Ленин кул куйган көн — сәламәтлек көне булып исәпләнелә.

Сәламәтлек саклауда материаль-техник базаның яхшыруы һәм кадрларның үсүе, санитария торышының нығуы нәтиҗәсендә Татарстанда 50 ел эчендә кешеләрнең үлеме 4,3 тапкыр азайды. Ә балаларның үлеме исә хәзер, революциягә кадәргегә караганда, 12,6 тапкырга ким.

Кешеләрнең уртача гомере ике мәртәбәдән артыгракка артты [70 яшь].

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте халкыбызның сәламәтлеге турында даими кайгырта. СССР Верховный Советы раслаган сәламәтлек саклау турында яңа законадательство нигезләре моның ачык мисалы булып тора. Бу сәламәтлек кодексы сәламәтлек саклау эшен камилләштерүдә яңа киң мөмкинлекләр ача. «Халыкның сәламәтлеген саклау,— диелгән анда,— Совет дәүләтенең иң мөһим бурычларыннан берсе».

Бу декларация генә түгел, бу — Совет дәүләтенең бүгенге чынбарлыгы.

# ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЕБЕЗ

— Юбилеебыз уңае белән революциягә кадәрге Россиядә, аерым алганда элекке Казан губернасында, социаль тәэминат эшләренең ни хәлдә булуы турында берничә сүз әйтсәгез иде, Фаизә Ганиевна!

— Патша Россиясендә, шул исәптән Казан губернасында да, картларга, хезмәткә яраксыз кешеләргә, ятимнәргә ярдәм күрсәтү, аларны нинди дә булса формада тәэмин итү дигән нәрсә асылда бөтенләй булмаган. Безнең көннәргә килеп җиткән кайбер мәгълүматларга караганда, мәсәлән, 1912 елны социаль тәэминатка Казанда яшәүчеләргә дәүләт думасы тоткан расходны бүлеп баксаң, җан башына бары тик берәр генә тиен туры килә. Картаеп яки башка сәбәпләр белән тәрбиячесез калган кешеләргә ярдәм итүне хөкүмәт үзенең бурычы дип санамаган. Бүтән категориядәге мохтаҗлар ярдәмне сәүдәгәрләрдән кергән барлы-юклы хәер исәбенә яшәүче аерым оешмалар аша гына алганнар. Монысы да әле аның эчкерсез булышу теләгеннән чыгып эшләнмәгән. Бу — буржуазиянең ярлыларга «ярдәм» иткәндәй кыланып, аларның аңнарын сыйнфый көрәштән читкә юнәлдерергә, үзен игелекле күрсәтеп, хезмәт ияләрен алдарга матавшуның бер чарасы гына булган. Моның нәтиҗәсе дә бик табигый. Хәер сорашырга чыккан хәлсез картларның, ятим балаларның кышкы суыкларда авыл араларында өшеп үлүләрен, шәһәр базарларында, урам чатларында тилмереп торган гарипгорабаларны, ач-ялангач мескеннәрнең үзгынчыларга ялварып сузылган кулларын өлкән буын кешеләре бик яхшы хәтерлиләр.



— Совет властеның беренче елларында бу мәсьәлә нинди планда җайга салынды!

— Социаль тәэминат мәсьәләсен хәл итү яшь Совет республикасы алдында торган чиктән тыш авыр бурычларның берсе иде. Күз алдына китерик: озакка сузылган империалистик сугыш, аннары гражданнар сугышы илнең экономикасын тәмам какшаткан, кая карама — ачлык, ялангачлык. Шуның өстенә йөз меңнәрчә сугыш инвалидлары, тәрбиячесез калган картлар, ятимнәр... Барысын да туйдырырга, киендерергә кирәк. Әмма властьны әле яңа гына үз кулына алган Совет хөкүмәтенең бу эшне кенә-сәгате белән хәл итәргә мөмкинлекләре дә юк диярлек. Ләкин аның кулында

хәзер иң әһәмиятлесе — һәм политик, һәм экономик шартлар, революция утында чыныккан, Совет хөкүмәтен чын мәгънәсендә үз хөкүмәте итеп санаган халык массасының иҗади инициативасына таянучы власть бар иде.

1917 елның октябрендә ук инде Совет хөкүмәте Россия хезмәт иясенә, эшчеләрнең страхование хакындагы лозунглары нигезендә, социаль страхование турында кичекмәстән декретлар чыгара башлаячагын белдерде.

Хезмәт ияләрен социаль тәэмин итү турында Халык Комиссарлары Советы Декреты — Совет властеның беренче елларында кабул ителгән бик әһәмиятле документларының берсе. Бу документ социаль тәэминатның принципиаль яңа системасына нигез салган беренче закон акты булды. Шуннан соң ул система туктаусыз камилләшә барды.

Инде әйтелгәнчә, илебез гаять авыр көннәр кичерә иде. Шуңа күрә мохтаҗ кешеләргә башта азык-төлек паеклары, кием-салым, хуҗалык кирәк-яраклары төсендә натуралата ярдәм күрсәтергә туры килде. 1921 елгы ачлыкка каршы республикабыз социаль тәэминат Халык Комиссариаты алып барган көрәшне гәүдәләндерүче архив документларын без бүген зур дулкынлану белән укыйбыз. Нинди генә чаралар кулланылмаган ул елларда. Казан шәһәрендә, мәсәлән, ачлыкка түзә алмыйча авыллардан килгән крестьяннар, гомумән, ачлар өчен махсус тулай тораклар, ашату пунктлары ачылган, ачлыкка каршы атналыклар уздырылган, балаларны ашату-дәвалау поездлары оештырылган. Ул көннәрнең сулышын ачыграк тою өчен, Татарстан республикасы социаль тәэминат Халык Комиссары исеменә тукландыру поезды хезмәткәре җибәргән доклад язуыннан (1921 ел, 11 ноябрь) кайбер өзекләр китерик:

«Поезд тирәсендә каралты-кура булмаганлыктан, балаларны теркәү һәм ашханә өчен җылы урын юк. Сабыйлар тышта яңгыр астында юеш җиргә утырып ашыйлар. Көненә барлыгы биш меңгә якын бала туендырабыз. Аларга суыкта, карлы-бозлы яңгыр астында чират торырга туры килә... Шуның өстенә тагын поезд су белән бик начар тәэмин ителә, нәтиҗәдә чират зурая. Ашыгыч чаралар күрүне үтенәм».

Натуралата шулай ярдәм күрсәтү хәрби коммунизм чорындагы тормыш шартларыннан чыгып эшләнде. Гражданнар сугышы бетү белән, Совет власте органнары дәүләт бюджетын анык билгеләнгән кредитларга нигезли башладылар. Шуңа күрә социаль тәэминатны да билгеле бер тәртипкә салу бурычы килеп басты һәм натуралата ярдәм акчалата ярдәмгә алыштырылды.

Экономика ныгу белән бергә пенсия турындагы законнар да үзгәрә, камилләшә бара. 1928 елны, мәсәлән, картлык буенча пенсия түләү системасы илебездә беренче тапкыр гамәлгә кертелде.

Ил өчен иң авыр вакытларның берсе булган Бөек Ватан сугышы елларында Коммунистлар партиясе, Совет хөкүмәте социаль тәэминат мәсьәләсенә игътибарны тагын да арттырды. Советларның Башкарма Комитетларында социаль тәэминат эшләренә җитәкчелек итү өчен Башкарма Комитет председательләренең махсус урынбасарлары булдырылды. Эшләүче барлык пенсионерларга, күпме хезмәт хакы алуларына карамастан, пенсияләре тулысынча түләнеп килде. Хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның семьяларын тәэмин итү буенча күп чаралар күрелде. Сугыш инвалидларын эшкә урнаштыру, профессияләргә өйрәтү оештырылды.

— Социаль тәэминатта кискен үзгәреш елы дип Сез кайсы елларны атар идегез!

— Бу сорауга өздереп кенә җавап бирүе кыен. Илдә Совет власте урнашканнан соң, социаль тәэминат мәсьәләләренең киң катлау хезмәт ияләре интересыннан чыгып тормышка ашырыла башлануы — бу үзе ук инде кискен бер үзгәреш. Алай гына да түгел, бу патша Россиясе шартларында бөтенләй диярлек булмаган нәрсәне булдыру дигән сүз иде. Ә инде совет власте елларына карата әйтелсә, мин социаль тәэминатта аеруча кискен үзгәрешләр елы дип 1956 елны атар идем. Мәгълүм булганча, 1956 елның 14 июлендә дәүләт пенсияләре турында закон кабул ителде. Бу социаль тәэминат системасы үсешендә гаять зур вакыйга булды, ул илебездә пенсия белән тәэмин итү эшен тамырдан яхшыртты. Картлык буенча пенсияләр күләме ике-ләтә, ә инвалидлык пенсиясе 1,7 тапкыр артты. Хәзер бездә уртача пенсия күләме эшчеләр һәм хезмәткәрләр эш хакының 72 процентыннан артыграк.

— 1956 елгы законнан соң социаль тәэминат өлкәсендә тагын нинди үзгәрешләр булды? Аларга да беркадәр тукталсагыз иде.

— Үзгәрешләр, әлбәттә, бар. Әйткәнемчә, законнар һаман үзгәрә, камилләшә тора. Бу безнең совет строеның үзенчәлекле, күркәм бер сыйфаты. Дәүләт пенсияләре турында закон кабул ителгәннән соң узган 14 ел эчендә аңа пенсия алуга хокуклы кешеләр даирәсен киңәйтүче күп кенә әһәмиятле үзгәрешләр кертелде. 1959 елда, мәсәлән, беркайда да эшләмәүче I группа сугыш инвалидларының, кайбер профессиональ авырулар аркасында инвалид булып калган эшчеләрнең һәм хезмәткәрләрнең пенсияләре арттырылды. Ә 1964 елны СССР Верховный Советы колхоз членнарына пенсия һәм пособие түләү турында закон кабул итте. Шул нигездә колхозчыларны пенсия һәм пособие белән тәэмин итүнең бердәм системасы булдырылды. 1965 елның 6 мартында СССР Министрлар Советы Ватан сугышы инвалидларына, Бөек Ватан сугышында һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең семья членнарына льготаларны киңәйтү турында карар кабул итте. Бу карар нигезендә I, II группа инвалидларга һәм тәрбиячесен югалткан семьяларга пенсиянең минималь күләме арттырылды.

КПСС Үзәк Комитетының 1967 елгы сентябрь Пленумы карары совет кешеләре хакында зур кайгыртучанлыкның яңа бер үрнәге булды. Бу карар нигезендә авыл хезмәт ияләренең пенсия алу шартлары эшче һәм хезмәткәрләрнекенә якынайды.

Хәзер илебездә 35 миллионга якын кеше пенсия белән тәэмин ителә. Моңа 11 миллиард сумнан артыграк акча тотыла. Ә социаль тәэминатның һәм социаль страхованиенең барлык төрләренә 14 миллиард сумнан күбрәк бирелә.

Бүгенге көнне Татарстанда 585 мең 518 кеше пенсия һәм пособие ала. Былтыр исә моңа 166 миллион сум чамасы акча тотылды. Бер үк вакытта социаль тәэминатның башка төрләре дә үсә һәм камилләшә. Инвалидларны хезмәткә урнаштыру, аларны торак, транспорт белән тәэмин итү, тәрбиячесез картларны, инвалидларны махсус йортларга урнаштыру һәм башка чаралар күрелә. 1964 елдан алып хәзерге көнгә кадәр Ватан сугышы инвалидларыннан меңгә якын кешегә түләүсез «Запорожец» автомобиле, ә 1260 кешегә моторлы коляска бирелде.

— Республикабызның социаль тәэминат эшендә үзләрен аеруча танытkan иптәшләрнең исемнәрен атый алмассызмы!

— Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең кайгыртучанлыгы аркасында безнең Татарстанда да бу эшнең бик әйбәт кадрлары үсеп чыкты. Без коммунистик хезмәт коллективы дигән мактаулы исемне йөрткән Чистай, Бөгелмә, Чирмешән, Бауман (Казан) район социаль тәэминат бүлекләре, аларның мөдирләре А. Матвеева, П. Михеев, Л. Беззубова, Е. Бондарев иптәшләрнең эше белән горурланабыз.

Социаль тәэминат ветераннарыннан министр урынбасары Е. Петрашень, бүлек мөдире Н. Якупова, министрлык бухгалтеры В. Кузнецова, министрлык инспекторларыннан С. Трашкова, Т. Ганина, А. Сәйфетдинова, Чистай шәһәренең неврология интернаты директоры М. Сибгатуллин, экспорт-врачлардан Н. Дулат-Алиева, А. Пономорева, Е. Кузьмина һәм Т. Копылова иптәшләр үзләрен аеруча хезмәт сөючән итеп таныттылар. Әле күптән түгел генә социаль тәэминат органнарының ун работнигына хөкүмәт бүләкләре бирелде. 25 кеше «РСФСРның социаль тәэминат отличнигы» значогы белән, 45 кеше Почет грамотасы белән бүләкләнде.

**Азат Әхмәдуллин**

# ДРАМАТУРГИЯБЕЗНЕҢ КАЙБЕР ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

Соңгы еллар татар драматургиясендә җанлану сизелә. Дөрес, хәзергә ул сан исәбенәрәк бара шикелле. Шул ук вакытта киләчәктә сыйфат үзгәрешләренә китерердәй уңышлар да юк түгел. Драматургиябез жанрлар ягыннан төрләнәнде. Соңгы елларда героик һәм эпик, социаль һәм психологик драмалар, күп санлы комедияләр язылды. Трагикомедия, трагедия, водевиль жанрына караган сәхнә әсәрләре туды. Шулай ук тематик яктан да драматургиябез һаман байый, төрләнә бара. Драматургик материал эзләп, авторлар тормышның төрле өлкәләренә мөрәҗәгать итәләр, сәхнәгә яңаданяңа профессия кешеләренең әдәби образлары күтәрелә. Тема-проблемаларның һәм жанр формаларының күп төрлелеге — сәнгатьнең нормаль үсүе өчен котылгысыз шарт.

Иң әһәмиятлесе шунда: драматургларыбыз — өлкәннәре, тәҗрибәлеләре дә, яшьләр дә — бу материалларга яңача, үзләренчә килергә тырышалар. Моны без образларны сурәтләү алымнарында да, сюжет төзүдә дә, конфликт һәм композиция мәсьәләләрендә дә күрәбез. Боларның бәрысы бергә драматургиянең массаларны коммунистик рухта тәрбияләүдәге тәэсир итү көче һәм роле артуга китерәләр, аның идея дәрәҗәсен күтәрәләр.

Бу җәһәттән бигрәк тә танылган драматург Риза Ишморатның иҗаты үрнәк булырлык. Ул Муса Җәлилнең үлмәс образын сәхнәгә чыгарды, океан киңлекләрен һәм стихия авырлыкларын җиңеп үткән дүрт батырның үрнәк образларын иҗат итте һәм, ниһаять, даһи Ленинның яшьлек елларын җанландыруга багышланган эпик картина тудырды. Р. Ишморат әсәрләренә идея аныклыгы, коммунизм эшенә бирелгәнлек, югары партиялелек хас. Тәҗрибәле драматург сәхнә үзенчәлекләрен яхшы белеп эш итә, аның пьесалары сәхнәдә уйнар өчен отышлы булалар, тамашачы тарафыннан яратып караталар.

Сүзне Р. Ишморат әсәрләреннән башлауның һәм бу якка борыбрак җибәрүнең үзенә күрә бер сәбәбе дә бар. «Вопросы советской литературы»[1] исемле җыентыкта әдәбият галиме, драматургия белгече А. Гладковская аның «Алар дүртәү иде» пьесасы турында тәнкыйть фикерләре язып чыкты. Әлбәттә, әсәр һәр яктан камил дип раслап булмый. Анда алынган тормыш материалы, ягъни Әсгать Җиһаншиннар вакыйгасы, чыннан да, драма әсәре иҗат итү өчен шактый җайсыз һәм авыр материал, күрәсең. Бу мәсьәләдә тәнкыйтьче белән килешергә туры килә. Ләкин аның: дүрт геройның батырлыгы үзенең табигый хәлендә драма өчен сюжет булырга яраклы түгел, чөнки бу кечкенә коллектив эчендә шәхси конфликтлар юк, дип кистереп раславы белән бәхәскә керергә мөмкин. А. Гладковскаяның чын драматизм бары тик кешеләр арасындагы бәрелеш-

[1] Вопросы советской литературы. Сборник. Рус телендә. Ленинград. 1968 ел.

ләр, каршылыклар нәтиҗәсендә генә туа ала дигән концепциясе гомумән бер яклырак. Һәм бу концепцияне «Алар дүртәү иде» пьесасы үзе үк кирә кага. Котырынган табигать көчләре белән көрәштә автор конфликт, драматизм күрә һәм аны укучыларга да җиткерә алган. Әсәрдә тәнкыйтьче күреп бетермәгән тагын бер нәрсә бар: стихия белән көрәш вакытында батырларны «нинди генә чара белән булса да үз-үзеңне саклап калу инстинкты» дигән куркыныч дошман сагалап тора. Башка шартларда, башка мораль принципларда тәрбияләнгән кешеләр бу дошман алдында чигенерләр һәм шуннан тәнкыйтьчебез бик тә күрергә теләгән шәхси конфликтлар да туар иде, бәлки. Р. Ишморат пьесасында исә ул андый дәрәҗәгә җиткерелми, җиткерелә дә алмый. Чөнки материал андый түгел, геройлар андый түгел. Әмма драматик хәрәкәтнең барышында бу момент билгеле бер роль уйный.

Бу уңай белән бер нәрсәгә басым ясыйсы килә: драма әсәрендәге конфликтны һәр очракта да нәкъ менә ике яисә берничә кешенең кара-каршы көрәше дип кенә карау мәсьәләне тарайтып аңлау булыр иде. Әйе, персонажлар арасындагы бәрелеш — ул конфликтның өстә яткан, күренеп торган, тотып алу өчен ансат ягы. Ә чын конфликтның табигате күп катлаулырак бит. Ул драманың барлык элементлары эчендә «эрегән» хәлендә була, идея белән, характерлар, сюжет, жанр, драманың стиле белән органик бәйләнештә генә ачыла. Чагыштыру тәртибендә фикер йөртсәк, конфликт — әсәрнең җаны ул. «Кешенең җаны» дигән төшенчә астында йөрәкне, яки башка берәр конкрет әгъзаның үзен генә аңлау дөрес булмаган кебек, конфликтны да пьесаның бөтен идея-художество концепциясеннән эзләргә кирәк.

Конфликтны тышкы кыяфәте буенча гына күзаллаучылар, мәсәлән, Ф. Хөснинең «Бертуган Таһировлар» драмасында да әллә ни зур яңалык тапмаслар. Чөнки монда кара-каршы торып тартышу-сугышулар юк дәрәҗәдә. Ләкин әсәрдә конфликт анык һәм көчле. Монда һәр нәрсә ике туган — Закир белән Зарифның начар эшләрен фаш итүгә юнәлтелгән. Автор, Закирдагы культчылык сыйфатларын, яраклашу психологиясен сурәтләп, кайчандыр күркәм генә саналган бер кешенең бозылу, рухи гарипләнү фаҗигасен күрсәтә. Әсәрнең нигезендә бик җитди һәм тормышчан конфликт ята. Бу конфликтны ачып бирүдә Заһид Таһиров билгеле бер роль уйный, ләкин хәлиткеч рольне түгел. Әсәрдәге төп образ да Заһид түгел, ә аның культ елларында кешелек сыйфатларын югалткан олы абыйлары. Басымны шушы тарафка юнәлтүе белән Ф. Хөсни шәхес культы авырлыкларын фаш итүгә багышланган башка әсәрләрдән үзгә булган пьеса иҗат иткән. Яңа, оригиналь образлар тудырган. Тирән фикергә, уйлануларга бай, тамашачыны да уйланырга этәрә торган әсәр биргән.

Конфликтны шундый киң мәгънәсендә, тирән итеп аңлауны Әхсән Баянованың «Күзләре нинди иде» исемле драмасында да күрергә мөмкин. Шагыйрьнең бу беренче пьесасының сәхнә гомере озын булмады. Бу, күрәсең, авторның сәхнә кануннарын әле тиешенчә үзләштереп җиткермәвеннән киләдер. Анда хәрәкәт сүлпән, образларның да күбесе ахырынача эшләнеп бетмәгән иде. Ләкин шул ук вакытта пьесага яңалык та хас: аның шул якларын аңларга омтылмастан, әсәрне бер селтәнү белән юкка чыгару, аз дигәндә, ашыгычлык күрсәтү булыр иде.

Әсәрнең үзенә күз салыйк. Бер карагандә, төзелеш начальнигы Хәмитованың кыланышлары бөтенләй үк нигезсез дә түгел. Ул бөтен көчен зур завод салу эшенә сарыф итә. Шул ук вакытта, планны вакытыннан алда үтәү өчен, кайбер «вак-төяк» гөнаһларга барудан да тайчанмый. Һәм аның бу мәсьәләдә үз фәлсәфәсе бар. Нигә, әгәр дә завод, кайбер әрем-шәрем итүләр исәбенә, бик үк гадел булмаган юллар белән булса да, бер ел алдан сафка басса, илебезгә гаять кирәкле булган продукцияне алданрак бирә башласа, начармыни?! Ул вак-төякләрне завод чирек айда каплаячак ич! Аның каравы илгә, халыкка күпме өстәмә файда киләчәк! Менә шул ялган фәлсәфә саф күңелле һәм тәҗрибәсез Айсаны фаҗигагә китерә дә инде. Хәмитованың эшләре бүгенге көн өчен файдалырак һәм кирәклерәк дип уйлый ул. Ә Салаватның «бөек эшләрне дә, кечкенәләрен дә бары тик намуска, гаделлеккә нигезләнеп кенә башкарырга мөмкин» дигән ышанычына Айса «киләчәк» фәлсәфәсе дип карый. Шул нигездә ул бергә эшләгән иптәшләренә каршы чыга. Катлаулы ситуация, тирән фикерләр бәрелеше ярдәмендә, Айсаның үлемен сурәтләү аркылы Хәмитовларның ялган фәлсәфәсе фаш ителә, җәмгыятебезнең таза, гадел принциплары раслана, аларның җиңә баруы

күрсәтелә. Драманың иҗтимагый яңгыраш көче әнә шунда. Шундый тормышчан конфликтта Айса характеры, ул ясаган ялгыш адымның сәбәпләре ачыла. Айса, һәм беркадәр Хәмитов та, драматургиябездә әлегә кадәр очрамаган образлар булып күз алдына басалар.

Конфликт һәм характер мәсьәләсен заманча аңларга тырышу соңгы елларда язылган башка кайбер пьесаларда да күренә. Югарыда телгә алынган әсәрләрдән тыш, «Шамил Усманов», «Шаулыйлар дулкыннар», «Ике буйдак», «Зөбәйдә — адәм баласы», «Күк капусы ачылса», «Җиргә тапшырылган серләр», «Миләүшәнең туган көне» кебек пьесаларда характерлар тирәнлегенә һәм тулылыгына, аларның оригиналь булуына омтылыш, сюжет төзүдә, композиция корылышында аерым уңышлар бар. Шулай да, тулаем алганда, драматургиянең үсеше әле тиешле темплар белән бармый.

Язучылар союзында уздырылган җыелышларның берсендә Фатих Хөсни:

«Без, Көнбатыштагыча, геройлыктан качу, әдәби геройларны юри кечерәйтү тенденциясенә ияреп бармыйбызмы?» — дигән иде. Пушкинның, халык драмалары зур мәйданнар таләп итә, дигән сүзләрен искә төшергәннән соң, ул шул нәрсәнең безгә дә җитмәве турында, бигрәк тә бу яктан драматургия һәм поэзиянең зур житешсезлекләргә ия булуы хакында сөйләде. Эш, бәлкем, Ф. Хөсни уйлаганча, Көнбатыштагы зарарлы тенденцияләрнең берсенә ияру-иярмәүдә түгелдер. Әмма олы язучының ачынып һәм борчылып әйткән әлеге сүзләре игътибарга лаек. Әйе, драматургиябездәге герой проблемасы безне борчымый кала алмый. Әйе, уңай герой, аның характер үзенчәлекләре мәсьәләсе үзенә житди игътибар бирүне сорый.

Үз чорында татар совет драматургиясендә эчке рухи халәте һәм тышкы кыяфәте белән ачык төсмер алган уңай герой образы формалашкан иде. Гадәттә, андый геройның характеры баштан ук мәгълүм була, һәм сәхнәдәге һәр күренеш, һәрбер вакыйга бу характерны ача, раслый бара иде. Геройның ныклы, бербөтен характерга ия булуы, көчәя барган каһарманлык — хәрәкәтенең эчке пружинасын билгеләп, персонаж башкарган эшләрнең эффектлылыгын тәшкил итә иде. Ш. Камалның Габбас Галины («Томан арты») яисә К. Тинчуринның Акбирдине («Кандыр буе») — шундый геройларның характерлы вәкилләре. һәр ике образда героик характер, тынгысыз, каһарманлыкка омтылучан шәхес чагыла. Мондый герой өчен үтеп чыга алмаслык киртәләр юк дәрәҗәсендә, ул һәр нәрсәне булдыра ала, эшли белә, башкарып чыга, җиңә. Үз тирәсендәгеләрдән дә, дошманнарыннан да бер башка югары тора ул. Хәзер бу герой күп кенә моментларда артык турысызыклы, бер яклы булып күренергә мөмкин. Ләкин ул чынлыкта үз дәверенең каһарманы иде, аны тормыш, чор оптимизмы үзе тудырган, аңарда безнең җәмгыятебез тарихының ул вакытлардагы алдынгы тенденцияләре, романтик настроениеләре, таләп һәм бурычлары чагыла иде. Бу уңай герой мисалында күп санлы укучылар һәм тамашачылар тәрбияләнде.

30 елларда ук формалашкан бу герой Ватан сугышы елларында яңа вакыйгалар һәм ситуацияләргә эләкте. Мирсәй Әмирнең Миңлекамалы шул геройның иң күренекле якларын үзендә туплаган, яңа шартларда сурәтләнгән классик тибы булды. Характерындагы алдан билгеләнгәнлек бу уңай геройны да һәр төрле киртәләр аша хәвеф-хәтәрсез алып чыга, җиңүгә илтә. Бу геройда характерның тагын да баюын, тулылануын, аның психологик бизәкләре арта төшүен күрергә мөмкин.

Еллар узды, сугыш авырлыклары артта калды. Совет халкы яңа тарихи дәвергә килеп керде. Җәмгыятебез алга хәрәкәт иткән саен, кешеләрнең культурасы югарырак күтәрелде, тормыш тәҗрибәсе артты, эстетик зәвыклары үсте. Дәһшәтле сугышта җиңгән совет кешесе хезмәттә дә яңадан-яңа уңышларга ирешә, аның дөнья каршында дәрәҗәсе күтәрелде. Яңа тарихи шартлар үз каршылыкларын тудырды, яңа конфликтлар барлыкка килде. Әмма безнең драмадагы уңай геройны аңлавыбыз һәм күзаллавыбыз нигездә үзгәрешсез калды. Киресенчә, аның тышкы кыяфәте элеккечә калды. Ә эчтәлеге белән бу образ инде үзенең әүвәлге мәгънәсеннән күп кинәйде, чөнки чынбарлык заманның уңай герое алдына яңадан-яңа һәм катлаулырак таләпләр куя иде. Андый уңай герой итеп тормыш яңа тип кешене бирде. Һәм драматургиядә дә шундый уңай геройны эзләү башланды. Шуның белән бергә, элек формалашканы да, гомумән драматик геройның синонимы төсендә, сәхнәдә һаман да яшәвен дәвам иттерде һәм ул әле дә сәхнәдә йөри. Алай гына да түгел, күпчелек драматурглар иҗатында ул һаман да үзенә

төп рольне, үрнәк итеп саналырлык образ ролен дәгъвали. Иң аянычлысы шунда: кайбер драматурглар, аның асылын, эчке мәгънәсен аңлау кебек мәсьәлә белән баш ватмыйча гына, аны ничек бар, шул килеш үз пьесаларына китереп кертәләр. Һәм андый каһарман инде мәгълүм яңалыкларны ача, акыллы сүзләр сөйли торган резонер булып сәхнәдә йөри бирә. Сәхнәгә ничек килеп керсә, шулай ук артык үзгәрешсез чыгып та китә.

Бу процессның үз дәверләре дә булганын сиземләргә мөмкин. Берара, актан ак, сөттән пакь үрнәк геройга реакция рәвешендә, «ялгышучы, хаталанучы геройлар» дип йөртелгән образлар ишәеп китте. Мондый персонаж тормышның күнегелгән агышыннан риза булмый, инде урнашкан һәм ныгыган нормаларга каршы чыга. Аның иң күренекле мисалы итеп Х. Вахитның «Рәхим итегез» комедиясендә Рәисә образын күрсәтү дөрес булыр.

Ләкин төп юл бу түгеллеген драматургларыбыз тиз төшенделәр. Акрынлап героик башлангычны (ө бүгенге көн героенда нәкъ менә шушы башлангыч үзәктә торырга тиешлеге мәсьәләсендә ике төрле фикернең әлегә булганы юк) гади кешедән, аның тирән эчке мәгънәсеннән эзләү башланды. Кабатлап әйтәбез, монда әле мактанырлык уңышлар күренми. Безгә калса, драматургиябез бүгенге геройны иҗат итүдә менә шундый бер зарури күчеш дәверен, озаккарак сузылган эзләнүләр чорын кичерә. Кичәге герой тамашачыны да, драматургларның үзләрен дә канәгатьләндереп бетерми. Чөнки тормыш күп мәртәбә катлаулырак һәм баерак рухлы кешеләр тибын күтәрде. Менә шушы «билгесезлек», ягъни кичәге уңай герой белән генә канәгатьләнмәү (кабатлап әйтәм: моны тормыш үзе таләп итә!), ә замандаш образын әле табып җиткермәү — гомумән дә драматургиябезнең торышы белән риза булмауга, күңел канәгатьсезлегенә китерә. Шул төп сәбәп, күрәсең, Фатих Хөснине дә югарыдагы уйлануларга этәргән булса кирәк.

Хәзерге көн героен традицион рамкалардан чыгарырга тырышу җәһәтеннән үз вакытында Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасы әһәмиятле роль уйнады. Мәгълүм булганча, бу пьеса башкорт, үзбәк сәхнәләрендә дә уңыш казанды. Анык билгеләнгән конфликт, заманга хас сыйфатларны чагылдырган күренешләр, шактый җентекле эшләнгән характерлар китерде аңар бу уңышны. Тәлгат образында драматург заманның алдынгы кешесенә хас сыйфатларны күрергә һәм шуларны тамашачыларга җиткерергә тырышты. Традицион геройдан үзгә буларак, Тәлгат һәр очракта, язмыш аңар билгеләгән һәр вакыйгада әзер рецептлар белән эш итми, эш итә дә алмый. Тормышындагы киләчәк адымны (сүз җитди адымнар турында бара, әлбәттә) дөрес атлау өчен аңар баш ватарга, уйланырга, икеләнү-шикләнүләр аша үтәргә, мораль һәм рухи көчләрен тупларга туры килә. Һәр кемгә очравы мөмкин булган авырлыкларны ул әле җиңәргә өйрәнмәгән. Ул, мәсәлән, аз гына бер җайсызлык килеп чыкты исә, Сәлимнәрдән китү өчен әйберләрен җыйный башлый. Бу бик табигый. Мөстәкыйль тормыш юлына яңа гына аяк баскан яшь егет өчен гаделсезлеккә каршы чыгуның иң ансат һәм уңай бер алымы бу. Чөнки Тәлгат үзе инанган карашларны чынга ашыруда баштарак әле шуннан да артыкны булдыра алмый. Урта белем алган егетнең тормышка һәм кешеләргә карата, алар арасындагы мөнәсәбәтләр турында формалашып килгән карашлары тормыш сынавын үтәләр. Җитди проблема, өлгергән, тормышчан проблема, гыйбрәтле проблема! Һәм әһәмиятлесе шунда: якты идеаллар, кеше характерындагы гүзәл сыйфатлар, безнең җәмгыятебездә әхлак нормаларының нигезендә ятучы принциплар пьесада өстенлек алалар, уңай герой шуларны раслауда күренекле роль уйный.

Тәлгатне тулы мәгънәсендәге хәзерге көн герое дип атап булмас, бәлкем. Ләкин монда хикмәт аның артык яшь булуында да, үрнәк булу өчен аның «тәти егет» итеп сурәтләнмәвендә дә түгел. Хикмәт аның эш-хәрәкәтләренең характерында: Тәлгат тиешенчә актив эш алып бармый әле.

Х. Вахит, үз эзләнүләренең асылын, төп юнәлешен күрсәтеп, берара матбугатта чыгыш та ясаган иде. («Тормыш дөреслеге өчен». «Социалистик Татарстан» газетасы. 1961 ел, 11 ноябрь). «Образны эчке хәрәкәтеннән, җитлегүгә таба үсүеннән, характеры камиллешүдән мәхрүм итәргә кирәкми» диюе белән ул, әлбәттә, хаклы. Ләкин шул ук вакытта автор мәкаләсенең гомуми юнәлеше белән һәм, барыннан да бигрәк, «Рәхим итегез» комедиясендәге Рәисә образын канат астына алуы белән, бер яклы һәм бәхәсле фикерне яклавын да күрсәтте, үзе дә сизмәстән, югарыда искә алын-

тан «хаталанучы геройлар» концепциясенә кушылды.

Иҗат практикасында исә драматург заман каһарманын эзләүдәге тәҗрибәләрен һич тә бу юнәлештә генә үткәрмәде, төрле тестә дәвам иттерде. Монда бер нәрсә күзгә нык ташлана: ул бу эзләнүләрен асылда комедия жанрында алып барды һәм, яңа герой иҗат итү принциплары ноктасыннан, тулаем алып караганда, «беренче мәхәббәт»тәге уңышына артык зур яңалык өсти алмады. Комедияләрендә («Рәхим итегез»дә Зәйтүнә һәм Марс, «Кайда соң син»дә Шәүкәт, «Карлыгач канат кага»да Айтуганов, «Илһамия»дә Илһамия) ул заман героен асылда традицион яссылыктарак хәл итә.

Драматургның аерым әсәрләрендә яңа геройны аңлауда һәм сурәтләүдә иске һәм яңа тенденцияләрнең аралашып килүе дә күренә. «Соңгы хат» пьесасында Нияз образы, мәсәлән, моның ачык мисалы.

...Медицина институтының соңгы курсында укучы өч иптәш ачыш ясыйлар. Институт аларга зур өмет баглый, аспирантурада калдырып, фәнни эзләнүләрең дәвам иттерергә мөмкинлек бирергә ниятли. Ләкин соңгы көннәрне генә, чыгарылыш кичәсе алдыннан, өчәүнең берсе — Нияз тәҗрибәләрне яңадан кабатлый һәм электе алынган нәтиҗәләрнең ялгыш булуын белә.

Нияз үзенең табигате белән дә, тәрбиясе белән дә саф күңелле, тугры, намуслы егет. Ул, үзләренең ялгышуларын ачык әйтеп, алар ясаган ачыш турындагы хата фикерләргә чик куярга тели. «Минем ирекле буласым килә. һәр төрле фальштан, ялганнан, гаделсезлектән арынып, ирекле яшисем килә! Кешеләрнең күзенә туры карый алырлык булып. Икеләнер чак түгел, без дөреслекне ачарга тиешбез»,— ди ул. һәм моны эшләр дә иде. Аңа каршы сөйләүче Зәфәрнең демагогик фикерләре дә комачаулый алмас иде аңар. Ләкин әле тормыш дигән нәрсә бар, ул гына куя ала торган, бер юлы гына, ансат кына җиңеп чыгып булмастай киртәләр бар.

Олы фән юлына басарга әзерләнгән яшьләр зур мораль сынау алдында калалар. Бик табигый хәл, ышандырырлык ситуация! Алай гына да түгел, җитди ситуация! Чөнки Ниязга, аның фикерләренә каршы Зәфәр китергән аргументлар да ышандырырлык кебек. Яшьләрнең беренче тәҗрибәләрен яклап чыккан профессор — Зөһрәнең атасы хаста булып түшәктә ята. Дөреслекне ачу каты авыру хәлендәге картка удар булачак. Ә моны эшләү «ярамый, врачлык этикасы юл куймый. Авыруга безнең ялганларга хакыбыз бар, ә борчырга юк». Моңар инде Нияз да буйсынырга мәҗбүр. Буйсына Нияз, ләкин килешми. һәм ул, бөтенесенә кул селтәп, авылга эшкә китә. Шуның белән ул, берьяктан, чигенә, ә икенче яктан караганда, тормыш юлында кыю һәм җитди адым ясый. Җиңел юлга түгел, ә киеренке хезмәт белән тулы практик тормышка аяк баса. Шул рәвешчә, монда да без уңай герой характерындагы яңа сыйфат ярылгысы белән очрашабыз. Ниязның эш-хәрәкәтә зур эчке киеренкелек, эчке көчләрне бергә туплауны сорый. Чөнки характер монда үзендәге һәм әйләнә-тирә аркылы аңар басым ясаган инерцияне җиңеп үтә, алдан билгеләп куелган «түгәрәктән», орбитадан ычкынып чыга. Шул рәвешле, драматург бер буын кешеләрен, бер үк иҗтимагый шартларда тәрбияләнгән, ләкин тормышка карата төрле нәтиҗәгә, төрле фикергә килгән кешеләрне үзара бәрелештерә. Бу — Х. Вахит өчен генә түгел, соңгы еллар драматургиясе өчен гомумән хас нәрсә.

«Соңгы хат» драмасының беренче пәрдәсендә уңай геройның хәрәкәте, эше яңача куела, тормышчан нигездә, ышандырырлык тасвирлана. Алга таба исә драмада аның сурәтләнеше традицион калыпка салына. Шул үк «явызларның явызы» — тискәре герой Дилбәр Галиевна, аның Нияз юлында корган киртәләре, соңгысының аларны бер-бер артлы җиңә баруы, егеткә үлеп гашыйк булган тагын бер чибәр кыз, анысының фидакарь тестә ярдәм итүе һ. б. Ш. Камал герое Габбас Галин кебек үк, Нияз да уңга-сулга һич карамыйча, яңа препарат уйлап табу өстендә эшли, соң чиктә үз теләгенә ирешә. Дөрес, драманың бу өлешендәге хәлләрнең дә тормышчан нигезе бар, ләкин алар тамашачыны асылда, күп дигәндә, мавыктыралар гына, уйландыру җәһәтеннән аз тәэсир итәләр, аларның үрнәк булу көче кими. Моның шулай булуына драмадагы үзәк вакыйгаларның каядыр сәхнә тышында баруы да ярдәм итсә кирәк. Аерым очракларда геройларның төп шөгыле эш-хәрәкәткә түгел, ә декларация ясауга юнәлтелгән.

Шулай да, кайбер җитешсезлекләренә дә карамастан, Х. Вахит драматургиясе тормыш максаты турында, хезмәттә, фәндә һәм мәхәббәттә ныклы фикердә һәм ал-

дыңгы караштa тору, килешмәүчән, кыю булу, инсафлылык һ. б. кебек җитди мәсьәләләрне, бүгенге көннең актуаль проблемаларын күтәрүе белән әһәмиятле. Ул бүгенге тамашачыны заман турында уйланырга этәрә, югарыдагы сорауларга җавап эзләргә мәҗбүр итә,— иң беренче, шуның белән хәзерге сәхнә әдәбиятында мәгълүм бер урын тота.

Уңай герой проблемасы ноктасыннан караганда, эзләнүләр героик-революцион һәм тарихи-революцион төрдәге пьесаларны да читләтеп үтми. Монда да вакыйгаларның һәм образларның тормышчанлыгын арттыру теләге белән яңалыкка омтылу, традицион рамкаларны киңәйтергә тырышу сизелә. Дөрес, күпчелек әсәрләрдә мәсьәлә традицион яссылыкта хәл ителә. Мәсәлән, С. Шәкүровның «Уракчы кыз», Ю. Әминовның «Умырзая чәчәкләре» кебек әһәмиятле әсәрләре шундыйлардан. Ләкин мәсьәләгә яңача килү омтылышы да киңәйгәннән-киңәя бара.

Бу җәһәттән ишекне беренче булып М. Әмир шакыды булса кирәк. Аның «Хөррият» героик драмасы үзенчәлекле. Иң әүвәл, әсәрдә проблема яңа. Монда Совет строе өчен барган көрәш елларында урын алган революцион аскетизмның шактый тулы һәм дөрес чагылган булуы хакында бер язылган иде инде («Көрәш һәм мәхәббәт». «Казан утлары» журналы. 1965 ел. 8 сан). Бу проблема әдәби яктан җентекләп һәм тулы эшләнгән, шактый зур идея йөге күтәргән Таһир образы аша бирелә. Таһирның көрәш юлы җитди вакыйгалар аркылы үтә, шулар эчендә егет үсә һәм ныгый. Шул ук вакытта аның тормыш юлында кулак кызы Бибисарага булган мәхәббәте зур гына роль уйный. Хәтта, кыю әйтергә мөмкин, хәлиткеч роль уйный. Чөнки шул мәхәббәте аркасында ул үлемнән котылып кала. Һәм иң әһәмиятлесе: бу мәхәббәт аңарга да, калган революционерларга да сыйнфый көрәш дип аталган искиткеч катлаулы мәсьәләне тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Геройга тормышның башта күренгәнчә алай бик гади генә булып чыкмавына инанырга туры килә: мәсьәләне дөрес хәл итүнең ансат булмавына, вакыты-вакыты белән күп газап чигәргә туры килүенә, кайвакыт әллә нинди зур батырлыкларның да ялгыш булып чыгуына, шәхси мәнфәгатьләрдән баш тартуның һәр очракта да чын каһарманлык билгесе булмавына ышанырга туры килә. Тормыш — гаять үзенчәлекле процесс, аны алдан билгеләнгән һәм инде тәмам үзләштердем дип уйлаган бер өлгегә генә сыйдырып булмый. Тормышта, бигрәк тә аның революция кебек әһәмиятле кичеш чорларында трафарет буенча гына эш итү мөмкин түгел. Әнә бит, ярлы гаиләдән чыккан, ягъни сыйнфый яктан иң ышанычлы кеше дип исәпләнгән Чамай иң түбән сыйфатларга ия икән, ә кулак кызы Бибисара исә, акылы белән аңлап, җаны-тәне белән бирелеп, революциягә хезмәт итә. Монда революциянең кеше рухына ясаган искиткеч чистарту тәэсире, шифалы йогынтысы беренче планга чыга. Шул рәвешчә, азатлык көрәше давылларында кешенең рухи үсү, чыныгу, яңару проблемасы әсәрдә берничә планда, моңарчы әле безнең драматургиябездә күрелмәгән рәвештә, яңача хәл ителә.

Героик драмадагы үзәк персонажны иҗат итүнең традицион рамкаларын баетуга омтылу «Шамил Усманов» әсәрендә дә ачык күренде. Бөек Октябрьның 50 еллык юбилеена багышлап куелган бу әсәрдә әдәбият һәм сәнгать өчен мәңге кирәкле һәм актуаль тема — революция темасы алына. Ул сәхнә чаралары ярдәмендә хәл итү өчен авыр, материалны яхшы белүне, политик белем байлыгы, зур осталык сорый. Революциядә төп көч — хезмәт иясе массасы, көрәшнең уңышлы тәмамлануы массалар белән җитәкчелек итүче партия эшчәнлегенә, аерым шәхесләрнең эшчәнлегенә бәйле. Димәк, мондый әсәрдә бөтен катлаулылыгы һәм җитдилеге белән масса һәм шәхес проблемасы алга килеп баса. «Шамил Усманов» драмасының авторлары — танылган прозаик һәм драматург А. Гыйләҗев белән әдәбиятчы А. Яхин гомумән бөтен әсәрнең һәм спектакльнең уңышы шушы проблеманың ни дәрәҗәдә дөрес һәм тулы хәл ителүенә бәйле булуын яхшы төшенеп эш иткәннәр. Моның шулай булуы прологта ук күренә. Авторлар аны нәкъ менә шушы проблемага басым ясау өчен керткәннәр дә, югыйсә аның ни дәрәҗәдә кирәк булу-булмавы хакында бәхәсләшергә туры килер иде. Монда пьесадагы төп фикернең асылына яктылык сирпегән әһәмиятле диалог бар. Яшь җитәкче Ш. Усманов турында халык арасында «үзенең абыйсын атып үтергән» дип бәет чыгарганнар (гәрчә бу очракта аның берниндн гаебе булмаса да). Шул турыда сөйләшкәндә, В. Куйбышев аңар болай ди: «Ә бәетне җитәкче иптәш турында да иҗат иткәннәр! Менә шулай... Массалар

белән җитәкчелек эшенә алынган кеше үзенең ничек яшәве турында тирән уйланырга тиеш. Бигрәк тә менә хәзер, кыен вакытларда, иптәш Усманов! Бер якта уянып килгән халык, икенче якта без, большевиклар. Масса һәм җитәкче мөнәсәбәтләре ифрат дәрәҗәдә җитди мәсьәлә. Ул гомергә шулай булып барачак!» Бу фикер әсәр буена дәвам итә. Соңыннан, мәсәлән, Шамилнең ялгышуы күрсәтелә. Һәм аңар массаның мөнәсәбәте сурәтләнә. Кызыл сугышчылар комиссарның ялгышуы өчен аны тәнкыйть итәләр, әмма үзен азатлык көрәшенә тулаем багышлаган кеше булуын дөрес аңлап, аңар ышаныч белдерәләр. Пьесада шәхси теләкләр һәм иҗтимагый мәнфәгатьләр арасындагы мөнәсәбәт проблема төсендә алына.

Спектакльне караганда күңелдә шундый бер теләк туа: беренче пәрдәдәге һәрбер добровольцны тотып, сабынлап-мунчалалап юасы килә, аның саф күңелен, революцион көрәшкә этәргән көчле рухын үзенә дә, бүтәннәргә дә ялтыратып күрсәтерлек итеп пычрактан арындырасы килә. Һәм тамашачы алдында бу шулай эшләнә дә. Кызыл сугышчылар массасы акрын-акрын пычрак катлавыннан арына бара. Әсәрдә шул шактый эзлекле сурәтләнә. Бу эштә Ш. Усмановның роле зур. Бер үк вакытта көрәш вакыйгалары, революцион масса белән эшләү аның үз психологиясен дә формалаштыра, чарлый, үстерә.

Бу пьесадагы төп образны тудырганда, авторлар 20 еллар эстетикасы дәрәҗәсендә торып эш иткәннәр, дигән тәнкыйть сүзләре дә булды. Моның белән һич тә килешәсе килми. Киресенчә, бу образда героик шәхеснең әдәби портретын бирүдә бүгенге эстетик карашлар югарылыгыннан торып эш итәргә тырышу бар. Ул ни дәрәҗәдә эзлекле һәм тулы эшләнгәндер, анысы икенче мәсьәлә! Авторлар героик драмадагы үзәк персонаж тибын иҗат итү өлкәсендә яшәп килгән әдәби штамплардан котылырга омтылганнар һәм мәгълүм бер күләмдә моңар ирешкәннәр дә. Ш. Усманов образында әдәби бәхәс — полемика элементы ачык чагыла. Һәм иң әһәмиятлесе — ул образның реаль, тормышчан нигезләреннән аерылмый. Драматурглар мондый герой турында бездә шактый нык тамырланган карашларны какшаталар. (Ә ул карашлар нигезендә андый герой психологик бербөтен характерлы, бар нәрсәнә революцион көрәшкә буйсындырган булырга тиеш дигән ышаныч ята.) Шуның белән героик характер тудырудагы яңа принциплар үстерелә.

Ш. Усманов үзен көрәшкә багышлаган кеше шәхси теләкләрен читкә атарга тиеш дип саный. Моны аның сөйгән кызы Зәкия белән сөйләшүеннән ачык аңларга мөмкин. «Сез бит сугышчы! — ди ул кызга.— Мин дә элегрәк бер кулыма кылыч, икенчесенә чәчәк тотып йөри алырмын дип уйлый идем. Булмый, Зәкия туташ! Менә сез аның якты мисалы! Кылычка да үреләсез, чәчәккә дә! Әгәр минем дүрт кулым булса, анда да дүрт кылыч тотар идем».

Чыннан да, бу яктан Шамил каты бәгырьле, һәр хәлдә, шундый булырга тырыша. Ләкин тормыш үзенекен итә: егет алдына кат-кат шул мәхәббәт мәсьәләсен, ягъни шәхси мәсьәләне куя. Усмановка, аны дөрес хәл итү өчен, күп вакытын һәм акыл көчен сарыф итәргә туры килә. Һәм катлаулы политик обстановкада, хәрби бәрелешләрдә югалып калмый торган Шамил мәхәббәт мәсьәләсендә тәҗрибәсезлек күрсәтә, еш ялгыша. Ул, үзе дә теләмәстән, бер кулына кылыч, ә икенчесе белән чәчәк тоткан җанлы, бай рухлы кеше булып күз алдына баса. Егет, йөрәге сызлануга түзә алмыйча, кызга: «Мин сезне Мәхмүткә тып-тыныч кына, сабыр гына тапшырды дип уйлыйсызмы? Монда сугыш гаепле! Минем кулларым буш түгел, Зәкия туташ!» — диярга мәҗбүр. Шулай итеп, гомумән геройның тулылануы килеп чыга, ул бай һәм үзенчәлекле характер булып алга баса. Дөрес, бу абстракт төстә түгел, ә тарихи яктан конкрет һәм перспективалы итеп бирелгән. Югыйсә шәхси һәм иҗтимагый моментларның үзара мөнәсәбәте турында урынсыз бәхәс туар иде.

Шулай да мондый геройны, алда әйтеп узганыбызча, ягъни 30 елларда ук формалашкан хәлендә, аңлау һәм күзаллау шактый көчле икән әле. Аны шушы ук драмада, аның сәхнәгә куелышында да күреп калдык. Драматурглар да, режиссер да Ш. Усмановны, мәсәлән, сәхнәгә күтелмәгәндә китереп чыгарырга яраталар. Геройны башкалардан югары итеп сурәтләү теләге спектакльдә хәтта шуңар китерде: Ш. Усманов гел өстә, каядыр югарыда йөри, беренче килеп чыгуында ук бүтәннәр кебек капка аша килеп керми, ә каяндыр өстән, әле аңарчы берәү дә күренмәгән мәйданчыктан, кем дә йөрмәгән баскычтан килеп төшә. Хәзер Ильяс күктән иңәмени!?

Әйе, уңай геройны кирәксез романтик

бизәкләрдән арындырырга, аны сурәтләүдә тышкы эффектлылыктан баш тартырга, үзенең эчке мәгънәсен җуйган, инде театраль штампка әверелгән традицион сыйфатлардан азат итәргә кирәк. Ләкин, шул ук вакытта, бу әле геройның гадәттән тыш булуын, аның алдынгы ролен юкка чыгарырга кирәк дигән сүз түгел. Киресенчә, уңай герой үрнәк булырлык һәм ышандырырлык сыйфатларга никадәр күбрәк ия булса, ул үзенең төп функциясен, билгеләмәсен шулкадәр тирәнрәк үтәячәк.

Бүгенге драматургиябезнең үсеш процессында Аяз Гыйләҗевнең иҗади тәҗрибәләре әһәмиятле һәм алар аерым игътибарга лаек. Драматург буларак, А. Гыйләҗев тирән психологик кичерешләрне сурәтләгән бай буяулар белән эш итәргә ярата. Бу аның беренче сәхнә әсәрләрендә үк күзгә ташланды. Һәм театр сәнгатенең серләрен үзләштерә барган саен, аңардагы бу үзенчәлек әһәмиятлерәк төс ала. Язучының тәүге пьесаларыннан булган «Җиз кыңгырау» драмасы үз вакытында күп сүзгә, хәтта бәхәсләргә очрады. Шулай да аның шактый үткен каләм белән язылган булуын берәү дә инкарь итә алмады. Характерлы бер нәрсә: әсәрнең уңай яклары турында сүз алып барганда, авторның Хәрмәтулла образын шактый тирән ачуы, җәмгыятебезгә ят карашта торган мондый кешеләрнең җыелма тибын бирүдәге уңышы беренче планга куеп каралды. Ә бит драмада төп тема — дөньяга карашын булдырган, үсеп барган кеше темасы иде. Ул Разия образы аша бирелә. Драматург героиняның эчке дөньясын ачарга, аның алга таба үсүенең эчке пружинасын күрсәтергә теләгән. Һәм аның бу теләге бөтенләй үк һавада асылынып калмаган, Разияның эчке кичерешләре тамашачы күңелендә дә чагылып, бу кызга карата теләктәшлек тудыра. Әмма аның ахыр чиктә, атасы Хәрмәтулла фәлсәфәсен кире кагып, искергән тәртипләргә каршы баш күтәрүе һәм яңалык ягына күчүе әсәрдә тулысынча ачылмый, тормыш логикасына туры китерү тәртибендәрәк эшләнә. Монда инде А. Гыйләҗев кулындагы көчле корал булган психологизмның аңардагы драматурглык осталыгына әле буйсынып бетмәве сәбәпче иде булса кирәк.

Психологик яктан чыннан да кызыклы, тирән эшләнгән, оста индивидуальләштерелгән образ — Хәрмәтуллага каршы аның кызы Разия өчен барган көрәштә, автор-ның фикере буенча, коллектив җиңеп чыгарга тиеш. Ә менә шул коллектив, аны тәшкил итүче аерым геройлар драмада тиешенчә эшләнеп бетмәгән. Мәүлә, Чәчкә, Бикбулат образлары статик хәлдә генә алына, аларның Разияга тәэсире отышлы булып күренми. Яисә, мәсәлән, Гәрәй образын алып карыйк. Романтик планда бирелгән, тынгысыз йөрәкле итеп сурәтләнгән бу егет колхоз тормышында үзенә урын таба алмыйча йөри. Ул каядыр омтыла, аның күңеле зур эшләр башкарырга ашкына, шул ашкыну аны авылдагы тормыштан канәгатьләнмәүгә, шәһәргә күчү теләгенә китерә. Драматург Гәрәй характерындагы бу сыйфатны баштагы ике пәрдәдә шактый ышандырырлык сурәтли башлый, бу яктан персонажның үзенчәлекле характерын тәгәл ача торган ситуацияләр дә тудыра. Гәрәйнең үз тормышын куркыныч астына куеп, машинасы белән язгы боз өстеннән елга аркылы чыгуы, шулай итеп колхозга кирәкле әйберләрне вакытында алып кайтуы аның холкына, аның кайнар йөрәгенә, тынмас җанына тапкыр килә. Ләкин соңгы пәрдәләрдә бу романтик образ сызыгы сыегая, тарая һәм трафарет буенча китә. Драматург персонажның төп билгеләмәсен, аны җанлы кеше итеп тотып торган сыйфатларны оныта, үстерми. Спектакль дәвамында бу егетнең авылда бөтенләйгә калуның кирәклеген тануы, үз урыны авылдашлары арасында икәнлеген аңлавы, күңеле әзли торган киң колачлы тормыш авылда да мөмкин икәнне күрүе өчен ниндидер хәлиткеч бер вакыйга булыр дип көтәсең. Гәрәйнең шундый ышанычка килүендә Разия язмышын тирән аңлау сәбәп булыр, техниканы колхозларга бирү кебек вакыйгалар аның киң колачлы эшләргә омтылган күңеленә хуш килер дип уйлыйсың. Үз чиратында, Гәрәйнең матур эзгә төшеп килгән тормыш сукмагын күрү Разия өчен гыйбрәт булырлык, атасының черек фәлсәфәсен кире кагу өчен ярдәм итәрдәй бер этәргеч булыр дип тә өметләнәсең. Берсе дә юк! Гәрәйнең колхозда төпләнеп калуында бары тик мәхәббәт кенә сәбәпче булып чыга: автор аны матур кыз белән кызыктыра. Шул рәвешчә, коллективның бер кисәген тәшкил иткән бербөтен образ тумаган, димәк, коллективны дөрес һәм тулы күзаллауга да зыян килә. Ахыр чиктә әйләнә-тирәсенең Разияга тәэсире дә бермә-бер кими.

(Алгарак узып, шуны әйтик. А. Гыйләҗев драматургиясендә бу мотив дәвам иттерелде. «Җиргә тапшырылган серләр»

драмасында, мәсәлән, Зәнәнең авылдан качарга омтылуы сурәтләнә. Ләкин монда автор аның бу теләген психологик яктан җитди нигезли (гаиләдәге асылда әтисе тарафыннан тудырылган әчпошыргыч бертөрлелек, күңелсез перспектива һ. б.), кызның баштагы хата карашларын аңлавын һәм бу мәсьәләдә дөрес юлга басуын да ышандырырлык тасвирлый.)

Беренче пәрдәдә Хөрмәтулла агайның шактый нык коелган кирпә-капкаларын үтеп, сәйгәне артыннан кыю рәвештә өйгә кергән, чын йөрәктән чыккан хаклык сүзләрен картның битенә бәреп әйтә алган Мәүлә бара-бара югала, схематик гашыйк һәм «дөрес» комсомолец образы гына кала. Коллективның кызга уңай тәэсире дә көчсезләнә. Билгеле булганча, коллектив ул җиндидер төссез һәм йөзсез бер масса түгел. Ул аерым шәхесләрдән тора. Ә ул шәхесләрнең һәммәсенең характерларына бәйле төстә уй-фикерләре, индивидуаль ихтыяҗлары һәм теләкләре була. Драматург аларны тулы канлы образлар итеп күз алдына бастыра алганда гына җанлы коллектив турында сүз булырга мөмкин. «Җиз кыңгырау» нәкъ менә шул нәрсәдән мәхрүм. Искелек һәм яңалык көрәшендә коллективның хәлиткеч роле бөтен тирәнлеге белән күренмәү аркасында пьесага яктылык җитми.

Моннан соңгы драмаларында персонажларны сурәтләгәндә А. Гыйләҗевнең психологик буяуларны торган саен остарак сала баруы, аларны, ягъни бу буяуларны, булганда тәҗрибәсе арта баруы күренә. Ул хәзер дистәгә якын пьеса авторы. Аның бигрәк тә «Киек каз юлы», «Көзге ачы җилләрдә», «Җиргә тапшырылган серләр» әсәрләре психологик яктан җентекләп һәм тәгәл эшләнгән образлары белән аерылып торалар.

Дени Дидроның драма геройларына карата әйткән шундый сүзләре бар: «Минем беренче фикерем шуңар кайтып кала: пьеса геройларын алдан уйлап акыллы итәргә кирәкми, ә аларны акыллы булуларын күрсәтергә тиешле шартларга куя белергә кирәк». (Сайланма хезмәтләр. Рус телендә. 1936 ел. V том. 107 бит.)

«Җиргә тапшырылган серләр» драмасындагы Кәрим Хәернасов образы белән танышканда әнә шул сүзләр искә төшә. Шактый киң таралган «акыллы» геройдан — китапларга язылган хакыйкатьне, дөрес сүзләрне уңлы да, суллы да «сиптереп» йөрүче персонажлардан үзгә буларак, бу герой үзенең акылын, киң күңелен, эшчәнлеген конкрет ситуациядә күрсәтә: 10 классны үз авылларында укып тәмамлау мөмкинлегеннән мәхрүм булу алдында торган дүрт укучыга ярдәм итү чарасын эзләп таба һәм шуны тормышка ашыру өчен көрәшә. Дөрес, Кәрим Хәернасов алда әйтелгән «акыллы» геройны шактый нык искә төшерә әле. Чөнки күп кенә очракларда ул да үзенең акылы белән генә акыллы булып күренә, ә эш-хәрәкәте белән түгел. Шулай да ул андый геройларга караганда күп бай, күп тормышчан. Аңарда ышандыру көче бар. Аның дүртесе дүрт холыклы яшьләрне үзенә каратып, үз артыннан ияртә алуы, аларда мөстәкыйль тормыш юлына керү өчен иң кирәкле булган сыйфатларны табып, үстереп җибәрә алуы пьесада ышандырырлык төстә тасвирлана. Автор тәгәл психологик буяулар ярдәмендә Илшат, Зәнә, Рәдиф һәм Шәрифҗанның рухи халәтләрен, аларның һәрберсенең эчке дөньясын, формалашу юлын күрсәтә. Беренче карашка әһәмияте артык зур да булмаган кендәлек вакыйгаларда аларның рухи ныгып, үсә баруларын сурәтли. Кәрим образы белән, геройның ваемсызлыкка, миһербансызлыкка каршы көрәшен тасвирлау аркылы «кеше — кеше өчен» дигән бөек гуманизм идеясе пропагандалана. һәм ул образның драматизмы аркылы үтемле төстә бирелә. Ә образның драматизмы түбәндәгедән гыйбарәт. Кәрим Хәернасов — сәламәтләнә алмаслык авыру кеше: аның шундый хәлдә була торып та, һәр нәрсәне үз күңеленә якын итеп йөрүе, җәмәгать эшен беренче планга куеп каравы герой характерының эчке пружинасын билгели. Дөрес, бу хәл соңыннан гына беленә. Шулай да тамашачы, аның авыру була торып та үзе турында уйламыйча, башкалар өчен янып-көеп йөрүен, шундый зур (алар авылы өчен зур) вакыйгаларны әйдәп баруын аңлап алгач, сәхнәдә булып узганнарга яңадан әйләнеп карый, геройга бәя бирә, аның олылыгын тагын да ачыграк төстә күзаллый.

Әйе, А. Гыйләҗевнең эзләнүләре торган саен җитдирәк төс ала. Тагын да уңышлырак сәхнә әсәрләре иҗат итү өчен аңар ул эзләнүләрне кыю төстә дәвам иттерергә кирәк. Шушы ук «Җиргә тапшырылган серләр» әсәрендә тормыш үзенчәлекләрен үзенә генә хас төстә күрә алуы белән бергә автор әдәби штампны хәтерләткән детальләргә һәм моментларга да урын биргән. Мәсәлән, Марат Кәримович образы,

аның «үсеш процессы» (әгәр дә бу персонажның соңыннан кинәт кенә «яхшылана» башлавын шулай дип әйтергә ярасә?!) драматургиябез өчен яңа түгел инде, ул күп кенә яклары белән безгә таныш образ. Шулай ук сәхнә әсәрләренең җитдилеге, зур актуаль проблемаларны күтәргән булуы өчен тырышкан хәлдә, алардагы хәрәкәт тыгызлыгына, аларның карау өчен кызыклы булуына, дулкынландыргыч, хәтта, кирәк икән, тетрәткеч булуына да күбрәк игътибар итәлергә тиеш. Хәзергә А. Гыйләҗев пьесаларына нәкъ менә шулар җитми.

Бүгенге уңай герой һәм аның характер үзенчәлекләре турындагы фикерләрне йомгаклау төсендә шуны әйтергә мөмкин. Безнең заманның, димәк, бүгенге драматургиянең дә герое — кул астында һәр очрак өчен әзер рецептлар тотучы кеше түгел. Яңалык өчен, коммунизм өчен актив көрәшүче, катлаулы шартларда, үз тынычлыгына һәм иминлегенә зыян китереп булса да, әйләнә-тирәдәгеләр белән каршылыкка керүче, дөрес юллар эзләүче кеше булыр ул. Аның эчке мәгънәсен героик башлангыч билгеләр. Ләкин ул башлангычны тирәннән, еш кына гадидән — гадәти көндәлектән, гади кешеләрдән эзләргә кирәк. Хәзерге драмада үрнәк персонажның бик мәһабәт булуы, бай һәм катлаулы тормыш юлын узуы мәҗбүри түгел. Ул әле авызында сөте дә кипмәгән кыз яки егет заты булырга мөмкин. Урыны белән ялгышырга да, инде кабул ителгән әхлак нормаларын аңламыйча, аларга каршы чыгарга да мөмкин. Төп хикмәт — аның чынбарлыкка мөнәсәбәтендә, үзенең вазифаларын аңлауда һәм аларны тормышка ашыруда нык булуында, үз-үзен тотуының тормышчан нигезләрендә.

Хәзерге драмада геройның чикләнмәгән хокуклары һәм мөмкинлекләре бар. Аның иң мөһим вазифасы шул: ул чын иҗатчы, гаять актив һәм коммунистларча принципиаль кеше булырга тиеш. Эштә дә, өйдә дә, көндәлек тормышта да, хезмәттә дә ул шәхси тормышын — аның алдында югары максат торса гына, халыкның уртак көрәшенә үзенең бөтен көчен сарыф итсә һәм күңелен сала алса гына — мәгънәле дип санарга хаклы. Һәм бу турыда тамашачы авторның махсус белдерүеннән дә, башка персонажлар авызыннан да ишетергә тиеш түгел. Геройның үзендәге алдынгы сыйфатларны чагылдыруы, сәхнәдә тормышчан мәсьәләләрне хәл иткәндә, нык киртәләрне җиңгәндә үзен күрсәтүе мәҗбүри.

Актуаль һәм тормышчан конфликтларга нигезләнгән сәхнә әсәрләрендә генә шундый геройлар үзләренең характер үзенчәлекләрен тулы ача алалар, ышандыру көченә ия булалар. Иҗатта шул хакыйкатьне тирән төшенеп эш иткәндә генә зур уңышларга ирешергә мөмкин.

Гази Кашшаф

# АНЫҢ ИДЕЯЛӘРЕ БЕЛӘН РУХЛАНЫП

1924 елның январендагы кайгылы көннәрдә Һади Такташ «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын язды. Гаять якты һәм олы талантка ия булган шагыйрь гадәттән тыш кайгылы кичерешләр эчендә, татар поэзиясендә беренче буларак, Ленин идеяләренең бөеклеген, кешелеккә җан җылысы бирүче бу акыл иясенең гадилеген, тормышчанлыгын зиһене һәм хисләре аша үткәрде. Дөнья пролетариатының юлбашчысы булган илаһи шәхеснең асылын Такташ: «Аны гасырлар тудырды», дип билгеләде.

Бу сүзләргә тирән мәгънә салынган. Әйе, Ленинны гасырлар тудырды һәм аның Идел буенда тууы да очраклы хәл түгел. Халыклар элек-электән Иделгә якынрак елышырга тырышканнар: берәүләре аңа, ана итеп, бәхет һәм җылы куыш табарга теләп сыенган, икенчеләре исә таларга һәм хакимлек итәргә омтылып килгән. Куәтле һәм бөек елга җәлладларның «кургашын зәһәрлегенә» дә, Разин һәм Пугачевның гадел ярсуларына да шаһит булган. Ярларыннан ачы күз яшьләре һәм тозлы тир тамып торган Иделдә хәсрәтле бурлаклар һәм кыю егетләр, тал чыбыктай сылу буйлы кызлар һәм язмышларына кол булып яшәгән бәхетсез бәндәләрнең исәпсез-хисапсыз җырлары туган.

Халыкның шушы нәфрәтенең стихияле көчен тиешле якка юнәлтүче, массаларны яктыга һәм бәхеткә алып чыгарлык бердәнбер юлны күрсәтүче кеше мондый авыр шартларда бик кирәк иде. Һәм, ниһаять, ул кеше туды. Ленинны гасырлар тудырды!

Яшь Ульяновның беренче революцион адымнарын сурәтләгән китаплар һәм брошюралар шактый.

Ильичның революцион эшчәнлеге башлану борынгы, узган гасырның 80 нче елларында Н. Е. Федосеевның беренче марксистик түгәрәкләре оешкан изге Казанда була. Ул түгәрәкләрнең берсенә Володя Ульянов та йөри.

Яшь Ильичның юридик факультетта укуы һәм беренче революцион чыныгуны да Казан университетында алуы шулай ук бөтен дөньяга билгеле. 1887 елның декабрендә, студентларның тарихи сходкасыннан соң, Владимир Ильич, кулга алынып, Кокушкино (хәзерге Ленино-Кокушкино) авылына сөргенгә җибәрелә.

Кокушкиноның Апакай исемле татар авылы белән орынып торган күрше булуы игътибарга лаеклы. Унҗиде яшьлек Ильич беренче сөргенен уздырган йорт ике авыл арасына салынган. Ул рус авылы белән татар авылын символик төстә берләштереп тора сыман. Кокушкино кешеләре дә, Апакайныкылар да, Сибгат Хәкимнең «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» шигырендә әйтелгәнчә, Ильичны үзләренең авылдашлары дип санаганнар:

Аңа син дисәң дә хакың бар,
Киткән ул монда бер кыш торып...
Элекке авылдаш икәнен
Яздылар арага кыстырып.

Хәзер безнең бөек якташыбыз идеяләренең яктылыгы җир шарының бөтен почмакларына да үтеп керә һәм ул колониализм коллыгыннан котылырга, азат һәм бәхетле булырга юл күрсәтә.

Татар халкының азатлыкка чыгу юлы озын һәм кыен булды. Патша самодержавиесе һәм дини фанатиклар белән бәйләнештәге милли буржуазия җәбере астында җәфа чиккән татар хезмәт ияләренең хәле аеруча аяныч иде.

Царизмның шәфкатьсезлегенә, кансызлыгына мисал итеп профессор Р. И. Нафиковның «Татарларда алдынгы иҗтимагый-политик фикернең формалашуы һәм үсүе» исемле китабыннан бер генә документны китерәм. Милли культураның үсүенә шартлар тудырган татар мәктәпләренең ишәя һәм көчәя баруын күреп котырынган Казан губернаторы 1910 елда Эчке эшләр министрлыгына болай дип яза: «Россиядә татар, бигрәк тә мөселман мәдәнияты юк һәм ул бу сүзнең асыл мәгънәсендә булырга да тиеш түгел, моны рус хөкүмәте ачыктан-ачык әйтергә тиеш»[1].

1970 ел безнең өчен ике зур юбилей елы: юлбашчыбызның йөз еллыгы Татарстанның илле еллыгына туры килә. 1920 елда Ленинның үз кулыннан дәүләт булу хокукын алган Татарстан бөек рус халкы һәм барлык тугандаш халыкларның ярдәме белән искиткеч уңышларга иреште. Илле ел эчендә ул куәтле промышленносте, бүгенге заманның иң яңа техникасы белән коралланган күп тармаклы авыл хуҗалыгы булган республикага әверелде. Әгәр күптән түгел генә шагыйрьләр һәм язучылар аны дүрт елга республикасы дип мактап җырласалар, сугыштан соңгы чорда ул биш елга республикасына әйләнде. «Дуслык» дип аталган бу бишенче елганың көчле агымы, республикабызның көнчыгышында башланып, Советлар Союзының бөтен Европа өлешен кисеп үтә. Дусларыбызны югары сыйфатлы нефть белән тәэмин итү өчен, Польша, ГДР, Чехословакия һәм Венгриягә тармакланып керә.

Промышленность булган җирдә шәһәр барлыкка килә, шәһәр булган җирдә культура үсә. Татарстан туфрагындагы тирән социалистик үзгәрешләр фәннең һәм культураның төрле тармакларында эшләргә сәләтле тирән белемле кадрларны мәйданга чыгарды. Шулай итеп, революциягә кадәр хыялда гына булган музыка мәктәпләре һәм консерватория, сынлы сәнгать һәм скульптураның үсүе табигый күренешкә әверелде. Ә инде элек бай традицияләре булган әдәбият һәм театр сәнгате яңадан-яңа үрләр яулыйлар.

Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ф. Кәрим, К. Нәҗми, Г. Кутуй, Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Х. Туфан, С. Хәким һәм башка язучыларның әсәрләрен Советлар Союзында гына түгел, бәлки чит илләрдә дә яратып укыйлар. Димәк, татар әдәбияты, башка тугандаш халыкларның әдәбиятлары кебек үк, күптән инде дөнья аренасына чыкты.

Сугыштан соңгы елларда легендар герой, шагыйрь һәм көрәшче Муса Җәлил иҗаты аеруча популярлык казанды. Ленин һәм коммунистлар партиясе социализм эшенә, интернационализм принципларына чиксез бирелгән, азатлык һәм халыкларның үзара тигезлеге интересларын җаны-тәне белән яклаучы яңа тип язучы тәрбияләп үстерде.

Бер әдәбият кына түгел, Октябрь кояшы астында туып үскән милли опера һәм балет сәнгатебез дә Советлар Союзының чикләрен үтеп чыкты. 1967 елны Монреальдагы Бөтендөнья күргәзмәсенә казакъ язучысы Мохтар Әүэзовның Татарстанның халык художнигы Б. Урманче ясаган портреты куелган иде. Бу факт шул ягы белән кызыклы — ислам дине кеше сурәте ясауны катгый тыеп килде һәм революциягә кадәр художникның таланты шәригать басымы астында һәлакәткә дучар ителгән иде. Хәзер художниклардан Х. Якупов, Л. Фәттахов, Б. Урманче һәм башкаларның әсәрләре республикабыздан еракта яшәүчеләргә дә таныш.

---

[1] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Казань. Рус телендә. 1964 ел. 38 бит.

Совет власте елларында Ленин партиясе күп нәрсәгә безнең күзебезне ачты. Без тарихыбызны яңабаштан яңача караш белән укырга өйрәндек яки өйрәнү юлында торабыз, узган заманнардан калган мирасның культура хәзинәләрен марксистик-ленинчыл караштан чыгып бәяли башладык, гасырлар буе язылып, җыелып килгән кулъязмалар һәм әдәби истәлекләрне өр-яңадан күздән кичереп киләбез. Марксизм-ленинизм тәгълиматы безне бүгенге вакыйгаларга һәм иртәгесе көнгә аек күз белән карарга өйрәтте. Безнең карашыбыз, офыгыбыз киңәеп киткәнен әйтеп тору да кирәкмәстер. Без киң масштабта фикер йөртергә, дөньяга, үз илебезнең хуҗасы, димәк, үз җиребез, үз ватаныбыз, социалистик культурабызның хуҗасы буларак, горурлык һәм кайгыртучанлык белән карарга өйрәндек.

Гадәттә әдәби тәнкыйтьнең артта калуы турында сөйләргә яраталар. Әйе, ул чыннан да артта калып килә. Ул хәтта басылып чыккан китапларга рецензия язарга да өлгерә алмый. Шулай да әдәби тәнкыйть, әдәбият һәм тел белеме сыйфат ягыннан шулкадәр үсте, алар хакында берничә авыз гына булса да җылы сүз әйтеп китмичә булмый. Әдәбиятның партиялелеге һәм халыкчанлыгы, чагылыш теориясе турында Ленин тәгълиматын, рус галимнәре һәм язучыларының эчкерсез ярдәме аркасында безнең тәнкыйтьчеләр марксистик-ленинчыл методологияне торган саен тирәнрәк үзләштерә баралар. Татар әдәбиятының тарихы, иҗтимагый фикере, тел гыйлеме һәм культура үсеше өлкәсендә Г. Халит, Х. Госман, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Х. Хәйри, Р. Нәфиков, М. Зәкиев, Д. Тумашева һәм башкаларның җитди хезмәтләре чыкты. Аларның күбесе русча да басылдылар, бу исә Бөтенсоюз күләмендә танылу дигән сүз. Әдәби тәнкыйтебез, элеккеге чорларга хас информация генә бирү, иллюстрацияләү, тупас социологизм белән мавыгу, эчтәлекне генә сөйләү һәм башка шундый җитешсезлекләрдән арынып, әдәби процессларны, иҗат методын, халыкчанлык, заман һәм герой, социалистик реализм проблемаларын тирәнтен өйрәнү юнәлеше белән бара.

Республикабызның 50 еллыгын без әнә шундый зур казанышлар белән каршылыйбыз. Бик авыр елларыбыз да булды безнең. Бүгенге якты таңга без гаять зур кыенлыклар аша килдек. Сугыш елларын гына хәтергә төшерик... Авырлыкны барыбыз да күрде, әдәби хәрәкәттә актив катнашырга тиешле кешеләргә аны тагын да ныграк татырга туры килде. Мин А. Фадеевны — күп милләтле әдәбиятыбызның Горькийдан соң иң зур эшлеклеләреннән берсен телгә алмакчы булам. Ул милли республикалардагы һәрбер язучыны иҗаты буенча белә иде. Язучылар оешмаларының, шул исәптән безнең дә, нәрсәгә мохтаҗлыгыбызны белеп тора иде. Менә бервакыт, 1943 елның октябрендә, ул безне Татарстан язучылар союзының отчеты белән президиум утырышына чакырды. Барлык язучылар мобилизацияләнгән яки үз теләкләре белән фронтка китеп беткәннәр. Ә без, кәгазьгә зур мохтаҗлыкка да карамастан, үзебезнең калын журналыбыз «Совет әдәбияты»н чыгаруны дәвам итәбез. (Сүз уңаеннан журналның сугыш вакыты булуга да карамастан, туктаусыз чыгып торуын искәртеп үтәсе килә...)

Күрәсең, Александр Александрович президиум карары белән генә хәлнең үзгәрмәячәген аңлагандыр, ул безне партия Үзәк Комитетына алып китте. Фадеевның үз сүзен ышанып сөйләве тәэсир итте: Үзәк Комитет безгә үз резервыннан журналның тиражын өч тапкыр арттырырлык кәгазь җибәрде. Бу чыннан да партиянең гаять зур ярдәме һәм Фадеевның акыллы һәм туганнарча хәлгә керүе, эчкерсез кул бирүе иде!

Көнчыгыштагы башка халыкларныкына караганда безнең культурага Ленин һәм рус революциясенең уңай тәэсире элегрәк булды диясем килә. Бу табигый, чөнки географик якынлык һәм тарихи шартлар нәкъ менә шуңа ярдәм иттеләр. Кешеләрдә иң изге уй-тойгыларны уяткан, хакыйкать һәм хөрлек каһарманы бөек Тукай үз халкының күңеленә гражданлык бурычларын җырлаган әсәрләре белән сеңеп калды. Ләкин бу бөеклек үзеннән-үзе генә килмәде. Ул наданлык, коллык һәм хокуксызлыкның кара пәрдәсен бер селтәнүдә юк итәрлек, табигатьтән өстен адәм заты түгел иде. Ул, әлбәттә, бөек кеше иде, тик аның даһи таланты чәчәк атуга китергән сәбәпне — шагыйрьнең революция давыллары эчендә, социал-демократлар хәрәкәте белән элемтәдә булуыннан эзләргә кирәк. Тукайның таланты чәчәк атуга большевиклар партиясе ярдәм итте. Шагыйрь партиядә член булып тормаса да, ул РСДРП ның Казан

комитеты члены Хөсәен Ямашевның иң якын дусты иде. Шуңа күрә Тукайның 1905 елга багышлап «Аң» шигырен язуы һич тә очраклы түгел.

> **Без Бишенче елны бер көнне уяндык таң белән,**
> **Эшкә дәгъвәт итте безне кемдер изге нам белән,—**

дип, иҗтимагый һәм милли азатлык өчен күтәрелгән революцияне тәбрик итте.

1907 елда яманаты чыккан Пурешкевич Дәүләт думасы трибунасыннан торып татарларны Төркиягә күчерергә тәкъдим кертте. Моңа каршы иң тулы һәм аек җавапны да Тукай авызыннан ишетергә туры килде. «Китмибез!» — диде ул кыю рәвештә. Аның горур сүзе пурешкевичларга янау булып яңгырады.

> **Иң бөек максат безем:— хөр мәмләкәт, хөр Русия!**

Киң масштаблы, перспективалы фикер йөртүнең, бөек идеяләр — бөтен Ватан азатлыгы, барлык изелгәннәр азатлыгы һәм бәхете турында хыяллар белән яшәүнең нәкъ үзе түгелме соң бу! Тукай биргән бу җавапның бөтен революцион-демократик татар әдәбиятының лозунгысына әверелүе дә һич очраклы хәл түгел. Владимир Ильичның Тукай иҗатын, аның фаҗигале язмышын белүен хәтергә төшереп үтәсе килә. Партиянең X съезды барган көннәрдә, 1921 елда, В. И. Ленин съездга килгән Татарстан делегатларын кабул итә. Юлбашчы Тукайны лаеклы дәвам итүчеләр турында аеруча игътибар белән сораштыра.

— Сүз уңаеннан әйтегез әле, сездә татар әдәбияты белән эшләр ничек тора... Тукаевны лаеклы дәвам итүчеләр бармы соң?

Аңа республика газетасының редакторы В. М. Бахметьев җавап бирә. Аның җавабы белән канәгатьләнеп Ильич болай ди:

— Димәк, дары савыты буш түгел!

Шунысы кызыклы, Ильич шагыйрьнең эшен гомумән дәвам итүчеләр турында түгел, бәлки л а е к л ы  д ә в а м  и т ү ч е л ә р турында сораштыра. Без монда юлбашчының халкыбызның бөек шагыйренә югары бәя бирүен күрәбез.

«Интернационалист социал-демократ булу өчен үз милләтең турында гына уйларга түгел, бәлки барлык милләтләрнең интересларын, гомуми азатлыгын һәм тигез хокуклылыгын үз милләтеңнән өстен куярга кирәк»,— дип язды В. И. Ленин 1916 елда «Үзбилгеләнү турында дискуссия йомгаклары» дигән мәкаләсендә (22 том, 367 бит). В. И. Ленинның бу сүзләре турында мин еш уйланам. Бу бит барлык халыклар, барлык культура эшлеклеләре өчен программа. Мин артка борылып, Х. Ямашев, Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Коләхметов, М. Вахитов, Г. Ибраһимов кебек әдәбиятыбыз һәм культурабыз корифейларының практик эшчәнлекләренә горурланып карыйм.

1907 елның 4 январеннан шул елның апреленә кадәр чыгып килгән татар телендәге беренче большевистик «Урал»ның эшенә тукталып тора алмыйм. Ул Үзәк Комитетның күрсәтмәсе һәм берничә, шул исәптән Урал, Уфа комитетларының карары буенча чыгарылган. Газетаның җаны, ленинчыл «Вперед» язганча,— «милләтчелекнең әсәре дә булмаган» ортодоксаль марксист Хөсәен Ямашев була. Шунысын да әйтергә кирәк, «Урал», Россиядәге төрки халыкларның барысы арасында да диярлек таралганлыктан, газетаның чиксез зур әһәмияте татар халкы белән генә чикләнмәде.

1905 елгы революциядән соң татар халкы арасындагы революцион-азатлык хәрәкәтендә «эшчеләр сыйныфының көрәше йогынтысында социаль юнәлеш нык сизелә башлады. Демократик мәгърифәтчелек революцион демократизмга күтәрелде». (Нәфиков, 100 бит). Марксистик-ленинчыл идеяләрнең киң таралуы бөтен татар культурасының сыйфат ягыннан үзгәрүенә көчле этәреш бирде. Киң халык массалары иҗтимагый-политик мәсьәләләрне аңлауда шулай ук яңа биеклеккә күтәрелделәр.

1906 елның азагында татар профессиональ театры туды. Аның бишегә янында Г. Камал, Г. Коләхметов, Ф. Әмирхан, актерлардан Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская кебек социал-демократлар белән тыгыз бәйләнештә булган кешеләр торды. Әгәр драматург Г. Коләхметов 1905 елгы революциядә турыдан-туры катнашучы, ленинчыл «Искра»ны аның берничә санн нарыннан ук эшчеләр арасында пропагандалаучы булса, татар драматургиясенең атасы Г. Камал, партиясез булуына карамастан, патша цензурасы биргән квалификациягә карагaнда, «социал-демократик газета чыгаручы иде. Аның «Азат», «Азат халык» газеталарында тәп журналистлар чыгыш

да социал-демократлар иде һәм алар газеталарны үз максатларында нык файдаландылар. Г. Камал 1906 елда Ленин партиясенең беренче программасын тулысынча басып чыгарды. һәм марксизм-ленинизм идеяләрен пропагандалаучы күп кенә башка мәкаләләрне урнаштырды. Минемчә, бу тирән ихтирамга лаеклы факт.

Яңадан театрга күчәм. Татар профессиональ театр сәнгате беренче адымнарыннан ук тар милли рамкалардан чыга башлады. Ул үзенең тамашачыларын татар драматургиясендә генә түгел, бәлки барыннан да бигрәк рус драматургиясендә тәрбияләргә тырышты: Островский, Гоголь, Сухово-Кобылин, Горький, Чехов әсәрләрен татар тамашачылары яратып карадылар. Театрда революцион-демократик тенденция барлыкка килде һәм үсеп китте. Авторлар саны ишәйде, сәхнәгә Шекспир, Шиллер, Байроннар менде.

Татар театры сәхнәсенә профессиональ-революционер эшче образы күтәрелде, анда сыйнфый көрәш идеясе яңгырады. Театр татарлар һәм башкортлар өчен генә түгел, бәлки Урта Азия һәм Казагыстан тамашачылары өчен дә аңлаешлы, үз иде. Казакълар һәм үзбәкләр, әзербайҗаннар һәм Кавказдагы тау халыклары театрны сагындырып килгән кунак, мәдәният нуры буларак кабул иттеләр.

Татар халкының демократик культурасы үскән саен башка халыклар белән культура бәйләнешы үсә, җәелә барды. Татар халкының культурасы, дистәләрчә, йөзләрчә инешләрнең һәм елгаларның суын үзенә җыйган диңгез сыман, башка халыкларның культура казанышлары белән баеп килде. Офыклар киңәя төште, төсләр мулрак һәм күп төрлерәк була барды, тел культурасы үсте, зәвык тагын да камилләште һәм аның фальшка, ясалмалылыкка сизгерлеге артты.

Профессор Р. И. Нәфиков үзенең «Татарларда алдынгы иҗтимагый-политик фикернең формалашуы һәм үсеше» исемле гаять кызыклы монографиясендә татар әдәбиятының 1905—1917 елларда үзенчәлекле үсүен әйтә. Ул рус әдәбияты тәэсирендә реакция елларында да үзенең демократик тенденциясен саклап кала алды. «Реакция елларында, рус булмаган тугандаш халыкларның телләрендә яңгырап, рус әдәбияты икенче кат туып кичерде»,— дип яза Нәфиков (356 бит.)

Татар телендә Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Крылов, Кольцов, Плещеев һәм башкаларның әсәрләре яңгырады. Үз чиратында рус әдәбияты аша Көнбатыш Европа классикасының куәтле дулкыны бәреп керде. Шекспирның кырыс реализмы, Байрон һәм Шиллерның романтикасы, Нәвои, Низами, Гомәр Хәйям, Сәгъди, Хафиз, Рудаки һәм башкалар йөзендә Көнчыгыш поэзиясенең килүе әнә шул хакта сөйли. Шушы уңайдан 1914 елның 2 октябрендә Ф. Әмирханның «Кояш» газетасында басылган бер мәкаләсен искә төшереп үтәм. Мәкалә «Олуг милләтнең олуг шагыйре» дип атала. Бу кеше — милләт бер бөтен дип распаучыларга, изелүчеләр һәм изүчеләр арасында коточкыч аерымлыкны танымаучыларга (мин бирелә 1908 елда «Әл-Ислах» газетасында басылып чыккан «Авырулар галәмендә» исемле публицистик уйлануларны күздә тотам) каршы баш күтәргән Әмирханның үзе. Бу кеше — татар матур әдәбиятында беренче буларак, Маркс һәм аның тәгълиматын кыю төстә телгә алган Әмирхан. Заманында ул кеше большевикларның Дәүләт думасындагы тактикасы турында хаклыкны язды. Меньшевикларның лидеры Плехановның капма-каршысы буларак, большевикларның тактикасы давыллы революция көннәрендә ничек булса, шулай элеккечә калды. Хәзер дә ул җеп калынлыгы да уңга борылмады (1907 елның 10 октябре), дип язды. Бу кеше «Культураны европалаштыруны яклап!» (прогрессив рус культурасын яклап дип укыйк), «хәкыйкый европеец» булуны яклап оран салган, рус әдәбиятына, бигрәк тә Тургеневка, Толстойга, Горькийга һәм башкаларга гашыйк Әмирхан иде. Югарыда телгә алынган мәкаләсендә ул Лермонтов турында аеруча рухланып язды, рус телен белүчеләр Лермонтовның «махсус гүзәллеге вә кәфәсәтенә даир язган шигырьләрен» искиткеч ярату белән укыйлар, диде.

Шуның өстәвенә Әмирхан Лермонтовның «шигырьләре шәрыкның бу матурлыгын бөтен руслар күңеленә якынайткан, бөтен яшь күңелләрдә шәрыкның шул гүзәллеге алдында ихтирам тудыргандыр...» дип раслый.

Социал-демократлар хәрәкәте, партия матбугаты татар язучыларын үз халкының, шулай ук тугандаш халыкларның рухи мирасына сак карарга өйрәтте. Бер-беренә ярдәм итү, әлбәттә, очраклы күренеш түгел иде. Мондый гүзәл сәхифәләрне татар театры тарихыннан шактый табарга мөмкин. Мәсәлән, «Сәйяр» труппасы Кавказда

гастрольдә йөргәндә, бөек әзербәйҗан актеры Хәсән Араблинский труппасы белән бергәләп чыгыш ясый. Ә Урта Азиядә йөргәндә шулай ук җирле интеллигенция вәкилләре белән тыгыз элемтәгә керә.

Татар милләтчеләре казакъ әдәбиятының мөстәкыйльлеген инкарь итәргә тырышкан бер вакытта Г. Ибраһимов аларга кискен төстә каршы чыкты. «Казакъ әдәбияты бар һәм ул үсәчәк!» — диде ул. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк. «Казакъ кызы» романында Г. Ибраһимов тарафыннан Абай Кунанбаев иҗатына бирелгән бәя заман сынавын уңышлы үтте. М. Гафури, Һ. Такташ, Ш. Усманов, С. Кудаш, К. Нәҗми, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Х. Туфан һәм башкаларның да казакъ, гомумән, Урта Азия халыкларына карата тирән ихтирам хисләре турында күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Минем Тукай белән әзербәйҗан сатиригы Сабир арасындагы матур иҗади дуслыкны искә төшереп үтәсем килә. Сабирның «Молла Насретдин» журналы Тукай сатирасының күпьяклы булып үсүенә уңай йогынты ясады. Безнең тарихчылар Идел буе, Кавказ, Урта Азия халыклары арасындагы бу үзара тәэсир итешүнең большевистик һәм революцион-демократик матбугат аша булуын исбатлыйлар.

Гражданнар сугышы чорында безнең язучыларыбызның бергәләп эшләүләре турында гаять кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, Беренче Армия политотделы газетасы «Кызыл йолдыз» 1918 елда Сызраньда чыга башлый. Бу Кызыл Армиянең сугышасугыша Көнчыгышка таба барган чагы була. Редакция эшкә җирле халыкларның вәкилләрен тарта. Башкортстанда чакта газетада Ш. Ходайбердин һәм Д. Юлтый эшлиләр. Оренбургта исә газета битләрендә «Кечкенә Җәлил»нең беренче шигырьләре басыла. Казагыстанны азат иткәндә исә газета казакъ, алга таба үзбәк, кыргыз телләрендә чыга һәм, ниһаять, газета үзенең юлын Төркмәнстанда, тәҗрибәсен төркмән иптәшләргә тапшырып, тәмамлый. Бу халыклар арасындагы дуслыкның якты сәхифәсе түгелме соң?! Хәзер безнең республикабызның нәшрияты эшендә тәрҗемәчеләр зур урын алып тора. Без, Көнбатыш Европа телләреннән булмасын, илебез халыклары телләреннән булмасын, басылып чыга торган әсәрләрнең бөтенесен дә оригиналдан тәрҗемә итәргә тырышабыз. Моның шулай ук ерактан килә торган традициясе бар. (Кечкенә генә искәрмә: Рабиндранат Тагор Россиядә беренче тапкыр революциягә кадәр татарча «Шура» журналында басыла).

Безнең лениннанабызның үзенә генә хас сәхифәләре бар.

Ленин татар халкының изелүен һәм хокуксызлыгын үз күзләре белән күрде. Һәм революциядән соң аның кадрларын аерата кайгыртучанлык белән тәрбияләп үстерде. Ленин белән очрашу һәм сөйләшү бәхетенә ирешкән күп санлы татарлар арасыннан мин ике кешене генә атап әйтмәкче булам. Аларның берсе революционер М. Вахитов 1917 елның 15 апрелендә «Кызыл Байрак» газетасын чыгарырга керешә һәм шуның белән татар эшчеләрен һәм хезмәт халкын социалистик революциягә әзерли. Социалистик революциядән соң Владимир Ильич декреты белән М. Вахитов Үзәк Мөселман Комитетының җитәкчесе итеп билгеләнә һәм, Ленинның якын көрәштәше буларак, аның гадәттән тыш комиссары вазифаларын үти. Социалистик Ватан куркыныч астында калгач, 1918 елда «Правда», «Известия» газеталары М. Вахитов һәм В. И. Ленин имзалары белән «Барлык мөселман хезмәт ияләренә мөрәҗәгать» игълан итәләр. Биредә дә Ленин характерына хас тыйнаклык үзен сиздереп тора: ул үзенең имзасын Вахитовныкыннан соң куйган. Биредә тыйнаклыктан бигрәк партия, совет власте мөрәҗәгать итә торган халыкларга хөрмәт белән карау күренә. Шуның белән партия һәм Совет власте дәүләт белән идарә итүгә сезнең вәкилләрегезне дә чакырдык дип әйтәләр сыман! Ленинның бу уйларын халык аңлады һәм Кызыл Байрак астына тупланды!

Ленин тарафыннан дәүләт белән идарә итү эше ышанып тапшырылган кешеләрнең икенчесе Г. Ибраһимов иде. Февраль революциясеннән соң ул берничә сул газетаның оештыручысы һәм редакторы булды. Г. Ибраһимов эсерлыктан зур тырышлык белән, эзлекле төстә большевизмга килде. Ленин белән әңгәмәдән соң ул, юлбашчының ышанычына лаек булуга канатланган хәлдә, әдәбият өлкәсендә Совет власте политикасын үткәрү өчен рухланып эшләде. 1918 елда контрреволюция М. Вахитовны атканнан соң, Г. Ибраһимовка Үзәк Мөселман Комитетына җитәкчелек итү эше тапшырылды. Ленин Г. Ибраһимовның формаль рәвештә сул эсерлар партиясе члены булып исәпләнүен белә иде, шулай да ул аңа эсерлар фетнәсеннән соң да яхшы

мөнәсәбәттә булды һәм әдипкә дөрес юлга чыгуда аталарча ярдәм итте. Г. Ибраһимов Советларның III съездыннан соң, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты члены һәм Ленин декреты белән Вахитовның урынбасары итеп билгеләнгән кеше буларак, беренче татар совет газетасы — Үзәк Мөселман Комитеты органы «Чулпан»ны оештыруга керешә. Бу газета 1918 елның башыннан Петербургта чыга башлый һәм бөтен Россиядә рәсми тестә чыккан беренче татар совет газетасы була. Ул 50 мең данә чамасы тираж белән чыга. Бу ул чор өчен гаять зур тираж. Анда эшләү өчен Көнчыгыш халыкларның коммунистлары чакырыла, алар арасыннан төрек коммунисты Мостафа Сөбхи дә актив эшли. Соңыннан Г. Ибраһимов зур марксист галим-тарихчы, әдәбият һәм тел белгече, романчы, гомумән, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе булып үсеп китә.

Совет Көнчыгышы өчен Г. Ибраһимовның әһәмияте гаять зур. Бу хакта Берды Кербабаев, М. Ауэзов, С. Муканов һ. б. язды. Дөнья әдәбияты институтындагы фәнни сессияләрнең берсендә Г. Ибраһимов йогынтысының илебез чикләрендә генә калмавы билгеләп үтелде. Мондый киң колачлы язучының формалашуы өчен без барыннан да элек Ленинга, аның үлемсез тәгълиматына бурычлы! Г. Ибраһимов кына түгел, бәлки шагыйрь һ. Такташ та, язучы Ш. Камал һәм башкалар да үзләренең дөньяга карашларындагы борылышлары, иҗади үсешләре һәм социалистик реализм методы белән иҗат итүче язучылар булып китүләре өчен Ленин тәгълиматына бурычлылар. һ. Такташ 1926 елда ук моны «Нәни разбойник» шигырендә:

**Шулай, әткәй,**
**Ленин юл күрсәтте**
**Юлдан язар үсал улың,—**

дип бәяләде.

В. И. Ленинның 50 еллыгын тәбрикләп, 1920 елда Ф. Әмирхан «Иптәш Ленин — төзелеш һәм яңарыш символы» дигән мәкалә язып чыкты.

Бүгенге көннәрдә безнең ленинианаиы Сибгат Хәким уңышлы дәвам итә. «Күңел Ленинга тора-тора кайта,— дип яза ул.— Бигрәк тә төрле сынаулардан соң шулай. Ә сынаулар ил тормышында яз булдымыни?»[1] Соңгы ел эчендә генә дә Ленинга багышланган уйланулар, очеркларның гаять әһәмиятле һәм оригиналь үрнәкләрен укыдык без. Г. Әпсәләмов, Р. Төхфәтуллин, З. Нури, Х. Сарьян, И. Низамов һәм башкаларның очерклары һәм шигъри әсәрләре безнең белемебезне һәм тойгыларыбызны баетты.

Әгәр бүгенге уңышлар турында сөйләргә теләсәк, без иң элек республикабызның казанышлары өчен Ленинга бурычлы икәнебезне әйтергә тиешбез. Әгәр Ленин һәм аның партиясе булмаса, безнең белән нәрсә буласын күз алдына китерүе дә кыен.

Партия безне бәхетле коммунистик җәмгыять төзү идеясе тирәсендә интернациональ семьяга туплады. Чыннан да, халыклар дуслыгы безнең очрашулар вакытында сөйләнә торган сүзләр генә түгел бит! Ул бөтенләй яңа әдәбият һәм фән турында бер-беренә иҗади ярдәм дигән сүз! Безнең һәрберебезнең тугандаш республикаларның кайсында гына булмасын, иҗади дусты бар, без аның белән автографлар гына алышмыйбыз, бәлки киңәшләр дә бирешәбез, вакыты белән бәхәсләшәбез һәм кайвакыт темалар сайлауда ярдәм дә итешәбез. Бу безнең дуслыкның күзгә күренми торган бер җебе генә булса да, аның турында гадәттә без матбугатта язмасак та, ул җеп шулкадәр нык, аны һичкем һәм һични өзә алмаячак.

Әгәр чит илләрнең кайберләрендә безнең милли культурабызның чәчәк атуын тамырга теләмәсәләр, ул аларның нәкъ менә шушы безнең культурабызны һәм әдәбиятларыбызны үзара баетучы, чәчәк аттыручы халыклар дуслыгы, иҗади дуслыкның күзгә күренмәс бәйләнешләрен аңлый алмауларыннан килә. Бу дуслыкны ныгытуда татар әдипләре бөек рус әдәбиятына, рус язучыларына революциягә кадәр дә еш мөрәҗәгать итәләр иде. Ф. Әмирхан Л. Толстойга хатлар язып торды. М. Горький үзенең киңәшләре белән күп кенә татар язучыларына дөрес иҗади юлны табуда ярдәм итте.

---

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. Казан. 1969 ел.

Безнең шатлыклы минутларыбыз да һәм авыр сынау көннәребез дә булды. Ләкин ни генә булмасын, безнең телләребездә һәрвакыт Ленин, аның үлемсез тәгълиматы, бөек образы безгә һәрчак ярдәмгә килә. Бу турыда С. Хәким гаять матур итеп:

Без узарга тиеш, әй, юллар бар,
Зур эшләргә чакырып ил дәшә.
Юлга шулай чыгар алларыннан
Күңелем Ленин белән сөйләшә,—

ди.

Без вөҗданыбыз белән икәүдән икәү генә калганда, күңелләребез Ленин белән сөйләшә, аның белән киңәшләшә. Шул җәһәттән бер гыйбрәтле вакыйганы искә төшереп үтү артык булмас шикелле. Муса Җәлил яраланып чолганышта кала һәм мәкерле дошман тырнагына эләгә. Җәзалаулардан, кимсетүләрдән, физик һәм рухи кыйналулардан соң аңар фашистик газетада эшләргә тәкъдим итәләр. Нишләргә? Кемгә киңәш итәргә? Аның әйләнә-тирәсендә үзе кебек үк бәхетсез бәндәләрдән башка беркем дә юк. Шул чакта Муса үзенең вөҗданы белән, Ленин белән киңәшләшә һәм аның хәлендә мөмкин булган бердәнбер дөрес карарга килә. Көрәшергә, бары тик көрәшергә! Ватан хакына, халыклар бәхете хакына, Ленин партиясе хакына көрәшергә! Аны таш капчыкка ташлыйлар. Менә ул фашистлар алдында хөкем көтә. Аның «Хөкем алдыннан» дигән шигыре дә бар. Шунысы характерлы, фашистлар хөкеме алдыннан да шагыйрь Ленин турында уйлый. Һәм Ленин аны батырлыкка рухландыра:

Аның исеме белән ачылган тел
Үлгәндә дә аны кабатлар...

(«Хөкем алдыннан»)

Әйе, Ленин һәркемнең күңелендә, һәм һәрбер кеше, Муса кебек, үзенең мактаулы эшен Ленин исеме белән башлый. Кирәк икән, бу эш өчен ул үлемне дә Ленин исеме белән каршылый.

Мөхәммәт Садри

# УТ ЭЧЕНДӘ ОЧРАШУЛАР

*Хәрби хәбәрче-оештыручы язмалары*[1]

## «Мәскәүне бирмибез, Берлинны алырбыз...»



Ватаныбыз, халкыбыз кичергән иң авыр, иң дәһшәтле вакытлар иде бу. Фашист илбасарлары Гжатскины алдылар, Можайск кырларына, Наро-Фоминскига, Мәскәү диварлары янына ук килеп җиттеләр.

Хәмит Шәрифуллин, Рәхим Алимбеков, Василий Самохвалов һәм йөзләрчә башка якташларыбыз героик Кызыл Армия сафына әнә шул дәһшәтле 1941 елда, сугыш Мәскәү янына якынлашкан куркынычлы вакытта килеп бастылар. Аларның уллары фронтта иде инде. Идел-йортта туып-үскән, ике сугыш утын кичеп чыныккан, совет Ватанын төзүдә бөтен дәртләрен һәм көчләрен биреп эшләгән бу баһадирларның сүзләре кыска булды:

— Мәскәүне бирмибез, Берлинны алырбыз! — диделәр алар. Төрле милләт халыкларының батыр уллары белән иңгә-иң торып, алар да дошман өстенә ташландылар. Ару-талуны белмичә тырышып, немец танклары килә торган юлларга, кырларга меңләгән миналар куйдылар. Дошман техникасы әнә шул мина кырларында, ут өермәләренә әверелеп, күккә очты. Аннан соң якташлар, танкларга утырып, автоматлардан ут яудыра-яудыра, үзләре атакага күтәрелделәр. Гитлерчыларга иркенләп качарга да ирек бирмәделәр, тылларына кереп юлларын миналадылар, күперләрне шартлаттылар, утлы боҗра эчендә калдырып юк иттеләр.

Татар халкының турылыклы улы танк гаскәрләре генералы Нагайбәков Татарстанның бу уллары батырлыгына бик зур бәя бирде. Саперлардан кече сержант Хәмит Шәрифуллин, өлкән сержант Василий Самохвалов, кече сержант Фатих Шәйхетдинов, ефрейтор Фатих Җамалиев, кече сержант Андрей Жилин, кызылармеецлардан

---

[1] Ахыры. Башы 5 санда.

Рәхим Алимбеков, Мөгаллим Сәрыймов, Хәмит Мөхәммәдиев, Габделхак Гафуров, Сөнгат Зәйнуллин һәм башка күп кенә якташларыбыз турында ул аерата мактап сөйләде.

— Алар сугышның чын осталары,— диде генерал.

Кызыл Армия сугышчылары, гитлерчыларны Мәскәү һәм Ленинград яннарыннан, Идел һәм Днепр буйларыннан алып ташлап, үз өннәрендә кыйный башладылар.

Хәзер инде утта чыныккан бу карт гвардиячеләр Мәскәүдән бик-бик ерак җирдә, дошман өнә янында яңа юл салалар иде. Юл тирән сазлыклар, күлләр, калын урманнар һәм биек таулар аша уза. Ул Берлинга барып керер өчен иң якын һәм туры юлларның берсе булачак..

Менә алар киң елга буена туктадылар һәм зур учак яктылар. Күпер салыр өчен агачлар килеп җиткәнче, ял итәргә, кайнар ботка ашарга, туган-үскән якларга хатлар язарга мөмкин.

— Туганнар,— дидем мин якташларыма,— бүген хатларга язасы сүзләрне миңа сөйләгез. Бирегә яшь сугышчылар да бар. Алар да сезне тыңласыннар. Сезнең тормышыгыз, дошманны оста кыйнавыгыз турында бөтен Татарстан, бөтен Ватан белсен!

Якташлар дулкынландылар. Уйлана-уйлана, янчыкларын чыгарып, тәмәке тәрергә керештеләр. Учак яны тып-тын калды.

— Нәрсә сөйләргә соң? — диде, беraз кыюланып, сапер Хәмит Шәрифуллин.— Өйгә без гади генә итеп язабыз, ә сиңа, иптәш, килештереп сөйләргә кирәктер бит!


Аның сүзен Чапаев дивизиясендә Колчакка каршы сугышкан Сибгат Вәлиуллин бүлде:

— Сөйлә, Шәрифуллин,— диде ул, кап-кара зур мыегын сыпырып,— синең ике Кызыл Йолдыз ордены кавалеры булуың турында, үзең туып-үскән Яңа Писмән районында, Зәй-Каратай авылында гына түгел, минем авылымда да, Балык Бистәсендәге Олы Елга авылында да белсеннәр.

Кече сержант Хәмит Шәрифуллин, тәмәкесен тәреп, янчыгын әйбәтләп кесәсенә салгач, башыннан кичергәннәрне берәм-берәм хәтеренә төшереп, сөйли башлады:

— Беренче империалистик сугышта мин укчы идем. Немецлар газ белән агуладылар, госпитальдә озак ятарга туры килде. Ватан сугышында 1941 елдан бирле мин йөз алтмыш фашистны үтердем. Аз рак әле бу. Әмма ләкин дошманның үз өнендә исәпне нык арттырырга уйлыйм. Шуны да әйтергә кирәк, дошманга һөҗүм иткәндә, безгә танкларыбыз барачак юлларга куелган дошман миналарын зарарсызландырырга туры килә. Сапер үз гомерендә бер генә тапкыр ялгыша, диләр.





## Хәсән Туфанга

Хәсән Туфан!
Казан, Уфа...
Сиңа мәкиббән.
Кайчан Мәскәүне мәкиббән
Итәрсең икән?..

И. ХАНТИМИРОВ шаржы



## Фатих Хөснигә

«Авыл өстендә йолдызлар» балкый,
Шәһәрдә — «Минем тәрәзәләрем».
Шәһәр турында зур әсәр язсаң
Тагын да үсәр дәрәҗәләрең.

Хәзергә кадәр, мене күрәсез, минем ялгышканым булмады. Дошманның көчле артиллерия-миномет утына да карамастан, дүрт йөздән артык минасын җирдән казып чыгарып зарарсызландырдым. Аннан соң Польшадагы Н. шәһәре азат итслү белән, андагы йортларны, подвалларны миналардан арчыдым. Ул шәһәрдән үткәндә, йортларга акбур белән: «Мина юк. Шәрифуллин», дип язганнарны күргәнсездер.

Яңа рубежны яулап алгач, аны ныгытырга туры килә. Без, саперлар, бер төнне бигрәк тә күп эшләдек. Ул вакытта бер үзем генә дә сугыш кырына ике йөз егерме мина куйдым. Таң алдыннан дошманның унике танкысы һәм автоматчылары безгә каршы контратакага ташланды. Күп тә үтмәде, мин куйган миналар, дошманның алдан килгән алты танкысын, тимер кисәкләренә әйләндереп, юк иттеләр. Гитлерчы автоматчылар, исән калган танклары көч-хәл белән генә качып котылды. Икенче бер сугышта мин, гитлерчыларның үз миналарын куеп, тагын биш танкысын юк иттем. Дошманның тылына, чигенеп барган юлына кереп җиде тапкыр шартлаттым. Кавказда һәм Карпатта һөҗүм барганда илледән артык күпер салдык.

— Ә Кавказ тауларында без күпме дот һәм дзотлар ясадык! — дип сүзгә кушылды орденлы сапер Рәхим Алимбеков.— Хөкүмәт бүләкләренә лаек булган дусларым Хәмит Мөхәммәдиев, Сибгат Вәлиуллин, Фатих Җамалиев, Мөгаллим Сарыймов һәм башка якташларым таулар арасында дотлар төзү белән бергә, уйсу җирләрдә миналар куюда да, кыялар арасында башка бик күп төрле инженерлык эшләре башкаруда да осталык күрсәттеләр. Без ясаган бер дот утыннан гына да биш йөздән артык фашист юк ителде. Икенче бер дот уты белән дүрт танк яндырылды. Н. шәһәре янында без куйган мина кырларына килеп кергән дошманның ике мең автомашинасыннан сигез йөзе кәл булып күккә очты, бер мең ике йөз автомашинасы безгә калды. Шул вакытта сигез танк та шартлаттык.

— Алимбеков,— диде Габделхак Гафуров,— син танк белән разведкага йөрдең, дошманның бер танкысын, үз йөрешле бер орудиесен яндырдың, үзебез күрдек, нигә ул турыда сөйләмисең?

— Н. шәһәре янында,— дип сөйләп китте Бөгелмә районы, Чыдамур авылының элеккеге лесхоз эшчесе Габделхак Гафуров,— танкларга утырып, немецларны Кавказ таулары арасыннан унбиш көн өзлексез куып бардык. Шул унбиш көн эчендә сугыша-сугыша, җиде йөз километр җир үттек һәм гитлерчыларны Кара диңгезгә кысрыклап дөмектердек.

— Карпаттагы сугышлар турында да сөйләргә кирәк,— диде, иптәшләренә карап, сапер Фатих Җамалиев.

Ул да күпне күргән, күп походларда катнашкан солдат. Ул да өч сугыш ветераны. Ватан сугышы солдатлары сафына килеп басуына да тиздән дүрт ел була инде. Алар Карпат тауларында да бик күп дот һәм дзотлар ясадылар, ташлар арасында күзәтү пунктлары булдырдылар. Тирән упкыннар буйлап үткән тар сукмакларны киңәйтеп, кыяларны ярып, таулар белән тауларны тоташтырдылар. Ашкынып аккан елгалар аша күперләр салдылар. Танкларга юллар ачып, аларны үз җилкәләрендә йөрткән көбек йөрттеләр. Һичкем көтмәгән урыннардан килеп чыгып, дошман өстенә ташландылар.

Карпат сугышларында, мәсәлән, Фатих Шәйхетдинов кына да дошман куеп калдырган 75 минаны зарарсызландырып, танкларыбызны коткарып калды. Якташлар, үз җилкәләрендә бүрәнәләр ташып, таулар арасындагы бер уйсу җирдә, тирән сазлык аша өч километр озынлыгында юл салдылар.

Якташыбыз, өлкән сержант Василий Самохваловның да осталыгы һәм батырлыгы таңга калырлык. Ул алгы сызыкка дүрт меңгә якын мина куя. Гитлерчылар атакага ташланабыз дип, шул мина кырларына танклары белән килеп керәләр дә күккә очалар. Дошман үз миналарын нинди генә хәйләләр белән яшерсә дә, Самохвалов аларны таба белә. Ул инде ике меңнән артык мина зарарсызландырды. Бер каты сугышта, командиры сафтан чыккач, аның урынына басты да, взводын һөҗүмгә алып китте. Василий Самохвалов дүрт орден һәм «Бик яхшы минер» дигән значок белән бүләкләнде.

Бөгелмә эшчесе Василий Самохвалов сары мыегын сыпыра-сыпыра үзе дә сүзгә керешге. Ул якташларыбызның осталыклары, батальондагы рус егете Иван Мальцев, Украина улы Михаил Головатенко, белорус Алесенко, Татарстан улы Хәмит Шәрифул-

лин, абхазияле Доменби Аблотия, мордвин Айгеров, чуваш егете Матвеев, үзбәк егете Юсупов кебекләрнең осталыклары һәм туганлыклары турында сөйли.

Әңгәмә кызганнан-кыза барды. Якташлар дошман тылына кереп миналар куюларын һәм шуның белән унбер мең гитлерчыны кырып бетерүдә гаскәрләребезгә булышуларын да, бер шәһәр өчен барган сугышта, танк десантларында хәрәкәт итеп, дошманның кырык биш мең солдат һәм офицерын юк итүдә катнашуларын да бәйнә-бәйнә тезеп сөйләделәр.

...Менә бер-бер артлы автомашиналар килә башлады. Аларга күпер салу өчен агач төялгән. Якташлар, автоматларын җилкәләренә асып, кулларына үткен балталар тотып, яңадан кызу эшкә керештеләр. Элек аларның берсе дә балта остасы булмаган. Ә хәзер алар сапер да, минер да, җимерүче дә, төзүче дә, автоматчы да, балта осталары да булдылар. Алар бөек совет Ватанының даны өчен, гитлерчыларны җир йөзеннән кырып ташлау өчен барысын да эшлиләр, барысын да булдыралар.

Менә алар шушы күперне салып, Берлинга бара торган юлны төзеп бетерерләр дә, танкларга утырып, ут яудыра-яудыра тагын да алга омтылырлар. Берлин өстенә бөек җиңү байрагын, хак эшебезнең җиңү байрагын күтәрү сәгатьләре көннән-көн якынлаша. Ерткычны үз өнендә тар-мар итеп бетергәч, башкисәрләргә гадел хөкем ясагач, алар, үзләре төзегән күперләр, киң юллар буйлап, азат ителгән җирләр аша, Казанга, Идел буйларына әйләнеп кайтырлар...

*1944*

# Танкист Салих Җамалиев

Төньяк Донец елгасының сул ягында, Белгород шәһәреннән көньяктарак булды бу сугыш. Ул сугышта Салих Җамалиев үзен баһадир итеп танытты.

Генерал Гани Сафиуллин корпусының сул флангтагы көчләренә каршы, күп кенә танклары, шул исәптән иллеләп яңа «тигр»лары белән, фашистлар котырып атакага ташландылар.

Экипаж командиры Салих Җамалиев хезмәт иткән полк танкистларына дошманны туктатырга, машиналарын юк итәргә боерык бирелде. Безнең танкистлар, Донец буендагы урманга кинәт бәреп кереп, дошманның җанлы көчләрен, яшеренгән ут нокталарын сытып-җимереп, урманның икенче ягына чыктылар. Шул уңайдан, Разумный дигән авылны сугышып алып, Крутой Логтагы һәм Генераловкадагы дошманның төп көчләренә каршы ыргылдылар. Фашистларның фронтка яңа китерелгән «тигр»лары шушы полосада һөҗүм итә иде. Контратака ясап, дошман танклары каршысына кисәк кенә килеп чыккан совет танкистлары, бердәм җимергеч ут ачып, гитлерчыларның уннарча танкларын яндырдылар һәм инициативаны үз кулларына алдылар. Дошман танклары каршысына килеп чыгу белән, инде бер «тигр»ны яндырып өлгергән Салих Җамалиев, яшеренеп кенә коры елга буйлап барып, өскә күтәрелә һәм безнең полкка таба дошман танклары үрмәләгәнен күрә. Бер, ике, өч... унөч танк саный ул. Баштагы танк якыная төшкәч, Салих команда бирә:

— Подкалибрным, заряжай!

Орудие коручы сержант Померанцев Җамалиев командасын күз ачып йомганчы үтәп өлгерә. Командир, механик-йөртүче Анатолий Морокинга машинаны туктатмаска кушып, «тигр»ларның иң алдагысына ут ача. Ләкин өч снарядның берсе дә танкны туктатмый. Җамалиевның җен ачуы чыга һәм механикка:

— Морокин, короткий! — дип команда бирә дә танкны бер мәлгә генә туктата һәм туры төзәп атып җибәрә.

«Тигр» өстендә шунда ук ут-төтен күтәрелә.

— Булды, беренчесе дөмекте! — ди Салих, күзен каплаган юеш чәчен артка сыпырып.

Яңа җиңү экипаж егетләрен дәртләндереп җибәрә. Алар икенче танкка һөҗүм итәләр һәм тагын бер «тигр» сафтан чыга. Совет танкистларының кыюлыгына, бер

танкның никадәр танкка каршы торуына котырынып, аны металл кисәкләренә әйләндерергә тырышып, фашистлар төрле яктан ут яудыра башлыйлар. Җамалиев маневр ясарга керешә: танкны әле алга, әле артка, бер уңга, бер сулга йөртеп, ата-ата тагын бер фашист машинасын яндыра. Совет танкысы белән дошман танклары арасындагы кыр тетен бөркеп торган җимерек дошман танклары, снаряд актарган җир-тузан белән каплана. Инде күзәтүе дә читенләшә. Оста маневр ясап төрле якка тибеп бөрөзлексез аткан совет танкысына үзләре снаряд тидерә алмагач, фашистлар яңа тактикага күчәләр: безнең танк экипажы игътибарын алар өчен, алар исерек автоматчыларын җибәрәләр. Җамалиев автоматчылар өстенә пулемет уты яудыра.

Гитлерчылар, сафлары сирәгәюгә карамастан, һаман Салих танкысына үрмәлиләр. Ул арада, икенче яктан тагын бер группа автоматчылар килеп чыга.

— Кабахәтләр, безне чолгап терелэй эләктермәкче буласызмы? Барып чыкмас!.. Померанцев, шрапнель белән! Тагын берне, тагын!

Дошман автоматчылары белән мәвыгып, аларга шрапнельле снарядлар һәм пулемет уты яудырганда, «тигр»лардан аткан снарядларның берсе безнең танкка тия. Танкның трансмиссиясе белән моторы зарарлана, машинага ут каба. Егетләрнең мазутлы чалбарларына, җиңнәренә ялкын үрли. Инде экипаж члennарының тыннары кысыла. Киеренкелек чиктән аша: танктагы сугыш припаслары кыза башлый, танк шартларлык минутлар якыная...

— Ни эшлик, иптәш командир, түзәр хәл калмады,— ди Морокин.

— Тимофеев, пулеметны сүтеп ал, чыгабыз!

Танк пулеметын, гранаталар һәм автоматларын алып, алар җиргә сикерәләр дә шуыша башлыйлар. Шулай ун-унбиш метр шуышып китүләренә «Т-34» сугыш кырын тетрәтеп шартлый. Бу шартлау дулкынынннан танкның башнясы югары күтәрелә һәм Салихлар янына ук килеп төшә.

— Саубуллашырга төштеңме? — диләр егетләр, шартлаган танкка һәм үзләре янында яткан башняга карап, һәм шуышуларын дәвам итәләр.

Салих әле һаман пыскыган җиң очларын, чалбар балакларын, итеген туфракка ышкып сүндерә. Шул арада каяндыр төшеп, миналар шартлый башлый, пуляләр сызгыруы көчәя. Шуыша-шуыша киемнәре тетелеп, тез тиреләре суелып бетә. Шулай барганда, Салихларга тагын утызлап фашист һөҗүм итә.

— Боларын да сыйлыйк әле, егетләр,— ди Салих,— совет танкистлары җиңелә торганнардан түгел!

Егетләр, пулеметтан һәм автоматлардан ут ачып, гитлерчыларны ятарга мәҗбүр итәләр. Шул вакыт Салихның уң кулына пуля тия һәм ул ярага якында шартлаган мина ярчыгы да өстәлә. Дошман уты радист-пулеметчы Тимофеевны да сафтан чыгара. Командир, Морокинга, Тимофеевка булышырга, аны тылга — үзебезнекеләргә таба алып китәргә кушып, үзе, яраларыннан кан агуына да карамастан, Померанцев белән фашистларның һөҗүмен тоткарлый. Нәкъ шул вакытта танкистларга ярдәмгә безнең штурмовиклар очып килә. Алар дошман танкларын, аның җанлы көчләрен җимерергә, юк итәргә керешәләр. Егетләр, яраларының сызлауларын, ару-талуларын онытып, торып басалар да дошманга тагын ут яудырлар. Шулай итеп, аларга полкка исән-сау кайтып җитәргә мөмкин була... Дүрт баһадирны полкташ дуслары зурлап каршы алдылар. Полк командиры полковник Верба:

— Бер танк белән унөч «тигр»ны куркыттыгыз,— диде, аларны берәм-берәм кочаклап,— җиңдегез, молодцы. Дүртегезне дә хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итәм.

Салих, госпитальгә китәргә теләмичә, санчастьта гына дәваланды. Терелгәч, командование аны танклар ротасы командиры итеп билгеләде.

Капитан Салих Җамалиев, үзенең ротасы белән, күп кенә авыр сугыш юлларын үтте. «Сын татарского народа» дип, рус телендә зур-зур хәрефләр белән язылган танк — командир машинасы — һәрвакыт ротаның алдында әйдәп йөри. Шушы танк экипажы һәм ротасы белән ул, кыю рейдлар, көтелмәгән налетлар ясап, командованиенең иң җаваплы заданиеләрен үти. Харьковка бару юлларында һәм Харьковның үзен азат итү өчен булган зур сугышларда Җамалиев дүрт йөздән артык гитлерчыны юк итте, өч «фердинанд», биш танк яндырды, уннан артык кыр һәм зенит тупларын, күп кенә пулемет нокталарын изеп, җимереп үтте. Днепрны кичеп, плацдарм алганда, үз экипажы белән генә дә дүрт танк яндырды. Танклар ротасы флагманын Сан-

домир плацдармында, Польша шәһәрләре һәм авылларында да күрделәр. Германия җирендә Җамалиев ротасы утыз самолетлы аэродромны кулга төшерде. Прага урамнарына да ул Идел буйларыннан сәлам алып керде...

Салих белән без Вена шәһәре янында, Дунай ярында басып торабыз.

— Зәңгәр Дунай дип мактап җырлаганнар кайчандыр үзен. Бер болганчык гади елга икән. Хәер, фашистлар шулай болгаткан инде аны. Күпме күз яше аккан, күпме кан коелган аның суларына.

— Чит илләрдән өйгә кайтыр чаклар җитә, киләчәктә ниләр эшләмәкче буласың? — дип сорыйм аннан.

Ул уйга кала, чөчен сыпырып куя һәм туган якларына карагандай итеп, еракларга күз төбәп:

— Иң элек үзебезнең Татарстанга, Чүпрәле ягына, Кырык-Садак авылына кайтам. Бу сугыш безнең гаиләне дә кырды: 1942 елда әти үлде, аннары Украинадагы сугышларда Кыям исемле абыем һәлак булды. 1943 елда Көнбатыш фронтында Мирза исемле олы абыем корбан булды... Элек туганнарны искә алып, туган якларга кайтам, ә аннары укырга кирәк, укырга! — диде ул.

...Күптән түгел, фронт истәлекләрен, язмаларны карап утырганда, Салих Җамалиевтан хат алдым. Ул туган якларына кайтканнан соң, үзе азат итешкән Харьковка китеп тормыш корган. Эшләгән, укыган һәм фән кешесе булган. Соңгы өч елда егерме ике фәнни хезмәт язган, икесен Украинада китап итеп чыгарганнар. Яңа зур хезмәте Мәскәү нәшриятына кабул ителгән. Киевта экономик фәннәр кандидатлыгына диссертация яклаган. Хәзер ул Харьковның җәмәгать туклануы институтында кафедра мөдире икән. Озакламый докторлык диссертациясе якларга тырышам, дип яза.

Балта остасы улының, баһадир танкистның фән өлкәсендәге уңышлары да сокландыра безне!

*1945—1969*

## Тупчы Мөхәммәт

Днепр ярына җитәрәк тукталып, алар сирәкмирәк кенә калган агачлар һәм чокыр-чакырлыкны каплаган куаклык арасында тирләп-пешеп эшләп алдылар. Тупны агач арасыннан елганың уң яктагы ярына каратып көйләп куйгач, Мөхәммәт, тиргә баткан бит-маңгаен сөртеп, бер мәл уйга калды. Алда, елганың теге ягында, фрицлар



*Шәйхи Маннурга*

Үлчәп кенә осталыкның дозасын,
Шәйхи Маннур яза шигырен,
прозасын,
Үзе белә булыр еле ярышта
Кемне куып җитеп, кемне узасын...



*Нәби Дәүлигә*

Төрле жанрларда яза:
Дөрес юлга басты ул да.
Масаймасмы алынды, дип,
Инде барлык бастион да.

В. АЛЬМЕНОВ шаржлары

тавышы ишетелми, тирә-юнь тып-тын. Димәк, дошман безнең бу тирәгә килгәнне сизмәгән. Күктә ноябрь болытлары йөзә. Ара-тирә өзелеп алган болытлар арасыннан ай чыга да Днепрга чума: «Сине азат итәргә килгән солдатларыңа үзеңне йөзеп кичәргә туры килсә, суың салкын түгелме?» — дип сынап карый шикелле ул. Болытлар айны тагын каплыйлар. Их, шушы яр буйларында учак ягып, бәрәңге пешереп, акыят тыңлап утырсаң, бер җырлап җибәрсәң иде! Күңеле йомшарып киткәндәй булды аның, «җыр капчыгын» чишеп җибәрәсе килде:

**Сарман буйларында йөргән чакта,**
**Битләремне юдым елгада:**
**Синең өчен тудым, синең үчен үстем,**
**Синең өчен яшим дөньяда!**

Кая ул җырлау! «Сарман» җырының сүзләрен эченнән генә исенә төшерде. Төн караңгылыгында аның күз алдына үзе туып-үскән ямьле Сарман яклары, Чукмарлы авылы кырлары, болыннары килеп басты. Сабан туйлары, Татарстан бәйрәмнәре үткән көннәрне чакларны искә төшерде. Чукмарлыда авыл советы председателе булып эшләгән иде бит ул. Ә хәзер ватанның азатлыгын һәм бәйсезлеген фронтта, ут эчендә яклый, халык биргән куәтле яңа «чукмар» — туп утлары белән кол итә ул дошманны.

Менә инде Днепр буйларына да җиттек. Әйтеп бетергесез авыр юллар үтелде, сугыш утлары кичелде. Башта ул автоматчы иде. Алгы сызыкта автоматчы булуы ансат эш түгел. Бик оста, җитез булырга, акыл белән эш итәргә кирәк. Мөхәммәт Галиев сынатмады. Алай гына да түгел, Төньяк-Көнбатыш фронтында, иптәшләре белән атакага ташланып, автомат уты белән үзе генә дә егерме гитлерчыны «теге дөнья»га озатты. Ә бер көнне аны һәм тагын берничә автоматчыны артиллеристлар курсына җибәрделәр. Мөхәммәт бик тырышып өйрәнде һәм аны орудие командиры итеп куйдылар. Бөек шагыйребез Һади Такташ туып үскән Тамбов яннарыннан, Тамбов урманнарыннан ул тагын алгы сызыкка килде, һөҗүм сугышларына керде, Воронежны азат итүдә катнашты, Курск дугасындагы дәһшәтле корыч кебек чыныкты.

Шәһәрләрне, авылларны азат итү өчен кызып киткән һөҗүм сугышларына, безнең автоматчыларга Галиев хезмәт иткән батарея һәм аның орудие расчеты башлап юл сала, дошманның ут нокталарын башлап ул тончыктыра иде. Днепр буйларына алар әнә шулай сугыша-сугыша, йокысыз-ялсыз утлы төннәр, кара урманнар, эссе далалар, сазлыклар аша килеп җиттеләр.

Менә тиздән тагын каты сугышлар башланыр, дошман әллә кайчан ук ныгытып куйган «Днепр валы»н бирмәскә тырышыр...

Мөхәммәт тын Днепр өсләренә бөрылып карады, ләкин караңгыда аны рәтләп күрмәде. Кайчан кичәрбез икән сине? Җырласаң, Сарман җыры сүзләре дә кулай икән үзеңә:

**...Синең өчен тудым, - синең өчен үстем,**
**Синең өчен яшим дөньяда!..**

Ул сискәнеп китте.

— Иптәш сержант! Сезне батарея командиры чакыра!

Галиев ашыгып китте. Землянкада сүзне кыска тоттылар: командование, бу батарея тупчыларының осталыгын, кыю һәм тиз хәрәкәт итүләрен истә тотып, нык ышанып, Днепрның уң як ягына таңга кадәр үк кичеп чыгарга, дошман игътибарын үзләренә җәлеп итәргә һәм берләшмә частьларына елганы болардан уңдарак уңышлы кичеп чыгуда ярдәм итәргә боерык биргән.

— Аңлашылдымы? Әйдәгез, ил боерыгын, ил ышанычын тагын аклыйк!

Артиллеристлар кызу эшкә керештеләр. Алдан ук әзерләп куйган бүрәнәләрне өстерәп төшереп, саллар бәйли башладылар. Куаклыклар арасына яшерелгән көймәләрне дә суга кертеп, өсләренә такталар җәйделәр. Алар искиткеч тиз эшләде, бердәм эшләде, ләкин кабаланмадылар, су чәчрәгән тавыш та ишетелмәде. Күп тә үтмәде, артиллеристлар, сугыш өчен кирәкле һәр нәрсәне барлап, тикшереп алдылар һәм туплар куелган саллар, көймәләр бер-бер артлы теге якка юл тоттылар. Ишкәкләргә дә су буйларында үсеп, тавышсыз-тынсыз ишә белүчеләр куелган, җил дә боларга

таба исә, ауга барганда, ерткычлар исеңне дә сизмәскә тиеш, диләр бит...

Таң беленә башлады. Таң сызылганда безнең артиллеристлар да ярга якынлаштылар. Беренче булып ярга Мөхәммәт Галиев көймәсе борынын төртте. Алар тиз генә төштеләр дә, көймәне саклык белән генә ярга ук тартып чыгарып, тупка, припасларга ябыштылар. Мөхәммәт, иптәшләре белән өскәрәк күтәрелеп, тупны җайлабрак урнаштырды һәм тирә-юньне күзәтә башлады. Ул арада башка саллар, башка көймәләр дә ярга килеп төртелде.

— Булды! — диештеләр егетләр, көймәләрдән төшкәч,— хәзер бу як ярны да бирмәбез инде!

Гитлерчылар якында гына икән. Безнекеләрнең шәүләләрен күргән сакчылар автоматлар белән теләсә кая атып шау-шу күтәрделәр. Йокылы-уяулы гитлерчылар, аңнарына килеп, «пантера» һәм «фердинанд»ларын ходка җибәрергә керешкәндә, тупчылар аларга туры төзәп ата да башладылар. Мөхәммәт расчетының бербер артлы озаткан беренче снарядлары шунда ук ике «пантера»ны кара тәтенгә әйләндерде, бер «фердинанд»ны җимереп ташлады. Ә икенче туплар бер взводка якын фашист автоматчылары өерен күккә очырды. Бөтен батарея ярсып сугышты.

Кояш күтәрелгәндә тирә-якка кара төтен болыты таратып янган унбер танк, җимерек биш «фердинанд» янында батальоннан артык фашист юлбасарларның үләксәләре генә ята иде. Мөхәммәтләр батареясы дошман позициясен алган вакытта, берләшмәнең беренче эшелоны да елганы ашыгыч рәвештә һәм уңышлы кичеп чыга башлаган иде.

1943 елның 6 ноябрендә Киевны азат итүчеләр сафында тупчы Мөхәммәт һәм аның ышанычлы дуслары Харламов, Левкин, Баталин да иң алда атладылар. Киевка җан кердә, ә егетләрнең, Днепр батырларының, күкрәкләрендә орденнар балкыды.

Днепр һәм Киевны азат иткәннән соң да сугышлар җиңел булмады. Житомир ике тапкыр кулдан-кулга күчте. Безнең баһадирлар, яңадан һөҗүм итеп, Житомирны тәмам җимерелүдән коткарып, тагын алга ашкындылар. Ватаныбыз чикләренә җиткәч, Көнбатыш Украинада яңа походларга күч җыйганда, Мөхәммәт расчеты үзенең сугышчан эшенә йомгак ясады: 2408 номерлы оруди белән алар Воронеж яннарыннан башлап дошман өстенә тугыз мең снаряд яудырганнар, дүрт танк, өч «фердинанд», сигез миномет батареясы, унике пулемет ноктасы, биш орудие, унике офицер, бер батальонга якын фашист автоматчыларын юк иткәннәр иде...

*1944*



## *Рафаэль Мостафинга*

Үзе портретчы,
Үзе тәнкыйтьче,
Үзе әзтабар...
Әдәбиятта
Үз мадоннасын
Ул да бер табар...
Менә бит нинди
Егет Зәздә бар!

И. ХАНТИМИРОВ шаржы.
Н. АРСЛАНОВ эпиграммалары.



## *Газа Кашшафка*

Кемнәр яза бу заманны,
Кемнәр яза борынгысын,
Исәп, ахры, киләчәкне —
Берсенә дә орынмыйсың.

Сугыш безнең гаскәрләребез кичеп чыккан Вислока елгасының сул ягында бара иде. Вислока язгы ташкыннан соң тулып аккан Казанка елгасына охшый. Ул Висла елгасына коя.

Болытлы караңгы төн. Күктә ай да, йолдызлар да күренми. Ләкин җир өстен өзлексез рәвештә күзне чагылдыргыч ракеталар яктырталар. Бу — безнең «клэщә» һәм «капчыклар»дан котлары чыгып тәмам котырынган дошман чөйгән ракеталар. Совет сугышчылары аларга төнен дә, көндезгә кебек үк, бер генә минутка да тынгылык бирмиләр. Дошман өстенә «катюша»ларның дәһшәтле утлары, артиллеристларның җимергеч снарядлары, куәтле миналар, пулеметчы һәм автоматчыларның ут яңгырлары ява. Немецлар пулеметлардан, минометлардан аталар да тагын ракеталар кабызалар. Әйтерсең лә, ул вакытлы яктылык аларны җимерелү һәм юк ителүдән коткара иде!

Таң вакытында, безнең сугышчыларны Вислокага һәм аның икенче ярына алып ташларга уйлап, дошман контратакага күчте. Безнең артиллеристлар, танкистлар, җәяүле сугышчылар аны ут тавы булып каршыладылар. Дошманның техника һәм җанлы көчләрен кырып ташлап, алга киттеләр һәм Н. шәһәрен алдылар.

Бу шәһәр янында гвардия лейтенанты Маннан Гыйбадуллинның миномет взводына бигрәк тә каты сугышырга туры килде. Ул, үзенең куәтле миналарын өзлексез рәвештә яудырып, дошманның берничә миномет һәм пулемет ноктасын юк итте. Фашистлар, шул взводны ничек кенә булса да бетерергә теләп, контратакага ташландылар. Алар бер рота, безнекеләр бер взвод иде.

Немецлар якыная төшкәч, Гыйбадуллин команда бирде:

— Ут ачарга! Гитлерчылар качып котылмаска тиешләр!

Көч-хәл белән күтәрерлек авыр миналар, миномет көпшәләреннән яшен тизлеге белән очып китәләр дә, дошман солдатларын өзгәләп, кара төтен күтәреп, җирнең астын-өскә китереп ярылалар. Миналар цельгә төшкән саен:

— Монысы Ватаныбыз өчен, монысы туган Татарстаныбыз өчен, туган Идел өчен, Кама өчен! — ди Гыйбадуллин.

Сугыш озакка бармады. Минометчыларга каршы контратакага күтәрелгән гитлерчыларның бөтенесе диярлек кырып ташланды. Сугыш тынгач, Гыйбадуллин, минометларны җыярга кушты да, Сталинград егете, гвардия өлкән сержанты Василий Орлов, Казан егете гвардия сержанты Николай Якошев янына килеп:

— Молодцы, егетләр, Польша җирендә дә Идел һәм Днепр өчен сугышкан кебек оста сугышасыз, бер генә минагыз да әрәм китмәде,— дип, икесен дә кочаклап алды.

Әйе, Сталинград өчен сугышкан батырларның берсе, гвардия лейтенанты коммунист Маннан Гыйбадуллин солдатлары гитлерчы бәдбәхетләрне рәхимсез кыралар. Соңгы сугышларда гына да алар дошманның алты пулемет ноктасын, бер миномет ротасын, бер күзәтү пунктын юк иттеләр, өч контратакасын кире кайтарып, ике ротага якын солдат һәм офицерларын кырып салдылар.

...Маннан Гыйбадуллин үзенең взводы белән тагын алга бара. Алда — Германия, алда — Берлин. Ул ат өстендә. Күп тә үтми, аның янына атын юыртып батарея командиры Абделгани Вәлиуллин килә. Маннан — Татарстанның Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылыннан. Ә Абделгани — Астрахань егете. Алар дуслар — Сталинград өчен сугышларда дуслашканнар.

Вәлиуллин үзенең булдыклы командирларыннан берсе Гыйбадуллинга яңа рубежга күчү турында өстәмә күрсәтмәләр бирә. Аннан соң алар, минометлар урнашкан һәм сугышчылар утырган повозкаларын күзәткәч, бераз араны уйланып тын гына баралар.

— Маннан,— ди, атын куалап, Вәлиуллин,— син хәзер Карамалыга кайтсаң, ни эшләр идең?

— Карамалыга кайтканчы, Казанга тукталып театр карар идем. «Хуҗа Насретдин»ны күрәсе килдә.

Шул сүзләрне әйткәч, Идел һәм Кама буйларында туып үскән, саргылт чәчле, зәңгәр күзле, чандыр һәм болай да көләч йөзле Гыйбадуллинның йөзе тагын да яктырып китә.

— Берлинны алгач, барысын да күрербез!..

*1944*

# Көлләр һәм гөлләр

Әле юеш кар, әле яңгыр яуган, естә һаман кара болыт асылынып торган, таш юлдан читкә чыксаң — тездән пычракка батып йөргән вакыт. Без, фронтның берничә хәбәрчесе, редакциябез урнашкан Одер елгасы буендагы таш утардан Бреслауга юнәлдек.

Беренче Украина фронты гаскәрләре тарафыннан ычкына алмаслык утлы боҗрага алынган Бреслаудагы фашистлар гарнизоны кан коюны туктатырга, бирелергә, корал ташларга теләмәде. Гитлерчылар керәп оялаган әлеге боҗраны безнекеләр тагын да кыса төштеләр. Шәһәр үзәкләренә үтеп керү өчен ярсулы урам сугышлары башланды. Бреслаудагы үз частебызга без нәкъ шул сугыш башланган чакта килеп төштек.

Әле янып торган таш йорт стеналарына ышыкланып, әле икенче бер йортның эченнән, хәрәбә өемнәре арасыннан кайнар көлгә, кое тузанга батып, әле өченчесенең подвалыннан үтеп, тагын бер ярым җимерек йортка килеп чыктык. Монысы, артиллеристлар белән бергәләп, иртән автоматчылар кулга төшергән һәм хәзер дивизионның күзәтү пункты урнашкан йорт икән. Янәшә кварталдагы полк штабыннан йомыш беләп кайтканда, автоматын әзер тотып, безгә юл күрсәтеп килгән яшь солдат:

— Иптәш капитан, кунаклар кабул итегез! — диде.

Гаубицалар дивизионы командиры, гвардия капитаны Петр Артюк, итекләреннән алып каскасынача, чәч һәм кашларына кадәр көлгә-тузанга баткан булуына уңайсызлана төшеп:

— Шушы йортның «өй туена» кергәч, иртә белән генә чистарынган идем, тагын көл-тузанга баттым, немец тыштан гына ялтырый икән, эче черек, тузанын яңгыр да баса алмый,— дип читкәрәк китеп ес-башын каккалый башлаган иде, фашистлар ут ачтылар, һәм аларның автомат тавышларына, миномётлары гөрселдәвенә кушылып, таш урамнарны шыңгыраштырган снарядлар шартлады, кайнар көл-тузан өемнәре күтәрелде.

— Гитлерчылар һәр кварталны, һәр йортны һәм подвалны терәк пункты — крепость иткәннәр, баррикадалар ясаганнар, Сталинград өчен бездән үч алмакчы булалар, кабахәтләр,— дип,



*Хатип Госманга*

Болай уйлыйм, хезмәтеңдә
Бик борынгы дәвер күргәч:
Язар еле бүгенгене
Борынгыга әверелгәч...

Ш. ГАЛИЕВ эпиграммалары



*Гомәр Бәшировка*

«Таң беленгәч» юлга чыгып,
«Сиваш»ларны кичтек тә,
Дәү үсмәч тә тирбәләбез
Сезнең «Яшел бишек»тә.

капитан чирканып бер читкә тәкерде, аннары, битен зәңгәр яулык белән сөртә-сөртә, офицер Коновалны чакыртты.

Полтава егете, өлкән лейтенант Василий Коновал полкта иң тәҗрибәле батарея командиры икән.

— Башларга вакыт, дускаем,— диде капитан,— урамның теге ягы кетә, яңа квартал кетә! Фрицларның «куз-колагын» бетерүне кемгә кушасың?

Сүз фашистларның күзәтү пунктын җимерү турында, зур чиркәү гөмбәзеннән тирә-якны, һәр хәрәкәтне карап, күзәтеп, артиллерия, миномет утларын кая кирәк шунда юнәлттергән җен оясын туздыру турында бара икән.

Бу эшне безнең үткен күзле старшина Дюкин башкарыр, иптәш капитан! — диде батарея командиры, бер дә икеләнмичә.

Татарстан егете Әхәт Дюкин шушы батарея ветераны булып чыкты. Без аның Сталинградны саклауда, Украина җирләрен, Польшаны азат итү һәм Германиягә кереп, Одер елгасын кичү сугышларында чыныккан егет икәнлеген командирдан белешкән идек инде. Менә әле дә, Коновал аңар тагын җаваплы сугышчан бурыч йөкләгәч:

— Сез дигәнчә булыр, иптәш өлкән лейтенант! — дип җавап бирде ул һәм батарея күзәтү пунктыннан гаубица янына ашыкты.

Расчет орудиены җимерек йорт почмагыннан урамга алып чыкты, дошманның борын төбендә генә таш өемнәр артына яшерде. Егетләр, бер дә кабаланмыйча, сугыш припаслары ташыдылар. Аларның снарядларны имчәк балалары кебек итеп, саклык белән генә кочаклап йөгерүләрен, гаубицаны әйбәтләп карап, кисәк ут ачуларын, расчет аткан тупларның гөмбәзнең нәкъ кирәкле җирләренә генә тиеп ярылуларын батарея командиры күзәтеп торды да:

— Булдырдың, Әхәт, җимердең козгыннар оясын! — дип, батыр расчет янына йөгереп чыга башлаган иде, болар позициясенә урамның икенче башыннан ата-ата гитлерчылар ябырылып килүен күреп алды. Дошман контратакага чыккан икән. Командир Асылов белән Алимбеков расчетларына ашыгыч команда бирде:

— Фашист хәшәрәтләргә, туры наводка белән!

Исмәгыйль Асылов расчеты бөтен урамны тетрәтте. Әхәт тә, гаубицаны яңа юнәлешкә көйләп, бер-бер артлы берничә снаряд очыртты. Егетләр снаряд беткән арада автоматлардан аттылар, аннары, снарядлар килеп җиткәч, яңадан үз урыннарына бастылар. Фашистлар күп, бик күп иде. Урам уртасында дистәләгән мәетләрен калдырып, алар йортларга күселәр кебек кереп постылар.

Бу минутларда, тупчыларыбыз уты астында, безнең автоматчылар һөҗүмгә күчте. Алар фашистларны ээзәрлекләделәр, урамның теге ягындагы әле бу, әле теге йортка бәреп кереп, подвалларны фаустпатрончылардан, чормаларны автоматчыларыннан тазарттылар. Берничә сәгатькә сузылган ярсулы сугыштан соң, тагын бер кварталны дошманнан тазартып, совет сугышчылары шәһәр үзәгендәге йортларны келәгә әйләнүдән саклап калырга ашыкты.

Һөҗүм итүчеләр сафында орудие йөртүче Хәбибулла Миңнуллин, сугыш припасларын ташучы Сәлимгәрәй Әхмәтҗанов, элемтә отделениесе командиры Зыя Әхмәдишин да бар иде. Әхмәдишин — Башкортстанның Кашка авылы укытучысы, Әхмәтҗанов — Татарстанның Сатмыш авылы колхозчысы, ә Миңнуллин — Казан эшчесе булып чыкты.

...Үлемгә дучар ителгән дошман үзенең яшәү сәгатен азга гына булса да кичектерү өчен шәһәрнең һәр йортына теше-тырнагы белән ябышып ята. Ләкин совет сугышчылары гитлерчыларны барлык терәк пунктларыннан бәреп чыгаралар, аларны торган саен күбрәк кырып, ут боҗрасын кысканнан кыса баралар.

Капитан Пустовой батальоны тарафыннан яулап алынган кварталда шушындый эчтәлекле сугышчан листок — «Молния» укыдык:

«Немец илбасарларга үлем! Бүген сугышларда үзләрен аеруча күрсәттеләр:

1. Сержант, комсомолец Проткин. Ул немецларга каршы атакага беренче булып күтәрелде һәм граната ыргытып бер гитлерчыны үтерде, икенче гитлерчыны яралады. Проткин үзенең кыю хәрәкәте белән бөтен ротаны алга барырга рухландырды.

2. Сержант, комсомолец Ибраһим Ильясов, үзенең отделениесе белән, дошман

котырган йорт подвалына беренче булып барып керде, граната сугышы башлады һәм дүрт катлы йортны яулап алды».

Батыр комсомолецлар Проткин һәм Ильясов хәзер инде бу кварталдан шактый ук еракта хәрәкәт итеп, дошманны тагын да күбрәк кыралар иде.

Ильясов янына баргандa батальон командиры капитан Пустовой әле яңа гына тагын берничә йорт яулап алганлыкларын сөйләде. Без шул йортлар янына җиткәч, парадный яннарында, ишек алларында совет сугышчылары пуляларыннан дөмеккән куп кенә гитлерчыларны күрдек.

— Бу явызларны кырып салуда Ильясовның да хезмәте бар,— диде командир.

Без команда пункты урнашкан подвалга төштек. Бирeдән ике йорт аша гына дошманны күзәтеп торган җирдән Ибраһим Ильясов та шунда килде.

Аруы йөзенә чыккан, урта буйлы, җитез егет Ибраһим Ильясов үзенең күргәннәре турында командирга кыска гына итеп сөйләде. Командир аңа яңа задание тапшырды. Ильясов, автоматын тагын бер тапкыр тикшереп һәм яна торган сыекчалар тутырылган шешәләр, гранаталар алып, шул заданиене үтәү өчен җимерек йортлар арасыннан үз отделениесенә ашыкты.

Яңа гына яулап алынган бу йорт хәзер инде немецлардан биш йөз метр ераклыкта, сугышчылар сүзе белән әйткәндә, «тылда» калган. Менә шушы йортның подвалында, Татарстанның Баулы районы, Тат. Кондыз авылында туып-үскән, ачык, күләч йөзле ефрейтор Котдус Вәлиев сугышчылар өчен котлетлар, тәмле печеньеләр пешерә дә алгы линиягә илтә. Сугышның нинди генә авыр шартларына да карамастан, ул офицерлар һәм сугышчыларны кайнар аштан өзми.

Подвалда үзе оештырган кухняга Котдус елмаеп килеп керде:

— Аш суынмасын дип, атны урам буйлап кызу куалый торгач, немецларның борын төпләренә үк барып җиткәнбез. Алар тәмле аш һәм печеньеләр исен сизделәр, ахры, безгә каршы ут ачтылар. Давай атны кире куарга, ашамый торыгыз әле, мин әйтәм. Командирга шушы хәл турында сөйләгән идем, эчә катып көлде:

— Ашның исе аларга, үзе безгә икән,— диде.

Шушы ук подвалда, Котдус кухнясы янындагы икенче бүлмәдә, санчасть урнашкан. Анда врач бар. Ул — Казанда туып үскән, Казан медицина институтын тәмамлаган медицина өлкән лейтенанты Мәршидә Хәбибуллина.

Котдус, шул бүлмәгә кергә дә, аш алып баргандa булган әлеге хәлне Хәбибуллинага да сөйләде.



*Мирсәй Әмиргә*

«Агыйдел» ага инде ул,
Тукталмый агар, диләр,
Мирсәй абзый Иделне дә
Бәлки бер табар, диләр.



*Сибгат Хәкимгә*

Шагыйрь булсаң, бу җиһанда
Ялгызың йөрмә икән,
Йөрмә икән.
Илһам белән Сибгат абый
Сез һаман бергә икән,
Бергә икән...

В. АЛЬМЕНОВ шаржлары

— Чын артист инде син,— диде аңа Мәршидә.— Сине күрсәм, үземне Казанда, Татар дәүләт академия театрында спектакль карап утырган кебек хис итәм. Татарстанның халык артисты Камал III кә охшатам мин сине! Эх, тизрәк бер генә спектакль карасак иде!

— Таңда бик шәп концерт була, ләкин безнең өчен түгел.

— Кемнәргә?

— Немецларга, безнең артиллерия «концерты»!

...Шәһәрне немецлардан арындыру өчен штурм барган вакытта укчы ротаның флангларында безнең снайперлар хәрәкәт итте. Тәҗрибәле снайперлардан кече лейтенант Леонид Волков, кече лейтенант Иван Гагин, сержант Мәхмүт Газизов һәм сержант Алексей Туменовка безне флангларыбызга ут ачкан дошман пулеметчыларын юк итү бурычы йөкләнде. Снайперлар бу сугышчан бурычны тырышып үтәделәр.

Рота сугышчылары, һөҗүмне уңышлы җәелдереп, әле генә яулап алынган бер кварталдан икенче кварталга урам аша чыккан вакытта дошман автоматчысы уң фланглан ут ачты. Бу гитлерчыны тизлек белән юк итү снайпер Газизовка тапшырылды. Газизов, янган йортларның подваллары һәм аварга торган таш стеналары аша үтеп, немец автоматчысы урнашкан урынны чама белән тапты да яшеренде. Немец та оста яшеренгән, аны табуы ансат түгел иде. Газизов немец автоматыннан чыккан ялкын һәм төтенне шактый озак күзәткәч кенә күреп алды. Аннары каскасы да күренде.

— Таптым,— диде Газизов дулкынланып,— һәм аның бераз күтәрелүен тын да алмыйча көтә башлады.

Күп көтәргә туры килмәде. Урам аша йөгереп үткән безнең сугышчыларны карарга башын күтәрү белән, Газизов яхшылап төзәде дә аңа атып җибәрде. Фашист шул минутта ук йөзтүбән килеп ташка капланып дөмекте. Задание үтәлде, ротаның уң як флангысы куркынычсызланды һәм сугышчылар урам аша чыгып алга баруларын тагын да омтылышлырак дәвам иттерделәр.

Бу сержант Мәхмүт Газизов тарафыннан юк ителгән 49 нчы гитлерчы иде. Аннан соң ул үзенең сугышчан исәбен 52 гә кадәр үстерде.

Коммунист Мәхмүт Газизовның фронтка килүенә бер генә ел икән әле. Шул бер ел эчендә Совет хөкүмәте аны Кызыл Йолдыз, III дәрәҗә Дан орденнары, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгән.

...Бреслауның 585 нче кварталындагы тактик яктан иң әһәмиятле зур йортны үзенең автоматчылар отделениесе белән беренче булып яулап алган Әнвәр Әбүзәревнең, оста минометчы Рәшит Садыйковның дошманнан чистартылган 589 нчы кварталның бер зур йортында олылап бөек Ленин партиясе сафларына кабул ителүләрен күрүем турында да әйтми китә алмыйм.

...Озакка сузылган авыр урам сугышларында фашист өрткычларның сырты сындырылды — Бреслау группировкасы тар-мар ителде, исән калган кырык меңнән артык солдаты һәм офицеры әсир төште.

Бөек Ватан сугышыннан соң, Совет хөкүмәте бу борынгы Польша шәһәрен аның үз хуҗасына — поляк халкына тапшырды. Бреслау үзенең чын исеме белән Вроцлав дип аталды. Вроцлав Совет халкы ярдәме белән канлы көлдән күтәрелде. Яңадан торгызылган өйләрдә һәм яңа салынган уннарча кварталларда тыныч тормыш кайный.

*1944—1969.*

# ПАРТИЗАН УЧАКЛАРЫ

*Бу язмаларның авторы Әхәт Шаһи улы Усманов 1901 елны Казан губернасының Тәтеш өязе Атабай авылында туган. Унҗиде яшеннән ул фронтка китә, акгвардиячеләргә каршы Астрахань янында һәм Идел буйларында сугышып йөри. 1930 елны Ленинградның тау институтын тәмамлый. 1929 елда Советлар Союзы Коммунистлар партиясе сафына керә.*

*Бөек Ватан сугышы башланган көннәрдә Әхәт Усманов Старая Русса янында геологик экспедициядә була. Ул шундук институтка әйләнеп кайта һәм Совет ватанының бәйсезлеге өчен икенче мәртәбә кулына корал ала. 1941 елның августыннан башлап 1942 елның июненә кадәр ул партизан отрядының командиры була, аннары Совет Армиясе сафларында немец фашистларга каршы сугыша, ике мәртәбә яралана.*

*Хәзерге вакытта Әхәт Усманов Ленинградта яши, ул — геология-минералогия фәннәре кандидаты, тау институтының профессоры.*

*Совет Татарстанына илле яшь тулган көннәрдә иптәш Усманов, Татрабфак бетергән иптәшләре белән бергә, Казанда бәйрәм тантанасында катнашты һәм без аңардан, Ленинград каласын саклаучы батыр якташыбыздан, дәһшәтле елларда партизаннар отряды белән җитәкчелек итүен сөйләп бирүен үтендек. Түбәндә Әхәт Усманов иптәшнең әнә шул еллар хатирәсен урнаштырабыз.*

## Студентлар ничек партизан булды?

Бу үзеннән үзе шулай килеп чыга. Ел да саен, Совет Армиясе көне килеп җитәр алдыннан, безнең институтта күргәзмә оештырыла, төрле-төрле документ-кәгазьләр һәм инде вакытлар узу белән саргая башлаган рәсемнәр Бөек Ватан сугышы барган авыр елларда тау институтының укытучылары һәм студентлары, илебез халыклары белән бергә, ничек итеп сугышып йөргәнне сөйләп торалар. Илебездәге иң борынгы вузларның берсе булган безнең институт коллективының сөйләсә сөйләр сүзләре күп аның. Мин шул елларның үз язмышыма кагылышлы булган бер генә сәхифәсен сөйләп бирергә телим.

1941 елның июль башларында безнең институтта партизан отряды төзү башланды. Бу вакытта инде студентларның күбесе хәрәкәттәге армиягә чакырылып, истребитель отрядларында дошманнан аяусыз үч алалар иде. Әмма шәһәрдә калган студентларга партизан отрядына ирекле булып язылу хакында партия һәм комсомол оешмалары мөрәҗәгать иткәч, ике көн эчендә без көткәннән өч мәртәбә артыграк гариза килде. Мәгълүмдер ки, уку елы барышында үзләрен иң тәртипле, иң чыдам итеп таныткан студентлар гына сайлап алынды.



— Бик тә авыр шартларда эшләргә туры киләчәк. Эчкәрегә, дошманның ерак тылына керәчәкбез, үлем белән күзгә-күз очрашачакбыз,— дип, без студентларны алдан ук кисәтеп куйдык.

Һәм менә беренче отрядның оешуы (соңыннанрак шундый икенче отряд та оешты) тәмамланды. Бу отрядка әле генә диплом яклаган тау инженерлары керделәр. Отряд командиры итеп мин билгеләндем, ярдәмчем булып институтны тәмамлаган студент Александр Птицын, комиссар булып яшь тау инженеры Анатолий Попов билгеләнде. Шуның өстенә, җитәкче үзәккә отряд парторгы Карпов, отряд радисты Кулькес һәм шәфкать туганы Бабашинский куелдылар. (Шәфкать туташы булырга бер генә дә хатын-кыз юк иде.) Отрядта дистә башы булып та аерым командирлар алдан ук билгеләнеп куелды. Барлыгы алтмыш биш кешегә җыелдык.

«Хәрби тәҗрибә»нең зурылгына карап без отрядны икегә бүлдек. Беренче төркемгә беркадәр хәрби әзерлеге булган студентлар һәм инженерлар туплады, аларның кайберсе ак финнарга каршы сугышкан, кайберсе Осоавиахимда булган иде. Икенче төркемгә хәрби эшне бөтенләй диярлек белмәгәннәрне керттек. Соңыннан, отрядны снайперларга, разведчикларга, җимерүчеләргә бүлгәч, отделение командирлары итеп тәҗрибәле иптәшләрне куярга тырыштык.

Өйрәнүләр башланды. Укуның беренче көннәре институтта узды, булачак партизаннарга синал дигән шартлаткыч матдәне уйлап табучы профессор А. Н. Кузнецов лекцияләр укыды. Ул безне төрле-төрле шартлаткыч матдәләрне ничек кулланырга өйрәтте. Бераздан безнең отряд Ленинградтан 25 километр ераклыктагы Кавголовога күчерелде. Анда партизаннар үзебезнең илдә ясалган һәм трофейга алынган сугыш коралларын өйрәнделәр, компас белән йөри белергә, картаны ничек укырга төшенделәр, карта буенча үзебез хәрәкәт итәчәк район белән таныштылар.

Кавголоводан безне янә Ленинградка кайтарып, баштанаяк киендерделәр һәм коралландырдылар. Институт лабораторияләре кирәк кадәрле синал табып бирде, ул яктан безнең хәлебез Ленинградның башка партизан отрядларына караганда уңайрак булып чыкты.

Кырык беренче елның егерменче августында өч автомашинага төялеп, ерак юлга кузгалдык. Сугыш юлларының язмышы төрлечә булды, кайбер дусларыбыз анда ятып та калдылар.

Тик юлга чыккан чакта безнең беребез дә моңсу түгел, барыбыз да сугышчан рухта, күңелләребездә җиңеп кайту, исән кайту уе иде. Безнең йөк машиналары, ул чактагы исеме белән әйтсәк, «Международный» дигән киң һәм иркен проспект белән көньякка таба җил уйнатып китеп бардылар, без Пулковский биеклегенә чыктык, аннан Пушкин һәм Слуцк (хәзерге Павловск) калаларын уздык, фронт сызыгына егерме километрлар кала туктап калдык. Коралларыбызны һәм сугыш кирәк-яракларын урманга ташыдык, радиаль разведка җибәреп, кыска вакытлы перевалга туктадык. Безне китергән машиналар кайтып китте. Ул чакта немецлар Ленин каласына бик хәтәр ашкыналар иде. Берничә көн узуга без дошман тылында, фронтның теге ягында калган булып чыктык. Командование безнең отрядка ике бурыч йөкләде: берсе — дошман турында мәгълүмат туплау булса, икенчесе — диверсия эшләре алып бару. Зур бәрелешләргә кермәскә, дошман гарнизоннарын читләтеп узарга кушылды, ник дисәң, андый бәрелешләр безнең кечкенә отрядны зур югалтуларга китерәчәк иде.

Безнең отряд махсус вазифа белән әзерләнгәнгә күрә, без аның сафына урындагы халыктан берәүне дә ала алмый идек.

Ленинград фронты штабының разведка бүлеге белән ике яклы элемтә урнаштырып, эшкә керештек.

Тылга килеп эләккән беренче көннәрне ук отряд, билгеле бер урыннарда яшеренеп торып, немецларның штаб машиналарына һәм хуҗалык подразделениеләренә һөҗүм ясый башлады.

Озак та үтми, безнең разведчиклар бик яхшы мәгълүмат алып кайттылар: безнең кулдагы мәгълүматларга караганда, дивизия штабы урнашкан авылдан көн дә сәен иртән сигез элемтәче юлга чыга. Алар мотоциклларга атланган булалар. Немецларга хас педантлык белән алар аны көн саен топ-төгәл бер үк вакытта башкаралар икән. Без тагы да төгәлрәк итеп бер нәрсәне белеп алдык: беренче һәм азакгы мотоциклларда сак бара, уртанчы мотоциклларда почта алып баралар, колонна башыннан санаганда өченче мотоциклда— гадәти почта, дүртенчесендә — яшерен почта, бишенче һәм алтынчысында — шулай ук гадәти почта.

Таш юлның алдан ук билгеләп куелган урынында олы юл баганасына ялтырвыклы ак тимер чыбык бәйлибез, чыбыкның икенче башы юлның икенче ягындагы блокка беркетелә, блок янында бик нытытып яшеренгән берничә сугышчы дежур тора. Шундый ук нәрсәне алгарак, юл борылышында да эшлибез. Барлык кавалькаданы уздырып бетергәннән соң, иң соңгы мотоциклчы узам дигәндә генә, беренче засада сугышчылары кинәт тимер чыбыкны мотоциклчының муен турысына җиткереп тарталар, мотоциклчы машинасыннан ычкына да бөке сыман атылып, кинәт читкә барып төшә. Аны шундук үтерәләр, документларын һәм коралын алалар. Алгарак узгач, башка мотоциклчылар белән дә шундый ук операцияне башкаралар. Тагын бер километр узгач, партизаннар төркеме исән калган беренче мотоциклчыларны атып үтерә, коралларын, почтаны һәм кием-салымнарын алып, бик тиз урманга яшеренә.

Шул рәвешле ауга йөрүне без үзара «коры операция» дип атадык. Шул беренче көзне андый эшләрне аз оештырмадык, әмма безнең тарафтан бер генә үлүче дә, бер генә яраланучы да булмады. Аеруча уңышлы көнебез дип мин егерме өченче сентябрьне санар идем. Безнең отряд егетләре шул көнне алты фашист белән бергә штаб машинасын, берничә мотоциклчыны һәм бензин илтүче җиде автомашинаны шартлатты.

«Коры операцияләр» партизаннарның күңеленә бик тә хуш килде. Заданиене үтәгәннән соң, алар бик канәгать булып, елмаешып кайтып керәләр иде.



*Әхмәт Исхакка*

Җәнлекләр елый урманда:
— Мәсьәлә каптың! — диеп, —
Шул Әхмәт Исхактан гына
Без бәла таптык! — диеп.

И. ХАНТИМИРОВ шаржы



*Габдрахман Әпсәләмовка*

«Татмебель»не тирги халык:
— Шушымы ирлекләре? —
Әпсәләмов томнарына
Чыдамый шүрлекләре!

Бервакыт баштагы группаның командиры итеп өченче курс студенты Дима Коваленский билгеләнде. Операция уңышлы узды, без инде группаның исән-аман әйләнеп кайтуын көтәбез. Вакыт уза тора, группа кайтмый да кайтмый. Борчыла башладык. Карасак бер заман, ни күрәбез: кулына ак флаг тоткан немец офицеры килә. Батып-җимереп, партизаннар командирының нәкъ үзенә илтүләрен сорый. Ә аңардан бераз арттарак безнең партизаннар атлый. Часовойлар аптырабрак калалар, әгәр алдан немец килә икән, нигә алар ул хәтле тыныч кыланалар соң әле! Аптырап, каушап, гитлерчыны үткәреп җибәрәләр, ул безнең янга килеп җитә, без бары тик шунда гына аңыбыз гитлерчы киемендә киенеп алган... Дима Коваленский икәнен таныйбыз. Үтерелгән фашист киеменә киенеп, «шаяртырга» уйлаган икән. Җитди генә аңлатырга туры килде үзенә, юкса андый шаяртуларның бик күңелсез бетүе дә мөмкин бит.

«Коры операцияләр» фронт белән командалык итәр өчен бик кирәкле мәгълүматлар бирә торган иде. Кавалькаданың дүртенче мотоциклчысын без гадәттә исән калдырырга тырыша идек. Мотоцикл бишегендә бик тә кыйммәтле кәгазьләр алып бару өстенә, ул, бик һәйбәт «тел» булып чыга, гадәттә ул штаб вәкиле һәм элемтәчеләрнең башлыгы була иде.

Почтаны без бик җентекләп тикшереп чыгабыз. Отрядтагы студентларның күбесе немец телен яхшы белә. Алар документларны тәрҗемә итәләр, фронт штабы өчен аеруча кирәк булганнарын бер якка аера баралар. Сайлап алган мәгълүматларны шифр теленә күчереп разведбүлеккә тапшырабыз. Бигрәк тә мөһим документларны фронт сызыгы аша үзебезнекеләргә илтеп бирергә тырыша идек. Разведбүлектән парольне, кайсы юнәлештә барырга кирәклекне һәм каян үтәргә мөмкин икәнлекне сорашып беләбез. Документлар илтүче партизаннар берничә мәртәбә дошман утына эләгеп яраландылар, әмма заданиене намус белән үтәп чыктылар. Фронт сызыгын узу коточкыч зур мәшәкатьләр белән генә түгел, партизаннарның гомерләре белән дә бәйле иде. Безнең отрядның сугышчысы, батыр йөрәкле Степанов фронт штабына документлар илткән чакта һәлак булды. Кичерәк кенә буйлы, бик җор егет иде ул. Һәйбәт разведчик иде. Крестьян киеменә киендереп җибәрә торган идек. Разведка ясаганда ул немецларга эләгә. Сарайга ябалар, кача, безгә кайта, таба алмый, без инде күченеп киткән булабыз. Чолганыштан чыгучы дүрт кешене очратып, 81 нче отрядның филиалы булып эшләп йөргән. Фронт штабына мәгълүматлар биреп торган, фронт аша чykканда, документ илтешли, һәлак булган.

Чираттагы «коры операциядән» соң гитлерчылар безгә каршы ике-өч машина карательләр отряды җибәрәләр, әмма без урман эченә еракка яшеренеп өлгергән булабыз, тактикабызны вакытлыча алыштырып, бүтән кирәкле эшләр белән шөгыльләнә торабыз, ә аннары кайда да булса уңайлы бер урында засада корып, таш юл өстендә мотоциклчыларны мәтәлчек атындыра башлыйбыз.

Карательләр берничә мәртәбә ауга чыгып та, буш кул белән әйләнеп кайтканнан соң гитлерчылар авылларга өндәмәләр ябыштырдылар. Өндәмәләрдә әйтелгән: урманнарда бандитлар барлыкка килгән, алар немец элемтәчеләренә ташланып, вермахтның данлы солдатларын талыйлар. «Бандитларның» оясын табып биргән кешегә бик зур бүләк биреләчәк.

## Гадидән катлаулыга

Көннәр уза торды. Безнең отряд әүвәлгечә Ленинград өлкәсенең урманлы төбәкләрендә — Мшинская станциясеннән көнбатышка, көнчыгышка һәм төньяк-көнчыгышка таба Вырица, Тосно, Октябрь тимер юлы магистрале юнәлешләрендә хәрәкәт итә иде. Сугышчылар төрле-төрле трофей кораллардан атарга бик яхшы өйрәнеп алдылар. Бездә ул кораллар шул хәтле күп җыелды, без аларның үзебездән артканын күрше партизан отрядларына да бирә бардык. Шартлаткыч матдәләр дә җитәрлек иде.

Отрядның «сугышчан репертуары» киңәя төште. Без дошманның складларына, гитлерчыларның зур булмаган гаскәри берләшмәләренә, хәрби тоткыннарны озата баручы конвойларга һөҗүм итә башладык. Шундый операцияләрнең берсендә берничә дистә кызылармеецны коткардык.

Безнең отряд партизаннары Ленинград — Кенгесипп таш юлы өстендә засада, комиссарның образлы сүзе белән әйткәндә, «тартарарам» оештыра торган булдылар. Бер көн эчендә без шоссеның күп кенә өлешен, күперләрне миналап чыга ала идек. Ә кечкә таба миналанган төштән ерак та түгел берничә шартлау ясыйбыз. Гитлерчылар сәгате-минуты белән шартлау булган җиргә карательләр отряды җибәрәләр, карательләр төягән машиналар таш юлга килеп керү белән юл өстендә бер-бер артлы шартлау баганалары күтәрелә, машина кисәкләре, гитлерчыларның гәүдәләре күккә оча. Гитлерчыларның исән калганнары яшеренеп яткан партизаннарның көйдергеч утына килеп эләгәләр.

Бер мәлне без «тартарарам» вакытында станоклы пулеметтан гитлерчыларның разведка ясап йөрүче самолетын бәреп төшердек. Без диверсия алып барган районга килгән фашист самолеты кара төтен тузгытып урман эченә мәтәлеп төште дә шунда каберен тапты.

Тавышсыз ата торган винтовкалар безнең бик һәйбәт ярдәмчеләребез булып чыктылар. Андый винтовкалардан засада вакытында файдалану дошман сафларында паника уята, чөнки алар безнең хәрби көчебез күпме икәнне белә алмыйлар, ә билгесезлек — куркыныч нәрсә бит ул. Гадәттә андый винтовкалар белән дошманның элемтә сызыгы янында дежур торучы сугышчыларны коралландыра торган идек.

Безгә бервакыт гитлерчыларның бензин алу пунктын юкка чыгарырга әмер бирделәр. Пунктның кайдадыр бер куе урман эчендә, Лугадан көнбатышкарак урнашканлыгы билгеле булды. Төгәл координатларын белеп, ул хакта да хәбәр итәргә кирәк иде. Федор Драко җитәкчелегендәге разведчикларыбыз задание үтәргә киттеләр. Озакламый алар пунктны чыннан да тапканнар. Һәр яктан калын кара урман белән уралышлы зур гына бер аланга урнашкан икән. Анда алгы сызыкка баручы автоколонналар гына түгел, шунда аланга очып килеп төшүче разведка самолетлары да ягулык тутырып китәләр икән.

Бензин алу пунктының координатлары фронт штабына хәбәр ителде. Шуннан соң бездән, бензин алу пунктына һөҗүм итеп, аны юкка чыгару өчен көчегез җитәрлекме, дип сорадылар, җитмәсә, күршедәге партизан отрядлары белән берләшергә куштылар.

Без күршеләребез белән элемтә урнаштырдык һәм операциягә әзерләнә башладык. Берничә көннән бензин өләшү пунктын тар-мар иттек.

Ләкин сугышчан заданиенең үтәлүе турында штабка хәбәр итәргә дә өлгермәдек, бездән унбиш километрлар гына ары фашист самолет-



*Әмирхан Еникига*

Мактый да мактый бу халык
«Әллүки»ең — милли көен,
«Шүрәле»сен, сабан туен
һәм Әмирхан Еникиен.

В. АЛЬМЕНОВ шаржлары



*Шәүкәт Галиевкә*

Укучым, уйныйк әле кети-кети! —
ди, күр әле:
Күлдерә — бармак та селкетми үзе,
вәт шүрәлә.

ларының заправкага төшүләрен белеп алдык. Бу ниткән әкәмәт! Бу пунктны да күзәтү астына алырга туры килде.

Координатларын ачыклап фронт штабына хәбәр иттек. Бу юлы бензин өләшү пунктын безнең фронт авиациясе ярдәмендә тар-мар итәргә әмер бирелде. Монысы инде алай ук ансат бу..ып чыкмады: гитлерчылар отпор бирергә әзерләнеп өлгергәннәр иде. Безнең берничә самолетны бәреп төшерделәр. Партизаннар ягыннан да югалтулар булды. Шулай да заданиене үтәп чыктык.

Туктале, үтәп чыктык дибез дә, шулаймы соң бу! Нәкъ икенче көнне, без шартлаткан беренче бензин өләшү пунктыннан унбиш километрлар, икенчесеннән ун-унике километрлар ераклыкта пунктның өченчесе пәйда булды. Берни булмагандай, гүя безгә уч итеп, үз эшен эшли бирә. Машиналар бензин ала, самолетлар аның бензины белән күккә күтәрелә. Ялган пунктлар түгел, күз буяу өчен генә куелмаганнар.

Нишләргә! Озын-озын уйлап тормастан, бу пунктка да дәррәү һөҗүм итсәк! Ләкин бит аның нинди югалтуларга алып киләчәген кем белә! Без авыр бер ребусны чишү өчен баш ватарга керештек. Һәркем үз уен әйтеп бирергә тиеш иде. Дүртенче курс студенты, гидрогеолог Павел Цветков иң кызыклы план әйтте. Үзара фикер алышкач, без аныңча эшләргә дигән ныклы карарга килдек.

Һәм менә мина эзләү аппараты белән коралланган Цветков, берничә сугышчыныияртеп, урман эчендә гаять зур бөҗәлар ясап йөри башлады. Ул туфракның һәр карышын тикшереп-капшап уза, наушникларда чыелдаган тавыш ишетелмәсме дип игътибар белән тыңлап бара, бөҗәлар әкренләп кими, кечерәя баралар, әйтерсең, күзгә күренмәс шартлы бер үзәккә якынлашалар.

Эзләү бер көн, ике көн дәвам итә... Ниһаять, Цветков эзләгәнен таба. Наушникларда чыелдау тавышы ишетелү белән, шатланып:

— Булды! — дип әйтеп куя.

Партизаннар чокыр казыйлар һәм бензинүткәргеч юан металл торба күрәләр. Аның буенча үзәк бензинсаклагычтан филиалларына сыек ягулык ага икән. Без аларның икесен шартлаттык бит инде. Мина эзләү аппараты белән бензинүткәргеч сузылган якка табан барып, Павел Цветков үзәк бензинсаклагычның урнын ориентацияли. Үзәк бензинсаклагыч тулысынча җир астына күмелгән, заправка пунктларыннан һәм самолетлар утыра торга мәйданнардан бөтенләй читтә, куе кара урман эчендә булып чыкты, бик көчле сак астында тотыла иде.

Өстәмә разведка безгә мәгълүматларны тагын да ачыклый төшәргә булышты, шуларга карап без операциянең планын бик җентекләп төзедек. Һәм операция гаять уңышлы барып чыкты. Менә, ниһаять, бензин өләшү оясы күккә очты, аның әле бактың исә тагын ике филиалы бар икән — берсе ни бары дүрт километр, икенчесе унбиш километр ераклыкта.

Шулай итеп, безнең бер студент иптәшебез, ак финнарга каршы сугышкан Павел Михайлович Цветковның тапкырлыгы отряд алдына Ленфронт штабы тарафыннан куелган бик авыр бурычны үтәп чыгарга мөмкинлек бирде. Шунысы үкенеч, Павел безнең Җиңү бәйрәмебезне күрә алмады, сугышларның берсендә ул, газиз гомерен биреп, үлеп калды.

## «Чапай» һәм «Фурман»

Нәүбәттәге бер диверсиядән соң безнең отряд карательләр белән авыр бер бәрелешкә катнашты. Ахыр чиктә без гитлерчылардан котылып, урманга яшеренә алдык. Арыган, ачыккан, бәрелештә хәлсезләнгән һәм йокысызлыктан интеккән кешеләргә ял кирәк иде. Привалда гөмбә ашы пешерергә — азык-төлек ягы шәптән түгел иде — коралларны чистартырга, киемнәрне тәртипкә китерергә тотындык. Гадәттәгечә, радиаль разведка җибәрдек, тирә-юньгә сакчылар куйдык. Разведка тирә-як авылларда гитлерчыларның юклыгы һәм гомумән тыныч булуы турында хәбәр итте. Кичкә кадәр сабыр итеп торырга, ял итеп алырга, ә төнлә базабызга кайтырга карар кылдык. Карательләр белән кабат очрашасы килми иде.

Төш вакыты узуга, кинәт бездән ике-өч километрлар гына арада атыш тавышлары ишетелә башлады. Шул якка шундук разведчиклар җибәрдек. Алар фашистлар

белән кемнәрнеңдер каты көрәш алып барулары, фашистларның каршы якны сазламыкка таба кысрыклауларын килеп әйттеләр. Күрәсең, партизаннардыр. Кайсы партизаннар! Каян алар! Без бит тирә-якта партизаннар юк дигән мәгълүмат алган идек. Ни дигән сүз була инде бу!

Озак баш ватып торырга вакыт юк. Урман сугышларында ни генә булмый. Иптәшләрне коткарырга кирәк. Оборонадагыларга ярдәмгә мин үзебезнең бик яхшы коралланган бер төркем партизанны җибәрдем.

Тиздән ату тавышлары көчәйде, күрәсең, безнекеләр сугышка катнашты. Озак та үтмәде, ату тынып калды. Тагын бер ярты сәгать зарыгып көткәннән соң без әйләнеп кайтып килгән иптәшләребезне күрдек. Алар белән ундүрт-унбиш яшьләрендә үтә дә арыган-алҗыган үсмерләр төркеме килә иде.

— Фрицлар белән сугышучылар менә шушылар инде,— дип хәбәр итте миңа партизаннар.— Сугыш җиңел булмады аларга. Үзләрен сезгә китерүне үтенделәр...

Үсмерләр төркеменнән икесе аерылып миңа таба атлады. Немец автоматлары, немец пистолетлары һәм гранаталары белән коралланган үсмерләргә карыйм — үз күзләремә үзем ышанмыйм. Малайлар гына бит әле! Каян килеп чыкканнар алар монда! Өстәвенә баштан-аяк коралланганнар!

Малайларның берсе мине, сынап-тикшереп, күздән үткәрде. Гүя бигүк ышанып җитмәгән төсле, тупасрак итеп:

— Ә син кем! — диде.

— Партизаннар отряды командиры мин. Сезне коткарган отряд командиры.

— Командир! — Малай нигәдер шикләнгән сыман булды.— Ә фамилияң ничек!

— Усманов. Ә сез кемнәр, каян килеп чыктыгыз!

— Мин,— дип, ул бер адым алга атлады.— Мин — Чапай... Сез ярдәмгә килгән отрядның командиры,— һәм ул миңа кулын сузды.

— Я, исәнме, Чапай,— дип, мин ихтыярсыз елмаеп куйдым.— Ничә яшь соң әле сиңа!

— Унбиш. Ә менә бу,— янында басып торган малайга таба башы белән ымлады.— Фурман. Аңар — ундүрт яшь...

«Әлбәттә, шулай,— дип уйлап алдым мин.— Легендар Чапай белән янәшә тагын кем булсын, билгеле, Фурманов».

Малайлар, малайлар! Уйламаган, көтмәгән җирдән безне партизан сукмаклары очраштырды. Сез үз-үзегезгә артык ышангансыз, алдын-артын уйлап җиткермәстәнме, фашистларга каршы сугыш ачкансыз, шушы тигез булмаган сугышта ундүрт-унбиш яшьлек үсмерләрдән җыелган кырык җиде кешелек отрядның утызы һәлак бул-



*Илдар Юзеевка*

Сынадык,
Сине моннан соң
Әйбәт шагыйрь санарбыз.
Тик бу «Соңгы сынау» булмас,
Бертуктамый сынарбыз...



*Гамил Афзалга*

Сатир:
— Гамил Афзал, җаным, ахирәт,
Сиңа миннән тагын ни кирәк?
Гамил Афзал:
— Сатир нәче миндә бетканче,
Бу дөньяда язык бетсәче —
Сатирага азын бетсәче!

И. ХАНТИМИРОВ шаржлары
ЗӨЛФӘТ эпиграммалары

ган. Безнең отрядка сезнең уңныдегез генә килеп җитә алды. Без бергәләп хуш исле, тәмле гөмбә ашы ашадык һәм сез халык батырлыгына тиң булган хәрби маҗараларыгызны безгә сөйләп бирдегез...

Алар барысы да Ленинградның бер һөнәр училищесында укучы малайлар булганнар. Җәен аларны, ул чакта кулланылган сүз белән әйтсәк, окоп казырга җибәргәннәр. Алар башка ленинградлылар белән бергәләп, шәһәрдән шактый еракта оборона корылмалары төзегәннәр. Малайлар көчләрен кызганмый эшләгән. Шунда ашап, шунда йоклап гомер иткәннәр, китәр алдыннан аларга ике атналык коры паек бирелгән.

Кинәт ишетәләр: тирә-юньдә гел немецлар, ычкыныгыз!

Бу хәбәр яшен тизлеге белән таралып өлгерә һәм, корылма төзүчеләр, көрәкләрен, ломнарын ташлап, төньякка, Ленинградка таба кузгалалар. Берничә километр узгач, алар гитлерчылар белән очрашалар, соңыннан билгеле булганча, фашистлар десант төшергәннәр икән.

Һөнәрче малайлар үзләренчә фикер йөрткәннәр: алар хәзер дошман территориясендә калдылар бит инде. Ленинградка юл ябык, димәк, бер каян да ярдәм алыр урын юк, урманга яшеренергә дә партизанлык итәргә кирәк. «Хәрби советка» җыелалар, үзләренең үсмерләр отрядын төзиләр. Командир белән комиссардан башка нинди отряд булсын! Шундук бер тавыштан отряд командиры итеп иң өлгер, иң куркусыз малай, башкаларны үз ихтыярына буйсындыра белүче Миша Зеленковны сайлыйлар. Миша үзен Чапай дип дәшәргә тәкъдим итә. Отряд комиссары итеп ул үзенең дусты Саняны (үкенечкә каршы, фамилиясе хәтеремнән чыккан) билгели. Шулай итеп, «Чапай» янында «Фурман» да пәйда була. Өченче үсмергә отрядның хуҗалык эшләрен алып барырга кушалар.

Боларын хәл итеп бетергәннән соң, калган коры паекны озаккарак җитәрлек итеп бүлеп чыгалар. Ниһаять, төп мәсьәлә алга килеп баса: корал каян табарга! «Чапай» үз планын әйтә, «Фурман» һәм башка сугышчылар аны хуплыйлар.

Озакка сузмыйча, эшкә керешәләр. Урман эчләренә берәм-берәм төшкән десантчыларны сагалап торалар да, көтмәгәндә ташланып, аларны коралсызландыралар. Отрядта немец автоматлары, гранаталар, пистолетлар, хәнҗәрләр әнә шулай барлыкка килә. Шул кораллар ярдәмендә немец олауларына һәм элемтәчеләренә берничә мәртәбә һөҗүм итәләр.

Биш-алты көн дә узмый, барлык малайлар инде коралланып бетә. «Чапай» белән «Фурман», партизанлык тактикасының барлык кагыйдәләренә туры китереп, хәрәкәт итүнең яңа планын эшлиләр. Алар дошман үзләреннән көчсезрәк булган сурәттә, җиңүнең үзләре ягында булачагына һичшиксез ышанган чакта гына һөҗүм итәләр. Дошманның көчлесе очраса, урманга яшеренү ягын карыйлар. Әйтергә кирәк, алар бик кыю һәм тәвәккәл хәрәкәт итәләр, малайларга хас йөрәксенүләре дә була, тик алдын-артын уйлап эшлиләр, гитлерчыларга, бигрәк тә тылдагы вак подразделениеләргә күп кенә мәшәкать тудыралар.

Иң мөһиме шул: боларның барысы диярлек үсмерләр ягыннан корбан бирмичә эшләнә. Күрәсең, әнә шул хәл малайларның беркадәр башын әйләндереп җибәргәндер, аларга дингез тубыктан булып күренә башлый. Менә ни өчен алар үзләренә коточкыч бәхетсезлек алып килгән көнне фашистлар вермахтының кадровый ротасына каршы һөҗүм ачарга батырчылык итәләр. Бу—аларның гаять зур ялгышлыклары була. Тылдагы хуҗалык взводы бер хәл, көне-төне муштровать ителгән кадровый башкисәрләр бөтенләй башка нәрсә бит ул. Гитлерчылар, әлбәттә, каушап калмыйлар, шундук контратакага күчәләр. Зур югалтулар бәрабәренә, атыша-атыша, яшь патриотлар чигенә барырга мәҗбүр булалар. Фашистлар ныклы бер ышаныч белән, әкрен-әкрен, аларны сазламыкка таба кысрыклый баралар, бер үк вакытта өч яктан инде камап та киләләр. Сазламык янында үлем уены башлана, әгәр шунда безнең отряд килеп җитмәсә, алар барысы да сазламыкта ятып калган булырлар иде...

— Я, нишлибез, «Чапай»! — дип сорыйм мин.

Ул дәшми. «Фурман» аңардан җавап көтеп тора.

— Рөхсәт итегез, иптәш командир, безгә сезнең отрядка кушылырга...

— Юк, дустым. Сез әйбәт малайлар, шулай булса да үзегезне фронт аша озатып

куярга туры килер. Анда сез бирелгәгә караганда кирәгрәк һәм файдалырак эш эшли алырсыз...

— Иптәш командир,— дип җыларга җитешеп дәште «Чапай»,— калганнар китсә китсен, мин каршы түгел, тик минем белән «Фурманны» үзегезгә калдыруыгызны сорыйм. Бик тә, бик тә үтенеп сорыйм. Ышаныгыз, без, ни боерсагыз, шуны үтәрбез. Үкенерлек булмас. Без партизаннар белән калырга тиешбез. Зинһар, иптәш командир...

Үзләрен чын солдатлар итеп тотучы шушы тынгысыз романтиклар минем күңелемне кузгаттылар. «Чапай» белән «Фурман»ны отрядта калдырырга карар кылдым. Калганнарын фронт аша чыгарып, генерал Федюнинский армиясе карамагына тапшырдык.

Үсмерләрнең икесе дә искиткеч, хәтта әйтергә мөмкин, алыштыргысыз разведчиклар булып чыктылар. Шунысы аяныч, «Фурман» бер бәрелеш вакытында һәлак булды, ә «Чапай» — Миша Зеленков — сугыштан соң хәрби училище тәмамлап, Совет Армиясенең кадровый офицерына әйләнде. Хәзер ул майор.

## Саня һәм Шура

Зур булмаган тагын бер вакыйганы сөйлим әле.

Лужки дигән поселок районында урнашкан иде безнең отряд, шунда апалы-энеле ике бала килде. Саняга — кыз балага — унөч яшь, энесе Шурага унбер яшь иде.

— Безнең әти фронтта үлде, әнине немецлар атып үтерде, әти кызылармеец булган өчен. Без авылдан качтык та менә сезгә килдек...

Чыннан да, партизаннардан да сыеныр почмак тапмагач, бу ятим балалар тагын кая барып сыена алалар! Тормышыбызда хәвеф-хәтәр никадәр генә күп булмасын, балаларга бездә уңайрак булыр дигән фикергә килдек.

Саня белән Шура озакламый безнең сугышчыларның иң яраткан балаларына әйләнделәр. Бу һәйбәт балалар эшсез утырырга риза булмадылар. Апалы-энеле ике туган, бәләкәй гәүдәле, ертык киемле ике бала көннәр буена гитлерчылар тирәсендә уралалар, алар шул хәлендә күзгә ташланып тормыйлар, аларга бирәү дә игътибар итми иде. Әллә ни кадәр кыйммәтле мәгълүмат китереп тордылар алар безгә.

Саня белән Шура бервакыт шулай чираттагы заданиене үтәргә киттеләр. Шурик алдан бара, бераз артка калыбрак Саня атлый. Авылга якынлашалар. Карасалар, немец солдаты басып тора. Шурага кычкыра бу:

— Малай, кил әле монда!..

Шурик икеләнеп туктап кала: барыргамы, юкмы! Аның бит күлмәге астында Совинформбюро сводкалары. Өстевенә арттан Саня килә. Гитлерчының ни уйлаганын кем белә! Бәлки, болай гына, берәр нәрсә турында сорар өчен генә чакырадыр, ә бәлки...

— Кил, юкса атам! — дип кабат кычкыра гитлерчы.

Шура түзми, кире борыла да чабып китә. Солдат винтовкасын күкрәгенә терәп атып җибәрә, пуля малайның аягына эләгә. Шура егыла. Бер үк вакытта аңа таба солдат та һәм Саня да йөгереп килә. Апасы алданрак килеп җиткән булса да, сводкаларны алып өлгерә алмый, малайның күлмәген күтәреп, сводкаларны фашист ала, малайны якасыннан сөйрәп авылга алып китә. Саня башта солдат белән янәшә бара, яралы энесен җибәрүен үтенә, ләкин берни дә барып чыкмагач, безгә хәбәр итәр өчен урманга чаба.

Хәлләрнең ничек икәнен белү белән без, комиссар белән икәү, киңәштек тә гитлерчыларны тар-мар итү һәм малайны коткару өчен авылга сугышчылардан кечле бер группа җибәрергә карар кылдык. Бу авылда фашистлар гарнизонының зур булмавы безгә мәгълүм иде.

Авылга без бәреп кердек. Гитлерчылар качты. Әмма Шуриккны коткарырга соңга калганбыз. Нәни геройны фашистлар инде атып өлгергәннәр иде. Палачлар аның гәүдәсен аягыннан агачка асып куйганнар һәм «Партизаннар белән элемтә тоткан өчен» дип язган такта беркеткәннәр.

Шурикны без олылап күмдек һәм фашистлардан аларның барлык явызлыклары өчен үч алырга ант иттек.

Саня безнең отрядта әле бик озак хезмәт итте, иң кыен һәм хәтәр бурычларны кыю рәвештә, үзенә хас тапкырлык белән башкарып чыкты. Сугыш бетәргә күп калмаган иде, кыз үзләренең авылына кайтып китте, соңыннан ул Остров шәһәренә күчеп килде.

## Соңгы операция

Безнең отряд фронт штабы өчен разведка мәгълүматлары җыюны дәвам итте, тимер юлларда һәм таш юлларда диверсияләр ясады, засадалар оештырып, олы һәм кече «тартарарамнарны» эшли торды, зур булмаган авылларда фашист гарнизоннарын, аларның складларын һәм комендатураларын тар-мар итте. Әллә ни зур операцияләр түгел иде болар, әмма ул заманда, сентябрь аенда, алар бик тә кирәк һәм мөһим иделәр. Ленинградка ыргылган гитлерчыларга без чын-чынлап зыян китереп тордык, аларның сугыш көчләрен бүлгәләдек, игътибарларын читкә юнәлттек, дошман тылындагы шартларны фронт командованиесенә җиткереп, ориентация ясарга мөмкинлек бирдек. Ленинград өлкәсенең оккупацияләнгән районнарында безнеке кебек ише отрядлар шактый иде.

Көз азаклары иде, безнең разведчиклар гитлерчылар гарнизоны урнашкан авылдан сигез йөз метрлар ары сугыш кирәк-яракларының зур бер склады барлыгын белеп алдылар. Шундук без фронт штабына хәбәр иттек һәм үз көчебез белән складның көлен күккә очырырга әмер алдык. Гитлерчылар безнең кайда икәнебезне белеп калмасын һәм сакны көчәйтмәсен өчен мөмкин кадәр тизрәк һәм кыюрак хәрәкәт итәргә кирәк иде. Разведчиклар, каравылны кайчанрак алыштырганны күзәтеп, ул хакта миңа хәбәр иттеләр. Каравыл алышкан чакта һөҗүм оештырырга дигән нияты карарга килдек.

Шул ук көнне кич белән, караңгы төшүгә, Александр Птицын һәм Александр Карпов җитәкчелегендәге партизаннар складны чолгап алып, тавыш-тынсыз гына каравылны алдылар. Складта төрле калибрдагы артиллерия снарядлары һәм мина снарядлары саклана икән. Шуларның барысы күккә очты. Гаҗәеп бер фейерверк барлыкка килде, ул безнең дошман тылында алып барган разведка-диверсия эшебезгә гүя йомгак ясагандай булды.

«Йомгак» сүзен куллануым юкка түгел. Кыш җитү белән тау институты отрядын яңадан формировать итү өчен «Зур җиргә» чыгарырга командование әмер бирде. Аның составына диңгез пехотасы сугышчыларын һәм берничә дистә җирле партизаннарны китереп куштылар. Отрядка башка бурычлар йөкләнде. Октябрь тимер юлы сызыгыннан Волхов фронты сызыгының теге ягына урнашкан районга чыгып, без Ленинградтан еракта, дошманның эчкәргерәк тылында хәрәкәт итә башладык.

Әдәби язманы Гариф АХУНОВ эшләде.

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

## В. НУРУЛЛИН. Төкле аягың белән. Хикәяләр. Казан. 1969 ел

Вакыйф Нуруллинның «Төкле аягың белән» дигән китабында 12 хикәя басылган. Иң әүвәл, ул хикәяләр кыска һәм җыйнак язылулары белән аерылып торалар. Автор тормышта очрый торган яисә очрау ихтималы булган теге яки бу вакыйганы тотып ала да, аны үз фантазиясе белән баетып, һәркем мавыгып укырлык әдәби әсәр тудыра. Вакыйф Нуруллин хикәяләренә җинелчә юмор, тел җорлыгы хас. Ул беренче карашка бик гади булып күренгән геройларның матур эшләрен, эчкерсезлеген, гадилеген сурәтли белә. «Юаш Садыйк» хикәясендәге Садыйк һәм Фания, «Лотерея билеты»ндагы Шәһидулла абзый, «Кайда син, Фәрит» новелласындагы немец карты Карл, «Уеннан-уймак»тагы саф күңелле һәм тиз ышанучан Галия, «Кияү Латыйп»тагы шаян һәм хәйләкәр Рәзия образлары, һичшиксез, автор тарафыннан белеп һәм яратып иҗат ителгәннәр.

Вакыйф Нуруллин өчен тагын шунысы характерлы: ул бервакытта да үзе белгән барлык нәрсәләрне бер хикәягә тутырып бетерергә тырышмый. Аның хикәяләрендә тормышның аерым бер кисәге, аерым бер эпизоды алына һәм ул акрынлап үстерелә, көчәйтелә бара. Дөрес, кайбер хикәяләренең ахыры табылып җитмәгән шикелле. Ләкин моның өчен авторны битәрләргә ашыкмыйк. Чөнки язучы һәр хикәясеннән соң укучыга уйланырга, аңа үзенчә фикер йөртергә урын калдыра. Тәҗрибәле, сизгер укучыга Вакыйф хикәяләрендә эчке агым барлыгын тою авыр түгел.

«Төкле аягың белән» җыентыгында «Җирдә кемнәр генә яшәми» дигән артык озын һәм әдәбиятыбызга берничи дә яңалык алып килми торган хикәя дә басылган. Ул кызыклы гына темага язылган булса да, бик ясалма чыккан. Бигрәк тә аның соңгы битләрендә полковник Сәхип белән Имаметдин мулланың очрашу күренешен беркатлы тасвирлау күңелдә ризасызлык хисе тудыра.

Әдәбиятыбызга үз тавышы белән килүче бу яшь автор үзенең иҗатында кызыклы гына үсеш чоры кичерә. Бу исә үз нәүбәтендә өлкән әдипләребездән һәм тәнкыйтьчеләребездән аның иҗатын даими күзәтеп баруны сорый.

## Пионер сәхнәсе. Коллектив җыентык. Казан. 1969 ел

Татарстан китап нәшрияты һәр ел саен олы һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен «Пионер сәхнәсе» дигән җыентык чыгарып килә. Безнең алдыбызда шул сериядән өченче китап. Җыентыкның кереш өлеше шагыйрь Рәшит Гәрәйнең «Партиягә» исемле шигыре белән башланып китә. Гарәй Рәхим, Заһирә Гомәрова, Мөхәммәт Садри һәм Резеда Вәлиеваларның шунда ук урнаштырылган шигырьләре юлбашчыбыз В. И. Ленинга, Бөек Октябрьга, комсомолга багышланып язылганнар.

Шунысы күңелле: «Пионер сәхнәсе»нең бу санында мәктәп сәхнәләре өчен язылган пьесаларга, әдәби-музыкаль монтажларга киңрәк урын бирелгән. Ул әсәрләрнең барысы да, бергә тупланып, аерым бүлеккә урнаштырылган. Укучы биредә Мирхәт Хөснимәрдановның «Йөз кырык җиденче» дигән дүрт пәрдәлек пьесасы, өлкән әдибебез Нәкый Исәнбәтнең «Быелтыр кысты» исемле бер пәрдәлек әкияте, Аяз Гыйләҗев һәм Альберт Яхиннарның «Шәрил Усманов» исемле драмасыннан өзекләр, Туфан Миңнуллинның «Иптәш командир», Рифкат Исмәгыйловның «Еллар үткәч» пьесалары, Касыйм Фәсәхов һәм Гәрәй Рәхим тарафыннан төзелгән әдәби-музыкаль монтажлар белән таныша ала.

«Шигырьләр, мәсәлләр» һәм «Нәни хикәяләр» дип исемләнгән бүлекләрдә сәхнәгә чыгып сөйләү өчен кызыклы әсәрләргә шактый урын бирелгән. «Нәни хикәяләр» бүлеге Хуҗа Насретдин мәзәкләре, аерым алганда, түбәндәге мәзәк белән ябыла:

«Күрше баласы хуҗаның баласына:

— Кара, кара, әтисе итекче, ә үзе ялан-аяк йөри,— дигән.

— Синең әтиең теш докторы, ә авызыңда бер тешең дә юк, дигән хуҗасының баласы».

Балалар өчен чыгарыла торган җыентыкларда аларга атап язылган яңа җырлар даими бирел барыла. «Пионер сәхнәсе»нең әлеге санында да Фәтхерахман Әхмәдиевнең «Кышкы көндә», Әхмәт Хәйретдиновның «Учак янында» дигән җырлары басылган. Күңелгә ятышлы ул җырларның сүзләрен Фәнис Яруллин һәм Заки Нури язган.

Китапны Т. Нурмөхәммәтов редакциялэгән. Җыентыкның яхшы сыйфатлы, бай эчтәлекле булып чыгуы өчен редакторның күп көч куйганлыгы сизелә.

**Х. САРЬЯН. Күңел моңнары. Хикәяләр. Казан. 1969 ел**

Моннан берничә ел элек Хәсән Сарьянның «Әткәм һөнәре» дигән повесте аерым китап булып басылып чыккан иде. Өлкән яшьтәгеләргә атап чыгарылган «Күңел моңнары» исемле бу җыентыгына язучының яңа хикәяләре тупланган. Ул хикәяләренең «Паку», «Бала хакы», «Төнге каравылчы» исемлеләре күңелдә аеруча дулкынландыргыч тәэсир калдыра. Аларда без укытучы Гөлләрнең тынгысыз әнисе, бик яшьли вафат булган әтисенә бөтен фигыле-холкы белән охшап үскән улы Рәмил хакына ялгыз гомер кичерүче Әнүзә, сугыш кырында ике аягын да югалткан, әмма бер генә минут та эшсез тора алмаган Хәнәфи агай кебек олы җанлы, кече күңелле кешеләр белән танышабыз. Автор үзенең кире персонажларын сурәтләгәндә дә тапталган юл белән китми, аларда әшәке сыйфатлар туугa сәбәпче булган вакыйга һәм күренешләрнең асылына төшенеп эш итәргә тырыша. Менә шуңа күрә аның кире геройлары да нәкъ тормыштагыча тулы канлы булып чыкканнар.

Хәсән Сарьян хикәяләренең тагын бер үзенчәлекле ягы турында әйтеп китәргә кирәк. Аларга сюжет төзеклеге, җыйнаклык һәм җиңелчә юмор хас. «Чишмә буенда», «Хәбетдиннең ике хаты», «Чуар тавык», «Ихтыярсыздан шаһит» хикәяләре укучының игътибарын үзләренең әнә шул матур үзенчәлекләре белән җәлеп итәләр. Х. Сарьян үз әсәрләренең теле өстендә эшләүгә зур әһәмият бирә. Аның хикәяләрендә әсәрнең күләмен арттыру өчен генә язылган җөмләләр, башкаларны шаккатыру өчен кулланылган купшы сүзләр бөтенләй диярлек очрамый. Боларның барысы бергә җыентыкка кергән хикәяләрне үтемле, җиңел укылышлы итә.

Дөрес, бу китапта әйбәт эшләнгән, укышлы хикәяләр белән бәрабәр, «Буш кубык», «Ул», «Миңләхмәт мәшәкате» кебек сүлпәнрәк язылганнары бар. Ләкин алар җыентыкны укып чыкканнан соң укучы күңелендә туган гомуми җылы тәэсирне суыта алмыйлар.

**Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Гашыйк. Шигырьләр. Казан. 1969 ел**

Яшь шагыйрь Фаил Шәфигуллин исеме поэзия сөючеләргә байтактан таныш. «Беренче карлыгачлар»ның тәүге китабында чыккан шигырьләрендә үк инде Фаилнең поэзиябезгә үзенчә аһән белән килүен сизәргә мөмкин иде. Аның узган ел ахырында Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Гашыйк» исемле җыентыгы бу тойгыны тагын да көчәйтә төшә.

Җыентык «Унҗидедә» һәм «Минем күзгә» исемле кечкенә-кечкенә ике бүлектән тора. Беренче бүлек «Гасыр уртасында» дигән шигырь белән ачыла. Бу шигырьдә «хаклык, ирек өчен көрәшеп үлгән» каһарманнарның бүген дә безнең сафта атлап барулары хакында сөйләнә, аларны курку белмәс көрәшчеләр итеп тәрбияләгән һәм еллар үткән саен безгә якыная барган бөек Ильичның үлемсезлеге тасвирлана.

> **Ал калалар, ГЭС, бакчалар — бар да**
> **Аның изге фикере.**
> **Ул тормышка үлмәс Прометей һәм**
> **Данко булып керде,—**

ди автор шигыренең Ленинга атап язылган өлешендә. Шигырь сөекле юлбашчыбызның һаман да безнең арабызда яшәвен чагылдырган образлы һәм тирән мәгънәле юллар белән тәмамлана. Ирек өчен, кешелек бәхете өчен көрәш темасына яшь әдип үзенең башка шигырьләрендә дә мөрәҗәгать итә. «Сиксән яшьлек Тукай», «Болай гына күзләр йомылган» шигырьләрен ул утыз яшькә дә житмичә дөнья куйган Тукай һәм Лермонтовка багышлый. Әлеге шигырьләр укучы күңелендә бу бөек җырчыларның ирекка чакырып яңгыраган көр тавышларын томаларга омтылган кара көчләргә карата чиксез нәфрәт уята. Җыентыкның беренче бүлегендә хезмәттә һәм яшьлектә туган хисләрне чагылдырган шигъри парчалар белән дә танышырга мөмкин.

Фаил Шәфигуллин — илебезнең ерак диңгез чикләрендә хезмәт итеп кайткан егет. Шуңа күрә аны күп кенә шигырьләрендә диңгезчеләр тормышы, диңгез күренешләре сурәтләнүе бик табигый. Андый шигъри этюдларның кайберләренә әлеге җыентыкта да шактый урын бирелгән.

«Минем күзгә» бүлегенә яшь шагыйрьнең «Вәли Батыр», «Бәхетсез машина бәете», «Сыра сатучы», «Мәрхәмәтле егет», «Минем күзгә» һәм «Ир хәсрәте» исемле юмористик шигырьләре урнаштырылган. Аларда автор мактанчыклардан, эш сөймәүчеләрдән, урынсызга көнләшеп яшәүчеләрдән көлә, тормышта очрый торган кайбер башка кимчелекләрне фаш итә.

Күләме белән әллә ни зур булмаган бу җыентык Фаил Шәфигуллин иҗатының житдилеге, камилләшә баруы турында сөйли.

**Г. АФЗАЛ. Илле адым. Шигырьләр. Казан. 1970 ел**

Үзенең күп санлы лирик һәм юмористик шигырьләре белән поэзия сөючеләрнең күңелен яулап алган шагыйрь Гамил Афзалның яңа җыентыгы басылып чыкты. Җыентык «Илле адым» дип атала һәм шул исемдәге шигырь белән ачыла. Бу шигырьдә, коллык богауларын өзеп ташлап, яңа тормыш төзүче азат кешенең куанычлы авазы яңгырый:

> **Бөек Ленин уйларыннан**
> **ялкын алып,**
> **Юлларымның ай үтсен**
> **көнен үтәм.**

**Талгын Идел ярларында**
**утлар ягып,**
**Тыныч тормыш дастаннарын**
**иҗат итәм.**

Шагыйрь лирик геройның көчле рухын, үзе атлап барган юлның дөреслегенә ахыргача инанганлыгын чагылдырган әнә шундый юллар белән тәмамлана. «Ленин солдатлары» шигырендә әдип Ильичның үзеч күргән һәм халыкларга азатлык бирү юлында корбан булган революция каһарманнарына дан җырлый.

Гамил Афзалның күпчелек шигырьләренә туган җиренең матурлыгына, аның табигатенең хозурлыгына карап соклану хас. Шагыйрь «бакчадай илләр эчендә» елмаеп туган «чалт аяз көннәргә», бодай басуларында дулкын кагып искән җиләс җилләргә, «лапаслар өстеннән ай чыккан гармунлы кичләр»гә гашыйк. Ләкин табигать күренешләрен шигырьдә тасвирлап күрсәтү аның өчен үзмаксат түгел. Ул күренешләргә Гамил Афзал кешенең эчке дөньясын тирәнрәк ачып бирү өчен мөрәҗәгать итә. Моның шулай икәнлеген «Рәхмәт», «Күзем ачтым, тәпи бастым», «Күксел таулар буенда», «Сагындым», «Салкын җилгә сибеп яфракларын», «Уйландыра торган чак», «Язбикә» һәм «Тирәк» шигырьләрен укыганда бик ачык тоясың.

«Илле адым» җыентыгында без шагыйрьнең соңгы елларда язган юмористик һәм сатирик шигырьләре белән дә танышабыз. Ул шигырьләр арасында «Вәсвәсәле уйлар», «Тәкый гаҗәп дыңнары», «Шомакойрык белән Сарытырнак диалогы» дип аталганнары тормышта очрый торган кире типларга карата укучы күңелендә ачу хисе уята.

Китапның тышлыгына каләм һәм штык рәсеме төшерелгән. Бу символик рәсемдә халыкларның якты киләчәге өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшүче җырчы һәм солдатның уртак максаты — җиренең гүзәллеген һәм иминлеген саклап калу максаты гәүдәләнә. Җыентыктагы шигырьләрдә иминлек сагында торган көрәшчеләрнең нәкъ әнә шул матур теләкләре үзенең поэтик чагылышын тапкан.

**Без бергә. Коллектив. Шигырьләр. 1969**

Поэзиядә инде үз көчләрен күптәннән сынап караучы дүрт авторның бу коллектив җыентыгы «Без бергә» дип атала. Шигърият мәйданына бергә аяк атлаган Әзһәр Габиди, Рамазан Байтимир, Маннур Саттаров һәм Хәйдәр Гатин үз иҗатларында үзләренә якыннан таныш булган, үзләре яхшы белгән темаларны яктыртырга тырышалар. Әзһәр Габиди, мәсәлән, күбесенчә, туган җир, аның матурлыгы, шунда бөреләнгән мәхәббәтнең орлыгы, сафлыгы турында яза. Аны бербергәрен эзләп тапкан ике гашыйкның тигез мәхәббәте шатландыра, яу кырында газиз улларын югалткан аналарның сагышы җанына тынгылык бирми.

**Урманнарда алан,**
**Аланнарда балан.**
**Йөрәгемдә яши**
**Яуда үлгән балам, —**

ди ул «Аланнарда балан» шигырендә чал чәчле ана исеменнән. Әзһәр Габидинең хезмәт кешеләренә, аерым алганда нефтьчеләргә багышланган шигырьләре арасында да шактый уңышлы эшләнгәннәре бар.

Рамазан Байтимир шигырьләрендә замандашларыбызның патриотик хисләре, аларның киләчәк көннәргә тоташкан уйтеләкләре чагыла. Шагыйрь һаман үсә, күтәрелә барган Казанны күреп соклана, кыю сафлар биек күтәреп барган байракка карап горурлана, үзен шул сафларда атлаучы бер солдат итеп тоя. Аның «Соңгы сүз» шигырендә изге яу кырында батырларча һәлак булган сугышчының иң мөкатдәс уйлары тасвирлана. Шигырь менә мондый юллар белән тәмамлана:

**Пилоткалар кинәт салындылар,**
**һәм башларны түбән идек без.**
**Әйтте солдат, әйтте соңгы сүзен:**
**— Коммунистча... Шулай диегез.**

Җыентыкка кергән әдипләрдән Маннур Саттаровны укучы юмористик һәм сатирик шигырьләр авторы буларак белә. Бу китапка да аның иҗатына хас булган әнә шундый әсәре сайлап алынган. «Тамаша», «Малай класста калгач», «Бюрократ абзы», «Бала ашату», «Потыш акчасына», «Мәхәббәткә өндәү» шикелле шигырьләрен укыганда Маннур Саттаровның уңышы чыннан да сатира-юмор өлкәсендә икәнлегенә тагын бер тапкыр ышанасың. Юмористик планда язылган шигырьләрне без Хәйдәр Гатин иҗатында да очратабыз. Моңа мисал итеп аның алеге җыентыктагы «Дөрес эзләмә», «Куючысы кемнәр була», «Бригадир хөкеме» һәм «Сөзгәк үгез» шигырьләрен китерергә була.

Яшь шагыйрьләрнең иҗат үрнәкләрен бергә туплап чыгару Татарстан китап нәшриятының беренче тәҗрибәсе түгел. Мондый җыентыклар элек тә чыккалады. Аларның кайберләрендә авторларның кыскача биографияләре һәм рәсемнәре дә бирелә иде. Ләкин «Без бергә» китабын чыгарганда нәшрият, ни өчендер, үзенең бу матур башлангычын дәвам иттермәгән. Ә бу бик кирәк иде.

**В. А. Климентовский**

# А. Н. РАДИЩЕВ

«Радищев... рус крестьяннарын изгән бөтен иләмсезлекне, бөтен авырлык һәм хокуксызлыкны башлап күрүче булды...»

*(М. Горький. «Рус әдәбияты тарихы».)*



Александр Николаевич Радищевка (1749—1802) хәзерге Татарстан җиреннән ике тапкыр узарга туры килгән. 1790 елда аның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» дигән атаклы китабы дөньяга чыга. Анда ул крепостной крестьяннарга карата кыргый башбаштаклыкның коточкыч күренешләрен тасвирлый һәм крепостнойлыкны революцион юл белән юк итәргә өнди. Моның өчен аны Екатерина II «Пугачевтан да яманрак гыйсъянчы» дип атаган һәм ун елга Себернең караңгы Илим шәһәренә сөргенгә озаттырган. Шунда барышлый (1790 елның ноябрь башында) ул Казанга кагыла. Аннары Пермь, Тобол, Томск, Иркутск аша Илимга юнәлә.

Яшь чагыннан ук кызыксынучан табигатьле Радищев, балалары белән аерылу һәм рухи тетрәү кичерүенә карамастан, әлеге мәҗбүри сәяхәте вакытында илнең иксезчиксез киңлекләре белән танышырга омтылган. Соңрак ул бу турыда болай дип яза: «Минем бик яшь чагымда ук ерак сәяхәткә чыгасым килә иде. Себерне күрү теләге аеруча зур иде. Бик рәхимсез рәвештә булса да, теләгем чынга ашты». (М. Муратов. «Радищевның тормышы». Детгиз. М. Л. 1949 ел.)

Радищев юлда вакытын бушка үткәрмәгән. Фельдъегер сагы астында барса да, күргәннәрен һәм ишеткәннәрен тукми-чәчми язып барган.

Аның шул чакта язган «Себергә сәяхәт язмалары» исемле көндәлеге безнең көнгәчә сакланган.

Радищев уз язмаларында Илимга барышлый үзе узып киткән станцияләрнең исемнәрен, алар арасындагы ераклыкны, геологик, этнографик һәм статистик күзәтүләрен, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы тасвирламасын, тарихи мәгълүматларны теркәп барган. Юл уңаенда ул крестьян өйләренә кагылып чыккан, җирле крестьяннарның көнкүреш һәм культура үзенчәлекләрен күзәткән. Крестьян өендә кунып чыкканда, ул хуҗалардан нинди кәсеп белән шөгыльләнүләрен дә сорашкан. Мәсәлән, әдип үзенең көндәлегенә элекке Казан губернасы авыллары һәм шәһәрләре хакында түбәндәгечә язган:

«1790 елның 11 ноябре.

Казаннан чыгып, кырлар, уйсулыклар, аланнар аша дворян авылы Берелегә килеп җиттек. Әллә ни чаклы исереклар Михаил архангел бәйрәменә җыелган иде. Атларны тиз бирмәделәр. Бикә моннан 30 чакрымдагы попка кунакка киткән иде.

12 се.

Арчага көндезге өчтә килеп җиттек. Ул Казанка буенда биек тау өстенә урнашкан.

Борынгы агач манаралар тора әле. Бер агач чиркәү бар. Халык җир сөрә һәм олаучы булып йөри. 26 чакрымда Арбаш[1] дигән татар авылы, 19 чакрымда Янгул[2] авылы бар.

Елга буйларында татар авыллары күп. Йөрек биш чакрымда...» [А. Н. Радищев. Сайланма әсәрләр. М. Л. 1949 ел.]

Соңрак Радищев үзенең искәрмәсендә шул ук Йөрек авылын искә алып болай ди: «Йөректә татар түрәсендә кунып чыктык. Ул һәр авылда ел саен 20 сумнан кимрәк булган эшләрне карау, хәтта урлауларны хөкем итү өчен сайлап куела. Ә зуррак низаглар булса, судка баралар. Уголовныйларны судка җибәрергә кирәк иде, ләкин судка үтерүчеләрне генә җибәрәләр; корыәи буенча хөкем итәләр».



В. А. КЛИМЕНТОВСКИЙ ◆ А. Н. РАДИЩЕВ ◆

1790 елның 13 ноябрьдагы язмасында болай диелә:

«Урман эченнән бардык; наратлык азрак, күбрәк чыршы, имән, каен, усак һәм шуның кебекләр. Татарлар ат алыр өчен Эрбеткә, Оренбургка, Семипалатинскига һәм Усть Каменогорск крепостена баралар...

Йөректән Вятка елгасына тугыз чакрым. Янгулда дала төлкесе койрыгыннан эшләнгән ике катлы юрган саталар иде. Тугыз тәңкә сорыйлар. Татарлар, чирмешләр, чувашлар тау итәкләренә һәм үзәнлекләргә утырганнар. Руслар тау өстенә. Чуваш һәм чирмеш өйләре кара, әмма андагы һава рус өйләрендәгедән сафрак, чөнки ишек алдыннан ук чолансыз-нисез өйгә керәсең. Алар суыкны ярата...

Татарларның өйләре ак, түрдә алды ачык кечкенә мич утыра.

Татарлар урманда аю, бүре, төлке, куян, тиен һәм сусар аулыйлар...

Вятка кичүе өстендә Юшков әфәнде карамагындагы рус авылы урнашкан, мужиклар фәкыйрь, өйләр тузган.

Вятка елгасының ике ягы урман, күбесенчә чыршы, елганың киңлеге. Нева сыман, 80 яки 100 саженьнар чамасы, елга аръягында биек, ләкин сирәк наратлык».

Радищев 1797 елда сөргеннән азат ителә һәм Илимнан кайтырга чыга.

Юлда салкын тидереп, 1797 елның 7 апрелендә Тобол шәһәрендә аның хатыны үлә.

Казан губернасыннан икенче мәртәбә узып киткәндә күргәннәрен ул «Себер буйлап сәяхәт көндәлеге»ндә шактый тулы тасвирлый, уннарча шәһәр һәм авылларны телгә ала.

«1797 елның 10—15 май арасы.

Пермьда И. Д. өендә шактый күңелле вакыт кичереп, хатлар алгач, Кама буйлап Лаешка чаклы йөзәргә килештем; төштән соң кузгалып киттек...

1797 елның 20 мае.

Кояш чыкканчы кузгалып, Агыйдел тамагын хәвеф-хәтәрсез уздык. Кама киңәя бара, ә су быел бик биек күтәрелгән.

Кама буенда авыллар күп. Ун чакрымга бер авыл да күренмәгән очрак аз. Бүген беренче тапкыр балык китерделәр, сөт, күкәй табуы читен. Барын да бушлай алырга яратучан хәрбиләрдән куркалар.

Агыйдел тамагында Кама бик җәелеп киткән, Ык тамагында да шулай ук. Бу елгалар Камага сулдан коялар.

---

[1], [2] Хәзерге Балтач районы авыллары.

Биек уң ярда, Ык койган җирдә, Ык-тамак[1] авылы утыра.

Шул ук якта, арырак, Каманың тарайган тирән тын җирендә Тихие горы[2] авылы урнашкан.

Аннары уң якта Чаллы[3] авылы бар. Ә читтәрәк Татар Чаллысы. Ык һәм Агыйдел тамаклары буенда болыннарны 20 чакрымгача су баскан. Ул болыннар татарларныкы булып, соңгылары аларны түләү барәбәренә вакытлыча файдалануга тапшырып торалар.

Чаллыга өч чакрым җитмәстән, якорь салдык. Чаллыда ашлык алмакчы идек, ләкин... булмады».

Радищев юл өстендәге һәр шәһәрнең һәм авылның үзенчәлекләре белән кызыксынган.

Көндәлегенең 1797 ел 21 май сәхифәсендә болай диелгән:

«Кояш чыкканчы якорьны күтәреп, Чаллы яныннан үтеп киттек, аннары сул яктагы Бәтке авылы турыннан уздык.

Елга бу урында уңга борылып, Камадан ике чакрым ераклыктагы Алабуга буеннан уза.

«Шайтан каласы». Алабуга турысындагы зур ташлы тауга менгәч, мин манара сыман бинаның ике бүлемнән торганлыгын күрдем. Аның түшәме инде җимерелгән, матча урыннары гына күренеп тора. Биеклеге дүрт, аркавы ике саженьнан әз генә артыграк булган ул корылма түгәрәк, аскы ягында ишекләр, ишек өсте комлы йомшак таштан эшләнгән... Өстә бер тәрәзә, икенчесе манарага уелган, икенче катының биеклеге сажень чамасы, буе өч сажень булып, түрдә диаметры саженьнан артмаган гыйбадәт урынына охшаш түгәрәк бүлмә бар.

Бина известьлы ташлардан салынган, ә эре алебастр төерләре белән кушып изелгән цемент һәм известьны җил ашаганлыктан, бина тишекләнеп беткән. Бинаның эчтән дә, тыштан да штукатурланган булуы күренеп тора, эчтә калку штукатура сызыкларын әле дә күрергә мөмкин, тәрәзә тыштан кәрнизләнгән».

Алга таба автор болай дип яза:

«Шунда бер яшь чичероне (юл күрсәтеп йөрүче, В. К.) очрап, ул бу бинаның гүяки шайтан тарафыннан төзелгәнлеген, дини идарәдә шул хакта язу барлыгын, ныгытманы кайчандыр бер баһадир алырга маташканлыгын, ә якынаю белән аның аягын кискәнлекләрен һәм ул аякның хәзер дә чиркәү ишеге төбендә сакланганлыгын түкми-чәчми сөйләп бирде.

Берничә чакрым арырак китеп, урманда тау уртасыннан ага торган Изге чишмәне карарга бардык. Чишмә тау түбәсеннән мул булып агып чыга. Чишмә турысында чокыр ясап, төбенә бур таш түшәгәннәр. Шунда кечкенә чиркәү тора, су алыр өчен чүмеч куелган. Чокырдан өч бармак киңлеге, бер карыш тирәнлеге улак үткәрелеп, су шуннан Камага агып төшә.

Суы үтә саф һәм тәмле...

Чишмәдән сулга борылып, тарлавыкка урнашкан Синтәк[4] авылына чаклы Каманың тар җиреннән бардык. Монда юан агачны чокып көймә ясыйлар. Андый тоташ бер агачтан эшләнгән көймәләрне күпләп алалар. Безнең кәрванга да һәркайсы өч һәм бишәр тәңкәлек 20 көймә сатып алынды.

Бу авылдан ары кайчандыр Шувалов Петрныкы булган Воткинск заводларына караган Котловка[5] авылы бар. Анда дегет агызып, аны Астраханьга чаклы илтәләр.

Свиногорье[6] авылына барып җиткәч, ярга туктадык. Кәрваннар өчен иң күп көймә монда сатып алына. Авыл Каманың биек ярына салынган. Ул Россиянең барлык авыллары кебек үк зур.

Тирә-якта бик күп ашлык кибәннәре күренә».

Радищев көндәлек язмасында «Шайтан каласы» турындагы искәрмәгә Алабуга хакында да мәгълүматлар өсти: «Алабуга шәһәре шактый зур, Кама култыгының урта ярына урнашкан, ә Алабуга елгасы шәһәрнең сул ягыннан үтеп, Камага уңнан коя».

[1] Хәзерге Алабуга районына керә.

[2] Хәзерге Алабуга районына керә.

[3] Хәзерге Чаллы шәһәре.

[4], [5], [6] Хәзерге Алабуга районы.

Радищев көндәлегендә хәзерге Мамадыш районы авыллары һәм Чистай шәһәре дә телгә алына. 1797 елның 23 маенда ул болай язган: «Кояш чыккач кузгалып киттек. Ләкин Омар[1] дигән зур авылны узып аз гына киткәч, яссы ташлардан торган биек яр кырыена туктадык... Яр буенда юлбасарлар чокыры таптык. Аның уртасында ташлардан учак урыны өелгән...

Кичкә чаклы диярлек торганнан соң, тын һавада тагын юлга чыктык. Туйкә, ягъни Покровское авылын узып киттек. Монда казна кораблары төзү өчен имән тәйкиләр. Аз гына җилләс тын һавада төн буе йөзеп Чистай шәһәре янынннан үттек. Аннан Россиягә бик күп икмәк озатыла...»

Радищев утырган баржа 1797 елның 24 май таңында, хәзерге Балык бистәсе турыннан үтеп, кичкә Лаешка килеп җитә.

Радищев, кәрванның Лаешта туктавыннан файдаланып, туганнарыннан көмие дә булса күрү өмете белән, атка утырып Казанга китә. Көндәлегендә ул хакта болай диелгән:

«1797 елның 25 мае.

Казанга киттем. Лаештан 57 чакрым. Юл борынгы имән урманы аша уза. Карама, юкә, зирек, каен, чикләвек һәм башка агачлар үсә. Чәчәкләре әле аз. Арыш көпшәләнә. 11 чакрым үткәч, Мишә елгасы аркылы кичү бар. Елганың киңлеге 10 сажень булса да, су ярты чакрымга җәелгән, куаклар арасыннан йөзеп үтәләр.

Монда полковник чинындагы Бохара илчесен очраттык. Ул узган ел фил алып килгән.

Икенче ярда патша авылы Покровское. Ямщик анда үзенең каенатасына кереп чыкты.

Монда юл иген кырлары аша үтә; күп кенә авыллар күзгә ташлана, нинһаять, сулда Идел һәм аның каршы яктагы биек яры күренә...

Таудан төшкәч, Казанга килеп җитәсең. Авылларның күренеше шәптән түгел, өйләр дә Себердәге сыман похтә түгел».

1797 елның 26 май иртәсеннән Радищев Казан белән җентекләбрәк таныша: «Иртәдән бирле Казан буйлап сәяхәт иттем... шәһәр буйлап исем китеп диярлек йөрдем».

Радищевның китап кибете һәм газеталар турындагы көндәлек язмаларыннан чыгып шуны әйтергә мөмкин: ул үзенең яраткан китаплары һәм газеталары, фәнни һәм матур әдәбият яңалыклары белән нәкъ менә Казанда танышкан.

27 майда, су транспорты белән эш итүче начальник янында булганнан соң, икенче көнне иртән Радищев Лаешка әйләнеп кайта: «Лаеш Кама Тамагыннан 30, Казаннан 57 чакрымдагы бер кечкенә шәһәрчек.

Урамнары төз.

Бер генә юньле йорт та юк.

Яр буенда берничә кибет салынган, анда Казан сәүдәгәрләре үзләренең товарларын саталар...

Монда халык бик күп...»

1797 елның 3 июнендә кәрван Лаештан кузгалып китә, ә 4 июньдә Радищевның Кама буйлап сәяхәте тәмамлана, чөнки Богородское авылы янында кәрван Иделгә килеп чыга.

Иделнең көймәләр йөри торган таулы ягына күчеп, кәрван Богородское авылы турында кунарга туктый.

5 июньдә кәрван Монастырское[2] авылы янында туктый. Радищев яшеллеккә чумып утырган ул авылны барып карап кайта.

6 июньдә кәрван Теньки авылыннан ераграк урнашкан тау буена барып туктый. Бу авыл, якындагы күпчелек авыллар кебек үк, Нарышкин исемле ак сөякнеке була. Моннан соң көймәне бурлаклар тартып китә.

Теньки, Ослан һәм Казан тирәсендә Радищев Идел бурлакларының авыр хезмәтен күрә, аларның сагышлы җырларын ишетә. Көндәлегенә ул болай дип язган: «Чирләп калган күп хезмәтчеләрне күрдем, аларга пашпорт бирмиләр, кыерсытулар күп.

[1] Хәзерге Мамадыш районы.

[2] Хәзерге Кама Тамагы районы Красновидово авылы.

Осланда каядыр барып килгән өчен хезмәтчене рәхимсез кыйнаганны күрдем.

Хезмәтчегә сәгатенә 25 тиен түләү һәм аңардан көнгә 50 тиен тотып калу турында килешенгән булса да, алар бушка озак көтеп торырга мәҗбүрләр».

Бу язмалар Радищевның сөргендә дә «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» әсәрендәге идеяләрдән баш тартмавы турында сөйли. Ул сөргенгә барганда ук язган бер шигырендә болай дип әйткән:

Беләсең килсә минем кемлегемне —
Мин бер мәхлук, агач, кол түгелмен,
Үз-үзеннән баш тартмаган бер кешемен.

*(Муратов. «Радищевның тормышы».)*

Башка сәяхәтчеләрнең көндәлекләрендә без Радищев фикерләренә тартым бүтән язмаларны күрмибез. Мәсәлән, консерватив карашлы шагыйрь В. А. Жуковский элекке Казан губернасы аша узганда аның гүзәл табигать күренешләренә генә сокланган. Халык тормышы контрастлары аның карашыннан читтә калган.

Югары Ослан тавы Радищевта көчле тәэсир калдырган. Ул 1797 елның 7 июнендә көндәлеккә болай дип яза:

«...Кичкә кырын ярга чыгып, олыларыбыз да, кечеләребез дә Ослан тавына күтәрелдек. Тауны авылдан өстәрәк куе чикләвек куаклары каплаган. Тауның текәлеге дә, урманның куелыгы да, черкиләрнең күплеге дә безгә күтәрелергә комачауламады.

Аның түбәсеннән гаҗәеп күренеш ачыла.

Тау артка таба сөзәкләнә башлый, уйсулыкта зур авыл бар.

Тирә-якта сөрелгән кырлар. Алар келәм булып еракка җәелә... Арырак киткән саен алар нәфис зәңгәр пәрдәгә өртелеп, бар әйберләр дә тоташ бер төскә әйләнә.

Идел аръягында җәелеп яткан сөзәк ярны куе урман каплаган, анда вак авыллар күренә. Куак араларында Идел суы ялтырый, комлы яр кырыенда балыкчылар төркеме җылым тарта.

Уң яктарак боргалана-сыргалана Казанка килеп кушыла. Калкулык өстендә агач ябалдашлары арасыннан Елан тавы монастыреның чиркәү манаралары, аның артында Казан күренеп тора.

Барысыннан да алда туп тишекләре уелган кремльнең ак диварлары күзгә ташлана.

Казанка һәм Иделдә көймәләр бик күп.

Казанка тамагында хәрби флот өчен яңа төзелгән бик күп көймәләр тора. Астраханьга озату өчен, баржаларга агач төяп яталар, түбәннән җилкәнле йөк көймәләре күтәрелә, аларның ерактагылары кояш нурларында ак һәм сары ярымшарлар булып күренә».

8 июньдә Радищев яңадан Казанга барып, Казанкадагы Адмиралтействоны, Болактагы пристаньны, Кремльне карап йөри, Елан тавы монастырендa була. 9 июньдә Радищев Осланны җентекләп карап чыга да юлын дәвам итә.

Көндәлекнең 1797 ел 10 июнь сәхифәсендә Зөя каласы турында шундый язмалар бар:

«Кояш күтәрелгәндә көймәбезне бурлаклар тартып китте. Зөя тамагында иртәнге ашны ашадык... Зөя каласы сул якта Иделнең бик үк текә булмаган ярында көймә юлыннан чакрым ярымда күренеп кала. Таш чиркәүләрнең күплеге аның күренешен бизи, ләкин күпәгәләр юк.

Бу урыннан арырак басулар, авыллар күренә. Тау янында Вязовое авылы утырган. Иделне кышын шуннан, язын Осланнан кичәләр.

Әгәр кайчан да булса Зөя каласында ныгытма корырга туры килсә, аны алу читен булыр иде».

Радищев Казан губернасының аерым шәһәр һәм авылларын, көндәлектән тыш, юлдан салган хатларында да телгә ала. Әдипнең язмаларыннан күренгәнчә, ул гомеренең азагынача хезмәт халкын «комсыз ерткычлар һәм туемсыз сөлекләр» җәбереннән коткару идеалына тугры калган. В. И. Ленин аны шуңа күрә рус халкының милли горурлыгы итеп санаган.

Н. ХИСАМОВ тәрҗемәсе

## Автономиябез тарихы

1919 ел, 12—13 октябрь — Мөселман коммунистлардан җаваплы работникларның Казан киңәшмәсендә Татарстан АССР төзү турында мәсьәлә тикшерелә.

1920 ел, 26 январь — Татарстан автономияле республикасын төзү мәсьәләсе РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы утырышында уңай хәл ителә.

1920 ел, 27 май — Татарстан АССРны төзү турында декрет чыга.

1920 ел, 25 июнь — Казан губерна башкарма комитеты үз властен Татарстан АССРның Вакытлы революцион комитетына (ВРК) тапшыра.

1920 ел, 23 август — Татарстан партия оешмасының 1 конференциясе була.

1920 ел, 26—27 сентябрь — Эшче, Кызыл Армия һәм крестьян депутатлары Советларының 1 учредительный съезды җыела.

1921 ел, 2—3 декабрь — Татарстан АССР Советларының Үзәк Башкарма Комитеты 1 сессиясе уза.

1921 ел, 2 август — Татарстан АССРның Дәүләт план комиссиясе оештырыла.

1924 ел, 8 май — Татарстанның административ бүленеше турында СССР Халык Комиссарлары Советы декреты кабул ителә.

1935 ел, январь — Советларның XVI Бөтенроссия съездында Татарстан АССР хөкүмәтенең отчеты тыңлана.

## Көрәш сулышы

1741 ел, 2 январь — Казан сукночыларының беренче забастовкасы була.

1774 ел, 12 июль — Пугачев явы Казан өчен сугыша һәм аның алдынгы частьлары Казанны ала.

1861 ел, 4—12 апрель — Бездна авылында крестьяннар восстаниесе була.

1862 ел — «Земля и воля» («Җир һәм ирек») оешмасының Казан бүлеге эшли башлый.

1878—1879 еллар — Казан губернасы крестьяннарының милли һәм хокукый изүгә каршы ачык чыгышлары булып уза.

1887, 4 декабрь — Казан университеты һәм ветеринария институты студентларының Владимир Ульянов актив катнашкан революцион сходкасы була.

1887 ел — Алафузов заводы эшчеләренең революцион чыгышы була.

1887 ел — Н. Е. Федосеев Казанда беренче марксистик түгәрәк оештыра.

1891 ел, 1 май — Алафузов предприятиеләрендә стачка була.

1892 ел — А. М. Стопани һәм Н. Э. Бауман оештырган социал-демократик түгәрәкләр эшли башлый.

1897 ел — Казанда беренче социал-демократик группа оеша.

1901 ел — Казан булочниклары стачка үткәрәләр.

1901 ел, 11 март — Казан эшчеләре һәм студентларының социал-демократик группа оештырган беренче политик демонстрациясе була.

1901 ел, 16 март — Паратск механика заводы төзелешендә стачка була.

1903 ел, январь — Казанда РСДРПның шәһәр комитеты оештырыла.

1903 ел, сентябрь — Казан трамвайчылары һәм Перов типографиясе эшчеләренең забастовкасы булып уза.

1905 ел, январь — Алафузов заводлары эшчеләренең забастовкасы була.

1905 ел, январь — Казан университеты студентлары забастовка оештыралар.

1905 ел, февраль — Казанга Я. М. Свердлов килә.

1905 ел, май — Игумнов урманында большевиклар оештырган маевка була.

1905 ел, июнь — Казан губернасының 125 волостеннан чакырылган крестьян вәкилләре җыелышы уздырыла.

1905 ел, август — Нижний Новгородта мөселманнарның беренче съезды уздырыла һәм ул «Мөселманнар Союзы» оештыра.

1905 ел — Крестовниковлар заводында, Мәскәү — Казан тимер юл эшчеләре һәм хезмәткәрләре арасында, Казан почтасы һәм телеграфында забастовкалар була, Алафузов театрында революцион митинглар оеша.

1906 ел, апрель — Буа өязенең Кече Чынлы авылында, Казан пристанендә, Бөгелмә өязенең Бәйрәкә авылында забастовкалар, Кукмара киез итек фабрикасында стачка булып уза.

1911 ел — Алафузов фабрикасы тукучылары баш күтәрәләр.

1914 ел — «Глазовцевлар»ның революцион түгәрәге оеша.

1915 ел — Зимин икмәк заводында стачка, Харитонов типографиясендә, Казан трамваенда һәм Тихогорск пристанендә забастовкалар булып уза.

1916 ел — Крестовников, Шабанов, Ярцев заводларында забастовкалар, Казан студентларының политик сходкасы оештырыла.

1917 ел, январь — Алафузовчылар забастовка ясыйлар.

1917 ел, март — Патша власте органнары бәреп төшерелә, Казанда эшче һәм солдат депутатлары Советы эшли башлый, «Мөселман комитеты» төзелә, Казан большевикларының февраль революциясеннән соңгы беренче оештыру җыелышы уздырыла.

1917 ел, октябрь — Казан металлистлары забастовка ясыйлар.

1917, 26 октябрь — Казанда кораллы восстание җиңә һәм Совет власте урнаштырыла.

1918 ел, 8 январь — Казанда икенче Бөтенроссия мөселман хәрби съезды һәм Идел буе Советларының өлкә съезды уздырыла.

1918 ел, март — «Болак арты республикасы» тар-мар ителә.

1918 ел, сентябрь — Казан акчехлардан һәм акгвардиячеләрдән азат ителә.

1919 ел, март — апрель — Беренче татар Идел буе укчы бригадасы оеша.

1919 ел, май — июнь — Чистай һәм Алабуга шәһәрләре, Татарстанның басып алынган бөтен җирләре Колчак гаскәрләреннән азат ителә.

# Ерак һәм якын тарих

Безнең эрага кадәр 100 мең ел элек — хәзерге Татарстан җирләрендә беренче кешеләр күренә башлый.

Безнең эрага кадәр 3—2 мең ел элек — елкада беренче металл әйберләр эшләнә башлый.

Безнең эраның III—IV гасырлары — елкага төрки телдә сөйләшүче беренче кабиләләр килә.

IX—X гасырлар — Идел буе Болгар дәүләте оеша.

986 е л — Киев Русена Болгар дәүләте илчелеге җибәрелә.

1223 е л — Иделдә монгол гаскәрләрен болгарлар җиңә.

1224 е л — Болгар белән Русь арасында тынычлык договоры төзелә.

1229 е л — Болгар белән Русь арасында хәрби договор төзелә.

1236 е л — Болгарга монголларның яңа һөҗүме.

1239—1240 е л л а р — Болгарда монголларга каршы баш күтәрү.

1240 е л — Монголлар баш күтәрүне бастыралар һәм Болгар дәүләте тар-мар ителә.

1256 е л — Болгарда акча сугу яңадан башлана.

1270 е л — Болгар халыклары монголлар изүенә каршы баш күтәрә.

1330—1331 е л л а р — Египетта Болгар дәүләте илчелеге эшли.

1361 е л — Болгарны Булат-Тимер гаскәрләре басып ала.

1431 е л — Болгар дәүләтен князь Федор Пестрый ахырынача тар-мар итә.

XV гасырның 30 нчы еллары — Казан ханлыгы барлыкка килә.

1469 е л — Иван III белән Казан ханы Ибраһим Казан — Русь чикләрендә тынычлыкны тәэмин иткән килешү договоры төзиләр.

1487 е л — Рус гаскәрләре Казанга поход белән килә.

1505 е л, 24 и ю н ь — Иделнең Казан янындагы Гостиный утравында Халыкара ярминкә үткәрелә.

1551 е л — Зөя крепосте төзелә.

1552 е л, 2 о к т я б р ь — Казанны Иван Грозный гаскәрләре ала.

1718 е л — Казан адмиралтействосына нигез салына.

1719 е л — Казанда казна күн заводы салына.

1720—1760 е л л а р — Саралы, Шильин, Таиш, Берсут, Миша (Нырты), Варзе-Алексеевск һәм Тимкан баныр заводлары салына.

1758 е л — Казанда беренче гимназия салына.

1770 е л — Казанда Ахун һәм Апанай мәдрәсәләре ачыла.

1780 е л — Әмирханов йорты каршында мәдрәсә ачыла.

XVIII г а с ы р, 90 н ч ы е л л а р — Казанда беренче театр төзелә.

1801 ел — Казанда беренче типография ачыла.

1804 ел — Казан университеты ачыла.

1821 ел — «Казанский вестник» («Казан мөхбире») журналы чыга башлый.

1835 ел — Казанда икенче гимназия ачыла.

1838—1917 еллар — «Губернские ведомости» («Губерна хәбәрләре») газетасы чыга.

1839 ел — Казанда экономик җәмгыять оеша.

1848 ел — Казан Шәһәр җәмәгать баннысы ачыла.

1855 ел — Бертуган Крестовниковларның сабын заводы төзелә.

1858 ел — Спасста суднолар ремонтлый торган механика заводы эшли башлый.

1860 ел — Казанда бертуган Алафузовларның, эрләү һәм туку фабрикалары һәм күн заводы салына.

1864 ел — Казан губернасында башлангыч халык училищелары ачыла.

1868 ел — Врачларның Казан җәмгыяте оештырыла.

1869—1892 еллар — «Казанский биржевой листок» («Казан биржа листогы») газетасы чыга.

1872—1874 еллар — «Камско-Волжская газета» («Кама-Идел газетасы») чыга.

1874 ел — Казан ветеринария институты ачыла.

1876 ел — Казанда хатын-кызлар Югары курсы һәм татар укытучылар мәктәбе ачыла.

1878 ел — Казан университетында археология, тарих һәм этнография җәмгыятьләре оеша.

1881—1882 еллар — «Волжско-Камское слово» («Идел-Кама сүзе») газетасы чыга.

1884—1906 еллар — «Волжский вестник» («Идел хәбәрләре») газетасы чыга.

1885—1886 еллар — «Казанские новости» («Казан яңалыклары») газетасы чыга.

1890—1892 еллар — «Казанские вести» («Казан хәбәрләре») газетасы чыга.

1891—1893 еллар — Мәскәү — Казан тимер юлы салына.

1894 ел — Казан шәһәр музее ачыла.

1895 ел — Казан художество мәктәбе ачыла.

1905 ел, 27 ноябрь — Татар телендә беренче демократик газета «Фикер» («Мысль») чыга.

1906 ел, июль — Татар телендә «Азат халык» («Свободный народ») газетасы чыга башлый.

1906, 22 декабрь — Казанда татарча беренче театр тамашасы күрсәтелә.

1907 ел, 4 январь — Большевикларның татар телендә легаль газетасы «Урал»ның беренче саны чыга.

1908 ел — Казанда большевистик газета — «Рабочий» чыга башлый (1917 елның 31 мартыннан башлап РСДРПның Казан Комитеты органы).

1917 ел, 15 июнь — Мөселман социалистик комитет (МСК) органы «Кызыл байрак» («Красное знамя») газетасы чыга.

1917 ел, 26 октябрь — Казан партия оешмасы һәм ревком органы «Знамя революции» («Революция байрагы») газетасы чыга.

1919 ел, ноябрь — Казан университетында рабфак ачыла.

1921 ел — Казанда авыл һәм урман хуҗалыклары институты ачыла.

1922 ел, май — «Безнең юл» («Казан утлары») журналы чыга башлый.

1922 ел — Казанда Татар коммунистик университеты (ТКУ) һәм татар театр училищесы ачыла.

1923 ел, январь — сатирик һәм юмористик журнал — «Чаян» чыга башлый.

1925 ел, февраль — Татпрофсовет органы — «Пролетарий Татарстана» журналы чыга башлый.

1925 ел, июнь — Беренче татар операсы — «Сания» куела (С. Габәши, В. Виноградов, Г. Әльмөхәммәтов әсәре.)

1925 ел — Казанда яңа салынган электростанция эшли башлый.

1926 ел, август — Партия Үзәк Комитетының эшче һәм крестьян хатын-кызлар арасында эшләү бүлеге һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты органы — «Азат хатын» журналы чыга башлый.

1927 ел, январь — Казанга Владимир Маяковский килә.

1927 ел, ноябрь — Казанда радиостанция ачыла.

1928 ел, август — Казанда № 1 мех фабрикасы эшли башлый.

1928 ел, август — Казанга Максим Горький килә.

1929 ел — Зеленодольскида фанера заводы эшли башлый.

1929 ел — Татар әлифбасы латинча алфавитка күчерелә.

1930 ел, март — Норлатта Татарстанның беренче МТСе төзелә.

1931 ел — Казанда Югары өлкә колхоз мәктәбе ачыла.

1932 ел — Казан киез итек фабрикасы эшли, кинопленка фабрикасы төзелә башлый, авиация институты ачыла.

1934 ел, 25 июль — Татарстан язучыларының 1 съезды республиканың язучылар союзын төзи. Аннан соңгы съездлар: икенчесе — 1950 елның июнендә, өченчесе — 1954 елның июнендә, дүртенчесе — 1958 елның июнендә, бишенчесе — 1963 елның февралендә, алтынчысы — 1965 елның февралендә, җиденчесе — 1968 елның мартында уза.

1936 ел, март — Югары уңыш осталарының Бөтен Татарстан съезды үткәрелә.

1936 ел — Татарстан художниклары союзы оештырыла.

1937 ел, 7 ноябрь — Казанда В. И. Ленинның музей-йорты ачыла.

1937 ел — Татар дәүләт филармониясе оештырыла.

1939 ел, 21 январь — Конюшкино авылында (хәзер Ленино) В. И. Ленинның музей-йорты ачыла.

1939 е л. февраль — Укытучыларның белемен күтәрү буенча Казан институты ачыла.

1939 е л. 5 м а й — Республика Верховный Советы Президиумы Указы белән татар әлифбасы латин графикасыннан рус графикасына күчерелә.

1939 е л. 17 и ю н ь — Татар дәүләт опера һәм балет театры ачыла (хәзерге бинасы 1956 елның сентябрендә әлгерә).

1939 е л. 11 с е н т я б р ь — Татарстан композиторлары союзының оештыру комитеты төзелә.

1939 е л. 7 о к т я б р ь — Татар теле, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты ачыла. Хәзер СССР фәннәр академиясе институты.

1939 е л — Казан Дәүләт университетында тарих факультеты ачыла.

1940 е л. 12 м а р т — Казанда Максим Горький музей-йорты ачыла.

1941 е л. о к т я б р ь — Казан Оборона Комитеты төзелә.

1941 е л. н о я б р ь — «Татарстан комсомолы» исемендәге танк колоннасы төзү өчен акча җыела башлый.

1942 е л. м а р т — Опера һәм балет театры беренче татар музыкаль комедиясе — «Башмагым»ны (Җ. Фәйзи әсәре) куя.

1942 е л. а в г у с т — Чистайда сәгать заводы эшли башлый.

1942 е л — Зөя — Ульяновск — Сталинград маршруты буенча яңа тимер юл линиясе ачыла.

1943 е л. 5 м а р т — «Правда» газетасында Татарстан хезмәт ияләренең фронтовик татарларга хаты басыла.

1943 е л. и ю л ь — Шөгер һәм Баулы районнарында промышленность нефте чыгарыла башлый.

1944 е л. с е н т я б р ь — Казан Дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла.

1945 е л. 13 а п р е л ь — Совет хөкүмәте СССР фәннәр академиясенең Казан филиалын ачу турында карар кабул итә.

1945 е л. 10 октябрь — Казанда Дәүләт консерваториясе ачыла.

1946 е л. 1 с е н т я б р ь — Казанда төзелеш инженерлары институты яңадан ачыла.

1949 е л — «Татнефть» тресты оештырыла.

1951 е л — Казанда А. Алиш исемендәге пионерлар сарае ачыла, пионерлар һәм мәктәп балалары өчен «Ялкын» журналы яңадан чыга башлый.

1952 е л — Казанда «Теплоконтроль» заводы беренче продукция бирә.

1954 е л. 1 н о я б р ь — Казанның Ирек мәйданында В. И. Ленинга һәйкәл ачыла.

1954 е л. 21 н о я б р ь — Казан университетының 150 еллыгы уңае белән университет каршына студент Владимир Ульяновка һәйкәл куела.

1955 е л. 27 ф е в р а л ь — Казан һәвәскәрләре беренче телевизион тапшыру оештыралар.

1955 е л — Миңнебай — Казан маршрутында магистраль газ үткәргеч төзелеп бетә.

1955 е л. г в а р ь — Бөгелмәдә Татар нефть фәнни-тикшеренү институты ачыла.

1956 ел, сентябрь — Казанда республика халык хуҗалыгы казанышлары даими күргәзмәсе эшли башлый.

1957 ел — Түбән Мактама газ-бензин заводының беренче чираты кабул ителә.

1957 ел, 24 май — 2 июнь — Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы үтә.

1957 ел, май — Казанда яңа елга порты ачыла.

1957 ел, декабрь — Әлмәт — Горький маршрутында магистраль нефть үткәргеч һәм Казан — Горький маршрутында газүткәргеч салынып бетә.

1958 ел, январь — Татарча һәм русча «Коммунист Татарии» һәм татарча «Азат хатын» журналлары яңадан чыга башлый.

1958 ел, апрель — Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре бирелә башлый.

1958 ел — Югары вольтлы Куйбышев — Бәгелмә электр линиясе төзелеп бетә.

1958 ел, август — Казанда Габдулла Тукай һәйкәле ачыла.

1958 ел, ноябрь — Норлатта беренче шикәр заводы эшли башлый. Аннан соңгылары Буада 1960, Зәйдә 1966 елда эксплуатациягә бирелә.

1960 ел, январь — Кушлавыч авылында Г. Тукай музей-йорты ачыла.

1961 ел, март — Кама буенда Түбән Кама шәһәре һәм нефть комбинаты салына башлый.

1962 ел, декабрь — Татарстан культура работникларының II съезды уздырыла. (Өченчесе 1967 елда булды).

1963 ел, январь — Зәй ГРЭСында беренче агрегат ток бирә.

1963 ел, 12 июль — Казанда нефтехимия гиганты — оргсинтез заводы эксплуатациягә бирелә.

1966 ел, ноябрь — Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм спорт сарае ачыла.

1967 ел, 1 ноябрь — Казанда Совет власте өчен көрәштә үлгәннәргә һәйкәл-монумент ачыла.

## Лаеклы бүләкләребез

1934 ел, 3 январь — Татарстан АССР Ленин ордены белән бүләкләнә.

1955 ел, 11 июль — В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан Дәүләт университеты Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

1956 ел, 2 февраль — патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.

1957 ел, 22 апрель — шагыйрь Муса Җәлилгә «Моабит дәфтәре» шигырьләре өчен Ленин премиясе бирелә.

1957 ел, 14 июнь — Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры Ленин ордены, Качалов исемендәге Казан дәүләт зур драма театры Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнәләр.

1967 ел, 7 январь — Казан авиация институты Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

# *САННАР, ФАКТЛАР*

Татарстан — дүрт елга иле. Республикабыз территориясе буйлап: Идел — 177 километр, Кама — 380 километр, Вятка — 60 километр һәм Агыйдел — 50 километр чамасы араны агып уза.

Татарстандагы 400 гә якын кечкенә елгаларның гомуми озынлыгы 6 мең километрдан артып китә.

Совет власте елларында Татарстанда эре промышленность продукциясе эшләп чыгару 334 тапкыр артыгракка үсте.

Республикабыз халык хуҗалыгында 170 меңнән артык югары һәм махсус урта белемле белгечләр эшли.

Совет власте елларында Татарстанда электр энергиясе эшләп чыгару 550 тапкырга үсте.

Советлар Союзындагы һәр өч моторның берсе Татарстан нефте белән эшли.

Советлар Союзында экранга чыгарылган һәр ике фильмның берсе Казан Куйбышев исемендәге химия заводы эшләп чыгарган пленкага төшерелә.

Советлар Союзында эшләп чыгарыла торган мех әйберләренең дүрттән бер өлеше Татарстанда җитештерелә.

Казан тимер юл станциясе аша көн саен 30 дан артык транзит поездлары үтеп тора. Республикада тимер юл озынлыгы Совет власте елларында 4,4 тапкырга, ә тимер юл буенча йөк ташу 75 тапкырга үсте.

1965 елда гына эксплуатациягә бирелгән Бөгелмә механика заводы үзенең продукциясен илебезнең барлык экономик районнарына һәм 15 чит илгә җибәрә.

Дөньяда иң зур һәм иң озын «Дуслык» нефть үткәргеч магистрале (4,5 мең километр) Әлмәт шәһәреннән башлана.

Һәр 10 мең кешегә Франциядә — 71, Англиядә — 58, Федератив Германия Республикасында — 45, Италиядә — 50, ә Татарстанда 190 студент туры килә. Хәзер республикабыз югары уку йортларында 61 меңнән артык, махсус урта уку йортларында 45 меңнән артык студент белем ала. Татарстанның югары уку йортларында, 55 фәнни-тикшерену институтында бер академик, 215 фәннәр докторы һәм профессор, 2 меңгә якын фән кандидатлары эшли.

Татарстан язучылары союзы 126 СССР язучылары союзы членын һәм инде исемнәре укучыларга таныш булган 200 дән артык яшь язучыларны берләштерә. Татар язучылары Совет власте елларында 160 тан артык роман һәм повесть, 500 дән артык сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр.

Татар театр һәм музыка сәнгатен ел саен 3 миллионнан артык тамашачы карый.

Татарстанда 250 меңгә якын семьяның телевизоры бар.

Хәзер татарлардан 176 Советлар Союзы Герое билгеле. Әлегә исемнәре безгә билгесез булган геройларны эзләү дәвам итә.

Бөек Ватан сугышында татар егетләреннән алты сугышчы Александр Матросов батырлыгын кабатлады. Шуларның берсе — Мансур Вәлиуллин. Хәзер Әлмәттә яши.

Бөек Ватан сугышында татар хатын-кызларыннан ике очучыга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. (Магуба Сыртланова һәм Ольга Санфирова.)

Безнең республикада 70 кеше Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды.

# ГОМӘР ГАЛИ

*(1900—1954)*

**Татар совет әдәбиятын үстерүгә күп көч куйган күренекле әдипләребездән Гомәр Галинең тууына 70 ел тулды. Аның тормыш һәм иҗат юлы Бөек Октябрь революциясе тәэсирендә әдәбият мәйданына килгән башка татар язучыларыныкыннан әллә ни аерылмый диярлек.**

**Гомәр Билал улы Галиев 1900 елның 16 июнендә хәзерге Татарстан республикасының Буа районы Иске Тинчәле авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Башта ул авыл мәктәбендә белем ала, аннан, бәхет эзләп, Донбасс шахталарына барып чыга, гражданнар сугышында катнаша — кулына корал алып Совет властен яклый. Гражданнар сугышы тәмамлангач, Гомәр Татар коммунистлар университетына укырга керә, ә 1924 елда коммунистлар партиясе сафына алына.**

**Башка замандашлары кебек үк, Гомәр Гали дә мәдәният фронтының күп тармаклары буенча киеренке иҗат эшчәнлеге алып бара: ул хикәяләр иҗат итә, тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр яза, күп төрле җәмәгать эшләре башкара. Гомәр Гали озак еллар буе «Безнең юл» журналының баш редакторы һәм Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли, ул татар әдәбияты буенча дәреслекләр төзи, Татарстан язучылары союзын оештыруда, яшьләр газетасын чыгаруда актив катнаша.**

**Гомәр Галинең беренче хикәяләре егерменче елларның башларында ук басыла башлый. Аның хикәяләренең төп геройлары — яңа тормыш төзү юлына аяк баскан батраклар, ярлылар, социаль һәм милли изүнең искиткеч авырлыгын үз җилкәсендә татыган татар хатын-кызлары. Үз хикәяләрендә автор әнә шул кешеләргә зур мәхәббәт белән карый, революция тәэсирендә аңы ачылган, үзен яңа тормышның чын хуҗасы итеп тойган яшь совет кешесенең — революция кешесенең типик образын бирергә омтыла. Зиннәт, Шакир («Кубан буйларында»), Кадыйр («Утыз бишәү, әти»), Нәфисә («Нәфисә җиңги»), Гайшә («Гайшә») кебек образларда әлеге яңа кешенең күркәм сыйфатлары бирелә.**

**Гомәр Галинең тәнкыйть мәкаләләре партиялелек, сугышчанлык рухында язылулары белән аерылып торалар. Аның татар совет әдәбияты классиклары Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ иҗатына багышланган хезмәтләре һәм башка күп кенә мәкалә-рецензияләре әле бүген дә әдәби-фәнни әһәмиятләрен югалтмаганнар. «Кара маяклар», «Пролетариат әдәбияты», «Казакъ кызы», «Бер мәдәни бәйрәм алдыннан», «Тирән тамырлар» турында» исемле мәкаләләрендә тәнкыйтьче Галимҗан Ибраһимовның иҗат эшчәнлегенә шактый тулы анализ ясый, аның иҗатының үзенчәлеге һәм әһәмияте турында кызыклы фикерләр әйтә. Икенче зур әдибебез Һади Такташ турында да ул дистәләрчә мәкаләләр һәм зур монографик хезмәт яза.**

**Дөрес, Гомәр Галинең аерым мәкаләләре бүгенге көн өчен искергәннәр инде. Аларда вульгар социологизм йогынтысы шактый нык сизелә. Әмма ни генә булмасын, Гомәр Гали иҗатындагы көчле якларны, матур сыйфатларны без әле дә тәкъдир итәбез, өйрәнәбез.**

**Вахит Монасыйпов**

# НЬЮТОН БИНОМЫ

Имтиханга Аллаһияр уналты кесәле камзул киеп килде. Кесәләрендә кош теле хәтле генә кәгазь кисәкләре, ягъни шпаргалкалар яшерелгән иде. Аның өстенә, камзулның түш кесәсендәге ике авторучканың берсе унлы логарифмлар белән корылган. Аллаһиярның уң колагына (эчәнә) кереп исә геометрик прогрессия членнары урнашкан, ә бәс куна башлаган куе соргылт сакалына Ньютон биномнары поскан иде.

Кыскасы, Аллаһияр башыннан аягына кадәр шпаргалка белән тулган иде. Аллаһиярның кәефе шәп, йөзе тыныч, йөрәге нормаль тибә, тик бер генә нәрсә борчый иде аны, ул да булса — уң колагының үтереп авыртуы. Нигә дисәгез, кичә малае белән сүзгә килеп, Аллаһиярга аның арт сабагын укытырга туры килгән иде.

Кара син аны, малай актыгын! Көпә-көндез ата хәтле атасы белән тарткалашып маташа бит, оятсыз! Әдәпсезлек! Әле җитмәсә, тугызынчы класста укып йөри бит, хәсиятсез!

Бәхәс алгебра дәреслеге аркасында килеп чыкты.

— Китапны шпаргалкага тураклар өчен чыгармыйлар! — диде улы, әтисенә туп-туры карап.

— Анда синең эшең булмасын, китер монда! — дип җикеренде Аллаһияр. Җикерүе ярдәм итмәгәч, җиңнәрен сызганып, кулына солдат каешы алды.

Дуэль, аңлашыла, әлбәттә, Аллаһияр файдасына тәмамланды. Киселевның «Алгебра»сы кискәләнеп-туракланып, аның кесәләренә кереп урнашты...

...Аллаһиярга уналтынчы билет эләкте. «Тәк, тәк...— дип уйланды Аллаһияр, маңгаен тотып.— Уникенче билет уң колак эчендә, ундүртенче — чалбарның арткы кесәсендә, унбишенче — җиң эчендә, ә уналтынчы билет... уналтынчы... Әйе, әйе! Ньютон биномы! Сакалга яшерелгән Ньютон биномы!

Аллаһияр зур саклык белән генә сакалын тентергә тотынды. Әһә! Менә ул кыштырдавык кәгазь кисәге. Аллаһияр шпаргалканы парта өстенә алып куйды да бармаклары белән шуны шомартырга телэде.

Лэкин кэгазьне парта өстенэ куюы булды — күз аллары карангыланып китте, әйтерсең, Аллаһиярның маңгаена бик каты бер нәрсә белән китереп суктылар.

Кәгазь кисәгендә: «Әти! Шпаргалить итү — алама гадәт»! диелгән иде.

## ШӘМСИ КӘЛӘШЕ

«Вакчыллыгына түзәр хәлем калмады, хуш!» дигән язу калдырып, хатыны китеп баргач, экономист Шәмси:

— Бүтән өйләнсәм, жир йотсын! — дип ант иткән иде.

Әмма ул икенче төнне үк тәүбәсеннән кире кайтты. Ничек инде юлбарыстай таза егет ике кеше йоклый торган караватта мендәр кочаклап бер ялгызы ятсын!

Иптәшләре дә:

— Өйлән, давай, өйлән! — Менә дигән кәләш табып бирербез үзенә! — дип куәтләделәр.

Күп тә үтмәде — бер кәләш табылды.

— Ниндирәк соң? — дип кызыксынды Шәмси.

— Исең китәрлек! Курчак инде, курчак!

— Буе озынмы, кыскамы?

— Синең белән бер чамадарак.

— Булмады алайса,— диде Шәмси, көрсенеп.— Кәләшнең буе метр да 67 сантиметрдан артмасын.

Әзли торгач, «метр да алтмыш жидене» дә таптылар.

— Хуш! — диде Шәмси.— Ә бил әйләнәсе?

— Кем аны үлчәгән! Бил бил инде ул! Нормаль кызлар биле!

— Бил әйләнәсе кырык сантиметрдан да ашмасын!

Шәмсинең бу таләбе дә үтәлде.

— Таптык! Нәкъ син таләп иткән размер!

— Аяк үлчәве белән кызыксынмадыгызмы?

— Анысын да сораштык. Утыз сигезле туфли кия.

— Батмый, егетләр, батмый! Миңа утыз алтынчы размерлысы кирәк!

Ниһаять, эзли-күзәтә торгач, Шәмси заказать иткән кәләшне моның алдына китереп бастырдылар. Туташның буе метр да 67 сантиметр, бил әйләнәсе — 40, аяк размеры 36 иде.

Шәмси үзенең кәләшен, лотерейга зур отыш чыккан кеше кыяфәтендә, өенә алып кайтты:

— Менә шушы булмады күгәрчендәй гөрләшеп яшәрбез инде, акыллым!.. Минем әле гомеремдә беренче тапкыр өйләнүем,— диде. Һәм акыллысының биленнән кочаклап алды.

«Ялгышмаганнар, биле таман гына икән!» дип уйлап куйды ул.

Аннары шифоньердан ефәк күлмәк чыгарды:

— Киеп кара әле, акыллым! Бер дә борчылма, размеры нәкъ синеке!

Кыз күлмәкне кулына алуы булды, борынына ниндидер ят ис килеп бәрелде. Хатын-кызлар сөртенә торган исле май иде ул.

Эшне сизеп алган кыз күлмәкне идәнгә атып бәрде дә ишеккә ташланды...

Шифоньердагы кием-салым Шәмсинең беренче хатыныннан калган әйберләр иде.

Галимҗан Насыйров

# БИК НӘНИ ДҮРТ ХИКӘЯ

## Озын куллар

— Ай-яй, бу кадәр күп печәнне хезмәт көненә алдыңмы?
— Юк, хезмәт төненә.

## Бер юлы ике дәрес

Энесе: — Аңладым бит инде бу Пифагор законын, тагын нигә кабыргага төртәсең?
Агасы: — Хәтереңдә нык саклансын: Пифагор йодрык сугышы буенча Олимпия чемпионы да булган.

## Нарасыйлык

Бала: — Әби, син сөйләгән сират күпере безнең күпердән дә куркынычракмы?
Әбисе: — Әйе, бәбкәм, аннан да ышанычсызрак.
Бала: — Алайса аны, безнең председатель абый кебек, әйләнеп үтсеннәр иде.

## Балыкка барыр алдыннан

Балыкка барырга кармакларын әзерли башлагач, хатыны кызып китте:
— Шул балыкның нәрсәсен яратасың син?
— Сөйләшмәвен! — диде ире.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ III СЪЕЗДЫ

24—27 мартта Москвада Россия Федерациясе язучыларының III съезды булып үтте. Татарстан язучылар союзыннан бу съездга Г. Ахунов, Н. Беляев, Г. Бәширов, И. Гази, А. Гыйләҗев, М. Елизарова, Р. Мостафин, Т. Миннуллин, З. Нури, А. Расих, В. Синев, Х. Туфан, Р. Фәйзуллин, С. Хәким, Р. Харисов, Ф. Хөсни, И. Юзеев, Ш. Рәкыйповлар делегат булып һәм Ю. Әминев, Н. Дәүли, Г. Кашшаф, Н. Бабенко, Ю. Белостоцкий, М. Шабаев, С. Сабиров, П. Евгеньев, С. Рафиков, Х. Гобәйдуллин, Г. Зәйнашева, Г. Рәхимнәр кунак булып катнаштылар. Съездда «Хәзерге заман прозасының кайбер проблемалары» дигән докладны М. Алексеев, «Советлар Россиясе поэзиясенең үсеш юллары» дигән докладны В. Федоров, «Тормыш, драматургия, театр» дигән докладны Мостай Кәрим, «Балалар әдәбияты турында» дигән докладны А. Барто ясады.

Фикер алышуларда Татарстан делегациясе исеменнән язучы Гариф Ахунов катнашты. Ул үзенең чыгышында В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән республикабыз язучылар оешмасында эшләнгән эшләр турында, әдәбиятыбызның соңгы елларда ирешкән уңышлары, үз тавышларын көннән-көн көчлерәк ишеттерә барган талантлы яшь каләмнәр турында сөйләде.

Соңыннан съезд РСФСР язучылар союзының яңа идарәсен һәм ревизия комиссиясен сайлады.

Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе И. Гази, союзның җаваплы секретаре Гариф Ахунов, «Казан утлары» журналы редакторы Зәки Нури, шагыйрь Сибгат Хәким РСФСР язучылар союзының идарә составына сайландылар. Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге житәкчесе Равил Фәйзуллин ревизия комиссиясенә кертелде.

РСФСР язучылар союзының III съездда сайланган идарәнең беренче пленумында идарә секретарьларының берсе итеп, язучы Ибраһим Гази сайланды.

## ДУСЛЫК КИЧӘСЕ

РСФСР язучыларының съезд көннәрендә татар һәм башкорт язучыларыннан бер төркем Мәскәү шәһәренең әдәбият сөючеләре белән очраштылар. Фәнни атеизм клубы һәм Мәскәүнең Тарихи китапханәсендә үткәрелгән бу кичәләрдә татар язучыларыннан Ибраһим Гази, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Гөлшат Зәйнашева, Ренат Харисов, Роберт Батуллин, Гәрәй Рәхим, әдәбият белгече Тәлгать Галиуллин, яшь шагыйрь Разил Вәлиев, башкорт язучыларыннан Рафаэль Сафин, Әсгать Мирзаһитов, Нәҗип Асанбаев, Әнгам Атнабаев, Муса Гали, Н. Игебай, Дагстан шагыйре Мөхәммәт-Заһит Әминевлар катнашты.

Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров татар шагыйрьләренең яңа жырларын башкарып, кичәнең программасын тагын да тулыландырды. ГИТИСта укучы башкорт артистлары Ф. Ихсанов һәм Р. Исрафилов иптәшләр дә үзләренең сәнгать осталыкларын күрсәттеләр. Өч милләт вәкилләре катнашында уздырылган бу очрашулар чын-чыннан дуслык кичәләре булдылар.

## ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕНДӘ

Казанның сынлы сәнгать музеенда В. И. Ленинның тууына 100 ел, республикабызга 50 ел тулган көнгә багышлап Татарстан художникларының рәсемнәр күргәзмәсе ачылды.

Күргәзмәдә В. И. Ленинның тормышына, көрәшенә багышланган картиналар төп урынны алган. Бөек юлбашчының әнкәсе М. А. Ульянованы гәүдәләндергән Мелентьевның «Ана» картинасы, В. И. Ленинның беренче революцион адымына багышлап язылган М. И. Семеновның «Протест» картинасы, Дәүләт премиясе лауреатлары Харис Якупов һәм Лотфулла Фәттахларның «Татарстан АССРны оештыру турындагы декретка В. И. Ленинның кул куюы» дигән зур полотнолы картиналары, Лотфулла Фәттахның «Уйлар» дигән картинасы һ. б. даһи юлбашчының кабатланмас образын зур мәхәббәт һәм җылылык белән башкарганнар.

Күргәзмәдә халкыбызның тарихын, республикабызның индустриаль төзелешләрен, авыл хуҗалыгы күренешләрен, нефть пейзажларын чагылдырган картиналар да халыкның игътибарын нык тарта. Рада Нигъмәтуллинаның агачтан кисеп ясалган скульптурасы «Бишек жыры» дип атала. Яшь кенә бер ана баласын көйләп тирбәткән-тирбәткән дә, бишек кырына башын салып үзе дә йокымсырап киткән. Шундый сак йокы ул, баласы кечкенә генә кыймылдап куйса да, озын керфекләр тибрәнеп ачылыр һәм иркәләүчән, моңлы бишек жыры тагын яңгырар төсле. Карт рәссамебез Бакый ага Урманченың «Сагыш» дигән скульптор портреты да игътибарны үзенә тарта. Гомер үткән, башыннан күп нәрсәләр кичергән, күп эшләр башкарган һәм әле дөнья кадәр эшләнәсе эшләре калган акыл иясе картны күрәсең аңар карагач.

Татар халык иҗатына багышланган бүлек күргәзмәдә аерым залны алып тора. Монда 19 йөздән калган тәнкә-чулпылар, көмеш беләзекләр, күкрәкчәләр һ. б. бизәнү әйберләре, татар хатыннарының зиннәтле киемнәре, ашъяулык, сөлгеләр, читек-кәвеш, түбәтәй-камзуллар куелган. Шулар янында ук татар орнаментларын файдаланып, зур зәвык белән, төрле төсләрдәге күннән эшләнгән башмаклар, билбаулары, сумкалар, диван мендәрләре һ. б. да бар.

Күргәзмәнең бер бүлеге графика өлкәсендә эшләүче художникларга багышланган. Биредә талантлы художниклардан Тавил Хаҗиәхмәтов, Е. Киселева, И. Язынин һ. б.ларның Татарстан китап нәшрияты чыгарган китапларга эшләгән рәсемнәре күрсәтелә.

Бу күргәзмә тамашачыларны республикабызның талантлы художниклары белән таныштыра һәм чын сәнгать зәвыгы бирә.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Минзәлә татар дәүләт драма театры В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстан АССРның 50 еллыгына багышлап, шагыйрь һәм драматург Әхсән Баяновның «Һәйкәл» исемле пьесасы буенча яңа спектакль әзерләде. Әсәрне сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Муллануp Мостафин куйды.

Премьерада автор үзе дә катнашты. КПСС райкомы һәм район Советы башкарма комитеты исеменнән КПССның Минзәлә райкомының беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое Хөсәенов, КПСС райкомының идеология буенча секретаре Г. М. Хәкимова, ТАССР культура министры урынбасары Ю. З. Әминев авторны һәм театр коллективын югары идея һәм художество эчтәлекле спектакль куюлары белән котладылар.

## ЯШЬЛӘР КИЧӘСЕ

Узган ел комсомолның Татарстан өлкә комитеты каршында яшь язучы, композитор һәм артистларның иҗади берләшмәсе оештырылган иде. Бу берләшмә Казан шәһәренең Актерлар йортында айга бер тапкыр үзенең кичәләрен үткәрә.

Бу кичәләрдә Актерлар йортының тамаша залы яшь эшчеләр, студентлар, хезмәткәрләр белән шыгрым була.

Март аенда алар «Дүрт Ренат кичәсе»нә килделәр. Кичәдә шагыйрь Ренат Харисов үзенең шигырьләрен укыды, биредә Ренат Еникеевның төрле елларда язылган музыкасы яңгырады, Ренат Таҗетдинов Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә тудырган образларының үрнәкләрен башкарды, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры артисты Ренат Ибәтуллин тамашачыларга балет номерлары күрсәтте. Берләшмәнең җитәкчесе язучы Роберт Батуллин кичәгә килүчеләрне дүрт Ренатның да иҗат юлы белән таныштырды.

Берләшмә апрель аенда үткәргән кичәсен «Мәңгелек дастан» дип атап, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулган көнгә багышлады. Р. Батуллин, Р. Гатауллин, Т. Камалиев, З. Мәликов, Ш. Маннаı
Р. Мингалимов, Гәрәй Рәхим, Р. Харис
Р. Әхмәтҗановлар В. И. Ленинга, ком
нистлар партиясенә багышланган шигь
ләрен укыдылар. Татар дәүләт акаде
театры артистлары Ш. Биктимеров, Һ. С
танов, Р. Таҗетдинов, Р. Шәрәфı
И. Баһманов, Н. Дунаев, Ә. Шакиров
башкаруында Н. Погодинның «Баһа
лар» һәм Н. Исәнбәтнең «Муса Җәл
спектакльләреннән өзекләр күрсәте
«Идел» эстрада коллективы белән Ил
Шакиров чыгыш ясады.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНДА ТАНТАНА
## ҖЫЕЛЫШ

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу
ненә багышлап, 21 апрельдә Татарстан я
чылар союзы каршындагы партия оеш
сының тантаналы ачык җыелышы бул

Җыелышта филология фәннәре кан
даты Азат Әхмәдуллин «Татар әдәбият
да Ленин образы» дигән темага кыск
чыгыш ясады. Шагыйрь Нәби Дәүли
Галимҗан Латыйпов үзләренең Лени
багышланган шигырьләрен укыдылар. Ш
гыйрь Рәдиф Гатауллин һәм драмат
Туфан Миннуллиннар партия членлыгı
кандидат итеп алындылар. Күп кенә
чылар батыр хезмәт өчен В. И. Ленин
тууына 100 ел тулуны билгеләп чыгарыл
юбилей медале белән, партиянең Татарс
өлкә комитетының, Татарстан АССР В
ховный Советы Президиумының, ТАС
Министрлар Советы һәм профсоюзлар ө
советының Ленин юбилее почет грамота
ры белән бүләкләнделәр. Ленин юбиле
багышланган республика хезмәт Даны
табына кертелүе турында Мирсәй Әми
Казан шәһәренең Хезмәт Даны китаб
кертелүе турында Мөхәммәт Садрига
ныкламалар бирелде.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

27 апрельдә Тукай һәйкәле янында
дицион шигырь бәйрәме үткәрелде. Бәй
не өлкән шагыйрь Сибгат Хәким ачты
алып барды. Н. Арсланов, Ә. Баян, Г.
нашева, Ә. Исхак, Г. Латыйп, З. Мали
З. Нури, Г. Рәхим, Р. Харисовлар яңа
гырьләрен укыдылар. Бу чыгышларын а
В. И. Ленинга һәм ленинизм идеяләре
танасына багышладылар.

Бу көнне Тукай премиясе лауреаты
рат Арсланов һәм шәһәр мәктәпләрен
укучылар шигырьләр сөйләделәр.

Шигырь бәйрәме кичен язучылар
Тукай исемендәге клубында дәвам и
Биредә дә яңа шигырьләр һәм композит
ларның шагыйрьләребез сүзләренә яз
җырлары яңгырады.

*
* *

Язучы Фатих Хөсни, Аяз Гыйләҗев, ш
гыйрьләрдән Илдар Юзеев һәм Шәү
Галиев шигырь бәйрәмен үткәрергә Т
кай-Кырлай авылына килделәр. Мәктәп
клубта шигырьләр укылды, әдәбият
рында зур сөйләшү булды.

Язучылар Габдулла Тукай торган йо
урынына каеннар утырттылар.

## СӘНГАТЬКӘ МӘХӘББӘТ

Түбән Кама шәһәренең яшьләре һәрва-
т Төзүчеләр клубына җыелалар. Біре-
татар драма коллективы эшләп килә.
билей көннәренә алар драматург Риза
moратның «Гөлзада» спектаклен куйды-
р. Үзешчән артистлар социализм төзү
шлау елларының каршылыгын, яңа тор-
ш төзүгә, белем алырга омтылган яшь-
рнең тормышын, иске карашларның җи-
реләә баруын бүгенге көн тамашачысына
ктый ышандырырлык итеп күрсәттеләр.
Спектакльнең премьерасында драматург
за Ишморат үзе дә катнашты.

## ЛЕКЦИЯ-КОНЦЕРТЛАР

Март аенда Тукай исемендәге Татар
әүләт филармониясе каршындагы музы-
ль лекторий Татарстан композиторлары-
ың шагыйрә Г. Зәйнашева сүзләренә яз-
н әсәрләреннән лекция-концертлар оеш-
рды. Казан шәһәренең культура сарай-
рында һәм мәктәпләрдә барган бу кон-
ртларда Татарстанның атказанган артист-
ры Ә. Галимова, Э. Җәләлетдинов, җыр-
ы Г. Дәминов, пианистка А. Фәйзуллина-
р катнашты. Музыка белгече М. Җиһан-
ина Г. Зәйнашеваның иҗаты һәм компо-
торларның аның сүзләренә язган җыр-
ары турында лекция укыды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Драматурглар секциясе Зәйни Шаһимо-
атовның «Сәхипгәрәй Сәетгалиев» дигән
ьесасын тикшерде. Татарстан республика-
ын төзү вакыйгаларыннан язылган бу әсәр-
ә автор күп кенә тарихи шәхесләр белән
ергә, В. И. Ленинның образын да алган.
Күп еллар архивларда утырып, күп ма-
ериаллар өйрәнеп язылган бу пьесада ав-
ор шактый гына уңышларга ирешкән.
Әсәрнең шул ягын билгеләп китү белән
ергә, утырышта катнашучылар, аны тагын
а камилләштерә төшү, образларны, бигрәк
ә бөек юлбашчы образын, тагын да яхшы-
рак эшләү өчен күп кенә киңәшләр дә бир-
деләр.

* * *

Проза секциясе соңгы утырышларының
ерсен яшь язучы Рифгать Кәрамиев иҗа-
ын тикшерүгә багышлады. Казан пред-
приятиеләренең берсендә электрик булып
шләүче, университетның тарих факульте-
ын читтән торып тәмамлап килүче яшь
прозаикның иҗатына Әмирхан Еники, Бар-
ас Камал, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихса-
нова, Сафа Сабиров, Хәсән Сарьян, Әнәс
Камал һ. б. язучылар нигездә уңай бәя
бирделәр һәм кимчелекле якларына кагы-
лып, аларны бетерү өчен файдалы киңәш-
ләр әйттеләр.

* * *

Шагыйрьләр секциясе дә үзенең соңгы
утырышын яшьләр иҗатына багышлады.
Биредә яшь шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов-ның шигырьләре тикшерелде. Чыгып сөйләүчеләрдән Х. Туфан, И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә. Баян, Г. Зәйнашева, М. Шабаев, Р. Батуллин, Р. Гатауллин һ. б. Р. Әхмәтҗанов иҗатындагы уңай якларны билгеләп үттеләр һәм аны Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итәргә вакыт дигән карар чыгардылар.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Казан Дәүләт педагогия институтының Актлар залында филология факультеты студентлары белән Тукай премиясе лауреаты драматург Хәй Вахитнең очрашу кичәсе булды. Студентларны драматург үзенең иҗат планнары белән таныштырды, аларның күп төрле сорауларына җаваплар бирде.

Тукай премиясе лауреаты Н. Гәрәева, артистлардан Ә. Шакиров, Р. Әхмерова, Ф. Хәмитова, Н. Дунаев, Х. Җәләловлар Хәй Вахитнең «Күк капусы ачылса», «Туй алдыннан» спектакльләреннән өзекләр уйнап күрсәттеләр. Кичә ахырында студентлардан оештырылган агитбригада чыгышы булды.

* * *

11—17 мартта Ульянов өлкәсенең Иске Кулатка районында В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган татар әдәбияты атналыгы үтте.

Г. Минский, Ш. Галиев, Т. Миннуллин, М. Фәйзуллина, Сәет Кальметов Яңа Кулатка, Усть Кулатка, Иске Мостак, Иске Атлаш, Урта Тәрәшкә, Кирюшкино, Иске Зеленое авылларында һәм Иске Кулатка эшчеләр поселогында хезмәт ияләре белән очраштылар. Иске Кулатка урта мәктәбендә укытучылар һәм укучыларга үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар. Бөек Ватан сугышында үлгән батырлар һәйкәленә Татарстан яшьләре исеменнән венок салдылар.

Районда чыга торган «Күмәк көч» газетасы редакциясендә дә әдәбият сөючеләр һәм журналистлар белән әңгәмә булды. Язучылар районлагы яшь каләмдәшләренең әсәрләрен укыдылар, аларга күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр.

* * *

Казан шәһәренең 106 нчы татар урта мәктәбе укучылары Максим Горький музеенда Тукай премиясе лауреаты, шагыйрь Сибгат Хәким белән очраштылар.

Шагыйрь үзенең Ленинга багышланган әсәрләренең ничек язылуы турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Язучылардан Г. Латыйп, Р. Гатауллин, Р. Ишморатова, В. Нуруллиннар Кукмара районы хезмәт ияләре белән очрашулар үткәрделәр.

Алар «Маяк», «Урал», «Восток», «Әсәнбаш» һәм Вахитов исемендәге колхозларда колхозчылар белән, Байлангар урта мәктәбендә, Олыяз сигезьеллык мәктәбендә укытучылар һәм укучылар белән татар әдәбия-

ты казанышлары турында әңгәмәләр үткәрделәр. Үз әсәрләреннән өзекләр укыдылар.
Кукмара эшчеләр поселогында үткәрелгән очрашулар да кызыклы гына булды.

### ТАМАШАЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Казан Актерлар йортында Татар Дәүләт күчмә театры артистлар коллективы һәм ветераннарының тамашачылар белән иҗади очрашу кичәсе булды.
Филология фәннәре кандидаты Баян Гыйззәт театрның иҗади эше турында сөйләде. Театрның баш режиссеры Равил Тумашев, Татарстанның халык артисты Касим Шамил, Татарстанның атказанган артистлары Бибинур Галиуллина һәм Газиз Гыйматов, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева иптәшләр мавыктыргыч истәлекләре белән бүлештеләр.
Соңыннан Юныс Әминовның «Умырзая чәчәкләре», Таһир Закировның «Язучылар», Рәисә Ишморатованың «Яшьлек канат җәйгәндә» дигән пьесаларыннан өзекләр күрсәтелде.

### АРТИСТНЫ ИСКӘ АЛУ

Казан Актерлар йортында РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Камал III нең тууына 70 ел тулу уңае белән кичә уздырылды.
Кичәдә Камал III нең тормыш иптәше, ТАССРның атказанган артисты Асия Масаутова, РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Фатыйма Ильская һәм башкалар катнаштылар.
Камал III нең тормыш юлы һәм иҗаты турында Татарстанның халык артисты Рәшидә Җиһаншина сөйләде. ТАССРның халык артистлары Касим Шамил һәм Хәким Сәлимҗанов кызыклы истәлекләре белән уртаклаштылар.
Соңыннан сәнгать осталары концерт бирделәр.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

Апрель аенда Башкорт дәүләт университеты студенты Рәдиф Тимершинның балалар өчен язылган шигырьләре тикшерелде. Семинар эшендә шагыйрьләр Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев катнашты. Яшь шагыйрьнең уңышлы шигырьләре матбугатка тәкъдим ителде.

* * *

Чираттагы семинар яшь тәнкыйтьчеләрдән Ил Саттаров һәм Миләүшә Маннуроваларның тәнкыйть мәкаләләрен тикшерүгә багышланды. Семинарны алып баручы Рафаэль Мостафин, Фарваз Миңнуллин һәм Ренат Харисовлар яшь тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләренә анализ ясадылар.

* * *

Яшь прозаик-журналист Илдар Низамов хикәяләре һәм очерклары белән танышып, язучылар Габдрахман Минский һәм Аяз Гыйләҗев индивидуаль семинар үткәрделәр.
Индивидуаль семинар тәртибендә яшь прозаиклар Тәүфыйк Әйделдинов һәм Зөфәр Хәмидуллинның хикәяләре дә тикшерелде. Язучылар Габдрахман Минский һәм Хәсән Сарьян хикәяләргә анализ ясадылар.

* * *

Казан дәүләт университеты студентлары — яшь шагыйрьләр Фәннүр Сафин, Рберт Миңнуллин һәм Зиннур Мансуровның әсәрләре тикшерелеп, шигырьләре «Беренче карлыгачлар»га тәкъдим ителде.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлек утырышында Р. Төхфәтуллинның яңа әсәре — «Җиләкле аланнар» исемле повесте тикшерелде. Хәтерләүләргә корылган, шигъри тел белән язылган бу әсәргә карата җыелышта катнашучылар күп уңай фикерләр әйттеләр, күп кенә иптәшләр повестьне берничә кисәктән торган зур күләмле әсәрнең яхшы башлангычы дип бәяләделәр. Җыелышта язучылардан Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Ю. Әминов, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, С. Кальметов һәм яшь авторлар катнашты.

* * *

Азнакай район газетасы «Маяк»ның чыга башлавына 40 ел тулу уңае белән уздырылган зур тантанада Р. Төхфәтуллин катнашты һәм котлау чыгышы ясады.

* * *

14 мәктәптә Татарстан АССРның төзелүенә 50 ел уңае белән тематик кичә уздырылды. Укучылар һәм укытучылар коллективы алдында Р. Фәйзуллин чыгыш ясады.


* * *

9 нчы номерлы шәһәр мәктәбе укучылары Әлмәттә яшәүче шагыйрь Ә. Маликов белән очраштылар. Автор соңгы елларда иҗат иткән яңа шигырьләрен укыды, ә укучылар исә Ә. Маликовның һәм башка шагыйрьләр әсәрләрен рус һәм татар телләрендә башкардылар.

* * *

Әлмәт районы Габдрахман авылында язучыларның халык белән очрашуы булып үтте. Яңа салынган культура сараенда А. Гыйләҗев, Р. Фәйзуллин, С. Кальметов, К. Булатова, Э. Мөэминова иптәшләр чыгыш ясадылар, иҗат планнарын уртаклаштылар.

# ТАТАРСТАНЫМ МИНЕМ




**МИРСӘЕТ ЯРУЛЛИН** музыкасы
**РЕНАТ ХАРИСОВ** сүзләре

Син безне тудырдың, үстердең,
Тик сиңа бурычлы мәңге без.
Юк бит ул тагын бер синдәй җир —
Язың — яз,
Җәең — җәй,
Көзең — көз!
Язың — яз,
Җәең — җәй,
Көзең — көз!
Көч бирдең, дәрт бирдең,
рух бирдең —
Улларың-кызларың баһадир.
Сокланмый мөмкинме соң сиңа —
Суың — су,
Күгең — күк,
Җирең — җир!
Суың — су,
Күгең — күк,
Җирең — җир!
Яуларда, хезмәттә, сәнгатьтә,
Исемең акладык, Татарстан.
Син безне күтәрдең, без сине —
Язың — яз,
Җирең — җир,
Даның — дан!
Язың — яз,
Җирең — җир,
Даның — дан!

*Хөрмәтле иптәш!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.

Әгәр Сез алдагы айлар өчен журналга язылмый калган булсагыз, һәр айның 20 сенә кадәр языла аласыз.

Журналга Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылырга мөмкин.

Аның өчен, журналның 73210 номерлы индексын әйтеп, аена 50 тиен исәбеннән акча түләү җитә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210